ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

9.1999





*Гөрләп*
*үтте*
*Илем*
*бәйрәме...*








Татарстанның Дәүләт
суверенитеты турында
декларация кабул ителүгә
9 ел.
*(30 август, 1999 ел.)*

# Казан утлары
# Qazan utlarь

*1999*

**9**

**(923)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИРЕ*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Гариф Ахунов,**
**Харрас Әюпов,**
**Хәлим Гайнуллин,**
**Тәлгат Галиуллин,**
**Миркасыйм Госманов,**
**Аяз Гыйләжев,**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары),*
**Салих Маннапов,**
**Туфан Миңнуллин,**
**Хатип Миңнегулов,**
**Ринат Мөхәммәдиев,**
**Нажар Нәҗми,**
**Булат Солтанбәков,**
**Ренат Харис,**
**Розалина Шаһиева.**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Альбина Әхмәтова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Гөлзадә Фәйзуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова.**

---

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Баш мөхәррир — 49-36-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 49-36-63,
гамәли хезмәткәрләр — 49-36-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Айдар ХӘЛИМ. Үсегез, үс, ирек пәрвәрләре... *Шигырьләр* ... 5
Камил КӘРИМОВ. Ком сәгате. *Роман* ... 10
Фәйрүзә ИСМӘГЫЙЛЕВА. Чатыртауның куенында. *Шигырьләр (Р. Фәйзуллин кереш сүзе белән)* ... 88
Илдус ХУҖИН. Тайгадагы фаҗига. *Хикәя* ... 94
Марис НӘЗИРОВ. Иннәреңдә канат барда... *Шигырьләр* ... 112
Мөхәммәт МИРЗА. Без мәңгелек юлында. *Шигырьләр* ... 117

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ XIII КОРЫЛТАЕ

Татарстан Президенты М. ШӘЙМИЕВ чыгышы ... 121
Халык язучысы Ә. ЕНИКИ котлавы ... 120
Р. МӨХӘММӘДИЕВНЕҢ хисап доклады ... 124

ПУБЛИЦИСТИКА

Миргазиян ЮНЫС. Альбатрос язмышы ... 134

ӘДӘБИ МИРАС

Афзал ШАМОВ. Картлар *(Әсәрдән өзек)* ... 146

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ. Күңел офыклары ... 161

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА

Заһир ИСЛАМ. Әхмәт Фәйзи иҗатында Тукай ... 167

МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

Гали АРСЛАНОВ. Гаяз Исхакый һәм татар театры ... 172

КИТАП КҮЗӘТҮ

Әбрар КӘРИМУЛЛИН. Аллалар, фиргавеннәр нинди телдә сөйләшкәннәр? ... 178

ХАЛЫК ИҖАТЫ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

Хуҗи МӘХМҮТОВ. Гыйбарәләр тарихына сәяхәт ... 182

ШАМИЛ РӘКЫЙПОВКА 70 ЯШЬ

Мансур ВӘЛИ. Кешелеклелекнең дәвамы— батырлык! ... 188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ... 192

*Журнал выходит один раз в месяц*

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

«Проза и поэзия»: окончание романа К. КАРИМОВА «Песочные часы», рассказ И. ХУЗИНА «Трагедия в тайге»; стихи Ф. ИСМАГИЛОВОЙ, М. НАЗИРОВА, М. МИРЗЫ.
«XIII съезд писателей Татарстана»: выступление Президента Республики Татарстан М. Ш. ШАЙМИЕВА, приветствие А. ЕНИКИ, отчетный доклад Р. МУХАММАДИЕВА.
«Публицистика»: статья М. ЮНУСА «Судьба альбатроса».
«Литературное наследие»: повесть А. ШАМОВА «Старики».
«Литературная критика»: рецензия Г. ГИЛЬМАНОВА на новую книгу Б. Рахимовой.
«К истории литературы»: статья З. ИСЛАМОВА «Тукай в творчестве А. Файзи ».
«К истории культуры»: Г. АРСЛАНОВ: «Татарский театр и Г. Исхаки».
«Книжное обозрение»: рецензия А. КАРИМУЛЛИНА на книгу Н. Фаттаха.
«Народное творчество» статья Х. МАХМУТОВА «В мире мудрых слов».
«К 70-летию Ш. Ракипова»: статья М. ВАЛЕЕВА.
«На наших обложках»: Фронтиспис к рукописи «Юсуф и Зулейха», работа каллиграфа Муллайима Кашмири. Индия, 1813 год; писатель Ш. Ракипов.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and Poetry": K. KARIMOV'S finishing novel «Sand clock», I. KHUZIN'S story «The taiga tragedy», the verses of F. Ismagilova, M. Nazirov, M. Mirza.
"XIII th congress writers of Tatarstan": speechs President of repablic of Tatarstan M. Sh. Shaimiev, A. Eniky, R. Muhamadiev.
"Publicism": M. JUNUS'S article «Fate of albatros».
"Literary legacy": A. SHAMOV'S story «Old man».
"Literary criticism": G. GILMANOV'S review on a new book of B. Rahimova.
"To literature history": Z. ISLAMOV'S article «Tukay in a works A. Faizi ».
"To culture history": G. ARSLANOV. «Tatar theatre and G. Iskhaky».
"Book review": A. KARIMULLIN'S review on a book of N. Fattah.
"The people works": H. MAKHMUTOV'S article «In world wise words».
The diary of social and cultural life.
In our covers: book «Usuf and Zuleikha». 1813 year. India. Calligraph Mullayim Kashmiry.

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-36-62 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итергә кирәк.

---

Журнал редакциянен компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 1.09.99 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы $70X108^{1}/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 8229 Заказ З-425
Журнал Татарстан Республикасынын Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 1999 ел.

# ШИГЪРИЯТ



## Айдар Хәлим

### ҮСЕГЕЗ, ҮС, ИРЕК ПӘРВӘРЛӘРЕ...

### «Түгәрәк имән» төбендә

*Кҗрмәделәр мине, ай, күз белән,*
*Тик сөйлиләр шелтәле сүз белән.*

Халык җырыннан.

**...Батырша һаман юк. Күзне кисеп,**
**Исә кызгылт сәмум ниндидер.**
**Җилкендердем, ил күндердем, дигәч,**
**Юк, йөрәк, яңадан җилкендер!..**

**Минме азатлык дип айкалмадым,**
**Бүген яңа гасыр тентүен**
**Үткән чакта**
**Сорыйм: милләтме без?**
**Әллә пошмас коллар көтүе?!**

**Бер тетрәнү көтә бездән тарих.**
**Бер кыйралыш көтә илаһи.**
**Ялган Ватан өчен корбан—савап,**
**Үзебез өчен—гөнаһ микән ни?**

**Ишетәсезме: күкләр күкри! Күкри!**
**Күрәсезме: ялт-йолт яшеннәр?**
**Безнең богауларны дөбердәтеп,**
**Офыкка аудара яшь өннәр?**

**Мин үзем шул яшеннәрдән туып,**
**Баш күтәреп хурлык-коллыкка,**
**Ак болытларымнан чалма киеп,**
**Җиргә сибәм якты орлыклар:**

**—Үсегез, үс, ирек пәрвәрләре!**
**Чүпләр үстермәгез арага.**
**Егерме беренче гасырга кол керү**
**Гөнаһ татар диган каръя[1]га!**
**Ишетәсезме: офыклар дөберди?**
**Күрәсезме: яшен кайрала?**
**Татар кылычының ак йөзендә**
**Алсу шәфәкъ булып кар яна!..**

## Пәйгамбәр туганда

*Хәмит Латыйпка*

**Томаннар астында томан,**
**Күк җиргә күзен йомган.**
**Җир исә гел тәһарәтсез**
**Капшана—тапмый комган.**

**Суеша кыргый тавышлар,**
**Ут та юк, очкын да юк.**
**Җирне шакмаклап сатарга**
**Бер тупас пычкы да юк.**

**Күзләләр яктыда күрми,**
**Өн салмый аек гоман.**
**Татарга—дөнья кәрмәҗин!—**
**Гел җырлый тиле сыман.**

**Нәкъ шундый шомлыкта Ходай**
**Шомланып туядыр ул.**
**Нәкъ шундый шомлыкта яңа**
**Пәйгамбәр туадыр ул...**

* * *

*Рәшит Әхмәтҗанга*

**Мин чынлап та кушмаган идем шул[2]**
**Сиңа миннән иртә китәргә.**
**Тыңламадың. Киттең. Туры килде**
**Миңа бераз сабыр итәргә.**

---

[1] Каръя (XX гасырның беренче чирегенә кадәр татар телендә актив кулланышта булган гарәп сүзе)—авыл җире. Биредә «даирә» мәгънәсендә алына

[2] Рәшитнең «Ачлык мәйданы» дигән китабында (Казан, 1993) миңа багышланган «Каракүз атлы кыз бала» дигән шигыренә ишарә. Анда шундый юллар бар:

Каракүз аша син миңа
Сәламнәр юллагансың.
Аннан соң үзеңнән алда
Үләргә кушмагансың...

(*Автор*).

Килер ул көн. Мин дә җан бирермен.
Кояш күзгә кереп югалыр.
Мәңге чыкмас. Минем «Хушыгыз!»дан
Җир «Саумы!» дип тетрәп кузгалыр.

Әлегә мин муенга дилбегә
Киеп ялан аяк җир сөрәм.
Буразна артыннан чыр-чу килеп,
Сандугачлар селәү эзлиләр...

## Балачак хатирәсе

Тымызык яшел яңгырның
Терекөмеш тамчылары,
Сикерешеп бии туфракта,
Кисә ут камчылары,—
Без исә лапас астында,
Паласта, чыланмыйча,
Такмак әйтәбез, суганны*
Авыздан чыгармыйча:

—Әпи-па-па-па, пи-па-па-па,
Маһи әби йон ката!..

Их, сөттәй җылы яңгырның
Яшькелт матурлыклары!
Балачак уеннарының
Кечкенә зурлыклары!
Риф, Камилы, Зыясы,
Вәкиле, Минзыясы,
Хәмдия, Гадәниясе,
Рәмзия, Хәниясе:

—Әпи-па-па, пи-па-па,
Маһи әби йон ката!..

Кайдадыр көйри калалар,
Авыллар көлдә бары,—
Без исә үткән сугышның
Иясез балалары,—
Лапаста, яңгыр астында,
Паласта, суган кабып,
Әйтәбез такмак—очсызлы
Такмакта хикмәт табып:

—Әпи-па-па, пи-па-па,
Кайчан соң этиләр кайта?!

*1982—1999*

* Ул шундый гамәли уен булган, күрәсең. Көпшәгә әйләнеп беткән суган кыягын авызга кабып, шулай туктаусыз такмак әйткән арада ул урталай кыелып төшә һәм без суганның эчендәге яшь зәһәрен чыгарып ашый идек.

* * *

*Таһир Хөрмәтуллинга*

**Син бит миңа туган да түгелсең,**
**Әмма синдәй туган бик сирәк!—**
**Синең хакка бүген сандугачлар**
**Сайрый алыр иде яхшырак.**

**Сайраттыра алмам микән, диеп,**
**Илһам бирмәмме, дип, мең кәррә,—**
**Мин һәр бөре бәгыренә үтеп,**
**Яшел байрак куккә күтәрәм.**

**Яшь җилләнә, яшелләнә дөнья,**
**Яшь илләнә!—сыймый колачка—**
**Шатлыгымнан нур әлмәгеп киеп,**
**Менәм—**
**Асылынам кояшка.**

**Яфрак белән шагыйрь язмышы бер.**
**Сөю—нәфрәт: канлы яшь җөй без.**
**Без кояшка баскычсыз да менеп,**
**Асылынган килеш яшибез.**

**Ә син, дускай, коткарырга теләп,**
**Төшерәсең нурлы элмәктән.**
**Мин яңадан элмәгемә керәм,**
**Шунда гына калам үлмәктән...**

***1999***

## Үтеп барышлый

**Шәһәр утларының җылысы юк.**
**Керфексез күз—шәһәр тәрзәсе.**
**Балкондагы азык әрҗәсендә**
**Кымшана ач йолдыз гәүдәсе.**

**Ун көн элек туңган ап-ак керләр,**
**Әнә, йәнә җепшеп кипшенә.**
**Туктап, шул керләрне кертеп китсәм,**
**Аңлашылыр микән кешегә?**

**Чакматаш юллардан үтеп барам...**
**Эх, вакыт юк кереп йөрергә!**
**Менә шулай, халыкка кермичә**
**Үтеп китте безнең гомерләр...**

**Сорау туа, шома яткан юлда**
**Очрап куйса җансыз сикәлтә:**
**«Бу йортларда синдәй кеше яши,**
**Бар, бел—үзең бүген ни хәлдә?»**

**Үксим—моңа кадәр ир-егеткә**
**Ник бирмәдем үгет? Ә нигә**
**Сузмадым чәчкәләр чын гүзәлгә?**
**Татлы ширбәт—һәрбер нәнигә?**

**Экраннардан пышылдыйсым килә:**
**Ник мондый без? Нигә дәшмибез?**
**Ник бу кадәр дөрес уйлыйбыз без?**
**Ник бу кадәр ялгыш яшибез?**

* * *

*Р. гә*

**Таң алдыннан җан җылысы эзләп,**
**Җәшкелт җаңгыр җекләп җилкәмә,***
**Юк, чорналып аңа,—сүрән йолдыз—**
**Бөтенләйгә килдем иркәмә.**

* «Җ» авазы махсус алынды. *(Автор.)*

Таң алдыннан җан җылысын, ахры,
Эзләп табып булмый әҗәткә,—
Шакыйм. Ул юк. Шакыйм. Юк. Чыгам да
Тупсадан ук калам гаҗәпкә:

Кергән чакта туң шомыртлар хәзер
Ялкын белән җанны ялмады—
Чәчкә аттылар!.. Бөркү ихатаның
Чәчкә атмаган җире калмады!..

Таң алдыннан җан җылысы туды!..
Җылыны учка җыйнап белештем:
Бу—мәхәббәт. Соңгы мәхәббәттән
Миңа чыккан бик зур өлеш бу!..

Таң алдыннан туган җан җылысы—
Сөю... Сөю соңгы буламы?
Гомре буе тулалмаган диңгез
Безнең яшьтән генә туламы?

Таң алдыннан туган җан җылысы—
Соңгы сөю... беләм үтмәсен.
Аһ, билгесез ләззәт!.. Сирәк дәһшәт!..
Көтәм. Үзем китәм. Көтмәсен.

Таң алдыннан туган җан җылысы—
Шомырттан сорадым: «Ул кайда?»
«Ул—мин бит ул,—диде.—Сине көтеп,
Тышта чәчкә аттым. Кер, әйдә».

*1996*

* * *

*А. га*

Сине эзлим. Беләм, якындасың.
Адаштыра безне кемнәрдер.
Нәрсә ашый күзне? Ач төтенме?
Бәлки илдән качкан көлләрдер?

Аерылу—ят, кавышу—җинаять.
Күзләреңнең шомырт карасын,
Якты чыктай, яшькә манам, әйдә,
Җем-җем итеп, чем-чем карайсын.

Без бәйләнгән тегә, бердәнбер җеп,
Корыч арканнан, дим, түземдер.
Кавышулар мөмкин... булмагандай,
Аерылу да мөмкин... түгелдер.

Их, белсәмче!.. Беләме соң яшьлек:
Чишмәсен кайсы тау култыклар?
Шулай гомер үтәр. Зиаратта,
Сәйдәш нотасыдай, юл туктар.
Шып туктар.

Исемемнең варисәсе бар ла,
Җисемемнең юк шул варисы.
Варисымны тәмугъ төбеннән дә
Килә, дускай, эзләп карыйсым..

*1993*

# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

**Камил Кәримов**

## КОМ СӘГАТЕ

РОМАН

* * *

Төнге сәяхәттән соң, йокылары туеп уянгач, Мәдиярның беренче сүзе Фазылның ачуын чыгарды.

—Су эчәсе килә...

—Кипшегән чиләктә бер тамчы су юк.

—Каенлык коесына барып кил әле, Фазыл.

—Күрдем мин ул коены. Биш-алты көянтәне чиратка куйганнар. Әбиләр чиләк өстендә, кул эшләрен тотып, саран коеда су саркыганны көтеп утыралар. Бик ашыкканнары суны ләме-ние белән тутырып, өйгә кайткач тондырып эчәләр, ди.

—Моңарчы ничек кырылып бетмәгәннәр соң алар сусыз?

—Ниса кортка әйтте бит әнә, урман эчендәге коеның суы кайнап чыга иде, бөтен авылга коенырга житә иде, ди. Соңгы бер-ике ел эчендә генә коргаксыды, ди. Инешләре дә хәлсезләнгән.

—Әйтмә әле шул дезертир кортканың исемен. Сөлек кебек ике яшь егетне ач утырта. Ә бәлки син аның кияве буласы кешедер?

—Ник ашатырга тиеш ди әле алар безне?

—Хәзер инде коеларының коруына да безне гаепләрләр. Су эчәселәре килгән саен безне каһәрләрләр... Кәнишне, без Каенлыкка килеп төшкәч, әй сөенгәннәр иде... Председатель Гарипов абый: “Су чыгарсагыз, авылны саклап калабыз, берәр ферма да корып жибәрербез”, —дигән иде. Юкса, суны Богады авылыннан—өч чакрымлы торба белән сузарга туры киләчәк, ди. Ул бәягә егерме кое бораулarga була.

—Әлфинәнең: «Су чыгара алмагансыз икән!»—дигән сүзен гомеремдә онытасым юк.

—Фазыл, зиндандагы әсир кебек уфтанып ятмыйк. Хәзер кояш кыздыра башлый. Вагон эче ипи миченә әвереләчәк. Син бер банка синтетик балга бер пачка маргаринны яхшылап болгата тор. Бер буханка ипиебез бар әле. Артыннан бер чәйнек чәй белән юсак, көне буе кикереп кенә йөрербез. Мин хәзер Богадыга барып, берәр канистра чишмә суы китерәм.

—Машинаң буш кайтмасын, Мәдияр, цистернага тутырып та алып кайт.

---

Ахыры. Башы 8 санда.

—Нишләргә кирәк ди ул шул хәтле су?

—Ниса корткага бүләк итәрбез.

—Төшаңа карата бик ярдәмчел син, әйеме, Фазыл. Ярый ла каршы ала белсә... Шушы дүрт кубометрлы суынны битенә сипсә нишләрсең? Ә?

—Ник, ана кирәкмәсә, әнә кояш астында торсын, кичкә чаклы җылына ул мичкә. Люкны ачабыз да рәхәтләнеп ванна керәбез. Автомобильле ванна.

—Син аны каян беләсең, Фазыл?! Әле буровойга килеп эшләвенә өч көн үтмәгән... Без чынлап та машина цистернасында су җылытып коенабыз бит. Эче иркен анын—берьюлы биш-алты кеше коена ала. Кайбер авылларда малай-шалайлар да рәхәтләнә безнең мичкәдә.

—Мин бик күп нәрсәне белеп тудым, Мәдияр.

—Әйтеп кара. Шаккаттыр әйдә.

—Әнә, юлның икенче ягында кыяклы түмгәкләр арасында казлар тезелешеп ятамы?

—Сон, яталар инде. Казларнын көтүгә чыгасы юк ич.

—Ник анда яталар дип уйлыйсың?

—Тыныч җир. Берәү дә борчымый. Вәт яталар...

—Юк, Мәдияр, минем укыганым бар, каз көтүен сарык көтүе кебек болыннан болынга куып йөртсән дә, ул гел бер генә урынга килеп ята. Казлар дымны тоеп, җир астындагы су агышын тынлап яталар, ди.

—Бер тотынгач, ахырынача ялганла инде, әйдә.

—Әйтәсем килгәне шул—Каенлык казлары безнең агрегатка якын да килми. Казлар юл өстендә җим чүпләп йөри торган кошлар, машина-трактор тавышыннан курка торганнардан түгел. Димәк, Каенлык казлары җир астындагы суның кайдалыгын белә. Иртә-кич алар гел әнә теге түмгәкләр арасында. Көндезгә кояш астында гына быкырдык күлләвеккә ашыгалар.

—Бәлки алар түмгәкләр арасында качышлы уйныйлардыр?!

—Юк. Әгәр без агрегатны казлар болынына күчереп янадан бораулыйсак су чыга, билләһи!

—Ну, Фазыл агайне, син берәр ел эшләсән, әллә нинди эксперимент-лар уйлап чыгарып, рабочий классның башын катырып бетерерсең әле.

—Разведка ясаган сыман итеп, нечкә долото белән, тиз генә бораулап карап буламы?

—Бер сәгатькә ун метр тизлек белән төшә алабыз.

—Чокыр казыр өчен председательгә янадан аңлатып, экскаватор сорасаң, тагын ярты көн үтәр дип исәплә.

—Үтми, Фазыл! Менә шушы су машинасының помпасын турыдан-туры бораулау торбасына тоташтырып карарга кирәк. Без склад мөдире Рәүф абыйның дачасына кое казып бирдек, чумарага... Бакчасында чокыр казырлык та урын юк. Үзең беләсең: су эзләп табар өчен су кирәк...

—Алайса нәрсә көтәбез соң? Вышка аударылган—агрегат күчәргә әзер. Торбалар җитәрлек. Мастер урынына басарга шүрләмисеңме соң, Мәдияр?

—Бер ел эшләсәң, син дә мастерга әйләнәсең лә! Әмир абый бит ул материал өчен, техника, документлар өчен җаваплы кеше генә. Ин авыр эш барыбер синең белән миңа кала. Бораулау агрегатын осталардан һәйбәтрәк беләм мин. Анысы өчен борчыласы юк.

—Ә нәрсәсе борчый?

—Сиңа рәхәт, син яңа кеше. Әгәр аннан да су чыкмаса, Әмир абый икебезне дә Казанга куып кайтарачак. Хәер, Минлегалиев мине үз бригадасына күптән чакырып йөри иде инде...

—Каенлык халкы җүләргә санамасмы безне?

—Авыл халкының исе китмәс, алар кул селтәде! Нишләгәнне абайламыйча да калырлар. Ярый, син әйтмешли, вакыт әрәм итмик. Син суга кит—дүрт тонналы чиләк белән. Ә мин, Фазыл, маргарин әлбәсен болгата торам.

Мәдиярга канатлар үстемени! Монарчы кушканны гына үтәп, янасына алдан барып тыгылмыйча, пычрак эшне ерактан әйләнеп үтә торган кыска торыклы, шадра йөзле, авыр сөякле егеткә өстәмә җан керде. Зәңгәр күзләренә килешеп торган кызыл балчык төсендәге җирән чәчен күпертмә бармаклары белән артка тарагандай итте дә эшкә тотынды. Фазыл тиз арада күрше авыл водокачкасыннан су алып кайтты. «Маз» платформасына көйләнгән унике тонналы үзйөрешле агрегатны яна урынга күчерделәр... Фазыл үзе белеп башкара алырдай эшләр житәрлек иде бугай—ул берсе-берсе житмеш-сиксән килограммлы төрле озынлыктагы бораулау торбаларын сөйрәп, яна урынга күчерде. Ниһаять, биш еллык тәҗрибәсенә карамастан, Мәдиярны да сагаерга мәҗбүр иткән минутлар килеп житте—вышканы күтәрергә кирәк иде. Ул май насосының гүелдәвен ишеткәч, Әмир кебек кулы белән ишарәләп, Фазылга читкә китеп басарга кушты. Иске техниканың кайбер өлешләре түзмәскә мөмкин. Йөз атмосфералы май фонтаны йөзенә китереп бәрсә—син үзенне күзсез калдым дип исәплә...

Май насосының гүелдәве көчәнүгә әверелде. Көчәнүле тавыш кинәт туктап, ыңгырашуга күчте. Һәм вышка уналты метрлы гәүдәсен күтәрә башлап, бер мәлгә җәһәннәмгә ут өсти торган гигант «Катюша»га әверелде. Ниһаять бөтенләй тураеп баскач, Фазыл аның корыч аякларын эт камыты чаклы каптыргычлар белән платформага беркетте. Долото үзенен ялтырап торган булат тешләрен жиргә батырды...

Башланды...

Тай дигәнең атка ияреп йөргәндә генә кирәксә-кирәкмәсә ләнләң сикеренә, әгәр арбага жигелсә, атка әйләнә икән ул... Мәдиярнын зәңгәр күзләре кысылды, шадралары куерды, чәчен тиктомалдан гына еш-еш артка тарый... Дулкынлана... Башка вакытта булса аптырап калган Фазылга: «Атлы казак» кебек күз алдымда торма әле, дияр иде. Һичьюгы вагон эчендә кечке очрашуларны көтеп әлсерәгән ак кәчтүнен искә алыр иде... юк. Мәдияр кинәт житдиләнде. Ул гел жир астыннан чыккан балчыкны учына ала. Әллә үзен юатыр өчен, әллә күнелсез булмасын өчен үзалдына сөйләнә:

—Хәзер, хәзер Фазыл, нишләргә кирәген үзем әйтермен...

Фазылның күрше авылдан машина белән су ташуы гына торкарлады эшне. Әле кояш төшке аш турысына килеп житмәгән иде. Долотога сигез бораулау торбасын ялгап төшергәннән соң Мәдияр: «Илле ике метр төштек», дип әйтеп бирергә дә өлгермәде, өстән куыла торган су ялангач стеналы скважина эченә убылып юкка чыкты. Жир бугазы суны өскә чыгармыйча үзенә йота барды.

Фазыл каушавыннан машина мичкәсенә сикереп менгәнен сизми дә калды, люкны ачып кулын тыгып карады.

—Су күп әле мичкәдә, помпа да эшләп тора. Кая китә соң су?!— дип кычкырды ул Мәдиярга.

—Жир астындагы ярыкка! Полный уход дип атала бу! Во!!!—Мәдияр ике баш бармагын берьюлы күрсәтте.—Менә тыңла,—диде ул шәрә скважина эченә урман чикләвеге чаклы балчык ыргытып.—Чулт итәме?! Димәк аста су бар. Хикмәте тик—калынмы ул су? Без агызганы гына түгелме?

—Алайса,—диде Фазыл, ниһаять үзенең эшкә ярардайлыгын исенә төшереп,—без Каенлык астында дингез таптык, әйеме?!

—Хәзер, хәзер, Фазыл, нишләргә кирәген үзем әйтәм. Без әле разведка ясап суны эзләп таптык кына. Хәзер зур долото белән скважинаны янадан юанайтып казырга кирәк, әнә теге юан торбалар белән ныгытырлык итеп. Юкса жимерелә ул. Аннары насос төшерәбез дә Каенлыкны коендырабыз.

—Су бар микән инде?

—Сумы?! Полный уходтан сонмы?! Бала-чага шул әле син! Кефир шешәсе! Ком сәгатен әзерли тор!

Казлар... Һәй, казлар. Сабан туе мәйданындагы көрәшне күрергә килгән кунаклар кебек агрегатны урап алганнар да Фазыл белән Мәдиярнын мәш килүен күзәтәләр. Үзләре, "га-га-га" итенеп, туктаусыз сөйләшәләр. Чиләкләрен онытып, чишмә башына килгән кызлар диярсен...

Мәдиярнын янадан үз холкына килүе Фазылга ышаныч өстәде, димәк, су бар инде!

Карангы төшә башлагач, Мәдияр генераторны ялгап, вышкадагы утларны кабызды. Бораулау агрегаты уенчыклары коелган яна ел чыршысына охшап калды.

Казлар гаилә-гаилә булып өйләренә таралышты. Кайтырга теләмәгәннәрен малай-шалайлар куып китте.

Долотоны чыгарып, бөтен нәрсәне сүндереп, бераз хәл алыйк, дип, «МАЗ» кабинасына кереп утыргач, Мәдияр гадәт буенча Фазылны үртәргә теләгән иде.

—Әлфинә янына барабызмы?

—Әйдә, киттек...

Алар, сүз куешкан төсле, икесе дә берьюлы йокыга киттеләр...

## Суны да юарга кирәк

Соңгы ике ел эчендә яңгырдан гайре су рәхәте күрмәгән Каенлык халкы өчен гаҗәеп манзара иде бу... Чалт аяз июль чилләсендә авыл урамына гөрләвек бәреп керде. Ул, чишмәсеннән качкан дулкын кебек, ашыгып, юлында очраган бөтен тузанны юып, машина көпчәкләре эзе буйлап хәлсез инешкә ярдәмгә ашыкты. Каешланып каткан урам өстендәге тузан оның бер кат юып алгач, әлеге гөрләвек күзгә күренеп чистарды. Казлар... Казлар дәррәү күтәрелеп, гөрләвекнең оясын күрергә теләгәндәй, бораулау агрегаты янына җиелдылар. Ә анда—скважинадан тәртә калынлыгындагы фонтан булып су бөркелеп тора. Казлар үз телләрендә берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә, Мәдияр белән Фазылны мактадылар. Кодрәтләреннән килсә, шланга башыннан үрелеп су эчәрләр иде дә, ләкин фонтан шавы ул казларны шүрләтеп, гайрәтләрен тыеп тора. Фазыл бала чагыннан ук сәке астында ояда утырган казның черек бүрәнә аша баш тыгып кычкырганын күргәннән бирле күңелендә әлеге кошларга үпкә саклап йөртә иде. Хәмдия белән аерылышуда казларның да гаебе бар кебек иде ана. Бактың исә, казлар аның өчен Әлфинәнең барлыгын белгән икән. Хәзер шушы тирән чишмәгә су алырга килгәч, һәр кеше Фазыл белән Әлфинәне искә төшерәчәк...

Авылның буровойга якынрак ягындагы өйләрдә чиләк-көянтә күтәрә алырдай кеме бар—су шавына җиелдылар. Ләкин күпме генә тырышмасыннар, су алалмадылар—фонтан чиләкләрне бәреп ата, кешеләргә чәчрәп якын килергә ирек бирми. Әлеге суның бетүе мөмкин дигәндәй уй халыкны кабаландыра, каушата һәм тынлаусыз итә иде. Кемнеңдер башына төплерәк уй килде:

«Җәмәгать, чиләккә генә сыймый моның суы. Зуррак савыт кирәк, бидоннарны алып килик».

Бидонга дип киткәннәргә авылның икенче очындагылар да ияреп килде. Каенлыкта су күрмичә коргаксыган нинди савыт бар—бөтенесе яңа чишмә янына җиелды. Су салкыныннан куәтләнгән чыр-чу фонтан тавышын җинде.

—Җәмәгать,—диде Мәдияр, авылның үз теленнәрәк кычкырып,—бу суны әлегә эчәргә ярамый! Аны өч көн буе агызып чистартканнан соң Казанга анализга илтәсе бар!

Ләкин халыкның Мәдияр әйткәннәргә исе дә китмәде. Киресенчә, биш-алты кеше аны үртәгәндәй, чиләк күтәреп эчә дә башладылар.

—Зәмзәм суы бу!
—Бәй, тәме нәкъ Уразай кодагыйларның чишмәсенеке кеби!
—Син, апаем, әнә безнең урман коесына анализ ясa.
—Суыңны кызганасың мәллә, инәннең бәчмәге, әйтмәсәм дә булмады?!.
Скважина янында көне буе кеше өзелмәде. Зур савытлары бетеп, инде бүтән су җыяр нәрсә калмады дигәннәре, янә килеп өч литрлы пыяла банкаларга, курчак чиләкләренә, бүген аш пешерәсе кәстрүлләренә, чәйнекләренә тутырдылар. Бала коляскасына кер кайната торган калай мичкә салып Ниса кортка килгәч, Мәдиярның суны сүндерергә исәбе бар иде, ләкин Фазыл ирек бирмәде.
—Суны туктата күрмә.
—Әбиеңә сәлам әйт...
—Әнә, Мәдияр, безнең су ага торгач, колхоз идарәсенә барып җиткән, Гарипов абый үзе килә.
Колхоз рәисе егетләрне күрмәмешкә салыштымы, әллә су фонтанын күргәч үз күзенә үзе ышанмадымы, «Волга»сы туктап беткәнне дә көтмичә, кыр термосын күтәреп чыкты. Су агышы аның кулындагы термосны тартып алып өч сәгатьтән бирле шарлавыкланып казылган чоңгылга томырды. Гарипов сабыйларча көлә-көлә суны чоңгылдан гына тутырып эчте, эчкән кадәресе кимегәч тагын тутырды һәм бөкеләп «Волга»сына ашыкты.
Бер сәгатьтән соң «Волга» тагын күренде. Тик бу юлысы ул су янына түгел, ә иске урында калган яшел вагон ишегенә терәлеп туктады. Мәдияр белән Фазылның анда икәнен белә иде ул. Вагон ишеге ачык булса да, шартына туры китереп шакылдатты рәис. Егетләр җавап бирергә ашыкмагач, тар баскычларга доң-доң басып, вагонга үзе керде.
—Әллә йоклап ятасыз инде? Шушындый бәйрәм көнне...
—Безнең өчен гади бер эш көне инде бу,—дигән булды Мәдияр, сер бирмәскә тырышып.
—Гафу итегез, төне буе эшләгәч алҗытты бераз,—диде Фазыл, тумбочка өстендәге ясалма балга болгатылган маргарин калдыгын яшереп.
Тик Гарипов абыйлары Фазыл кулындагы баллы май белән каткан ипи кисәген күреп өлгерде шул. Һәм кинәт кенә ишектән башын тыгып, шоферына кычкырды.
—Багажникны бушат әле! Тиз бул!—һәм рәис, «старший» иттереп Мәдияр беләнме, Фазыл беләнме сөйләшергә белмичә, тумбочкага ымлады.—Өстәлегез кечерәк!
—Җитә ул безгә.
—Әйе, бу колхозда җитә ул безгә,—диде Мәдияр, Фазылны үзенчә җөпләп.
—Сез егетләр миңа үпкәләмәгез. Җитәкче хәлен җитәкче булгач кына беләсең. Су чыкмый икән дип, кара кайгыга салдыгыз, валлаһи! Бәй, мастерыгыз кая соң әле?
—Казанда ул... Өченче көн инде...
—Ничек Казанда?! Ә бу скважинаны кем казыды?!
—Икебез.
—Юк, икебез түгел, Мәдияр берүзе. Минем разрядым бәләкәй әле, беренче атнамны гына эшлим.
—Аның каравы суны кайдан эзләргә кирәклеген син әйттең...
Бөтен килеш кыздырылган ике тавык, салкын килеш ысланган биш симез балык, бер кирпеч ипи куйгач, өстәлдә шешә куярлык та урын калмады.
—Суны да юарга кирәк бу дөньяда. Мин үзем эчмим, инфарктан соң, врачлар белән хатын бер сүзгә килеп, тыеп торалар. Ну бүгенге вакыйга хакына унбиш тамчы йотарга риза—карволол булып урнашсын. Әйдәгез, сезнең исәнлеккә егетләр, сез казыган коеның суы бетмәсен! Бетмәс микән, егетләр?!

Мәдияр ком сәгатен кырлы стакан урынына куйды. Бер бүлемнән икенче бүлемгә вакыт агышы булып ком сибелә башлады.

—Скважинадагы суның күплеге шушы сәгать белән үлчәнә инде. Насос эшлиме—эшли, комы коеламы—коела, су агамы—ага! Торба эчендәге суны погружной насос ике генә төкерә. Әгәр җир астындагы чишмәгә юлыксан—су мәңге бетми.

Мәдияр ком сәгатен тагын... тагын... тагын әйләндерде. Ә су ага да ага...

—Ә дебеты зурмы?

—Кызыл насос төшердек, сәгатенә 16 тонна бирә торганы. Биш сәгатьтән бирле ага.

—Каенлык дингез өстендә утыра,—диде Фазыл сүзгә катышасы килеп,—безнен вагон төче дингез ярында.

Кырлы стакан Фазыл кулына күчте.

—Мин бу аракыны калдырам, диде ул. —Кем әйтмешли, иртәгесе көнгә ризык теләп торсын. Каенлыкка еш килермен әле мин. Ни дисән дә, беренче авылым, беренче скважинам.

—Беренче мәхәббәтен! Бу егет Ниса корткагызнын кияве буласы кеше.

—Сез Гарипов абый, Мәдиярнын сүзенә игътибар итмәгез. Ач карынга салынган аракысы барып җитте бугай анын.

—Ә нәрсә, ялгыш сүз ишетмәдем әле мин. Кал, энем, безнен колхозда. Хуҗалыкларда инде алты скважинабыз бар. Инженер-оператор итәрбез үзенне. Читтән торып кына институтка кертербез. Су тирәсендә эшләүче белгечләр тансык. Аена 150 тәңкә акча алырсын. Өй салып бирербез.

—Нишләп ана 150 сум гына түлисегез килә? Менә миңа Балтачнын Карадуган авылында 160 сум түлиселәр иде.

—Мәдияр!

—Сон, алайса, без дә 160 итәрбез.

—Шаяртуыгыз өчен рәхмәт, Гарипов абый,—диде Фазыл, стаканны тулы килеш өстәлгә кире куеп,—бораулаучы эше күбрәк кызыктыра шул мине.

—Чынлап сөйләшүем иде, юкса... Чаллы авылы өстенә шәһәр сала башладылар да, хәзер өч ай саен ике-өч кешебезне чүпләп торалар. Дилбегә тартырдай, теләсән камыт кидерердәй яшьләрне генә алалар... Лимит белән сораталар... Ярый, егетләр, сез сыйланыгыз, мин комбайннар янына ашыгам. Кичкә Ниса кортка бәлеш пешереп көтә сезне. Теләсәгез, Әлфинә оныкачаен да китертәбез конвой белән, теләсәгез, Самат абыегыз үзе алып килер...

—Юк, юк, Гарипов абый, алай ярамый!.. Хәер, сезне анламассын, әллә чынлап сөйлисез, әллә юри үртисез?!.

—Колхоз эше өчен чынлап сөйләсәң дә ярый, кем, Фазыл энем. Ярый, хуш иттек, рәхмәт сезгә, тәмле чишмәгез өчен рәхмәт!

Колхоз рәисе китүгә, Фазыл Мәдиярны тәрбияләргә кереште:

—Син нәрсә инде, кеше алдында минем серне чишеп маташасын?

—Авылнын сере юк. Казанда гына ул—кем кемне нишләтсә дә һичкем белми. Ә авылда ни уйлаганынны да күреп торалар... Гарипов алдында эчмим мин дип кылтаюын эчемә тиде.

—Чынлап та эчкәнем юк.

—Мин дә, биш ел элек буровойга килгәндә, аракы күргән кеше түгел идем. Юл өстендәге эш сындыра ул... Нинди кызыгы бар соң бу зимагурлыкнын? Гел юлда, гел вагонда, гел чегән тормышында...

—Өйлән алайса.

—Әһә. Дурак ди мин! Өйләнеп хатынынны Казанда калдыр да елга унике тапкыр получка алырга кайтканда күрерсен. Ул анда яшәп ята, син юлда яшисен.

—Әмир абый өйләнгән бит әле.

—Ут йотып ята. Айга бер тапкыр кайтып кочаклап килер өчен айлык получкасын түләп тора... Өйләнмим. Авыл саен кунак егет мин! Кемне сөйсәм, кемне кочсам да, намус газабы кичерәсе юк. Үземә үзем хуҗа! Эшлим, яшим, сөям, теләсәм эчәм дә... Мине үзенә өйләндерә алырдай кыз берәү генә бу илдә, ул да булса—Дон дәрьясы читендә...

—Эчмәгән булсаң, Әлфинәне күреп кайта идек, машина белән генә...

—Суны туктатмыйча өч тәүлек кудырасы бар. Саклап утыр. Ә мин Нәсфия янына барам.

Су ага да ага. Аның шаулавы авыл тирәсендәге бар табигатькә үтеп керде. Казлар ниһаять агрегат янына килмәс булды, урам уртасыннан йөгергән кәүсәр гөрләвекне куып йөрмичә оя-оя булып өй түрләрендә көтеп яталар. Суга килүчеләрнең чыр-чуы сабырланды, яңа чишмәнең сүнмәслегенә ышанып, чиләкләре бушаганга гына киләләр—чират та юк, кабаланучы да. Каенлык чишмәсе инде ул хәзер, аны бораулаучылары үзләре белән алып китә алмаслар. Беренче минутларында дәртле җыр сыман бөркелеп торган су шаулавының хәзер инде сагышы бар. Тигез җирдән казып алган бу сөенеч чишмәсен авылы белән бергә ничек калдырып китәсең?! Мәдияр инде биш ел эчендә иллеләп чишмә белән аерылышкан кеше. Ул мондый рәвештәге сагышларга ияләшкән бугай. Ләкин Фазыл өчен Каенлык чишмәсе беренче наз, беренче шатлык, беренче табыш һәм беренче югалту кебек. Тора-бара Фазыл аңа кадәр эшләгән бик күп агайлар ише, калын тиреле зимагурга әверелеп, Ходай ни юнь кылса —шуны ашап, кемне сөйсә —шуңа юанып, получкадан получкага чаклы вакыт үткәрер өчен генә гамьсез яшәргә өйрәнер, күнегер, ияләшер... Тик Каенлык онытылмас. Беренчеләр һәм соңгылар онытылмый—уртадагылары күмелсә—күмелер... Туган авылны оныттырып торырлык Каенлык, ниһаять, куанып эшләрдәй бораулаучы эше, Хәмдиядән якынрак Әлфинә—беренче мәхәббәтнең үзе түгелмени?!

Авыл монтеры чишмә янына багана утыртып, идарә итү щитына колхоз тогын тоташтыргач, агрегаттагы генераторның кирәге калмады. Һәм Мәдияр Әмир килгәнче дип вышканы егып, корыч арканнарны җыеп бораулау торбаларын үз урынына тәгәрәтте. Анда-монда килеп тотынган Фазылны юатып!

—Хәзер, хәзер, нишләргә кирәген үзем әйтәм, яме,—дип торуы Мәдиярның һаман да кирәксә —житди, кирәксә —шаян, якын кеше икәненә искәртә иде.

Актаныш самолеты техник сәбәпләр аркасында кич житкәндә генә килеп төште. Һава торышына кагылышлы сәбәпләрне күреп аңласа да, мосафирлар техник сәбәпнең ни икәнен, самолетның ник соңарганын тәки төшенмәделәр. Әмир дә Казан эчендәге аэропортта алты сәгать буе көтеп утырды. Самолет менә килә, менә килә дип сәгать саен вакытны суздылар. Ә бит алты сәгать эчендә ул Киндерле бистәсендәге фатирына ике тапкыр кайтып, ике тапкыр кызын сөеп, хатыны белән ике кат саубуллаша ала иде. Актаныш аэродромына килеп төшкәндә ул инде үзен ике вагон цемент бушаткан ялчы кебегрәк хис итте. Шушы халәттә Каенлыкка житеп, вагон эчендә аракысы эчелеп бетмәгән шешә күреп, аэропортта каршы алмаган егетләр өстенә ай-һай жикеренмәкче иде ул, әмма шул чакны ачык тәрәзәдән су шаулавын ишетеп, кинәт юашланып калды. Монда инде кайсыгызның эше бу дип сорап торасы юк. Димәк, Мәдиярның оста булырлыгы бар, димәк Фазыл да эшкә ярый... «Исәнмесез, ул-бу юкмы?» дип күрешәсе урынга, Әмир Мәдиярның кулындагы тавык сыйрагын урталай сындырып, кырлы стаканны мөлдерәмә тутырып каплады да сорау яудырырга тотынды.

—Ничә метрдан? Озак маташтыгызмы? Колхоз председателе скважинаның чын тирәнлеген беләме? Ничә труба төшергәнегезне карап тордымы? Утыз метрга арттырып әйтсәк шикләнмәсме, процентовкага кул куяр микән?

Ниһаять сорауларга кыска-кыска җавап ишеткәч, ул Казандагы нәчәлникләрнең яна фәрманын җиткерде:

—Иртәгә Алабуга районына күчәбез—сезгә сәлам шул булыр!

# Суфия

Кояш көнчыгышта баеды

Ике гашыйкның аерылышуына һәрвакыт өченче кеше гаепле. Туган-тумачамы ул, күрше-күлән, дус-ишме, дошманмы ул, хезмәттәшме—барыбер... Арага керәләрме, нахак сүз ишеттерәләрме, тартып алаларны, буйсынырга мәҗбүр итәләрме?.. Аеручылар ин сөексез кеше булып арага керә. Өзелеп сөйгән ярлар искә төшкән саен, шул ярларга ияреп сөексезләр дә күз алдына килеп баса.

Әгәр Әмир кабыл-тибел генә җыештырып, бригаданы Казанга алып чыгып китмәсә, Фазыл әле Әлфинәне күрер өчен һичшиксез җаен табасы иде. Бөтенләй икенче тарафка юлга чыккач, кыз белән болай да әлләни якынаеп өлгермәгән аралар ерагаер гына... һәм моның сәбәпчесе—Әмир. Дөрес, бригаданы Казандагы түрәләр фәрманы йөртә. Ләкин ул фәрманны Әмир алып кайтты. Димәк, Фазылны Әлфинәдән ул мәхрүм итте.

Мәдиярның да аңа үзенчә шелтәсе бар. Бактың исә, Әмир аны кочаклап алып аркасыннан сөеп, мактарга тиеш иде. Су чыгара алмаганнар дигән хурлыклы даннан коткарды бит ул бригаданы. Бөтен җаваплылыкны үз өстенә алып. Останың беренче җинүне тиешенчә бәяләмәве егетнен рухын төшерде...

Кыскасы, Мәдияр белән Фазылның кояшы бүген көнчыгышта килеш баеды. Чыклы үләннәрдә соңгы эзләрен калдырып, яшел вагонны су ташучы машинага, ә долотолар, колач җитмәслек ачкычлар, цемент капчыклары һәм инструментлар төялгән дүрт көпчәкле арбаны бораулау агрегатын күтәргән «МАЗ»га тактылар. Кирәк-ярак төшеп калмады микән дип, эш урынын тагын бер кат йөреп баккач, автокәрван олы юлга чыгып басты. Ерак сәфәр алдыннан, Әмир җиргә төшеп, тәмәке көйрәтте. Аңа ияреп Мәдияр да «Аврора» кабызды. Капусы ачыла башлаган таннан, ярау җил көткәндәй, Фазыл тәмәке төтененнән качып, авыл ягына борылды.

—Син минем янга утыр. Рульдә алыштырырсың. Самолет белән очканда гына тиз ул. Актаныш белән Казан арасы 500 чакрымга җыела. «МАЗ» бик авыр машина, рульдә берәр сәгать кайтсаң, вагон бушаткан кебек буласың... Ә Мәдияр безнең арттан әкрен генә ияреп. Юлны хәтерләп кал. Актанышка киләсең булыр әле. Күпме эзләнсән дә, Татарстанда утыз ике генә район. Бер йөргән юлларга кабат-кабат әйләнеп кайтырга туры килә.

—Мин тиз генә Ниса кортка янына кереп чыгыйм әле,—дип бүлдерде Фазыл остазның вәгазен.

—Юл сәдакасы бирәсең мәллә?

—Йомышым бар иде...

Кортка инде ишек алдына чыккан. Сыер сава торган ак чиләген казык башына элеп маташа. Фазылны күргәч ул, чиләген дә алырга онытып, кулларын аљяпкыч итәгенә сөртә башлады.

—Бәй, иртәрәк ачыккансыз түгелме соң? Бүген китәсез дип ишеттем.

—Бүген түгел, түткәй, хәзер үк...

—Үзегез беләсездер инде анысын. Чуенда итле бәрәңгем пешкән. Әйдә, чакыр калганнарыгызны.

—Ашап тормыйбыз, ашыгабаз. Мастер шулай диде. Түткәй ниме соң?..

—Нәмә дисең?

—Ниме соң, түткәй?

—Әйт сүзенне!—Ниса кортка егетнен кем турында авыз ачасын белә, тик ниндирәк гозер әйтеләсен генә төшенми, шуна күрә сер бирергә ашыкмый.—Бүген көтү кайтканчы Аккүзгә барып киләсем бар ие.

—Түткәй. Әйт инде Әлфинәгә, пожалысты, срочно Казанга чакыртканнар диген. Саубуллашып та өлгермәдек. Түткәй, Самат абыйга сиздермә инде, яме!

—Ул чаклы исәр түгел лә инде мин...

—Түткәй, Әлфинәне күрсәң...түткәй.

Ниса кортка Фазылның ялварулы тавышын тоеп, аның «Әлфинә» дигән саен каушавында самимилек һәм эчкерсезлек чалымнарын сизеп, саф яшьлеккә генә хас кичерешләренә ышанды, аңа ихлас ярдәм итәргә теләде. Ул шушы мизгелдә оныгасының ышанычлы «подруга»сына әверелеп, клубка ашыккан яшьләр сыман, ялт кына өенә кереп чыкты да Фазылга китап тышыннан кисеп алынган бер катыргы тоттырды. Катыргының икенче ягында Әлфинә рәсеме—Аккүзнең иген кырында, шәфакъ нурында ничек басып торган булса—шул Әлфинә.

—Бер усал егет кызымның кулыннан тартып алган булган. Бөгәрләнгән иде, катыргыга үзем ябыштырдым.

Бу минутта кортка көтүгә чыгасы малларын да онытып, әллә ниләр сөйләргә җыенган иде бугай, тик Каенлык тынлыгына «МАЗ»ның сискәндергеч быргысы үтеп керде.

—Түткәй, рәхмәт! Мине чакыралар әнә...

Фазыл хушлашырга да онытып чыгып чапты.

Җәйге көннең учак кебек чагы. Сүлпән генә кабынган учак яна торгач, бөтен утыннарны комсызланып ялкынга йота да тагын сүрелә—көн озынлыгы да шулай. Каенлыктан чыккач иртәнге һаваның дымсу салкынлыгы көн учагында кызып, бөркү тузанга әверелде. Ян тәрәзәне ачмасаң, кабина эче төннеген япкан кара мунчага әверелә.

—Ун сәгать буе кайтасыбыз бар, Фазыл агайне. Мин сине үз яныма сөйләшеп барыр өчен алдым, —диде Әмир.

—Юлы бигрәк озын, сүзебез житәрме?

—Күршең әйбәт булса, сүз күп ул, кияү! Син ян көзгедән Мәдиярны күреп барырга тырыш, ара ерагайса, әйтерсең.

—Каенлык көзгедән югалды.

—Ну и чурт сним! Татарстанда безне көтеп торган өч мең алты йөз авыл бар. Ләкин Актанышка бүтән аяк басасым юк!

—Мин аңламыйм сине, Әмир абый.

—Бораулау остасы булып, үзеңә бригада җыйгач аңларсың әле.

—Миңа зурдан кубып хыялланырга иртәрәк әле. Әнә, Мәдияр биш ел эшләп тә...

—Нәрсә, Мәдияр?!. Үсеп житкәч остазыңның күтенә тибәргә кирәкме? Каенлыкта минем аркылы үрелеп батырлык эшләргә кем кушкан аңа? Имеш, кырык ел буе шушы эштә бөкресен чыгарган Әмирнең кулыннан килмәгәч, борын астында маңкасы кипмәгән малай, яңа урында су барлыгын тоеп, үз белдегe белән скважина бораулаган.

—Су чыккач сөенече уртак түгелмени?

—Мин чыгарсам уртак иде. Ә сезнең уеныгыз мине мыскыл итү генә. Күрегез янәсе! Яшьләр талантлы! Кешегә пенсияне тикмәгә генә бирмиләр, имеш. Тагын ике ай көтсә, мин аңа бригаданы калдырып китә идем, бөтен агрегатны, менә шушы кәрванны да... Көзгедән кара, киләме ул хайван?..

—Килә. Безнең тузан эчендә чак күренә.

—Шул кирәк аңа! Иснәсен! Бик беләсең килсә, агайне, Мәдияр өчен борчылып соравым түгел—машинасы исән йөрсен. Шушы арбалы

«МАЗ» бөтен агрегаты белән, вагоны, су ташучы машинасы, бораулау торбалары, тирәнгә төшә торган насослар—бөтенесе минем өстә. Алар өчен мин җавап бирәм. Безнеңчә җавап бирү—ул авария өчен, урланса, ватылса, төшеп калса—кесәңнән чыгарып түләү дигән сүз. Сез ватасыз, мин түлим. Бәйгегә малай-шалайны җибәрсәң—атны яндыра!

—Ватмадык ич!

—Шул гына җитмәгәние! Менә хәзер үзең уйлап кара: безнең скважина... юк, сезнең скважина өчен документлар тутырырга дип, Каенлыкка прораб Сәфәров килеп төшә. Процентовкаларга кул куйдырганда колхоз председателе хәлне сөйләп бирә. Ә Сәфәров моны Казанга кайтып бөтен мелиораторларга җиткергәч, Әмирнең кулыннан килмәгән, Мәдияр шаккатырган!.. Пенсиягә чыгарга ике ай кала дигәндә, инде шәт «Атказанган мелиоратор» исеме алам дигәндә... Мәҗлес ашына чабата тараканы төште... Куам мин аны... Гаражда өч елдан бирле Владимировтан калган агрегат ята. Шуны аякка бастырсын, үзенә яңа бригада җыеп эшләп карасын.

Ун сәгать буе остазның эч пошыргыч зарын тыңлап бара калсаң, Саескан Тавы кичүенә җиткәнче башың катып, йөрәгең тотып, саруың кайнап, чыдамың бетәр иде. Шөкер, Пучыны үтеп Ык елгасы аша салынган агач күпергә җиткәч, Әмир сүзне икенчегә борды.

—Актанышның язмышын хәл итә торган күпер бу. Аэродромының туны эрегәч, самолетлар төшә алмый. Һәм менә бу күперне дә сүтеп ташлыйлар, өлгерсәләр... Өлгермәсәләр, Ык ташкыны агызып китә. Аннары Актаныш белән Казан арасында юл өзелә. Самолетлар көн аралаш килеп аэродром өстенә Казанның почта капчыкларын ыргытып китәләр. Ә районныкы өелеп ята—Минзәлә күперенең янарганын көтеп. Юл өзегендә калганым бар... Ай буе эшләдек... Аэродром ябылырга ике көн бар әле дип, шалтыратышып тордык,—алданрак яптылар. Актанышта бүленеп калдык. Юл өзелде. Эш бармый—ни материал китерә алмыйлар, гөрләвекләр аркылы-торкылы ага, ни юлы су ташырлык түгел. Вышканы урыныннан да кузгата алмадык—сөрелгән басу өстенә туры килгәнбез—баскан җиребез кара боламыкка әверелде. Ә кайтасы килә.

—Ник вагонында гына ятмаска?!

—Ай буе эшләп кара да, өеңә, гаиләңә, әти дип өзгәләнеп торган кызың янына кайта алмыйча интегеп кара...

—Алайса бораулаучыларга өйләнмәскә генә инде.

—Өйләнеп хатыныи үзе белән вагонда йөртүче мастерлар бар—Антонов—бораулаучылар арасында беренче булып машина алган кеше. Атна-ун көн дә үтмәде—урладылар. Шул ачудан бөтен бригадасын куып таратты да хатынын эшкә урнаштырды. Саба районының Баландыш авылында бергә терлекләр өчен культуралы көтүлеккә артезиан скважиналар бораулаганда минем бригаданы ярышка чакырган иде әле.

—Антоновмы?

—Әйе, хатыны белән. Антонов үзе бораулый, үзе су ташый, үзе торба ялгый. Хатыны чалбар киеп әрле-бирле йөри шунда.

—Хатынын интектереп йөрүенең мәгънәсен аңламыйм.

—Получка алган көнне аңлыйсың аны. 100 метрлы су скважинасы бораулаган өчен чама белән биш йөз тәңкәлек нәрәд ябыла. Шул акча бригада эшчеләренең разрядларына карап бүленә. Әйтик, Каенлыктагы скважина акчасын өчебезгә бүләчәкләр. Ә Антоновның бригадага дигән акчасы хатыны белән икесенә генә бүленә. Җәй көннәре хәвеф-хәтәрсез генә эшләп торганда айга өч скважина борауларга була. Димәк, Антонов гаиләсе айга бер мең ярым акча эшли дигән сүз.

—Дүрт айдан тагы яңа машина алдымы?

—Алды, пычагым! Икенче айда ук авария ясады. Хатынын күзколак була күр дип, станок янына калдырган да үзе водовозка белән суга киткән. Әйләнеп килсә—дизель сүнгән, бораулау торбасы долотосы ние белән аста кысылып калган. Прораб Сәфәров безнең техник

куркынычсызлык инженерына докладной язып биргән. Антонов штраф түләде... Бораулаучының хатыны иренең акча көрәп алып кайтканын өйдә генә көтеп ятарга тиеш. Әгәр өендә көтеп торучы кешесе булмаса, ирләр бомжга—сукбайга әверелә.

—Ә бая сөйли башлаган «юл өзеге» ничегрәк булып бетте.

—Актаныштан чыгып кача торган тагын бер юл бар—Әҗәкүл пристанендә—Агыйдел аша бозлы кичү. Ык елгасы ярсып ташыганда Агыйделнең бозы бүртә генә башлый

Биштәрне кабыл-тибел тутырдым да Әҗәкүлгә ашыктым. Агыйделнең уртасы күбенгән сыер корсагы ише күпергән. Менә шартлыйм, менә ярылам дип тора. Ә ярның ике як читеннән—боз өсләтеп су ага. Нишләргә белмичә нәүмизләнеп торам шулай... Кыска кожан, чүпрәк бүрек, аучылар итеге кигән, кармак таягы тоткан берәү килеп басты. Ун сум акча бирсәң, сунын сай жирен күрсәтәм, синең кебекләрне иртәдән бирле озатып йөрим инде, ди бу. Мин әйтәм, салып бир итекләренне—егерме сум түлим дим. Юк, ди агай, теге якка чыккач итекләрне бу якка чаклы ыргыта алмыйсың, ярлары киң, ди. Алайса күтәреп чыгар дим. Юк, ди бу тагын... Син алпамшаны күтәрсәм, таеп егылам, ди, заразы...

—Әмир абый, син берүк дулкынлана күрмә, рульдә икәненне онытма. Тизлекне дә арттырдың...

—Шыңшыма, апаем, Агыйдел кичүләремне мин йокы аралаш та сөйли алам. Кызыма сөйли-сөйли ятлап бетердем инде.

—Шуннан. Боз өстеннән су ага, ә син ничек чыктың?

—Теге агай әйтә: аяк киемнәренне, чалбарыңны салып йомарлап тотасың да ялан тәпи ерып чыгасың ди. Чыккач коры киемнәренне киясең... Чуртым да салкын тими ди. Минәйтәм, яланаяк чыгар өчен сиңа акча түлисе дә юк. Тотам да тәпилим, хуш, дим. Ә ул миңа: Бәхил бул!» ди. Мин күрсәткән жирдән ерып чыга аласың, суы бот төбеннән артмас, ә теләсә-кайса жирдән йөзеп чыксаң батасың ди.

—Акча бирдеңме?!

—Ун сумны, рәхмәт тә әйтмичә кесәсенә алып салды. Бер урынга килеп кармак таягын суга тыга бу—су тездән генә. Бил тиңентен чишенеп, ялан тәпи килеш кереп киттем. Ә агай кармак таягын төртеп: «Уңгарак! Сулгарак! Туры бар!» дип кычкырып тора... Ялан тәпи килеш бозга басканың бармы синең?

—Шәледәге иске өебез кышларын таң атканчы кар бозы кебек суына торганые...

—Күкәй баш, әйтмәсәм дә булмады. Бот төбеннән карлы су ага, ә төбендә майлы боз! Илле метрлап шулай чыктым. Ярга үрмәләп менүгә коры киемнәремне кидем дә йөгерәм Янжегет авылына. Жылыныр өчен йөгерәм, тиз барыр өчен түгел. Карлы боламыкны изеп унсигез чакрым үткәч, Иске Янжегет пожарныена килеп егылдым. Бер чүмеч су эчкәнемне хәтерлим. Төне буе пожаркадагы симез кандалалар талап чыккан үземне, аны да сизмәгәнмен. Иртән Нефтекамга утырып киттем. Аннан Янавыл станциясеннән Казанга поезд йөреп тора.

—Әгәр салкын тидереп гомерлек чир алсагыз... Мин булсам, самолетлар оча башлаганчы вагон саклап ятар идем.

—Син сакларсың. Ә менә мин кызымны, хатынымны сагынгач, түзалмадым. Бозлы сулар кичеп, бусагама кайтып егылдым. Ә Суфия жиңгәң өйдә юк иде. Ул кичне кунарга да кайтмады, хәтта! Анасын өшкерием...

—Гаиләң янында гына эш беткәнме?!—дигән булды Фазыл, өйдә кунмаган хатын турында ишетмәмешкә сабышып...

—Сиңа рәхәт ул. Буш арба кебек шалтырап барасың әнә... Мин үземнең гаиләмне иркен яшәргә күнектердем. Аена өч йөз-дүрт йөз алсаң да житми хәзер. Алты йөз-жиде йөз кирәк! Ә бит колхоз председательләре дә ике йөз егерме сумнан ары алмый.

—Кырык ел буена әйбәт эшләгәнсең икән, Әмир абый.

—Үземә житми житүен, тик кызымны аякка бастырыр өчен кодрәтемнән килгәнен кызганмам.

—Мин дә хәерче малае дигән ярлыктан котылырга телим.

—Акчаны күп эшләрсен, апаем. Эчмисен, тартмыйсын, хатыннар янына йөрмисен әле.

—Юк! Пока юк...

—Баерсын. Ләкин тирестән чыккан корт тирескә генә кукәй сала. Хәерчелектә туган бала хәерчелектә үлә. Бала акча өстендә туарга тиеш! Бай этиләр, матур әниләр кирәк дөньяда.

—Ә минем ише ятимнәр нишләргә тиеш?

—Эшләргә. Рәтләп өйләнергә. Бала бишеген алтын-көмешкә күмәргә тиеш.

—Үзем өчен яшәмичә дәме?

—Бала өчен яшәү—үзен өчен яшәү инде ул! Мөлкәттә туган бала бер телем икмәк табу турында хыялланырга тиеш түгел. Ул укып-белем алу, төшемле эш табу, нәсел агачын ныгытуга көч түгәргә тиеш! Нәсел агачынын тамыры кайда була?

—Туган авыл туфрагында, Әмир абый.

—Юк, энекәш! Нәсел агачынын тамыры—караватта!

—Сәгать ничә икән әле?

Остаз, ун кулы белән рульне кысыбрак тотып, сул кулын янагына тидерде, ияген сыпырып алды:

—Тәк, сакал борнавыннан сизелгәнчә, сәгать инде сигез тулып килә. Тагын ике сәгатьтән Зәйгә житәбез. Теге хәсрәт көзгедән күренәме?

—Мәдиярмы?.. Күренә!

Остазга ияреп, Фазыл да битен сыпырып алды. Имән бармагынын сырты белән мыегын төзәткәләде

«Синен сәгатен сигез, ә минеке унсигез! Абзана унсигез тулды. Көн аралаш сакал кырам. Мыекка тимим, анысы никтер бик акрын үсә. Кулга акча кергәч, электр белән кырына торганны алам әле. Юкса бу пружиналы бритва сакалны йолкый»,—бу сүзләрне егет остазына әйтеп тормады, уйлап кына алды.

—Мин унынчыда укыганда Шәле мәктәбенә бер кеше килде. Белми калдык, әллә язучы, әллә артист, әллә режиссер инде шунда. Вәт, ул әйтә: Татарстанда бик күп атамаларнын үз исеме бар, ди. Сорочие Горыны—Саескан тавы ди ул. Зеленодольск шәһәрен Яшел Үзән ди Кама—Чулман исә —Вятка—Нократ икән. Дербышки поселыгы—Дәрвишләр бистәсе икән... Аны тынласан...

—Казан автовокзалына кергәч: «Саескан тавына чаклы бер билет бирегез әле», —дип сорап кара... Үрәткән язучыгызны бик тиз таптырырлар...

Юллар, юллар... Алып китүчесе дә, кайтарып куючысы да шушы ук юллар. Тармакланып жиргә уелган—буш жиргә түгел, кешеләр күбрәк яши торган жиргә. Юлда йөрү—яшәүнен бер формасы. Йөрелмәгән юлнын кадере юк! Бер юлны икенчесе кисә; кечесен олы юл каплап үтә; пычрак юллар көзге артыдай чем-кара асфальтка килеп кушыла; чуерташлы күтәртелгәннәре кинәт өзелеп, икмәк басуы читенә алып чыга... Юлны юл алыштыра... Бөтенесе дә мөһим, бөтенесе дә хәрәкәтле. Максатка илтүчесен генә олы юл диярләр, хәтта ул сукмак кына булса да, кемдер аны олы юл дип зурлап әйтер. Чөнки һәркемнен дә үз максаты үзенә якын. Коры юл, су юлы, чуен юл... Теләсә кайсын сайла. Аягын тартса, дөнья күрәсен килсә, юлга чык.

Чит жирләргә алып китүче юлларны яратмый Фазыл. Ерак юлга чыгарга риза ул үзе—тик Татарстаныбызда гына булсын. Үзебезнен юлларда сагыш юк, сагыну газаплары интектерми. Туган авылын искә төшсә, сөйгән ярларын чакырса, жәяүләп китәргә, Чулман белән Иделне каек белән кичәргә; Мишә, Ык, Шушма, Үшнә, Сөлчә, Зөя кебек елгаларын колачлап йөзәргә була. Ә чит жирләрдә ерак араларны кичүе ай-һай авыр...

Чаллы яныннан үтешли Әмир Кама ягына ымлады: күргәнең юктыр әле, янәсе.

Фазыл Татарстан җирендә Казаннан гайре тагын бер зур кала булырга тиеш дип күз алдына да китерә алмый иде әле... Ә анда—яр читендә—цемент белән комнан өелгән ак шәһәр калкып килә. Җәйге челләдә ул ерактан тузанланып, кояш нурын кире чәчеп балкып тора. Түбәләре ябыласы йортларның стеналары киртләч-киртләч бетон блоклы. Шул йортлар арасында калкыган йөк краннары чытырман кебек куе. Әйтерсең лә төн чыкканчы әкияти кала салынырга тиеш—бөтен илнең төзүчеләре шунда җыелган.

—Заводы төзелеп бетмәсә дә, машинасының исеме билгеле инде. Килер бер көн—безнең бораулау агрегатларын «МАЗ»ларга түгел, «КамАЗ»ларга төяп чыгарырлар, иншалла!—Әмир бу сүзләрне бер горурлык хисе белән әйтте, гүя яңа шәһәрне коруда аның да өлеше бар!—Кама аркылы күпер салачаклар—ГЭС өстеннән. Аннан соң Актаныштан Казанга кайтуы 200 чакрымга якынаячак. Ну мин Актанышка бүтән бармыйм.

—Ә мин кире китәр идем.

—Ну и җүләр! Актанышның җир катламнары катлаулы, анда безнең эше кое казучыларга акча эшләве авырга төшә. Менә, ичмасам, Чаллыда эшләп карадылар безнең егетләр. Шәһәр салынасы җиргә типовой проект белән, бригада саен унышар скважинаны ай ярым эчендә актарып ташлаганнар. Ә син Актанышым, дисең... Пенсиягә чыгар алдыннан кайбер районнарны маршруттан бөтенләй сызып ташласам да ярый.

—Акча дип кенә гомер үткәреп булмый торгандыр ул, Әмир абый!

—Әллә Мәдияр кебек син дә дөньяның беренче чибәрен эзләп йөрисеңме? Безнең эшкә акча эшләп, аякка басып, йорт-җирне күтәреп, бала-чагаларны туендырып, мул яшәр өчен генә киләләр. Юкса, айлар буе гаилә җылысы күрмичә, егерме биш градуслы суыкларда кызыл балчыкка каткан сырган чалбар киеп, солярка корымында кул җылытып, яңгыр асларында ачлы-туклы килеш сигез сәгать урынына уналтышар-егермешәр сәгать эшләргә кем риза булсын?! Менә кызны үзем сайлаган кешегә кияүгә бирәм, министрларча туй ясыйм, фатир бүләк итәм—яшәсеннәр! Аннан соң хатын белән икәүләп, пенсиядә түшәмгә төкереп, минераль суларда коенып, зәм-зәм сулары эчеп, гөлләребезгә чишмә сулары сибеп... Кырык ел буе югалтканнарны кайтарып, аллам боерса, яшәп күрсәтермен... Ә-ә?! Малай актыгы! Ник дәшмисең?

—Дәшсәм, үпкәләрсең шул...

—Тагын Актаныш, дисең инде... Сиңа анда кайтыр өчен ике генә юл бар: беренчесе—иртәгә үк безнең урынга җибәреләсе бригадага—белеп тор, башка бригадага ияреп китәсең. Икенчесе—көз көне Ростов янындагы Батайск шәһәренә барып, бораулау остасы дигән диплом апкайтып, үзеңә яңа бригада туплыйсың, туп-туры Актанышка юнәләсең. Башка чараң юк.

Зәй ашханәсендә җебегән кәтлит белән иске бәрәңге боламыгы сыпыртып, Акташта машиналарга бензин-солярка өстәп, Бута авылының шарлавыклы чишмәсеннән сулар эчкәч, Әлмәт, Чистай, Алексеевск районнарының юл өстендә аунап яткан авылларын үтеп, тавыкларын өркетеп, сарыкларын куып, сыерларына кычкыртып, кызларын үртәп бара торгач, ниһаять, Чулман елгасының иң киң җиренә—«Саескан тавы» кичүенә килеп җителгән.

Икенче ярның причалына килеп төртелгәч, тимер трапны төшерделәр. Бораулаучылар кәрваны чыгып киткәч, паром җиңеләеп, сикереп куйды. Инде яр буеннан үр менгәч, туры Казан юлы... Руль Фазылга күчте...

Әмир, кабина эчендәге сәндерәгә менеп ятса да, күзен юри генә йомып, руль артындагы яшь егетне сынап барды. Ышаныргамы моңа, юкмы? Ышану дигән сүз бу урында сер саклый белүне аңлатмый. Остаз сүзеннән чыкмыйча, күбрәк эшләгән абыйсын узышмыйча эшли алырмы

бу? Әмир өчен анын алтын куллы булуы да, баскан урында жир асты үзгәрешләрен тоя белүе дә, бораулау барышында яна ысуллар кулланырга маташуы да мөһим түгел. Киракса, остаз ул нәрсәләрне үзе бик шәп башкарыр. Гади бораулаучы остаз янында гел гади булып калырга, әйткәнне жиренә житкереп үти беләргә генә тиеш. Тынлаучан эшче —остазның жан тынычлыгы. «Үзем, үзем!»«Мин, мин!» «Беләм, беләм!» дигән бик күп егетләр килде инде бу бригадага. Әнә, Сибгатуллин—Агыйделдән буровойга су ташыган чакта Актаныш аэропорты начальнигы Лимарның илле тәнкә акчасына кызыгып, Әҗәкүл пристаненә бер рейс авиабензин илтеп килгән. Өч кенә чакрым ара, ярты сәгать эчендә Әмир сизми дә кала, янәсе... Ә бит су ташый торган мичкәгә бензин салгач, шул су белән жир куенына керәсе! Артезиан чишмәннән гомер буе бензин тәме киләчәк иде. Бораулауны туктатып, ике көн буе дүрт кубометрлы мичкәнен эчен хлорка белән юдылар... Ул су ташучы «ГАЗ»ик белән күргәннәреме?! Елгадан су суыртам дип буш килеш ком өстенә килеп туктыйлар, су төялгәч урыннан кузгала алмыйча баткакка чумалар... Машинаны сүтеп чыгарган чаклар да булды. Ә Коновалов дигәне, машинадагы суны тиз бушатырга өйрәтәм, дип, мичкәдәге суны помпа белән суыртып ике минутта эш бетермәкче булды. Ә мичкәнен өске төннеген ачмаган, су чыксын өчен һава кереп торырга тиеш бит әле... «Эһ!» дигәнче машина мичкәсенен корсагы эчкә батып керде—тыны чыккан көпчәк шикелле сытылды, таудан тәгәрәгән кебек янчелде... Машина мичкәсе бер янчелсә, тиз генә игә китерәм димә! Югары басым белән су тутырып, көчкә кабарттылар... Ә Владимиров дигәне гомер буе бораулаучы булып эшләгән кеше! Елгала озаклагач, әллә батты микән, дип, машинаны эзләп киткән иде Әмир. Владимиров иртәдән үк—«ләх!» Әмир ана: бернәрсәгә дә кагылма, без килеп житкәнче тик кенә карап тор, дип, кат-кат тукыды! Ә Владимиров нишли? Болар бик озаклады, миннән качып эчеп йөриләр, ахрысы, дип, су буенда чиләнеп яткан егетләрне югалтып, эзләргә чыгып китмәкче була. Җәяү түгел... Бораулап торган агрегаты ние белән «МАЗ»га утыра да китә... Уналты метрлы вышка жир астындагы бораулау торбаларын сындырып гөрселдәп ава... Владимиров үзе ауган машина кабинасыннан да чыга алмыйча йокыга китә. Эчүеннән дәвалар өчен бүлнискә салып коткардылар аннары... Югыйсә, гомер буе түлисе зыян иде... Әгәр Каенлыкта Мәдиярның «үзем-үземе» аркасында хәвеф килеп чыккан булса... Юк, кем ничектер, әмма Әмир сүз тынлаучан, таныш нәрсәне дә сорап, белгәнен дә кинәшеп эшли торган егетләргә ныграк таяна. Фазыл әнә шундыйга охшаган. Авылдан авылга күчкән чакта уналты метр озынлыктагы вышканы жилкәсенә салган «МАЗ»ны Мәдияр сорап ала торган иде... «МАЗ»нын рулен үз кулына алгач ул, такыр юлны әйләнеп үтеп, жыелып торган су тулы чокырларны туздырыр, кызлар күрсә туктап сәгать сораган булыр, Ә инде олы юлда ГАИ машинасы күрсә, иске танышларын сәламләгәндәй кычкыртып үтә торган иде. Мәдиярның андый кыйланышларын яшь эшчеләргә хас һавалыкка юрап, бала-чага холкынын соңгы чагылышлары дип, түзде Әмир. Ләкин инде биш ел гомер үтте. Тик Мәдиярның алтыдагы холкы һаман үзгәрми.

Әнә Фазыл «МАЗ»ны үзенә гашыйк иттерергә теләгәндәй, бөтен ихтыярын жигеп, сакланып һәм сокланып, гайрәтле машинанын жанын тоеп бара. Каршы яктан килгән транспортны «без спецмашина!» дип, юлдан кысрыкламый, уникe тонналы әзмәвер өчен мондый чокырлар пүчтәк кенә ул дип очынмый.

Әмир кабина эчендәге нәни көзгедән Фазылны күзәтеп бара. Егет аны-моны сизми, бөтен игътибары—Казан юлында. Юлдагы үзгәрешләргә хирысланып чыраен бозмый. Руль тыныч торган мәлләрдә болай да төзек кара чәчен уң кулы белән тарап куйгандай итә. Остаз беренче көннәрдә бу гадәтен сизмәгән иде әле анын. Калын кара мыегы иягенә куләгә төшереп тора. Кара каш, коңгырт күз—болай чыраенда ачуны китереп торырдай берни дә юк. «Минем Язиләмә ошап та куяр әле бу»,

—дип, үзенә генә мәгълүм яшерен уйларын уйлаган жиреннән Әмир машина сәндерәсендә йокыга китте.

## Ирең кайчан кайта?

Астрологлар фани дөньяда яшәүче бар халыкны инкубатор чебешләре ише санап, унике йолдыз астына бүләргә тырышалар. Унике төрле язмыш вәгъдә итеlә, унике ассортиментлы бәхет, унике канатлы өмет һәм унике төрле яңалык! Йолдызнамәгә ни язсалар да, бары тик унике халыкка гына бүленергә тиеш. Җир йөзендә чама белән өч миллиард алты йөз мең кеше яши дип исәпләсәк, шуны унике йолдызлыкка бүләсе бар. Төгәлрәк исәпләп торырга вакыт юк, саннарны махсус түгәрәклик... Шулай итеп, астрологлар капусындагы йолдызнамәнең һәр йолдызына өч йөз миллион кеше туры килә. Ә бу инде үзегез беләсез—уртак бәхетле, уртак өметле һәм бертөрле язмышлы өч йөз миллион кеше дигән сүз!..

Татарстанның Мелиорация һәм су эшләре министрлыгына буйсына торган «Ак Чишмә»дә йөз егерме бораулаучы—ягъни кое казучы бар. Һәм менә аларның туган йолдызлыкларын онытып, барысын бер исемлеккә теркәп, бөтенесен бер йолдыз астына тезәргә була—әйтик, «Сукояр»га! Ник дигәндә, шушы йөз егерме кешенең язмышында бик күп нәрсә охшаш. Аларга зимагурлык хас, өйләренә кайтсалар да, бер атнадан ук йөргән юлларын, күргән нужаларын сагына башлыйлар. Ашау-эчүгә нәзберек түгелләр: кашыкка ни эләксә—шул ризык, баш астына ни эләксә—шул мендәр... Бөтенесе дә авыл егетләре. Бөтенесенең гадәтләре, кимчелекләре һәм хәтта профессиональ чирләренә кадәр бертөрле... Алар һәммәсе дә авыл кызларына өйләнерләр... Көнләшмәсләр... Көнләшә торганнары өйләнгәч бораулау эшләрен ташлап, сигез сәгатьле режимга күчеп, утрак тормышка чумар. Һәм алар урынына башка егетләр килер, чөнки әлеге сан йөз егермедән кимемәс, чөнки акча күп төшә торган урын буш тормас. Әгәр син бораулаучы икән—гомергә бораулаучы! Эштән ике генә сәбәп белән китә аласың: йә —хәвеф белән, йә—пенсиягә чыгып! Башка сәбәпләр белән китә башласаң, сине хатының шундук кире күндерә. Йә үгетләп, йә китәм, дип куркытып, алай да ярдәме тимәсә, ярсый-ярсый елап... Бораулаучы хатыннарын гаеп итәргә ашыкмагыз. Гомер буе вахта ысулында яшәгән хатыннарның мона тулы хакы бар!

Әмирнең хатыны Суфияны гына алыйк... Бәхетлеме ул, бәхетсезме? Ир хатынымы ул, толмы? Авыл кызымы ул, шәһәр кешесеме?! Елга ничә тапкыр күрешә ул Әмир белән? Кайчан кайта Суфиянын ире—бүген төн уртасындамы, иртәгә таң алдыннанмы, әллә берсекөнгә кичме? Моны Әмир үзе дә әйтә алмый. Кайтса, кайчан китәсен белми. Әгәр Суфиясы: «Кайчан китәсез?» дип сораса, Әмир һич үпкәләмәс: «Туйдың мәллә миннән?» дип куяр һәм аклану йөзеннән: «Станциягә сигезле торбалар кайтырга тиеш. Цемент төяп җибәрәсе бар. Погружной насослар беткән», дип, сөйләнеп йөрер дә көтмәгәндә генә китеп тә барыр. Суфиянын хәлен аңлар өчен сез Әмирнең айлар буе юл биштәренә җыелган киемнәрен юып карагыз! Солидол, мазут, солярка корымы кебек тапларны кер юу порошогы белән бетерергә була... Ә менә син җир астыннан, җәһәннәмнән чыккан кызыл балчыклы «хы-бы» куртка белән сырган чалбарны юып кара... Айлар буе мунча күрмичә кайткан иреннең куна тактасы хәтлек аркасын ышкыр өчен генә дә Суфия чыдамлыгы кирәк.

## Алпавыт җене

Бер эштә эшләүчеләрнең, гадәттә, профессиональ язмышлары уртак булыр...

«Ак чишмә» бораулаучылрынын язмышында бердәнбер аермалы

як—ул аларның балачагы һәм авылдан чыгып киткәнче кичергән яшь гомерләре. Балачак белән үсмерчак —һәр егетнең шәхси хәзинәсе.

Кешенен эчке табигате шулайрак корылган—жирдә күбрәк яшәгән саен ул үзенен үткәнен ныграк сагына башлый. Туксан яшьлек бабайлар бәлки үзләренең ир уртасы чагын «яшьлегем» дип сагына торганнардыр. Әмирнен әле балалык елларын сагыныр чагы. Олыгаю—сагынырга өйрәтә. Гомер юлынын шартлы рәвештә билгеләнгән урталыгы үтелгәч, кешене ялгыз минутларында сагыш сагалый башлый. Искә төшерденме—үткәннәрнең төсләре жетеләнә, кешеләре әулияга, ә әйткән сүзләре изге догага әйләнә.

Әмирнен әтисе Сабиржан—Колай алпавытына хезмәт итте. Күп вакытларда алпавыт Сабиржаннын хатынына да эш таба. Андый көннәрдә Әмир салынган кабык арбаны утардагы атлар кимереп бетергән баганага бәйләп куялар да онытталар. Әле ярый, кабык арбанын авызын марля белән бәйләп куярга онытмыйлар, юкса чебен-черки Әмирнен кызарып торган бит алмасын бик ярата.

Әмир шул кабык арбада үсте. Үсә торгач, марлянын бер кырыен ачып, жиргә төшә торган иде. Чирәм өстендә тәгәрәп йөргән чебиләр белән куышып аргач, көпчәк чәкүшкәләрен баскыч итеп, тагын кабык арбага менеп ята. Менеп ята, ләкин йокыга китми—алпавытнын житен чәчле нәни кызы шешәгә тутырып баллы сөт китергәнне көтеп ята. Әмир чүлли шешәне ике куллап йолкып алгач, житен чәчле кыз марля эченә тирәнрәк тыгылып, малай астындагы чүпрәкләрне тикшерә. Көне буе кабык арбада яткан баланын чүпрәк юешләмәвен һич аңлый алмый кызый. Әгәр ул малайнын арбадан төшеп чебиләр өстенә чәптер иткәнен үз күзләре белән күрсә, бәлки баллы сөт китерүдән гайрәте чигәр иде...

Яз житүгә Сабиржан Колай алпавытынын баш крәстияненә әверелә. Жирнен төп табышы Алафузов фабрикасы өчен үстерелгән житен сүсеннән керә. Язгы кар каралып, көзге яфраклар жиргә ятканчы Әмирнен әтисе иң кирәкле кеше. Алпавыт аны управляющий дәрәжәсендә тота, ләкин үзенә әйтеп үсендерми, кирәкле надан үзеннән биегрәк сикерер дип курка...

Сабиржаннын сүзе—сүз. Ул Алафузов заказын үти алырдай бу жирләрне үзе өлгертә. Баштагы мәлдә Колай алпуты Сабиржаннын һәр кылганын күзәтү астына алып, биргән кинәшләренә байны бөлдерер өчен наруш уйлап чыгара дип кенә уйлый иде. Көннәрдән бер көнне Сабиржан алпутнын чәчләрен үрә торгызды.

—Бер болыннан берьюлы дүрт-биш төрле жан иясе туена ала. Әйтик, кеше анын уксын—кузгалагын, жиләген жыя; казлар чирәмен йолкый; кәжә-сарык яфраклы үләннәрне чемченер; шунда атлар куып кертсән—сарутларын кыркыр... Безнең кырларда атлар гына утлап йөри сыман. Жиләкләре ел саен жыелмый кала шикелле.

—Боларын мин дә беләм,—диде алпут, сабырсызланып,—бала-чага вәгазен сөйләмә, ни әйтергә телисен?

—Кешенекенә каз тими, кәжәнекенә ат кагылмый икән, димәк, ел саен житен утыртып, без жирнең гел бер төрле ашын алабыз дигән сүз. Әгәр житеннән соң ул кырга бәрәнге утыртып карасак?..

—Син мине Алафузов белән талаштырасың киләме?! Мин ана житен сүсе урынына бәрәнге сабагы китеримме?

—Кырның яртысына житен, яртысына бәрәнге чәчик. Шулай итеп бәрәнге жире житеннән, ә житен жире бәрәнгедән ял итәр. Ашы жыела торыр.

—Ярты-порты унышка риза түгел мин.

—Корылык елларда түзәсен ич.

—Корылык ил белән килә... Тәк торганда житенне киметсәм, Алафузов килешүне өзәр. Аннан соң синен бу әкиятен кәжә-сарык-сыерлар өчен генә тансык.

— Әйдә, бәхәстән!

—Ниен белән бәхәсләшмәкче син, ахмак, бетен беләнме? Җирне бозсаң, аның бер дисәтинәсе генә дә 12 пот житен бирә. Ә син үзен бөтен гаиләң белән бер пот житен бәясенә тормыйсың!

—Әйтүем дөрес булсын, сүземә колак саласыңмы-юкмы, анысы, бай абзый, синең эш.

Алпут ярлы-ябага Сабирҗанга җикеренмәде, кизәнмәде, байларча көлмсерәп китеп барды. Ләкин бер кавым киткәч, арбадагы Әмир ишетелерлек итеп әйтеп салды:

—Үзең теләгән урыннан ике дисәтинә җир бүлеп ал, сынап кара! Ике ел... юк, өч ел вакыт бирәм!

Бүленгән җир май башында ук кардан арынды. Сабирҗан тубал күтәреп чәчүгә чыкканда туфракка яланаяк басарлык түгел иде әле. Колай мужиклары шаркылдап көлеп калды... Алпут түзмәде, Сабирҗанга аркылы төште.

—Карлы суга чәчеп симәнәне әрәм итәсең киләме?! Зыян арттырып йөрисең шунда...

—Өч ел дисеңме?! Инде сүзеңдә тор! Бер тубал орлыктан гына бәлмәссең әле.

Иртә чәчүнең файдасы шул булды—яңгырларга саран июнь ае житкәндә, Сабирҗан чәчкән житен буйга көрәеп үсеп өлгергән иде. Ә буйга житкәч, тамырга күләгә төшә—үсемлекне кояш уты өтә алмый. Башка кырлардагы житеннәр тишелеп чыгуга рәхимсез кояш кулына калып, дымга сусап кәрләләнделәр, тармакландылар. Үзе иккән кеше генә белә—яхшы сүс чыксын дисәң—житенне мөмкин кадәр озынрак итеп үстерергә кирәк, тармакландымы—юньле уңыш көтмә...

Икенче елны Сабирҗан кишәрлекләрне алыштырып чәчте. Һәм бәрәңгедән бушаган урында дисәтинәсеннән 15 пот житен үстерә алды.

Ә өченче елны... уракка төшкәнне дә көтеп тормады алпут—Сабирҗанның аркасыннан сөйде—икеләтә уңыш чыгачагы күзгә күренеп тора ласа!

Ниһаять, Колай алпуты Сабирҗан карамагына үзенең бөтен кырларын тапшырды. Баш крәстияннең үзенә эш тими, авыр күтәртмиләр, җәяү йөртмиләр аны, фәлән итегез дә төгәл эшләгез дип, башкаларга кушып кына йөри. Биш-алты ел эчендә алпут басуында эшләргә кеше кулы житми башлады. Моны ишетеп Шәехзада, Дүртиле, Тугаш мужиклары Колайга килеп көнлеккә ялланды. Әмир бәби арбасын бәләкәй «уфалла»га алыштырып, житен көлтәсе ташырлык малай булып үсте. Кул арбасына төялгән житен өстенә житен чәчле алпут кызы утырып кайта—ул күзләрен тутырып ачса—житен көлтәләре чәчәк аткандай була иде...

Кеше гомере әнә шулай вакыйгаларга, хатирәләргә, сагындыргыч көннәргә бүленгән һәм аларны кояш баешлары, тулган айлар, күкеле сәгатьләр, манара азаннары, ком сәгатьләре санап тора...

Октябрь инкыйлабыннан соң, кара кучерлар Колай алпавытын, кыңгыраулы тарантасларына төяп, гаиләсе белән алып киттеләр. Киндер җирләрен Дүртөйле, Тугаш, Шәехзада мужиклары үзара бүлеште. Алпут жене кагылган дип, допросларга чакыртып, Сабирҗанның теңкәсенә тиделәр.

Әмир үсте. Балачагын үсмерчак куалады. Үсмерчакны яшьлек кысрыклады... Ир уртасы булдым, дип, сөенә-сөенә яшәп ятканда тагын нидер ашыктыра аны... Чишмәләр арасында бүленеп калган гомер, ком сәгате кебек кирегә агып, үзенә дәшә: «Әйдә, Әмир, чираттагы дүрт атналык ялыңны ал да монарчы үткән юлларыңнан тагын бер кат йөреп чык. Ни хәлләрдә яталар икән син казыган электр чишмәләре?»

Ләкин Суфия ханымның үгете кырыс.

—Чукынып йөрмә, эшлисе—эшләнгән, акчасы алынган. Сөйгән кызларың күптән әби инде анда... Житен чәчле кызлар, шомырт күзле егетләр татлы йокыдан калган төш кенә ул...

Төш—уйларның дәвамы... Уйлану—үсүнең бер халәте. Уйлар физик

эшкә караганда да тизрәк картайта.

Әкрен үсә, тиз картая кеше...

## Әх-әх! Ой-ой-ой!

Әмир Суфияны Алабуга районыннан алып кайтты.

Ул елның җәендә Әмир Әшрапов бригадасына бер тирәдә дүрт кое борауларга дип, яна маршрут билгеләделәр. Элеккеге Бондюг төбәген үзенә йоткан Алабуганың дүрт авылын картадан эзләп тапкач, Әмир егетләргә зур өметләр өстәп:

—Маршрут—во!—дип куйды.

Костенеево авылы Нократ белән Чулман кушылган култыкка—яшь калкулык өстенә салынган. Су чыгару өчен йөз егерме метр калынлыктагы ташлы катламны, бер атна буе, һәм көне-төне, агрегатны туктатмыйча борауларга туры килде. Егетләр чиратлашып йоклады, чиратлашып ашады. Эшләгәндә дә берсен-берсе алыштырып, әле мастер, әле су ташучы, әле дизелист вазифасын үтәделәр. Ниһаять, сигезенче көнне су фонтаны бәреп чыкты.

Бехтерово белән Тугыжа авылында әллә ни нужа күрмичә, Туен елгасы бассейнының җир астындагы йомшак суын, эре ком арасыннан сөзеп алгач, Удмуртия чигендә яткан Ижевка авылына күчтеләр.

Менә шунда гына Әмирнең төп хәйләсен анлап алды инде егетләр. Иң әүвәл олы юлдан ераграк яткан авылларның эшен бетереп, соңыннан олы юлга якын авылдан Казанга кайтып китәргә җайлырак булыр дип, кат-кат искәртергә ярата торган остаз, ник соң әле Алабуга районына кергәч кенә үзенең ияләнгән гадәти ысулын үзгәртте дисән—ул Ижевка авылын үзең барып күрергә кирәк икән! Текә яр өстендәге авылның теләсә кайсы тәрәзәсеннән карасан да, дулкыннары тыпырдап торган иксез-чиксез су! Инеш буенда үскән Шәле малайлары Каманың шушы буынын күрсә—океан дияр! Инде саллырак елга буенда тән ныгыткан егетләр дингезгә тиңләр! Кояш астында Чулман су көрән җәймәгә чәчелгән энҗе бөртекләре сыман... Күрше казлары чаклы акчарлаклар шул энҗеләрне тузгыткан көмеш балык чүпли. Су ягыннан агылып торган тыгыз дымсу һава кысан үпкәләргә шыплап тула. Бу авылга кунакка кайткан һәр кеше аз сүзлегә әйләнеп, кыска-кыска сүзләр белән , хәтта ымлыклар белән генә сөйләшәләр. Аһ, бу һава! Абау—суның чисталыгы! И-и—алмагачлары! О-о, оҗмах! Ай-вай! Ах-ух! Әх-әх! Ой-ой-ой!.. Шуңа күрә дә Ижевкага ике-өч көнгә килгән кунак, ашыктырып торган мәшәкатьләрен онытып, бер-ике атнасыз китә алмас. Ун көн эчендә колхозның бөтен теше коелган тырмаларына теш куеп, ферма түбәләренең калаен алыштырып, су чаннарының эченә кургаш йөгертеп өлгерәбез дигән чегәннәрнең чатыры ике ай буе шинми... Кыр эшләренә ярдәмгә дип җибәрелгән студентлар уныш бәйрәмен үткәрмичә кайтып китә белмәс. Ахыр чиктә Казанның югары уку йортлары Алабуга районы белән тозелеш отряды студентлары төзегән килешүдән бөтенләйгә баш тартыр. Икмәк ташырга дип килгән күчмә колонна шоферлары сонарып кайтканнары өчен ел саен язма рәвештә шелтә алырлар.

Менә шуңа күрә Ижевка авылының печәннәре дә соңрак чабылыр, игеннәре соңрак урылыр, бәрәңгеләре карлы янгырда җыелыр. Туып-үсеп торган һәр кызы, буйга җиткәнче үк, авылга килгән командировочный зимагурларга ияреп китеп барыр. Ә инде авылдан бер киттеме—кызлар кире кайтмый. Кызларын югалткан авыл егетләреннән дә ятим кала. Һәм колхоз эшенә ярарлык җирле халык югала бара. Бөтен эш завод-фабрикалардан күчмә колонналар белән куып китерелгән вакытлы ялчылар кулына күчә.

Әмир тәгаен генә әйтә дә алмый инде, ул чагында бригадада

кемнәр эшли иде соң әле?.. Бармаксыз Зәбирме, әллә Елгыр Юрамы, жил очырмаса ярар иде, дип, тотыныбрак йөри торган чандыр Ипполитовмы, әллә Аю Гамилме?.. Юк, аларын хәтерләми Әмир... Бик күптән булган хәл инде бу. Ул чагында аккан елга сулары, кире әйләнеп кайтып, кыргый чишмәгә әверелгәндер... Жыр булып шаулаган яшь наратлар иннәренә чыбык күтәреп, олы юл читләренә багана булып тезелешкәндер. Ул чагында очып килгән сайрар кошларның оялары югалып, баладан туган балалары картаешып, сайраудан мәңгегә тукталгандыр.

Фазыл ул чакта, Шәленең тимурчылар командасына ияреп, мәктәп ишегалдына көл ташыгандыр, тимер-томыр сөйрәгәндер, кош тизәге белән тотылган кәгазь жыеп йөрмәгәндер дип тә әйтеп булмый. Кыскасы, сүз Әмирнең элеккеге бригадасы хакында бара.

## Гырламасаң, рәхим ит...

Алабуга председательләренең һәр гектардан унжиде центнерлы югары уңыш алу турында партия кушканча хыялланып йөргән чаклары... Ижевка авылына Казанның Моторлар төзү заводыннан зур төркем өстәмә көч килеп төште. Килгән эшчеләрне фатирга урнаштыру өчен колхоз рәисе аш пешереп ашата алырдай һәм ким дигәндә ике-өч карават куярдай өе булган һәр авылдашны контор янына чакыртты. Әмирнең өч башлы бораулау кәрваны килеп төшкәндә контор янында эшче базары башланган иде инде. Начальство әмеренә буйсынырга күнеккән авыл халкы чынлап та күп жыелган, ләкин Казан зимагурларын алып китәргә ашыкмыйлар, бик жентекләп өйрәнәләр... Узган елгысы кебек әлкәш түгел микән, күзләре бик мут—хатын-кыз белән шаяра торганы түгелме, араларында тәмәке пыскытмый торганнары юкмы, хужалыкта булышырга эш рәтен белүчесе булмасмы? Кыскасы, чын сайлау бара. Капка төбендәге чирәмлекне машиналары таптап бетерер дип, шоферларны бөтенләй алып кайтырга теләмәүчеләр дә күп иде.

Председатель бораулаучыларга пошаманга төшәргә ирек бирмәде. Әмиргә карап әйтте:

—Ахыр чиктә мин сезнең өчегезне үз өемә алып кайтам. Бер тапкыр да ягылмаган, өр-яңа буралы мунча салдым, менә дигән итеп яшәрсез! Ашау иркен... Су кирәк түлке. Яр чишмәсенең суы каты—самавыр борыннары тыгылып бетте—юшкыны күп утыра. Мин бит инде су скважинасы сорап сезнең трестка әллә кайчан заказ биргән идем. Проекты да ике елдан бирле әзер. Әзрәк килешеп-кинәшеп эш итсәгез, мин сезне сабан туе чорынарак чакыра идем. Менә бу мәхшәрне күрми идегез.

—Заказлар күп шул. Бөтен кеше су сорый, халыкның корылык еллардан коты алынган... Аптырамагыз, берәр әбинең буш почмагы табылыр әле. Председатель фатирына урнашу ул бораулаучылар арасында бик макталмый...

—Нәрсәсе бар инде аның?! Миңа калса, киресенчә! Председатель өендә кунак булу—обком инструкторларына гына тәти торган бәхет. Колхозны семинарларга әзерләгәндә атналар буе яталар...

Кое казучыларны үгетләүнең файдасы юк. Колхоз житәкчесенең өендә яту ул көнче күрше белән яшәү кебегрәк—көрешкән саен: «Бүген ничә метр борауладыгыз? Күпме торба китте? Суы бетмәс микән? Насосы капремонттан чыккан нәрсә түгелме? Торба артларына тоташтан бетон төйдегезме? Тишекле торбагызга жиз сетка урадыгызмы—насос ком суырмасмы?» дигән бихисап сорауларга жавап бирә калсаң—эшнең бөтен сере бетә—димәк акчасы кими, стимулы югала дигән сүз! Скважинаның чынбарлыктагы тирәнлеген, су эченә төшерелә торган насосның төсен һәм размерын, торба артына бетонга диелгән цементның кая киткәнен...

эш ахырында процентовкага кул куясы житәкчеләр белергә һәм күрергә тиеш түгелләр... Чөнки ул серләр һәммәсе бергә кушылып, бригада өчен өстәмә акча китерә.

Үзенне сайлап алганнарын көтеп, базар түрендә торулары жинел түгел... Әгәр авылы—башка, манзарасы—бушка булмаса, Әмир кәрванны Казан ягына куаларга да риза иде инде. Ләкин еллык отпускаларын көзге һәм язгы юл өзегендә, кышкы раштуа суыкларында гына күрә торган бораулаучылар Ижевка авылының «дингез буен» кулдан ычкындырырга теләмәделәр... Бригада шушы матурлыкта жаны теләгәнчә эшләп, күнеле булганча ял итеп, төрле хәйләләр белән вакытны сузарга тиеш. Әмир белә-белгәннән бирле бер генә бораулаучының да әле чын дингезгә барып житә алганы юк. Чын дингездә су коену ул министрлык кул астындагы трест, трестка буйсына торган идарә һәм идарәләр өстенә өелгән күпсанлы контора чиновникларына гына тәти торган ләззәт.

Ниһаять, жәеп ак яулык яба торган авыл карчыкларына үч иткәндәй, зәңгәр косынка бәйләгән, көн бөркүлегенә исе китмичә юка оек өстеннән йон оек киеп шахтер калошы сөйрәгән апаларны үртәп, ялан тәпиен чигүле ак чүәккә яшергән, беләгенә шәһәр мадамнарыныкы кебек кабарып торган ак сумка элгән, жете шәмәхә бәрхет күлмәкле бер ханым килеп басты. Ул Әмирне баштанаяк һәм ашыкмыйча гына күздән кичерде. Сугымлыкка үгез сайлагандай, егетнең әле артына, әле алдына басты, яннан карады, инбашына суккалады—болай, шапылдатып, яратып сөйгән атлы кыланып кына...

—Нәрсә, Разыя апа, урманнан агач сөйрәтергә буйвол эзлисенме әллә? —диде колхоз рәисе, Әмир өчен унайсызланып.

—Рабочиең өйләнгән нәмәрсәме?

—Юк әле, апа, буйдак мин, өйләнергә вакыт юк. Гел юлда.

—Йоклаганда гырламыйсызмы?

—Юк.

—Аягыгыз да тирләмиме?

—Юк инде, юк...

—Карасана! —дип, бәрхет ботын чәбәкләп куйды Разыя. —Бу ел да гел холостой ирләр генә килгән икән —нәкъ узган елдагыча, беренче сортлылар гына! Дөрес, узган елгы ирләрнең ун көн эчендә "буйдак" дигән ярлыклары коелып төште. Узган елгылар өч атнага гына жибәрелгән булган. Ә алар ай буе Ижевкада яттылар. Яттылар шул... өч атналары үтеп, дүртенче атнаның рәхәтен күрмәделәр —берәм—берәм хатыннары килеп төшмәсенме, минсинайтим?!

—Да, Разыя апа, синен фатирантның да хатыны бик жаһил булган дип сөйләделәр.

—Нәрсә авызыңны жырасың? Синең колхозың алга чыксын дип зыян күрүчеләр без. Абау, абау! Узган ел минем постоялый егетнең хатыны! Төн уртасында, пычак тоткан килеш, өебезгә бәреп кермәсенме! Шакылдатып- дөбердәтеп тә тормады дәжжал! Анда гына булган ир! Суфия кызымны күкрәгем белән каплап өлгермәсәм, харап итә иде... Фатирга керту берни түгел ул... Син аларны матур гына озатып кара, жанашым. Юк, юк, быелдан башлап мужикларын керттем юк!—дип такмаклады Разыя.—Минем өем чиста, Суфиям мич яныннан китми, кулыннан килмәгән эше, пешерә белмәгән ризыгы юк—үзем өйрәттем! Так шту, минем өем буйдак егетләргә генә лаек!

—Алайса, без өчебез дә сезнең лаеклы фатирантларыгыз инде, исемегезне кем дисез әле, Разыя апамы? Без хәзер, машиналарны капка төбегезгә китереп туктатырбыз. Өегезне күрсәтегез дә үзегез кайта торыгыз.

Разыяның өен төн уртасында күз бәйләп тә таба аласың... Күрше тирәләрендә хуҗасын югалткан өйләр жимерелеп, сатылып һәм сүтелеп беткәч, Разыяныкы иң кырый йорт булып калган, шуна күрәдерме, өй түрендәге яшел чирәме—маржа тарагы белән таралган кебек, машиналарны

урамның каршы ягына—куак чытырманнары гына исән калган иске нигез түренә куярга туры килде.

Тар озын бурага, үзеннән дә кинрәк веранда өстәп, бер түбә астына керткәннәр. Җилкапкасы ачылганда чирәмне тырнап кала. Куян сукмагыннан биш-алты адым атласаң, баскыч төбендәге чыптага килеп басасың. Көл белән ышкып юылган сап-сары болдыр идәннәренә килеп терәлгәч, аяк киемнәрең үзең дә сизмәстән төшеп кала.

Егетләрне ишек алдында калдырып, Әмир Разыяның өй эчен үзе күреп чыгарга теләде. Ошамаслык нәрсә күрсә, артык мескенләнеп тормыйча вагонда гына калырбыз дигән уй ташламаган иде әле аны. Ишекнең эчке ягындагы келәсен күтәрәм дип, эленеп торган киндер бауны тартмак җиреннән тынып калды Әмир. Анда Разыяның өзек-өзек тавышына рәхәт ыңгырашу катыш мышнау кушыла: «Аскарак, өскәрәк! Һой-һой! У-у! Эх-х, рәхәт! Менә шулай, менә шулай! Тагын бераз гына! Ашыкма, җыртасың! Авырттырма дим! Армадыңмы әле? Ник болай рәхәт соң бу?!.»

Әмир ишек тоткасына ябышып калды. Өйгә керсән, нәрсәгә юлыгасыңны белгән юк, тәрәзәдән күреп алсалар—качып тыңлап йөрисеңмени, хәсис, дип, ирештерерләр, сабый баланы хурлаган кебек оялтырлар... Тәвәкәлләргә—берни белмәгән-ишетмәгәнгә сабышып, килергә дә керергә!

Ишек тупсалары майга интекмәгән—тавышсыз-тынсыз гына ачылды. Разыя ике куллап мич почмагына таянып, шәмәхә бәрхет күлмәген башыннан әйләндереп каплаган. Ә бер кыз кулына кием щеткасы тотып, кишер кырган тавышлар чыгарып, Разыяның аркасын кашый. Кашынган тән кызгандыр күрәсең, өйгә өлкән яшьләрдәге кешеләргә хас тир исе катыш җир исе таралган. Шуңадырмы, юньләп хатын-кыз тәне күрмәгән килеш тә Әмирне Разыяның җилкәсе кызыктырмады, гәрчә ялан тәнендә кызыл рейтузы ут янып торса да. Киресенчә, арка кашучы кыз күз карашын җәлеп итә. Ул, Разыяга ярарга тырышып, үрелеп-үрелеп кашыганда күзгә яфрак кебек коелам-коелам дип торган сары парча халаты күтәрелеп, итәге капларга тиешле ап-ак ботлары балкып ала. «Йә хода, сабырлык бир! Хатын-кызларга көч белән ташланучы ирләр менә шушы мизгелләрнең колыдыр ул!..»

Әмир ишекне каты итеп япса да, оялудан чәрелдәп кычкыручы, яисә каушап мич артына ашыгучылар күренмәде. Разыяның бәрхет күлмәге үзе урынына сыдырылып төшкәч, Әмир көч-хәл белән телгә килде:

—Гафу итегез берүк, өстегезгә килеп кергән өчен!

—Кызым, Суфия, әллә ник май исе чыга, өчпочмаклар көеп ятмыйдыр ич?!—диде Разыя, Әмирнең гафу үтенүен әллә ишетеп, әллә ишетмичә.

Кызы почмакка кереп киткәч, Разыя тагын Әмирне баштанаяк күздән кичерде.

—Син ул ишегалдындагы малай-шалай тәкәләрнең бригадирымы сун?

—Безнең эштә бригадир дип аталмый инде ул. Мин бораулау мастеры.

—Мачтыр, дисең алайса? Җае килгәндә бораулыйм дисең инде, ә?! Авыл саендыр әле...

Чаршау артында Суфияның пырхылдап көлгәне ишетелде.

—Елга ун-унике скважина тишәбез инде,—диде Әмир, эше белән горурланырга теләп.

—Ә үзең өйләнмәгән дисең.

—Гел юлда йөргән кешегә кем чыксын?! Өйләнер өчен бит ул берберенне озаклап күрергә, танышырга, ияләшергә кирәк. Ә без авылдан—авылга күчеп тәк йөрибез, унбиш-егерме көн саен. Ияләшеп өлгермибез...

—Егерме көндә әлләниләр эшләп ташларга була ул, җан кисәгем. Әгәренки беренче көненне үк әрәмгә үткәрмәсән... Әйдә, чакыр егетләренне. Юкса, кызым мич янында көеп беткәндер...

## Алып китмәгәннәр

Өйнең бурасы озын булса да эчтән урталай бүленмәгән, миче бер башта—ишек кырыенда, ә түрдә—өстәлле як. Уртада ике як стенада кара-каршы ике караватъ, икесе дә пирамидасыман өелгән мендәрләрдән сыгылып тора.

Суфия, егетләргә кушылып, өчпочмак янына килеп утырды. аерым ашау дигән нәрсәне оныткан инде ул. Күптән оныткан... Алты елдан бирле.

Суфия сигезъеллыкны тәмамлаган җәйдә Ижевка авылына Казаннан фәнни хезмәткәрләр экспедициясе килеп, бер талантлысы Разыяларга урнашкан иде. Анысы хак, яшь галим фольклор эзләп авылда бер генә кич кунды. Ләкин ул күрше авылларда эше беткәч тә, төн саен Суфияларга кайтып куна иде. Йә җәяү кайта, йә велосипед таба, йә илтеп куялар үзен. Бер унбиш көннән соң, авыл аралары бик ерагайгач, яшь галим фатирны алыштырган—кайтудан туктады. Аның каравы Суфия, театр училищесына керәм дип, Казанга киткән җиреннән, имтиханын тапшыра алмыйча елап кайтып керде. Шул көннән соң укуын да дәвам итмәде, авылдан да китмәде. Фатирантларның юньлесе кайбер хуҗаларның кызын ияртеп киткәли ич, дия-дия Разыя һәр уныш елында эшчеләр кертә хәзер. Әле узган елны ике шофер белән Суфияның берүзен калдырып, Чиләбегә барып килде Разыя—элеккеге эш урынына. Ул анда чуен юллар янартучы ПМСта шпал кагучы булып эшләгән иде. Шул эштә бер монтажник белән никахсыз гына кавышып, ремонтчылар өчен бирелгән тимер юл вагонының бер купесында Суфия дөньяга килгәнче бергә яшәгәннәр иде. Суфияны роддомнан алып кайттылар—шул көнне үк дәдәй җан тәслим кылды. Купенең өске сәндерәсендә йоклаган җиреннән тавышсыз-тынсыз гына оеган, мәрхүм, Чиләбе туфрагы җинел булсын үзенә. Врачлар килеп: инфарктган үлгән—бик куркыныч төш күргән булса кирәк, диделәр. Һәм Разыя ярты яшьлек Суфиясен күтәреп, кыска гомерле иренең туган нигезенә—Ижевка авылына кайтып төпләнде. Нигездә аның җитмеш яшьлек әнисе генә калган иде... Ул да озак яшәмәде.

Разыя Чиләбедән кайтып керсә—бөтенесе дә искечә. Җилкапка чирәмне җыртып бетергән, ишек алдындагы сукмак кинәйгән, өйгә терәп салган такта сарайда сарык белән кәҗә сөзешә. Шоферлар уборканы төгәлләп китеп барган, ә Суфия тагын үз өендә утырып калган... алып китмәгәннәр... Кызның үсмер чагы булмады да, ахрысы, ана уналты яшеннән үк кинәт егерме алты тулды бугай...

Бер табак шулпалы өчпочмакны ялтыраткач, егетләр яңа фатирга бик тиз ияләште. Араларында безнең дә танышлар юк микән дигәндәй, ашык-пошык кына фотолар альбомын карап өлгерделәр. Верандага чыгып, моңарчы яшәгән фатирантлардан калган журналлар, туган елын югалткан газит исекләрен укыштырган булып Суфиянең урын җәйгәнен күзәттеләр. Аның буяу тимәгән сап-сары иләндә йөрүе тагын да гыйшыкландыргыч нәфесне көчәйтә иде. Сабый баланың бит алмасы кебек үкчәләре, тез астындагы итләч чокырның сумсадай кабарып торулары, парча халат итәген биеткән түгәрәк ботлары, мендәр күперткәндә гәүдәсенең бил турысыннан уйнаклавы, кочагың җитмәслек арт саны Әмирнең гакылын томалый, күзен сукырайта. Һәм ул Суфия гәүдәсенең кайсы өлешенә күз салса да, берни күрми, чөнки карашларын балкып торган ботлар каплый сыман иде...

Йокылары качкан егетләр тоташ тәрәзәле верандада Суфияга карата уянган комарлары өчен бер-берсеннән оялышып күпме утырырлар иде, белмим, шулчак әни кешенең тавышы хәлне җинеләйтте.

—Суфия, кызым, егетләргә авылны күрсәтеп кер. Санаулы көннәрен әрәм итеп ятмасыннар. Үзем дә өйдә утырмас идем әле, уборкага килгән абзыйлар арасында мина тиннәрен күрмәдем.

Урамга чыгу белән үк Суфиянын Әмирне култыклап алуын калган егетләр—ияреп йөрмәсәгез дә ярый дип аңладылар...

## Сукыр эчәгесе өстендә

Нинди озын көн иде—тотылып бетте... Офык көннең соңгы кисәген йотты. Иннеккә буялган шәфәкъ нурлары Чулман дингезенә төшеп эрегән. Шәһәрдән авылга килгән шефлар, тиз арада авыл кешесенә әверелеп, яр буена учак тергезгән. Янган ит исе катыш төтен таралган. Учак тирәсеннән качып йөргән төркемнәрдә күмәкләп көлгән ирләр арасына берән-сәрән кызлар тавышы килеп кушыла. Һәм шунысы мәгълүм, йөрәгендә җаны булган һәр кешенең игътибары бүген Чулман суы өстендә. Кыйбласын югалткан кичке җил комач кызыл дулкыннарны төргәкләп ярга китереп бәрә—вата-җимерә, исән калганнарын икенче ярга тәгәрәтә. Ул дулкыннар шавында язгы кошлар сайравын алышты-рырдай аһәң бар сыман. Әмир шушы авылда туып-үскән кешеләрдән көнләшеп куйды. Мондый матурлык эчендә яшәү бик сирәкләргә генә тәти бит ул. Каласы иде монда бөтенләйгә яшәп. Суфия да шушы авылның бер өлеше. Сокландыргыч манзара эчендә ул үзенә кызыктырып тартып тора. Әйтерсең лә ул Әмир белән кечкенәдән таныш, әйтерсең лә ул аны армиядән көтеп алган. Беркемгә иярмәгән, беркая китмәгән. Язмышның күк капусы ачылганын көтеп, акланмаган өметләрен онытып, рәнҗеткән ирләрне кичереп, рухын сындырмыйча: «Яраткан кеше кемлегемә карамас әле», дип, Әмирне көтә-көтә яши торган, ялгыша торган. Әмир: «Суфия!» дип дәшкән саен ул аңа якынрак килә. Егетнең көчле бармаклары билен кытыклаганга да түзеп, күзенә карап еш-еш елмая. Тасмасыз гына үрелгән калын чәчен җил тузгыткан саен күкрәгенә кайтарып толымын үрә.

—Суфия!

—Нәрсә бар?

—Чәчең калын синең, мамык шәл ябынган кебек.

—Өстемә әйтеп күз тидер тагын.

—Төнлә белән күз тими.

—Чәчем каты минем, шуңа күперә. Ат кылы кебек.

—Колын ялы кебек,—дип төзәтте аны Әмир.

«Колын ялы» дигәнне, шушы егерме алты яшенәчә житеп, әлегә берәүдән дә ишетмәгән мактау сүзе дип кабул итте, ахрысы, Суфия үзе дә Әмирнең биленнән кочып, башын аның иңбашына салды. Егетнең тәжрибәсезлеген сизә иде ул. Юкса Суфиянең бөтен тәне Әмир карамагында. Никтер ул башкалар төсле кулларына ирек куймый. Монарчы күргән ирләрнең ике кулының да кайда кыймылдаганын тоя иде ул: бер кулы күкрәк тирәсен кармалар, икенче кулы җилкә чокыры буйлап шуышып билдән түбән өлешне капшар.

—Суфия!

—Нәрсә бар?

—Монарчы ничек урламадылар соң сине?

—Мин сине көттем.

—Кабатла әле тагын.

—Сине көттем.—һәм Суфия, башын кыңгырайтып, иреннәрен шундый итеп бөреп куйды ки, әгәр үпмәсәң, егет дигән мактаулы исемеңә шик төшерер идең...

Ә иртән, калган өчпочмакларны табада кыздырып табынга китереп куйгач, Суфия чәйле чынаягын кичә үбелгән иреннәренә терәде дә Разыяга гына текәлеп карап:

—Чәйдән шофер исе килә, әни,—дип әйтеп куйды. Үзе шатлыгын көчкә тыеп, көлә. Аның көлүе күзләрендә, кулларының дерелдәвендә

һәм чынаяк өстендә биегән чәй дулкыннарында сизелә. Аның көлүенә ана кешенең елмаюы өстәлде.

—Берәр бензинлы нәрсә капкансыңдыр, кызым...

Егетләрнең берсе көлеп җибәрмәс өчен, тыелам дип, тончыга язды.

Бораулау агрегатын урнаштырган арада кояш инде Чулман елгасын җылыта башлаган иде. Әмирнең: «Егетләр, ашыгып эшләмәбез!» дигәне—күңлек эшне тиз-тиз генә әтмәллик тә калган вакытны су коенып, рәхәтләнеп ял итәрбез мәгънәсендә әйтелгән иде.

Кичә генә урып-җыюга дип килгән егетләрнең алтысын амбардан алып бораулаучыларга ярдәмгә җибәрделәр. Җәмгысы тугыз көрәк казынса да, сигез кубометрлы чокырны житкерүе җинел түгел. Әлбәттә, бер чокырга тугыз көрәк сыймый—сыйса да, казуы кыен. Шуңа күрә ике төркемгә бүленделәр. Берәүләр казыганда икенчеләре тәмәке тарта, икенчеләре көрәк тотканда беренчеләре бораулау агрегаты тирәли йөреп Әмиргә сораулар яудыра: «МАЗ»ның двигателе алты цилиндрлымы? Нефть чыкканчы казый аласызмы, көче житәме? Ин зур долотогыз ярты метрлы гына икән, сырлы тәгәрмәчләре бораулаганда су белән майланамы? Торба бора торган ачкычларыгыз ике пот чамасы бар, ахры?..» Кыскасы, егетләрнең техника тирәсендә кайнашканы сизелеп тора—сораулары таныш—авыл саен механизаторлар сораштырып тенкәгә тия торганнары. Урып-җыю егетләре хәйран кыюлар, вагонга кереп сәндерәгә ятып караучылар да табылды. Араларында пилмән бәбәкле егет—Фәрит атлысы—бигрәк әрсез кылана: «Ну, егетләр, бу вагонның рессорлары йомшак—кызлар белән аркылыга-торкылыга тибрәнергә була!»—дип тора. «Алып куйган яртыгыз юкмы?»—дип, тумбочка шүрлекләрен дә капшап чыкты. Әмир аларны тизрәк урамга озатып, ишекне бикләп маташканда Фәрит һаман үзенекен итте: «Бу йозакка любой ачкыч ярый!»

Чокыр казылып беткәндә кояш, кодрәтеннән килгәнчә, Чулман суын җылытып эшен бетергән, инде Казан ягындагы офыкка авышкан иде. Егетләр чокыр төбендәге көрәкләрен дә алмыйча су коенырга йөгерделәр. Әлбәттә, аларга Әмир дә иярде. Көтү кайтып Суфия кичке аш әзерләгәнче ике сәгатьләп вакыт бар әле.

Киемнәр салынган ярны онытып, су коена халык. Кыланышлары—су чәчрәтешеп, батырышып уйнаулары, тиктомалдан кычкырып көлүләре, бер-берсенә дәшеп нидер күрсәтергә, шамакайланырга тырышулары—барысы да сабыйларча, тик тавышлары гына калын, сүзләре дорфа һәм менә төшеп калам, менә төшеп калам дип торган трусиклары гына җилкән чаклы...

Шактый коенылган, ахрысы, тау башыннан парча халатын җилфердәтеп Суфия төшеп килә. Ул Әмир ошатырдай сөйкемлелеген саклап, кичәгечә гел үзгәрмәскә тырышкан.

—Әмир! Кайтыгыз, бәлеш пеште!—диде ул, унарлаган йөзүче арасыннан Әмирне танып.

Чакыруга бөтен егетләр дә судан чыкты. Яр буендагы дулкыннар юган өстәл-өстәл ташларга тезелешеп егетләр киенә. Үзләре дер-дер калтырыйлар, үзләре никтер ашыгалар. Иң алдан Фәрит киенеп өлгерде. Ашык-пошык сыгылган трусигының дымы чалбар төбеннән килеп чыкты. Ул әлләни тартыну кичермичә Суфия янына килеп басты.

—Ә безгә... бәлеш?!

—Сезгә кабыклы бәрәңге белән борчак чумары. Көтүдән аягын тайпылдырып кайткан карт сыерны суйганнар. Иртәгә ит өләшерләр үзегезгә. Ә бәлеш бораулаучыларга гына.

Фәрит әле Әмиргә, әле кызга каранып алды да:

—Син Суфиямы?—дип, җавап көтте.

—Әйе, мин Суфия!

—Точно! Әниең Разыя. Әтиең юк. Чиләбедән кайткансыз, сиңа егерме алты яшь, шулаймы?

—Шулаен шулай. Ну мин сине күргәнем юк, беләсем дә килми.

—Аның каравы мин беләм. Сукыр эчәгең өстендә ясмык хәтлек минең бармы?

Суфия халатының путасын кысыбрак куйды.

—Ә-ә! Бондюг больницасында яткан идем шул. Шунда күргәнсендер. Ну бит мин сукыр эчәгемә операция ясатмадым. Ул чагында салкын тидереп кенә авырган идем. Температурам кырык бергә җиткәч илтеп салганнар.

—Юк, юк! Суфия, барыбер беләм мин сине. Бүген кич күрешсәк, әйтеп бирәм!

—Әй, башымны катырып җөрмә әле, бар, кабыклы бәрәңгегез суынмасын... Карале,—диде ул бер читтәрәк ишетмәмешкә сабышып торган Әмир янына килеп, —носкиеңны киеп торма, хәзер чайкап бирәм, сабын алып төштем.

Егетләр таралышып, Суфия су читендә оек чайкаган арада Әмир таштан-ташка яланаяк сикереп, тау чишмәсе янына килде. Чишмәнең авызы куышланып тора, су юлын агач улак белән сузганнар, ул агып төшкән урында аякларны күзгә күренмәс йөз энә белән чәнчерлек салкын су чоңгылы хасил булган. Чоңгылдан арткан су зур гөрләвек булып Чулманга йөгерә. Һәм сөтләч Чулман шушы кәүсәр гөрләвекне сөенә-сөенә йотып бара.

Чишмә шаулавына Суфия тавышы кушылды:

—Шушы чишмәгә була авылыбызга пристань салганнар. Ял көннәрендә көне-төне чират монда, кемдә нинди савыт бар—күтәреп киләләр... Әле мин кечкенәрәк чакта еш күрә идем—Чаллы ярыннан сыерлар йөзеп чыгып, шушы чишмәне кинәнеп эчәләр дә кире йөзеп китәләр иде. Бу араларда андый сыерлар бик күренми. Хуҗалары чыгармый торгандыр, уборкага килгән әрсезләр урлап суяр дип курка торганнардыр.

—Никадәр байлык әрәм агып ята!—диде Әмир, Суфияне җөпләгәндәй.

—Үзебез дә әрәм ятабыз инде.

—Әрәмме? Әйт әле, Суфия, чынлап та сукыр эчәгең өстендә ясмык кадәрле минең бармы синең?

—Ник аны бая ук сорамадың? Бөтенесенә күрсәтә идем, бу кадәр исең китәсен белсәм әгәр... Менә кара, мә!..

Һәм Суфия, төймәләрен чишеп, халатын ачып салды, парча халатны бөтенләй алып атарга теләп җил күтәрелде. Баштарак Әмир ышанмыйча, нужәли күрсәтә инде дип кенә караган иде, соңыннан ул Суфиянең ирләр куенына сусап өлгергән ачык гәүдәсен күреп «аһ!» итте. Кинәт Чулман өстендәге бер мут дулкын Әмирнең җанына үтеп кердеме—гәүдәне дер селкетеп эчтән бәргәләнде, күкрәк читлеген какты, сулыш юлларын тузгытты, яңакларны төйде, баш түбәсен кадаклады. Бары тик ясмык кадәрле миңне үбеп алгач кына теге дулкын иреннәр аша Суфияга күчте.

—Кайтыйк әле, Әмир! Су буенда җәзалама мине...

Бәлешне Суфия кисте—өлеш тәлинкәләренә бүлеп биш кашык куйды. Егетләрнең үз өлешен алган һәркайсы башкаларны көтмичә үк ашарга ябышты, Чулман суында чапырдап, карыннары бик нык ачкан иде. Әмир ашыкмады, гәрчә бәлешнең беренче өлеше ана тисә дә. Ул Суфияны күзәтеп утырды: һич артык хәрәкәт ясамыйча бәлеш бүлүләре, өлеш тәлинкәләрен «Рәхим итегез» дигән шартка туры китереп куюлары, соңыннан «Ашыгыз тәмле булсын»га торырлык елмаюлары бигрәк килешә. Өч кеше иркенләп сыярдай урынга ике йөрәк кысылышып утырганны күреп, Разыя үзенең күңелендәгең чыгарып салды:

—Никах укытасы гына бар сезгә!.. Койган да куйган кияү!

Әмир каршы дәшмәде: «Суфия ни әйтер икән, әнисенә каршы төшәрме, әллә ризалашып елмаеп куярмы»,—дип, җавап көтте. Ләкин Суфия да тел өстендәге бәлеш йөземен йотарга куркып, Әмирнең җавабын

кәтә иде шул. Һәр ике якнын дәшми калуы үзара ризалашу кебек анлашылды.

Бәлеш табасын ялтыраткач, егетләр өй эчен басып алган мич кызуыннан качып, ишек алдына чыктылар. Инде Суфия тиз генә табынны җыештырып, Әмир янына йөгереп чыгарга тиеш. Ун минут үтте, ярты сәгать. Ниһаять, бер сәгать чамасы көтә торгач, Әмир кызны эзләп, өйгә үзе керде... Юк ул өйдә! Әнисе ике караватнын берсендә стенага карап оеган. Юрганын аяк очына өеп куйган. Өй эчендәге кичке эңгер Разыянын тән яктысын капламаган әле. Кызыл рейтуз керешеннән өстәрәк, кендегеннән унгарак, сукыр эчәгесе өстенә мөһер урынына сугылган нәсел тамгасы—ясмык кадәр мине шар ярылып ята. Ул аю йокысына чумган ише кылана, Әмирнен керүен сизмәгәнгә сабышты—чөнки анын «кияү»гә җавап тотарлык аклану сүзе юк иде...

## Яшел вагон җилсез тирбәлә

Әнә ян тәрәзә төбендә гөлләре юкка чыккан—идәнгә тезгәннәр! Әмир шул тәрәзә аша урамга сикерде—Суфиянын сукмагы тәрәз төбеннән башлана—тизрәк табыйм дисән, эзеннән төшмәскә. Ләкин кая бара сон бу эзләр?.. Клубта бер генә кыз да юк—анда гел кичә килгән ирләр генә доминога чират көтә. Чулман буенда, чишмә янында, урамнарда, бакча башларында—һичкайда юк—качып киткәндәй юк иде Суфия. Әмир аны таба алмавына сөенергә дә, көенергә дә белмәде. Бәлки Ходай аны зур хатадан саклап калырга телидер. Хыянәт—гадәт бит ул! Егет белән кыз чагында ук арага кеше керсә—ул гомер буе котылгысыз хәвефкә әйләнәчәк. Ә барыбер Суфияны эзләп табасы килә, йөзенә тутырып карап: «Син азгын, аллакчы, бөтен кыланышларын ялган гына. Ялган булган җирдә хыянәт бар. Бораулаучы кешегә ышанычлы, тугры хатын кирәк. Бораулаучы елнын утыз-кырык көнендә генә өенә кайта ала. Калган өч йөз көнне анын хатыны ялгыз яши, муллыкта, көрлектә, иректә яши!»—дип анлатасы килә. Хәер, алай озын итеп анлатып торунын кирәге юк. Син мина кирәкмисен, Суфия, дип хәзер үк хушлашырга, өйләрен ташлап, хәтта районнарын ташлап бөтенләй башка районга күчеп китәргә. Кайда сон бу кыз? Кем куенында? Ник күрәсе килә сон аны?.. Көнчелек дигән аяусыз дошман туктаусыз һөҗүм итә. Инде сулышларны тыеп бер үбешкәч, куенына алып зиһенен ялагач, ниһаять, сайлап алган ярын гына күрергә тиешле урындагы миненә ирен тидергәч—җинелергә әзер килеш нигә сон әле ул башка бүтәннәр куенына кереп китте... Хәзер Әмиргә төн уртасы дип тормаска, бораулау мәйданына килеп двигательне кабызырга һәм тан атканчы эшләргә дә эшләргә! Эш ул—сызлаган җиргә дару! Җинелгәнгә—юаныч! Көчсезләргә—мәйдан, хәерчегә—канат ул эш.

Карангыга күз ияләшеп, көндез тугыз көрәк казыган зумф янына килеп баскач, төнге буе тып-тын торасы буровойда вагон рессорларынын тигезсез шыгырдавы ишетелде. Әгәр ул шыгырдау тулай торак караватлары кебек тигез ритмнар белән өзлексез тирбәлсә, уртак телгә килгән ике азгын арасына керү ваемсызлык саналыр иде, хәтта вагон йозагын каракларча ачып керсәләр дә. Ләкин вагон көчле җилдә калган көймә кебек әле бер, әле икенче якка чайкала, эчке стенага бәрелгән сангырау дөпелдәүгә ризасыз тавышлар кушыла:

«Кит, хайван! Кит диләр сина! Кагылма! Эченә тибәм! Шул нәмәрсәнне шартлатам хәзер! Юк дигәч юк! Ач ишекне яхшы чакта!»

Кызнын өзгәләнүе бикле вагон эченнән аерымачык ишетелмәсә дә, Әмир инде бу авазны—бүгенге тынгысыз кичнен сонгы борчулары итеп кабул итте—димәк, Суфия Фәрит кулыннан ычкына алмый! Әмир утка сикергән янгын сүндерүче кебек, вагонга ташланды. Ләкин ишекнен

дүрт вак шөреп белән беркетелгән тоткасы бер йолкуда суырылып чыкты. Ишек эчке яктан шудырмага бикләнгән иде.

—Ач, Фәрит! Җибәр Суфияны! Ишекне ватып керсәм, эш зурга китә—иманынны укытам, беләт!

—Әмир! Тәрәзәне ватып кер! Иртәгә куярлар әле. Кулны каерып тоткан ул, юкса мин аны үзем дә тибеп очырам!..

—Фәрит! Исән чакта, бар, кит!

—Үзең кит!—диде Фәрит, артык пошынмыйча.—Мина аны доверенность белән тапшырдылар, мужик күрмәгән атлы кыланмасын!

—Суфия, әйт, нишлим?

—Әмир, ишекне каер, тышта лом бетмәгәндер әле!

—Соңгы тапкыр әйтәм! Суфияны, яхшылык белән җибәрмәсән, ватып керәм, ну сигез кубометрлы зумфка күмеп куям, заразы!

—Куркытма! Иртәгә егетләр белән килеп, үзенне күмеп китәрбез әле!

—Ах, әле син теленә салынып маташасыңмы?!—Һәм Әмир, ишек ватудан ваз кичеп, бүтәнчәрәк җәза уйлап тапты.

Кичтән бирле ял итеп, двигателе бераз суынса да, су ташучы машина җинел кабынды. Башка вакыттагыча төчкереп, киреләнеп интектермичә, Әмирнең ни теләгәненә төшенгәндәй, буйсынып үкерә-үкерә вагон янына китте. Эш кенендә, авылдан авылга күчү өчен, бу вагонны машинага тагам дисәң: «Алга, артка, бераз янгарак!» дия-дия, ике кеше (тагучы белән тагылучы дип аңларга кирәк) шактый чиләнә торган иде. Ә бүген, вагон тәртәсе машинаның фаркоп дип аталган ыргагын үзе эзләп тапты—бик җинел җигелде. Инде Әмир, ихтыярый әсирләргә сүз катып маташмыйча, вагонны сөйрәп, фара яктысына килеп кергән иң беренче юл буйлап китеп тә барды. Вагон эчендәге ыгы-зыгы, Суфиянын Фәриткә кычкыруы, Фәритнең Әмир адресына сүгенүләре ишетелмәгән кебек, бу минутта ава-нитә калсалар, андагы ике кешенең гомере өчен җавап бирәсе барлыгы да онытылган иде. Хәзер бораулау остасы бер генә әмергә—көнчелек дигән явыз дошман кушкан үч алу әмеренә генә буйсынды. Яңгыр вакытларында шактый казылып һәм өч атнадан бирле корылыкта шакыраеп каткан тирән эзле юл Чулман яры буйлап авылдан ерагайды. Ерагайган саен машинаның тизлеге артты, аның саен ян көзгедән күрелгән вагон почмагы ныграк сикерде, ыргактан ычкынырга теләп алга-артка йолкынды, гүя Әмирдән шәфкать—миһербанлык сорады. Миһербанлык килгәнче ярты сәгать юл үтелде. Ниһаять, Әмирнең ачуы тир булып маңгаеннан бәреп чыкты: Фәрит сәндерәләргә бәрелеп берике җирен кара яндырса да—вәссәлам, ә менә кыз бала әлеге җәзаны ничек кичерер? Әмир, юлдан читкә чыгып, үсмер урман арасына кереп туктады. Кабинадан сикереп төшү белән вагон артындагы ишек янына килде. Тик кулындагы монтажканың кирәге калмады—ишек төбенә хәтле ачык иде. Ул инде кемнең дә булса чыкканын көтмичә, эчкә сикерде һәм аптырап калды: идәндә өч кат матрас өстендә Суфия утыра.

—Кая теге пилмән бәбәк?! Үтерәм мин аны!

—Ул инде кузгалып киткәнче үк сикерде. Мин инде сине әллә Казанга алып китәсенме дип торам.—Суфиянын искиткеч тыныч тавышына сокланып, монтажка идәнгә шуып төште.

—Ә син ник төшеп калмадын?!

—Бу минем язмышым арбасы. Мин гомерлеккә дип утырдым. Төртеп төшерсәң, тагын менеп утырам.

—Алайса, нигә дип шул Казан ышпанасы белән вагонга кереп бикләнден? Тәрәзәдән чыгып качып, спектакль уйнап...

—Казанныкы түгел ул. Әни сөйләгән мужикнын авылдашы. Просто Казанда эшли генә. Ижевка авылына уборкага җибәрәләр дигәч, тегесе минем турыда сөйләп биргән.

—Нәрсә сөйләгән? Ни өчен?

—Без бит инде узган ел аның белән кавышабыз дип йөргән идек.

Ә анын хатыны килеп төште. Шул кадәр дә ышандырып йөргән иде...

—Ә Фәриткә нәрсә калган?

—Ул су буенда: «Мин сине беләм, фәлән дә төгән» дип такылдап маташтымы—вәт шул теге хайван сөйләгән булган ана...

—Кеше күзе төшмәслек жирендәге минне күргәннәр идеме?.. Ну, теге хайванын дип әйтүем.

—Күрмичә. Кавышырга йөргән идек дидем ич.

—Ярар, узган ел бер авызын пешкәч, нигә дип тагын Фәрит янына тәрәзә аркылы сикерден?

—Ул сезнең ишек алдында утырганыгызны күргән дә—тәрәзә шакыды: «Чык әле, сөйләшәсе бар, әгәр чыкмасан, бораулаучы егетенә сөйләп бирәм»,—ди. Чыгыйм әле, хатын-кыз шикелле сүз йөртмәсен, авызын ябыйм, минәйтәм. Ә ул, читкәрәк китеп сөйләшик, Әмирен ишетә күрмәсен, дип, буровоегыз янына алып килде. Үзе һаман сөйләми.Ул арада, кесәсеннән ачкыч чыгарып, вагоныгызны жинел генә ачып куйды.

—Син очып кереп киттенме?

—Керде ди! Кулымны каерып борганын сизми калдым. Юкса алып керә алмый иде ул мине...

—Ник сон безгә кычкырмадын? Төнге тынлыкта ишетер идек ләбаса, ишек алдында идек ич без.

—Хурлыгы ни тора! Аннан сон, мин ана бирешмәслегемне белдем, теләмәгән хатын-кызны исән чакта жинеп булмый.

—Жинмәдеме?

—Улмы?! Жуләр! Ана ди тагын, буш куык! Просто кулны борып алгач: «Әгәр мина бирелмәсән, узган елгы хәлләренне Әмиргә житкерәм»,-ди.

—Ә син?

—Сөйләсән сөйләрсен инде, синең астына кереп ятканчы тол картаям мин лутчы ,дидем.

—Әйттенме шулай дип, Суфия?!

—Әйттем генәме, эченә дә типкәләдем әле.

—Суфия, берәр жирен бәрелмәдеме?

—Юк. Идәнгә утыргач, сикертми-нитми, чайкамый икән бу вагон. Өч кат матрас өстендә рәхәт кенә... Озаклап сөйләшергә жыенасын, ахрысы, Әмир?

—Төне буе!

—Алайса ишекне яп. Тан алдыннан барыбер салкынча...

Зур жинүнен тантанасы башланды. Әмир берни әйтмичә генә өч матрасны рәттән тезде.Суфия утырган сәндерә астындагы сандыкны ачып ап-ак япмалар чыгарды.

—Крахмалланып үтүкләнгән килеш болар.

—Зөфәф кичләре оештырып торма инде ак простынялар белән. Кемлегемне сөйләп бирдем ич.

—Кешечә булсын! Ап-ак урын-жир өстендә! Бу безнең беренче төн, Суфия!

### Төшемдә оятсызландың

Әмирнен турыдан-туры сөйләшүе Суфиянын ризалыгын белү ниятеннән, жәелгән урыннын икесе өчен икәнлеген аңлатырга теләве иде. Тегесе каршы дәшмәгәч ул вакытлыча аклык белән капланган өч матрас һәм өч мендәр өстенә, өч юрган эченә Суфияны күтәреп салды. Кыз, көрәшеп алжыган пәһлеван кебек хәлсезләнеп, Әмиргә буйсынды. Шул арада ул икенче бер халәттә, назын кая куярга белмәгән хатын-кызга әверелеп, тәрәзәдән үтеп кергән бөтен ай нурларын үзенә жыйган да балкып торган тәненә Әмирнең кагылганын көтә.

Егетнең дә үз хәле хәл, монарчы әрәм яткан хисләренә юаныч тапкач, ул хәзер нидән башларга белми, ярсып-ярсып чишендерәсеме, әллә кабаланып-кабаланып матур сүзләр тезәсеме? Саф мәхәббәт турында хыялланган егеткә тәҗрибәле кыз ярдәм итте.

—Әмир, мин сине төшемдә күргән идем. Сөйләргә дип кич җиткәнне көтеп йөрдем.

—Сөйлә. Түлке озакка сузма. Таң аткач, соң булыр.

—Сөйләргә оялам.

—Шулай укмыни?

—Әйе.

—Мин анда, төшендә нишләдем соң?

—Әйтергә оялам. Оятсызландың...

—Начар итепме?

—Юк. Иркәләп назладың. Аннан суырып үптең, тыныңж житмәде. Өстәмә сулыш алып тагын үптең. Күкрәкләремне дә үптең, чишендерел бетердең. Мәхәббәтнең күпчелек өлеше оятсызлыктан гына тора бит ул!

—Менә болай итепме, Суфия, менә болаймы?

Һәм Әмир кыз төшендә күргәннәрне ахырынача өнгә ашырды. Егетнең менә болаймы, шушылаймы, дигәненә Суфия рәхәт ыңгырашу белән генә җавап бирә торды. Хатын-кыз күңелен яулаганда беренче булырга омтылмаган ирләр юк. Нәкъ шул ук рәвешчә, яуланган чагында кияүгә чыгарга омтылмаган хатын-кыз юк. Шушы ике омтылыш ике йөрәкне башта якынайта, аннан буйсындыра, соңыннан аера. Һәркемгә мәгълүм ки, аерылуның сәбәбе кавышкан көнне үк билгеле була... Ләкин Суфияның тәҗрибәсе талантка әверелеп, Әмир куенында тәҗрибәсез кыйланырга кушты. Егетнең утлы кулы ясмык кадәр мин өстеннән шуып киткәндә ул тәнен куырып «Нишлисен?» дигән булды. Ләкин карышмады, көчле куллар иң нәфис киемен салдырганда «Абау, кирәкми, син бит мине харап итәсен»,-диде, тик үзе, тизрәк чишендер дигәндәй, арт санын матрастан күтәребрәк торды. Әкренләп җинүче сыйфатына кергән Әмир иң мөһим мизгелгә терәлгәч, Суфия аның сизгер киеренкелеген каушатмаслык тавыш белән генә:«Бетерсәң бетер инде, күпме саклап йөрергә тагын»,—диде. Ә ике тән бергә кушылган мәлдә кыз үзенең кул сыртын тешләп, үксеп-үксеп елады. Ләкин шул ук вакытта аның сулкылдавы тәненә тыгызлык өстәп, гәүдәсен бәргәләп егеткә рәхәтлек өстәрдәй хәрәкәт ясый иде. Әмир, кызның елау сәнгатенә җинелеп, өзек-өзек юату катыш вәгъдәләр такмаклап, аның күз яшен киптерде. Һәм үзенең беркатлылыгына рәхмәт йөзеннән кирәк минутта үбелде, кирәккәндә кочылды, авырту көткән мизгелдә шыңшу да ишетте. Ике омтылыш арасында вакытлыча тигезлек урнашты. Пәһлеваннар язмышы—кыз кулында. Ялганмы ул, сафмы—наз барыбер наз инде ул.

Сораулар азайды. Хәләл җаваплар кимеде. Бер мәлне икесенең күз карашлары шулкадәр якынайды ки, хәтта вагон эчендәге төн кисәге юкка чыккандай тоелды. Суфияның күзләрне күзгә терәп ишеттерәсе гозере бар иде.

—Әмир... Синең җанында минем балам бар... Бир син аны миңа...

## Кушаматы—кияү

Киичен тәрәзәдән Фәрит белән чыгып качкан Суфияның, көтү куылып көн ачылганда Әмиргә ияреп кайтып керүен күргәч, Разыя сөенеченнән бот чабып куйды:

—Кияү?—диде ул бораулау остасына.

Шул көннән башлап Әмиргә «Кияү» кушаматы иярде, бактың исә,кыз ягыннан әти-әнисе исән кешеләр һәр иргә дә «Кияү» дип дәшәргә тиеш—монысы татарның гамәл китабына язылган кануны, тик

ул сүз кушамат булып бик сирәк тагыла—ашыктырыбрак әйтелгән очракларда гына...

Өйләдән соң көннең кашы жыерылды.Аяз күк Бондюг ягыннан болытлар жыя башлады. Болытның сабырсыз өерләре, килә-килешкә яшен мазар, күк күкрәүләр белән кисәтеп тормыйча, күтәргән суларын кая туры килсә —шунда койды. Авыл эченә юеш тузан исе таралды. Икмәк ташыган чордагы корылыкка ияләнеп, сизгерлеген югалткан мохит көтелмәгән янгырга әзер түгел иде. Чулман өстендәге акчарлаклар симфониясе ыгы-зыгылы какафониягә әверелде. Каз командалары ана казларның борчулы кисәтүенә жинел буйсынып, өйләргә ашыкты. Авыл эчен ярдагы ояларыннан янгыр жиле белән өркетелгән карлыгачлар, керәшәләр телгәләде. Аяклары юешләнгән чикерткәләр, көй чыгара алмыйча, «Чыр-чыр!» килеп, әрекмәннәр астына сикерде. Ниһаять, куерган болытлар артыннан яшен камчылары уйнады. Өйдә бердәнбер хужа булып калган әбиләр бисмиллаларын әйтеп тәрәзәләрне сыпырды, көзгеләрне каплады, радиоларны чыбыгыннан өзде. Яшен камчыларын каплап, авыл өстенә Бондюг тузанының кара бураны ябырылды. Тоташтан янгыр башланды. Суга төшкән мәче шикелле лычма юешләнеп көтү кайтып керде. Вак-төяк йомышлар белән мавыгып төп эшеннән бүленгән машиналар чиный-чиный гаражга үрмәләде. Амбарда өрдергеч жайланмалар сүнде. Авыл эчендәге утны өзеп тордылар.

Бораулаучыларның өч кешелек бригадасы гына эшне ташламады. Жил какшатмасын өчен вышканы дүрт яктан жиргә тарттырган корыч арканнарның казыкларын кагып, дөресрәге, ныклыгын тикшереп чыктылар. Фәритләр истәлеге булып калган сигез кубометрлы зумф Чулман суы белән тулган—пычракта машина интектереп су ташыйсы юк. Ротор тигез аваз белән көйләп долотолы торбаларны жинел әйләндерә. Егетләр вагон тәрәзәсе аша, читтән торып эш барышын күзәтеп утыра. Мондый вакытта станокның идарә итү рычаглары янында Әмирнең басып торуы кирәкми.Эш автоматка куелган кебек үзе генә бара. Яшен сугу куркынычы янамый—уналты метрлы вышка үз әйләнәсендәге бөтен жан иясен яшенуздыргыч булып саклый.

Түбә астында янгырдан качып йоклавы рәхәт булган кебек, янгырны тынлап эшләве дә күнелле—өстеннән коеп тормаса. Егетләр, кичке ашауны онытып, дөресрәге, янгыр астында чыланып йөрергә иренеп эш белән мавыктылар. Долото кимерәсе кызыл балчык известьле ак балчык белән алышынды, циркуляция суы мич агартасы акшар төсенә керде. Анысы тагын озак бармады—долото каты таш катламына житеп бораулау агрегатының бөтен буыннарын шакылдатырга тотынды. Шалтор-шолтырлы тавыш күк күкрәвен күмеп китте, бөтен авылга таралып, рам ырмавыннан какшаган тәрәзәләрне дерелдәтте. Бораулау тизлеге эш башында ук кимеде, бер сәгать эчендә долото нибарысы ярты метр тирәнлеккә төшә алды, дөресрәге калын доломит катламын ярты метр гына тишә алды.Димәк, жиде метрлы квадратлы валның жиргә кергәнен көтәр өчен кименде ундүрт сәгать буе шакылдарга кирәк. Болайга китсә, Ижевка авылындагы сиксән метрлы скважинаны кименде ай буе бораударга туры киләчәк! Әмир өчен шәп бит бу, билләһи!Бер айның утыз көненә утыз төнен дә кушсан—гашыйк кешеләр өчен үзе бер гомер жыела! Ә аннан сон икенче авыл көтә... Икенче төрле яшәү. Суфия каламы? Әмир китеп барганнан соң, Разыя түти тагын яна фатирантлар алып кайтыр... Әмир тойган ләззәт, хәләл сөелү, сыену һәм сөену, үбешү һәм рәхәт ыңгырашулары белән жанга сенгән Суфия башка бүтәннәр куенына калсынмы? Әмир малына чит кеше кул сузсынмы? Юк, күз алдына килсә дә, көнчелек утын дөрләтә торган хәлләргә үз ирегең белән юл куярга ярамый!..

Янгыр сылтавы белән бөтен колхоз эш ташлаган көндә Әмирнең караңгы төнгә чаклы буровойны туктатмавы Суфиянын кулкасын кабартты. Төн янгырныкы да, эшнеке дә түгел, Суфиянык бит инде ул! Әмирнен фатирга ашыкмавын ничек анларга? Ояламы, хурланамы, үкенәме? Әллә

фатирдан ваз кичеп, вагонда гына кунып яшәргә жыенамы? Йа хода, авыл халкы алдында оятын кая куярсың?! Бәлки, икеләнеп, уйга чумгандыр. Уйланса уйлансын, ныклы карарга килгәнче уйланып утырсын... Ир кеше тимер-томыр шалтыравында уйланырга күнеккән инде ул... Ә бәлки аларның бөркәнеп кайтырга...әйе шул, вагон эчендә кожан-плащ ише нәрсәләре күренмәде...

Суфия, үзенең тапкырлыгына үзе сокланып, буровойга йөгерде. Култык астына клеенкалы өстәл япмасы. Бер хатын-кыз плащы һәм Әмир белән икесенә ат жигүчеләрдән калган кожан күтәреп вагонга килеп керде... Ә инде буровойны сүндереп, егетләрне алданрак кайтарып жибәргәч, «кияү» вагон ишеген бикләргә дә онытып янгырлы Суфияны матрас жәелмәгән сәкегә күтәреп салды. Кызның: «Нишлисең, жүнсез, абау, кабаланма шулхәтлек, куалап торучы юк ич, кайтып ашап киләсең мәллә?» дигән сүзләре «кияү»не тагын да ныграк канатландырды. Ошбу төн кичәгесенә караганда да ләззәтлерәк булып кабатланды...

## Яңгырлы гыйшык

Янгыр туктамады.

Кояш нуры үтәли чыга алмаслык калын болытлар тигезләнеп, күк йөзен тоташ төтен төсенә манды. Янгыр инде салам түбәләрне изеп, такыр сукмакларга кибәргә ирек бирмичә, ял итә-итә ява. Янгыр ял иткән арада бөтенләйгә туктады, ахрысы, дип, капкаларыннан чыккан игенчеләр, аяк астындагы ләпеккә батып, кире борылалар. Сыер савучылар белән мал караучылар, аларга өстәп Әмир бригадасы гына эшен ташламады. Янгыр унынчы көнен яуды. Өлкә комитетыннан күңелсез прогнозлар алып кайткан райком секретарьлары колхоз житәкчеләренә ай буена сузылачак циклон турында хәбәр житкерделәр... Аксак сыерны ашатып бетергәч, Ижевка авылына кыр эшләренә дип килгән ирләрне «техпомощь» машинасына төяп, тизрәк Казанга илтеп куйдылар—завод-фабрикалардагы коры урыннарына кайтып, илгә файда китерсеннәр, диделәр. Разыяның фатирантлары Ижевка авылында бердәнбер кунак булып калгач, ашау-яшәү шартлары бермә-бер яхшырды. Ләкин янгыр астында бораулаудан күңелләре үсмәгән егетләрне көн саен итле бәлеш, шулпалы өчпочмак, симез сумса, «бәхетле» пилмәннәр ашатып та сөендереп булмады. «Кияү»нең Суфия белән вагонда кунып ятулары, өйгә кайткач, бөтен дөньяны онытып сайрашулары, «теща» ролена кергән Разыяның «кияү» дип төчеләнүләре егетләрнең күңеленә әлләни хуш килмәде. Ахыр чиктә Әмир аларны Казанга кайтарып жибәрде.

—Барыгыз,—диде ул аларга,—ял итегез, ун көнсез контор күзенә чалынмагыз. Ун көннән соң, прорабны күреп, химанализга су алып кайттык, Ижевкада скважина бораулап бетте диярсез.

Һәм Әмир әле ун гына метр тишелгән скважинаны проекттагыча сиксән метр казылды, суы чыкты, эше бетте дип язу язды. Һәм ул язуны ябыштыргач, өч шешәгә Чулман ярындагы ташлы чишмәдән су тутырып, егетләр аша Казанга жибәрде.

Егетләр киткән көнне үк, күрше караваттагы әниләре янында төне буе мышнап ятмас өчен, кияү белән Суфия вагонга күченделәр, өйгә сирәк кайттылар. Янгыр аркасында колхозның Суфия кебек төрле эшкә йөрүчеләре ял итте. Көндезләрен ул буровойда кияү янында кайнашты, ә кичләрен алар караңгы төшкәнне көтмичә үк «ирле-хатынлы» уйнадылар.

Егетләр Казаннан әйләнеп кайтканда Суфияны укшыта башлаган иде инде. «Ул кадәр агуланырлык итеп нәрсә каптың соң син?»—дип борчылып йөргән Әмирне Разыя юатты: «Кияү, Суфияң малай йоткан. Малай кеше карында чакта ук мәшәкатьле жан иясе!..»

Күңелемдә барыбер шик калды, миңа кадәр бик күпләр белән

типтергәндер әле, бераз күнел ачыйм да, күрше авылга күчкәндә калдырып китәрмен, дип үз-үзен юатып йөргән Әмир «малай» шатлыгыннан шикшөбһәләрдән ваз кичте.

Тукай авылына күчеп килгәч, бригада вагонда яшәде. Әмир берүзе Ижевкага кайтып йөрде. Ул иртән килеп житкәч кенә эш башланды, ул кайтып киткәч, эш туктады.Бригада егетләре кияүне әлләни үртәмәделәр, акыл өйрәтмәделәр, кирәгә үгетләмәделәр. Житди кыланышларыннан чамалап егетнең өйләнүе шушыдыр, әйе, болай да өйләнергә мөмкин икән, дип мыекларына урап куйдылар.

Тукай авылында эш бер атнага бүленде. Көтмәгәндә-уйламаганда Казаннан прораб килеп төште, үзе генә түгел—гидрогеологны иярткән. Лабораториядә Ижевкада бораулаган су скважинасынын анализларын кабатларга кушканнар.

—Ашыгыч рәвештә тагын өч шешә су кирәк!—диде прораб.

—Шешәләрен Казаннан ук күтәреп кайттык,—диде гидрогеолог.

—Анализлары әйбәт түгелме, әллә жир астында шикәр диабеты таралганмы? Гомердә икешәр тапкыр анализ тапшырганыбыз булмады,—дип акланды Әмир, теге суларнын кайсы чишмәдән алынганын исенә төшереп.

—Ижевка скважинасынын суында: магний сульфаты, кыскасы, шифалы су,—диде гидрогеолог.

—Ә мин ул суны яр буендагы чишмәдән генә алып жибәргән идем,—диде Әмир, эшнең зурга китүеннән шүрләп.

—Үзен бораулаган скважинаның суын тикшертмәденме?

—Нәрсәсен тикшерәсең инде анын? Безнең скважинада шул ук яр чишмәсе суы. Бораулый башлагач, чишмә тирәнлегендәге су катламына фильтр куеп калдырдык. Сиксән метргача тишсәк тә, бүтән су катламнары очрамады. Бигайбә, безнең скважинаны беренче шифалы чишмә дип атый аласыз,—диде кияү.

Диделәр дә диделәр һәм, уртак фикергә килеп, скважинадан тагын өч шешә су алып, кабат химик анализга жибәрергә булдылар. Ләкин бер хикмәте аркылы килде—яңа казылган Ижевка скважинасына колхоз электр үткәреп өлгермәгән иде әле. Суны да бораулау агрегатынын генераторы белән генә кудырганнар иде. Яңадан бораулау агрегатын Ижевкага күчереп тормас өчен, скважина эченә шешәләрне бау белән төшереп кенә тутырдылар. Ләкин тагын бер хикмәт аркылы килде. «Кондуктор» дип аталган юан торба артындагы бушлык тоташтан цементланмыйча, өстән күз буяу өчен генә сылап куелган иде. Моны гомергә шулай эшләгәннәр. Торба артын цементлар өчен кимендә өч көн буе бетон измәсе болгатырга һәм торба артына ыргытырга кирәк. Өч көнлек эшкә нибарысы 24 сум акча түләнә. Шуңа күрә бораулаучыларның цемент белән быкырдыйсылары килми. 24 тәңкә өчен өч көн интеккәнче яңа урында өч көн буе борауласаң, күрәп акча аласың ичмасам. Начальство белә инде моны, белгәнгә күрә документлар тутырганда тампонаж ясадыгызмы, дип, сорап торганнары юк. Акчасы да шуңа күрә киселеп беткән инде анын.

Тагын сүз куерды.

—Ләкин бу шифалы су скважинасы,—диде гидрогеолог.—Өстән пычрак төшмәскә тиеш ана!

—Бәхәс күтәрсәләр эшегез судка китәчәк!—диде прораб.

—Бәлки монда киләчәктә «Шифалы су» комбинаты төзелер,—диде гидрогеолог.

—Так шту, труба артына тампонаж ясарга туры килер, иртәгә үк бер машина цемент жибәрәбез. Рәхәтләнеп болгатыгыз!—диде прораб һәм өч шешә су тоткан гидрогеологны житәкләп, Казанга китеп барды.

Өч көн һәм өч төн буе бетон болгатты егетләр. Бер атнадан үзәк санэпидстанция һәм Курророрт идарәсе вәкилләре тагын анализга су сорап килгәннәр. Буш шешәләренең авызы марлялар белән бәйләнгән... Колхоз, ашыгыч тәстә баганалар утыртып, электр сузды... Анализга алганчы суны

тагын ярты тәүлек кудырдылар. Шифалы су әрәм китмәсен әле, дип, Әмир машинаның мичкәсенә мөлдерәмә тутырды да шул кичне, башкала вәкилләрен озаткач, су ташучы машинага утыртып, Суфияны Казанга алып китте. Бөтенләйгә...

Гвардия урамындагы «СМУ Водстрой» каршысына килеп туктагач, машина мичкәсендәге хәзинәне бик тиз бушаттылар. Чөнки Ижевка авылындагы «Шифалы су» хакында идарәдә хәйран сүз таралган иде инде.

## Фатирга бикләп

Әмир, Суфияны житәкләп, Идарә начальнигы бүлмәсенә килеп кергәч, авылдан төяп кайткан гаилә хәлен ничегрәк аңлатырга икән дип аптырап торганда, житәкче кеше аның алдына буш кәгазь бите китереп куйды. Ручка бирде.Һәм әйтеп торып үз исеменә үзе гариза яздырды. Гариза язган көнне үк фатир алган кеше юк дисәләр, сез Киндерле бистәсендәге «Водстрой» урамына килеп Әмир Әшраповны эзләп табыгыз. Ул сезгә сөйләп бирер, өендә туры китерсәгез. Әмир ул фатирда елның утыз көнен генә яшәр. Калган көннәрдә ул гел юлда. Әгәр акчасы белән фатиры булмаса, мондый эшкә гомер буе кем түзсен соң?! Күпме егетне кызыктырып, күпме язмышны ияртеп алып китте, күпме гомер акты инде су эшләре белән?!.

Әмир ике бүлмәле буш фатирга Суфияны бикләп, икенче көнне үк Тукай авылына эшкә китте. Икенче атнада ул аның әнисе Разыяны да төяп кайтты. Туганнарымны сагындым дип йөдәтмәсен, Суфияның бөтен туган-тумачасы үз янында хәзер. Чөнки кызның әнисеннән башка бүтән бернинди дә туганы юк иде. Әйдә, икесенә ике бүлмәле фатир... Әниле-кызлы рәхәтләнеп яшәсеннәр. Әмир акча төяп кунакка кайтыр. Кайткан саен бала үрчетер. Суфия үзенең элеккеге дусларын эзли алмас, жидесигез бала үстерсә, аның башкага вакыты калмас...

Ләкин беренче бала тугач, аңа Язилә исеме кушып бәби ашы үткәргәч, Әмир өстәл сугып элеккеге фикерен үзгәртте:

—Бүтән бала тапмыйсың!

Чөнки Язиләнең дә кендегеннән астарак, сукыр эчәгесе өстендә, әлегә көйгән борчак кадәр генә мине бар иде... Нарасыйның эче йомшарган чакларында Суфия аны беләгенә салып тота, Әмир комган белән жылы су коя. Артып калган суны кияү гел әнә шул «көйгән борчак» өстенә агызды. Күпме су агызды инде ул ана... Юк, мин юылмый икән...

... Хәзер ул, мөгаен, ясмык кадәр зурайгандыр. Язилә инде тәрәзәдән чыгып качкан Суфия яшендә... Әмирнен юлдан кайтып кергәнен хәзер өч хатын-кыз көтеп ята. Әти кешенең алар өчен сүзе каттый: «Төн уртасында кайтып керәмме, таң алдыннанмы, кич беләнме.—Барыбер мин кайтып кергәндә өчегез дә өйдә булыгыз! Кояш баеганнан соң өйдә юк чагыгызны туры китерсәм... карагыз аны! Ижевкадагы ярык тагараклы буш нигезегезгә кайтарып ыргытам!.. Өчегезне бер бауга бәйлим дә...»

Һәм көннең күбрәк өлешен инде урын өстендә үткәрә торган Разыя,пенсиягә стаж жыелсын өчен генә Ветеринария шәһәрчегендә лаборант булып эшләүче Суфия һәм шул фәнни базада кече хезмәткәр вәкаләтендә исәпләнгән Язилә дә кояш баегач, тәрәзәдән-тәрәзәгә йөреп, Әмирне көтәләр... Ишек алдында машина туктаган тавыш ишетелгән саен, ишекне песи тырнаган саен, тәрәзә өлгесен жил уйнаткан саен өчесе дә: «Кайтты!» дип сикереп торалар—кияү, ир һәм әти кешегә беренче булып ишек ачарга ашыгалар. Өметләнгән, көткән көннәрнен бик сирәгендә кайтты шул Әмир... Кайткан саен кызының колагына киртли торган булды: «Мин сиңа үзем кияү табам! Авылларны аркылы-торкылы йөреп чыгам да иң яхшысын сайлап алып кайтам!»

Әмир үзенең өч минле гаиләдә яшәү мәгънәсен Язиләдә күрде.

Әти көнеленә хуш килердәй ир табып, йортлы-жирле, мал-мөлкәтле гаилә корырга ярдәм итә алса, туган йорт жылысыннан мәхрүм калган елларын, һәркем өчен санап кына бирелгән ин кадерлесе—фани гомерен заяга үтмәде дип исәпли алыр.

## Әмир кияүнең Фазыл кияве

Актаныш белән Казан арасы үтелеп, бораулаучыларнын кәрваны Киндерле бистәсенә килеп кергәндә төн инде икенче ягына авышып яткан иде. Мәдияр ике катлы кызыл кирпеч йортның тулай торак дип аталган өч бүлмәле, тугыз караватлы фатирына кереп китте. Ак Чишмәнен Мәдияр кебек дистәләгән буйдаклары өчен махсус тоталар иде ул фатирны. Ялгызаклар башлы-күзле булып таралышып беткәч, берәр мохтаж гаиләгә өч бүлмәле фатир итәрбез дип күпме генә өметләнмәсеннәр... бушамады ул фатир. Ялгыз бораулаучыларнын өйләнеп торырга вакытлары юк идеме, ашыкмадылар. Инде тәвәккәлләп өйләнгәннәре тулай торактагы караватны бушатуга анын урынына гаиләсен ташлап качкан башка бүтән килеп ята иде. Хәер, чакырылмаган кунаклар да еш кунып кала бу караватларда. Жилкенчәкләр янына сумка тотырып керәләр, бушанганчы утыралар, тан атып, машиналар уянганчы йоклыйлар. Чөнки Киндерле бистәсе шәһәр үзәгеннән 25 чакрым читтә булгач, китәм дигән чакта теләсә кайчан китеп тә булмый. Кайчан кайтып төшәсен алдан әйтеп йөрмәгәч, Мәдиярнын караваты бик еш «занято» була торган иде. Мәдияр югында икешәрләп ауный торгач, карават пружинасы чокырланып салынып төшкән, матрасы идәнгә тия хәзер. Ләкин Мәдияр түзә. Үзенең караватында кемнәрнеңдер ирле-хатынлы уйнап яткан чакларына туры килсә һич аптырамый, бәйләнми-нитми, башка караватка барып ава. Казанга чаклы 25 чакрым икән, Мәдиярнын Шүләнгеренә хәтлек 160 чакрым әле, төн уртасында ордым-бәрдем чыгып китәрлек ара түгел.

Мәдияр Фазылны да тулай торакка кыстап караган иде. Ләкин Әмир, получка алгач Шәлегә кайтып китәсе Фазылны үзенә дәште, тулай торакта бозып бетерәсез сез аны, диде. Һәм алар төн уртасы тангa таба авышканда, Әмир кесәсендәге ачкыч белән ачып, Разыялы, Суфиялы, Язиләле өйгә килеп керделәр.

Төн уртасынын баллы йокысыннан, китап укып утырган жиреннән биш кенә минутка оеп киткән кешедәй кинәт уянып, түшәк, күпшы, көләч килеш Суфия Әмир каршысына килеп басты:

—Кайттынмы, сөяркәм?

Әмир борынын күтәреп иснәгәндәй итте:

—Тәмәке исе бар димме... Өйдәгесен кая яшердең? Тәрәзәдән чыгып качтымы?

Кайткан саен кабатлана торган «кияү» шаяртуы бу. Гомер буе кабатланып уенлыгын югалткан әлеге сүзләр хәзер инде «исәнме-саумы» кебек янгырый. Ләкин ул сүзләргә Суфиянын Ижевка авылында үткән яшьлеге, Фәрит белән вагонга бикләнүе, ясмык кадәр мине һәм никахсыз үткән гаилә бәхете бергә сыйган. Һәм Әмир, кайтып кергәч, «Исәнме, сөяркәм!»нән гайре артык сүз өстәсә, вакытлыча онытылып торган язмыш сәхифәләре пыр тузып, күпертелеп, жете буяуларга манылып телгә килеп керә.

—Яшь кияү алып кайттым мин сезгә!

—Кияү?!—дип, Суфия нәрсәдер өстәмәкче иде, Әмир бүлдерде.

—Сина түгел, Бондюг беләте! Язиләгә алып кайттым!

—Әмир абый, мин сезне генә озатып куйдым, Мәдияр көтеп торам диде.

—Китмисен, агайне!

—Сез, энем, Әмир абыегызга аптырамагыз. Гел шулай сөйләшә ул. Без ияләнгән инде аңа, үпкәләмибез...

—Энем түгел, Фазыл кияү ул! Бригадага яңа егет килде дип әйттемме?

—Әйтмәдең, сөяркәм—йөрәгем, әйтмәдең...

—Өлгермәгәнмендер. Кая, Язилә, ник йоклап ята ул?

Эчке бүлмәдән, мәҗлескә барасы кыздай киенеп-ясанып Язилә килеп чыкты.

—Әти, син кайткач кем йокласын инде. Әби дә уяу.

—Әбиеңә сәлам әйт! Бүлмәсенә кереп тормыйм. Кызым, менә күреш Фазыл белән. Бергә эшлибез. Әйбәт кияү! Мин әйбәт дигәч, әйбәт инде. Нәрсә, яна уклау кебек почмакта сөялеп торасың, күреш киявең белән.

—Исәнмесез...—диде Язилә Фазылга таба борылып. Бу исә кызның әтисе кушкан өченгә ярарга тырышудан түгел, кемнәр белән эшли икән дип кызыксынып каравы иде.

—Кызым матур минем. Әтисен яраткан бала бәхетле була ул.

—Безнең Язиләбез гел минем яшь чагыма охшаган—койган да куйган, —дип, сүз кыстырды Суфия.

—Юк!!!—диде Әмир—Причем монда син?! Кызым үзе матур...

—Әти, ярарыгыз инде, кеше алдында сүз куертмагыз.

—Кызым, әниең йокласын, мин барыбер акча алып кайтмадым бүген! Син безгә табын көйләп бир, яшергән жирдән бер ярты чыгар.

—Әмир абый, мин эчмим.

—Үзем эчәрмен, кияү! Эчкәч холкым әйбәтләнә минем. Бу өйдә шушы кызым гына алтын багана. Калганнарының яшьлек хыялы да, картлык өмете дә мин түгел... Кияү бездә куна бүген, вәт шул!!!

## Динә

Актанышта тоз ялаталар

Нәкъ Казан артында суга тилмергән авыллар идарә начальнигы М.Т. Ориничевның куен дәфтәренә теркәлгән. Ул елларда Наил Кадыйрович гидротехник булып кына эшли иде әле. Оешманың исеме дә «Ак Чишмә» түгел, ә «СМУ Водстрой» дип атала иде.

Әмир Әшрапов Актаныштан кайткач М.Т. Ориничев бүлмәсенә кереп, картларча зарланып алды. Шуңа күрәдерме, Әмирнең җөмләләре озын-озак, сүзләре бәйнә-бәйнә иде.

—Михаил Терентьич, сез нишләптер иң ерак районнарга гел мине генә җибәрәсез?! Туйдым. Башкалар кебек минем дә Казан тирәсендә эшлисем килә. Көн саен өйгә кайтып йөреп, үз өендә пешкән ризыкны ашап, хатын җәйгән урында йоклап, өс-башны вакытында алыштырып кешечә яшисе килә... Алҗытты.

Начальникның гаепле бала сыман, дәшми-нитми, каләм очы белән газета битен тишкәләп утыруын күргәч, Әмир батыраеп дәвам итте:

—Сезнең куен дәфтәренә язылган авылларда эшлисем килә дип әйтергә телим мин... Яшерен-батырын түгел, «Промбурвод» егетләре үзләренә чакырып тора, эшләре рәхәт, Казан эчендә актарынып тик яталар. Пенсиягә чыгасы яшем булмаса, ике дә уйламас идем.

Әмирнең зарланырдай зары бетмәсә дә, ярсуы сүрелде. Ни сәбәптәндер кулына тотып кергән эш бияләен сигезгә бөкләп җитәкченең җавабын көтте.

—Дөрес, Әмир, Монголиядән кайтканнан бирле сине гел ерак районнарга җибәрергә туры килде. Биектау, Питрәч, Лаеш районнарында

бораулыйсы скважиналарны мин бүләк урынына саклыйм. Бөтен бүләкне дә Әмир Әшрапов бригадасына өләшергә диген приказ юк! Исенә төшер әле—чит илгә эшкә китәр өчен ничә кеше гариза бирде?! Вәт, вәт, егерме биш гариза арасыннан өчегезне сайлап алгач, калганнары, әнә, министр исеменә күпме жалоба язды? Монголия белән Иранда су скважиналары бораулап кайту—бүләк түгел идеме?.. Айлык хезмәт хакыгызның алтмыш проценты ике ел буе җыелып монда көтеп ятты. Чит илдә эшләгәнегез тулысынча кулыгызга керде, машина алып кайттыгыз, өй җиһазлары, кием-салымның затлысын контейнерга төяп, Казанга җибәрдегез. Шулаймы?

—Анысы шулай, Михаил Терентьич, рәхмәт. Ну, яшь чагым түгел бит. Өйдән ерак китәсем килми.

—Менә монысы икенче мәсьәлә...—Кояш кебек ачык йөзле начальникның чырае тулган ай кебек сагышланып калды. Хәтта борын очларына чаклы җыерчык басты.—Без синең белән бүген-иртәгә пенсиягә китәсе кешеләр. Наил Кадыйровичның институтка кергәнен көтәм. Яраткан урыныңны ышанычлы кешегә калдырып китсәң, тынычлап ял итеп була... Ә син үзең бригаданны кем кулына әзерлисең? Мәдиярга тапшырасыңмы? Ростовтан укып кайтканына биш ел бар, ахрысы, инде?..

—Фазыл Шәмсетдинов калса лутчырак.

—Кем әле ул?

—Дизельче булып килгән яна егетне әйтәм.

—Мастерлыкка укымаган ич әле ул?

—Мин аның укып кайтканын көтеп тора алам.

—Остазның сүзе—гарантия! Кул астыңда эшләгән егетләрне синнән дә әйбәтрәк белүче юк. Алайса, Әмир туган, тагын берәр ел эшләргә туры килә үзенә?..

—Кирәксә, ике ел да көтәрмен.

Ориничев куен кесәсеннән блокнот чыгарды.

—Менә сиңа яна маршрут. Язып ал! Күлбаш, Әлдермеш, Чыршы, Торнаяз... Сая, тагын... тагын берсе Шәле... Алты скважинаны берьюлы бирәүгә дә бүләк иткәнем юк иде әле. Суфия ханым рәхмәт әйтер әле миңа.

—Ие... Ветераннар кибетеннән талонсыз-нисез генә алты кило колбаса алган кебек булды бу.

—Колбасанны борычларга рөхсәт ит,—диде начальник, борын очындагы җыерчыкларын күз кырыена күчереп,—ошбу бүләкнең әҗере бар—янадан Актанышка китмичә булмас. Син андагы катламнарның төзелешен яттан беләсең. Яна кеше җибәрсәк, Актанышка күнектергәнче биш-алты ел үтәчәк. Ә вакыт юк...

Актаныш дигән сүзне ишетүгә, Әмир сигезгә бөкләнгән коры бияләйләрен боргычлап сыгарга керешкән иде. Ориничев ана икенче кат зарлану вәгазенә тотынырга ирек бирмәде:

—Сез бораулаучылар газетаны елга бер генә укыйсыз. Ә без монда көн саен укып, «кызыл почмак»та бергәләшеп тикшереп, әйтелгән фикерләрне язып, заманча яшәп ятабыз... Менә бу газетаны үзенә бүләк итәм. Өенә кайткач, Суфия ханым белән бергә укып чык...Чаллыда ГЭС төзелгәч, Каманың сөзәк ярында яткан авыллар су астында калачак...Шул исәптән Актаныш үзе дә. Анда тау башына, коры җиргә Яна Актаныш шәһәре салыначак.Менә кайда кирәк син, Әмир! Бер мәйданда Яна Актаныш өчен унҗиде су скважинасы казырга диелгән. Нишләп унҗиде ул, нишләп егерме түгел... анысын белмим?! Министрның фәрманы безнең өчен закон! Бригадаң киреләнсә, әнә, башка егетләрне ал, кеше җитәрлек...

—Егетләр риза ла ул. Актаныштa тоз ялаталар диярсең, әллә кайсы җирен яраталар шуның.

—Синең тел төбеңдә сәяси наданлык бар, иптәш Әшрапов! Актаныш безнең министрның туган ягы. Шуның өчен генә булса да яратырга тиеш син аны.

—Ник гел мин генә тиеш. Бераз башкалар да яратып карасын...

—Пенсиягә чыгар алдыннан сүз тыңлаучан булалар иде.. Әле мин сиңа бер сер ачарга жыенам... «Республиканың атказанган мелиораторы» дигән мактаулы исем булдыру турында сүз бара. Министерствода шул Указның проекты бар, үзем күрдем. Беренче номерлы таныклыкны сиңа бирергә дигән тәкъдим әйтелде. Пока матур гына эшләп тор... Медален зурлап юарбыз!

Кайсы гына ир заты беренче булырга теләми икән?!.

Әмир начальник бүлмәсеннән канатларын җилпеп чыкты. Юк, мактаулы исем турындагы хыял гына сөендермәде аны, һич юк, ә таныклыкның беренче номерлысы сиңа тапшырылачак дигән хәбәр күңелен үстерде. Шул ук вакытта, күп еллар буе эшләгән начальнигының һәр елаган сабыйга конфет тоттырып чыгарырга бик оста икәнлеген белгән өстенә, барыбер куанды...

Күлбаш, Әлдермеш, Сая, Чыршы һәм Торнаяз авылларында эшне коры тотты Әмир. Көне-төне бораулады лар. Ял итәргә төннең нибарысы өч-дүрт сәгате генә калып барды. Әмир үз өенә кайтып йөрүдән туктады. Хәтта Киндерле бистәсеннән унике генә чакрымда яткан шәп юллы Әлдермеш авылыннан да кайтмас булды, вагонда яшәп эшләделәр. Бу хәлгә Суфиянның эче пошса да, ике ай эчендә биш скважина тапшырган Әмирнең күпме акча алып кайтачагын чамалаган хатын ирен эзләп килеп тикшеренеп йөрмәде, түзде...

## Сүгенми торган көтүчеләр

Начальник «бүләк иткән» алтынчы авыл Шәле иде. Дөресрәге, Шәле дип аны Фазылның күңеле булсын өчен Әмир генә шулай атады. Проект кәгазьләрендә ул «Мулланур Вахитов исемендәге колхоз» дип теркәлгән. Борауланырга тиешле скважинасы бөтенләй Шәледә түгел, ә колхозга кушылган рус авылы Люткинода иде. Никита Хрущев кушканча, вак-төяк авылларны эреләндерәбез дип, җиң сызганып «күчереп салу» эшенә керешкәнчегә кадәр Люткино авылы үз көнен үзе күрде. Икмәген үзе җыйды, мал асрады, кем әйтмешли, маржасы «сытый», урысы «целый» иде. Шәленекеләр аларга өй салып бирде,шуның өчен печән-ит белән түләү алдылар. Люткино картлары киез итек басу остасы булып, Шәлене киез итеккә тиендерде. Биш мең кешеле авылны киез итекле иткән Люткино авыллары кыш чыкканчы баеп, җәй көне шул акчага Шәленең балта осталарына өй салдырта торганнар иде. Кыскасы, ике авыл арасында акча әйләнеп йөрде. Хрущевның кукурузлы сәясәте Брежнев абзыйга да мирас булып калды. Люткино белән Андреевка дигән урыс авылларын, кәгазьләр тутырып, чеп-чи татар авылына—Шәлегә кушып куйдылар. Партия съезды карары нигезендә үзәккә күчереп саласы вак авыллар, кәгазьдә күчкән саналып, чынлыкта исә теләсә кая чәчелеп бетте. Шәлегә күчәсе килмәгән Андреевка авылы ике-өч ел эчендә таралып, өйләрен утынга сатып бетерде. Йөз егерме хужалыклы Люткино җимерелә башлады. Игеннәрен Шәле халкы барып урды, сыерларын Шәле киленнәре барып сауды. Шәленеке Хәбибрахман Хәлембаевны урысларга бригадир итеп куйдылар. Люткин халкы хәзер итек басса да эчә, өй сатса да эчә, мал-туарын аракыга алыштыра... Бригадир Хәбибрахман да урыс көен көйләде. Көн саен иртән хатыны Зәйтүнә ана әбәтлек төенчек төйнәп, тарантаска утыртып озата, көн саен кичен тарантасындагы печән өстендә бөгәрләнеп йоклаган Хәбибрахманны сөйрәп, карт алаша кайтып керә... Биш-алты елдан соң бригадирның да кирәге калмады. Өйләрен югалткан йөз егерме нигезне кычыткан басты. Люткиноның чәчүлек мәйданына хужа булып калган Вахитов колхозы ул урында маллар өчен сугарулы көтүлек җәяргә булды.

Үз гомерендә бер-ике көн көтү көтеп караган кеше «культурный»

көтүлекнен нинди булуын күз алдына китерә аладыр. Димәк, көтүчене сүгендерә торган сәбәп юк, маллар тәртипле, сүз тыңлаучан, мөгезсез сыерлар көтүне ташлап качмый, печән эзләп дистәләрчә чакрымлы такыр болын таптап йөгерәсе юк. Кыскасы, барысы да культурно! Авыл хуҗалыгы министрлыгына мелиорация министрлыгы тәкъдим иткән генераль план нигезендә, гомерендә сыер тизәге күрмәгән кызыл дипломлы шәһәр егетләре культуралы көтүлек өчен проектлар сыза башлады. Тип-тигез болынлыкны өч картага бүлеп салалар. Һәр карта, болын кисәге дип әйтик инде, тимер чыбыклы багана белән әйләндереп алына, сыер көтүе беренче картага куып кертелә—печәнне кыркып мул сөт бирә. Аннан сон аларны сүгенми торган көтүчеләр икенче картага куып кертәләр, анысы беткәч өченчесенә. Ул арада беренче картада печән яналан үсеп өлгерергә тиеш... Көтүченең кирәге юк, чөнки әйләндереп алынган тимер чыбыкта җинелчә ток йөри, сыер якын килсә, ул аны чеметәчәк. Ин мөһиме, бер ашап киткәннән сон, үлән тизрәк үссен өчен болынга туктаусыз су сибәргә кирәк. Ә су скважинадан чыгарга тиеш.

Шәленең кыргый болынлыкларын кинәйтеп, культуралы көтүлек итәбез дип, Мишә елгасы янындагы Питрәч сазлыгын "тимер чабата" кигән тракторлар ергалады; әрәмәләрне,ваграк куакларны, эре-эре карама, зирек, сөяннәрне, тәртә юанлык шомыртларны, болын урманнарын, миләш бакчаларын партия түрәләре күрсәткән урынга өеп, ут төрттеләр. Сазлыкларны ерганаклар буйлап агызып киптереп бетерсәләр дә, Мишә буендагы мелиораторлар болынын үлән чәчәрлек итеп тигезли алмадылар. Төпләр-тамырлар актарылып, кәс кантарлары тау-тау өелеп, әрәмәләр кеше аягы баса алмастай җиләк-җимешсез кыргый чытырманлыкка әверелде... Табигатьне үзгәртеп корып булмаган кебек көтүлекләргә дә культура кермәде. Көтү бер-ике кат таптап киткәннән сон, артык су сибүдән гумус, сыер авырлыгына түзә алмыйча, боламыкланып тамыразыкны юкка чыгарды. Суга кинәнгән кысыр болыннарны сыерлар яратмый торган каз тәпие үләннәре басып алды. Колхоз көтүләре яңадан элеккеге такыр, ләкин туклыклы болыннарга таралды.Культуралы көтүлекләрнең чыбыкларын өзгәләп, баганаларын урлап бетерделәр. Хәер, монысы сонрак әле аның. Ә бүген Шәленең элеккеге Люткино бригадасына культуралы көтүлек ясар өчен су скважинасы бораударга дип, Әмир бригадасын җибәрделәр. Дөресрәге, Фазыл кичә үк кайтып китте инде...Бораулау агрегаты вагоны-ние белән бер атнага гаражда калган иде.

## Безнең амбразура

Кайда ничектер, Ә менә «СМУ Водстрой»да бораулаучыларга получка дигән нәрсәне һаман бер вакытта —айның унынчы көнендә, көндезге сәгать икедә өләшәләр. Конторда һәм гаражда эшләүчеләр үзләренә тиешле сиксән-йөз егерме сум акчаны иртәнге якта ук алып куярлар—бораулаучыларның аяк астында буталып, тел шартлатып йөрмәсеннәр өчен шулай эшләнә бу.

Тимер ишеккә уелган касса төннегән амбразура, диләр монда. Кассиршаның елмаюын күрер өчен җанын бирергә әзер торган агай-эне чираты пружина кебек кысылган, артык кешене этеп-төртеп чыгарырга әзер тора. Бу кысылу көчен акча күрергә зар-интизар булган гаилә башлыкларының яшәү өчен көрәшүе дип түгел, ә бер күчкә өелгән акчаның тарту көче дип анларга кирәктер. Әмирдән сон Мәдияр басты, Фазыл—алар артыннан—бишенче разрядка күтәрелгәч уртага басарсың, диделәр. Әмир кулына эләккән акча бәйләмен күргәч Фазыл: «Миңа калмас, ахры»,—дип уйлап куйган иде. Калган. Кассирша кызыл карандаш белән «чәүкә» төрткән урынга кул куйганда Фазыл бөтенләй кабаланды, хәтта язылган сумманы юньләп күреп тә өлгермәде. Кассирша

«амбразура»ны каплаган Фазыл алдына саный-саный да өя, саный-саный да өя...

Чиратның киеренке пружинасы бушлыкка этеп чыгаргач, Фазыл күздән югалырга ашыкмады, чөнки кассирша: «Мин сиңа ялгышып артыграк биргәнмен!»—дип кире «амбразура» капларга чакырыр кебек тоелды аңа. Ләкин, аларны шундук оныттылар.

Ул акча бәйләмен куен кесәсенә салган иде—артык бүлтәеп чыкты. Шуннан соң ул аларны тәмәке кабы кебек данәләп, бөтен кесәләренә бүлеп тыкты. Болай күзгә ташланмый, аннан соң «суконный жуликлары» бер кесәнне чистартса, башкалары исән калачак...

Автовокзалга дип Казанның үзәгенә таба кире барырга кирәк иде, Фазыл, вакыт әрәм итмичә, әнисе янына тизрәк кайтыр өчен Шәле машиналары туктый торган ипи кибете янына юнәлде. Унбиш минутлык тротуардан атлаганда Фазыл әллә егерме тапкыр кесәләрен капшагандыр... Акчалары урынында... тик кесә капшау гына гадәт булып кала күрмәсен. Мөхәрләм малае да тәнәфестә ике кулы белән еш-еш чалбарын күтәргәндәй итә иде... Төшми инде чалбары, гадәте шундый, күрәсең, тегерманче малае кесә төбендә гел акча йөрткәндер.

Үзе салган өйнең бусагасына кайтып утыргач, кесәләрендәге байлыкның исәнлеген тоеп, Фазыл сөенеченнән телсез калды,

Динә түрдәге өстәлдә сырлы бәлак белән керләр тәгәрәтә иде. Улының бусагада утыруын ул стенага элеңгән көзгедән карап торды. «Исән-сау гына кайттыңмы, улым»,—дип сөенеп сәламлисе урында, әни кеше, үз улын үзе танымагандай, керләреннән аерылмады. Бераздан ул: «Шабыр тиргә баткан маңгаеңны сөрт!»—дигәндәй, сырлы бәлак астындагы уклаудан сүтеп алып, чүпләмле сөлге ыргытты.

—Этләр куды мәллә? Утка төшкәнсең...

—Синең янга ашыктым. Нихәл, әни?!..

—Шәле юлына чыккач ашыккансындыр. Өйгә кайткач, хәл сорап маташмаслар. Хәлне аны гел белешеп торалар... юньле кешенең балалары. Теге дөньядан юл юк. Бик барып күрердәй булырсыз әле.

—Ничә тапкыр чыгып киттем өйдән, гел буш кесә белән кайтып кердем. Бу юлысы баеп кайтасым килде. Шуңа озаграк йөрелде.

—Балаларыгыз булгач, ана бәхетенең ни икәнен анларсыз әле. Акчагыз ниемә кирәк?..

—Өй салганда алган ссуданы берьюлы түләп бурычтан котылыр өчен кирәк бу акча, әни!..

Һәм Фазыл караватөстенә капланган чигүле ак япмага кесәләрен бушатты. Күбрәк итеп күренсен өчен ул аларны бер кучкә өйде. Динә оят күренешкә тап булган яшь кыздай, улын ярамаган шөгыль өстендә тоткан аналарча сискәнеп куйды.

—Үзеңнекеләрме?! Бурыч түлисе бар дип берәрсен рәнжетмәденме? Безгә хәрәм мал килешми!

—Хәләл мал, әни! Эшләп, маңгай тиремне түгеп алдым!

—Һай, улым!—Динә сырлы бәлак өстенә капланды, шыкырдап кипкән, тәгәрәтелгән ак ашъяулык өстенә анын сабырсыз күз яшьләре тамды.

—Син нәрсә инде, әни, мәет озаткан кеше кебек жебеп торасын! Сөенергә кирәк. Әйдә правлениегә, ссуданы түләп кайтабыз, күрсеннәр безне!

—Һай, әйбәт эш тапкансын, балам. Аллага шөкер, «хәерче нәселе» дигән кара сакалыбыздан котылдың бугай...Жыеп куй акчаларынны. Туеңа дип сакла.

—Нинди туй, әни! Бурычтан котылыйк әле...

—Өздем инде мин колхоз белән араны... Ссуданы кенән түләп кайттым.

—Акча кемнән алдың, әни?! Абый жибәрдеме, әллә үзбәк жизниднме?

—Өйне саттым.

Ике арада шыксыз тынлык урнашты... Бактын исә, япма өстенә акча өелгән караватлары, урам исе сеңгән ак кергләре, кояш нуры тулган идәннәре, кызарып пешкән арыш икмәгенә юмарт мичләре, балкып торган тәрәзәләре белән бу өй инде чит кеше кулына күчкән. Әнисе белән улы үзләре салган өйдә үзләре хужа түгел.

—Ник син мине көтмәден, әни!

—Киттен дә югалдын... Үлгән булсам, кабер казышырга да таба алмаслар иде үзенне... Апан янына Үзбәкстанга китәм, анда хет утын ташыйсы юк ди.

—Әни, авылда нигез беткәч, кая кайтып йөрербез?

—Хәйдәр абыен исән чакта Шәле ятим итмәс безне. Фәризә жингән сине үз баласыдай якын күрә...

### Кала күмәче

Иртә вафат булган ирнен фани дөньядагы йөге тол хатын жилкәсенә өелә. Чандыр гәүдәле, жинел сөякле, тынгысыз жанлы Динә 34 яшеннән иненә өч бала күтәреп, салам түбә астында сытылган черек өй ишек алдында көрәк-сәнәккә, балта-уракка таянып калды. Ирләр күтәрә алмасны күтәреп, хатыннар түзә алмастай нужаларга чыдады ул. Балаларым ач-ялангач булмасын, ятимлекне тоймасын, дип, эшләде дә эшләде. Көз көне хезмәт көненә тиешле икмәк бүлгәндә бодай-арыш—борчак капчыклары төялгән олау иң әүвәл Диналәр капка төбенә килеп туктый. Елга 650 хезмәт көне эшләү күп кенә механизаторлар кулыннан да килми иде. Башкалар өй түренә ике-өч жәймә жәйсә, Динә үз өлешенә тигән яна икмәк бөртеген алты-жиде жәймәгә жәеп киптерде. Бөртекләр өй түренә жыелган кояш жылысында көн эчендә кибә. Кибәкләрен жилгәргән чакта әнисе Фазылга сызгырып торырга куша. Ходайның рәхмәте, ятимнәр сызгырса, бөркү көнне дә жил чыга икән... Динә, бөртекләрне казан чиләкләргә тутырып, жәймәләргә коя: Фазыл сызгыра да сызгыра, әнисе жилгәрә дә жилгәрә. Озак итеп, жиренә житкереп, күршеләр алдында мактаныр өчен түгел—горурлыгын, куанычын тыя алмыйча жилгәрә ул...

Әллә артык еш сөйләгәнгәме, егерме беренче елгы ачлык, сугыш елларындагы кытлык турындагы фажигале хатирәләргә балалар колагы күнекте... Алар хәзер колхоз икмәгенә риза булмыйча кала күмәче сорый-лар. Әтиле балалар кулында алма-хөрмә күреп кайткач, өйдә пышын-пышын зарланалар, әниләренен жанына тияләр.

Алма белән хөрмә Шәле бакчаларында үсми, Шәледә гөл савытла-рында да бәрәнге үсә. Ә алма-хөрмә—кала жимеше.

Динә Казанга бәрәнге сатарга китте.

Базарга яна бәрәнге чыкканчы урамдагы базла кыш чыккан иске бәрәнгене озатасы бар.

Шоферлар капчык башыннан илле тиен ала, шуна күрә Динә ун капчыкка сыярлык бәрәнгене биш кычыткан капчыкка тутырып, күтәреп төяргә жайлы булсын өчен авызын ике колаклап текте.

Хәйдәр күрше Жамалилардан арба алып чыгып жикте. Төягәндә Хәйдәр капчыкның төбеннән, ә Динә колакларыннан күтәрде. Фазыл үгезнен дилбегәсен тотып торырлык малай гына иде әле. Бәрәнгеләрне жил тегермәне янына меңгереп куясы—анда иртәнге жиделәргә Казаннан брезент бөркәнгән кузовлы такси килеп ала. Ул машинага Шәленен бөтен кешесе дә сыя бугай—Казанга барасы иде дигән берәүне дә калдырмый, бөртекләп—дынгычлап төяп алып бара да Чех базарына бушата. Хәйдәр үгезе жил тегермәне тыкрыгына борылган минуттан—Фазыллар инде әниләренен Казаннан бәрәнге сатып кайтканын көтә башлый. Әйтерсен лә Чех базарының иннек иренле, кершән битле, алка

колаклы, капрон сыйраклы, парча күлмәкле кылтым түтәйләре Шәле бәрәңгесен җил тегермәне янына килеп каршы ала.

Абыйсы белән апасы мәктәптән кайткач, шобага салып өйнең өч тәрәзәсен бүлешәләр. Ничә тапкыр салсаң да, ул шобаганың җавабы бер—колхозның гараж ягына карый торган тәрәзә абый кешегә эләгә, апа кешенең тәрәзәсе клубка йөри торган урам ягында. Ә инде Фазылга, гадәттәгечә, ишек алды тәрәзәсе кала. Абыйсы —ак калач кötә, апасы — зур алма, ә Фазыл әнисен генә көтә. Урамда тораклор тавышы ишетелсә, йә ат кешнәсә, һич югы үгез мөгрәсә дә, өч бала шундук үз тәрәзәсенә ябырыла. Сөенечле хәбәрне кем иң алдан әйтә?!

«Әни кайтты!!!»

Көн саен, сәгать саен яңгыраса да ялыктырмый торган, сөендерә торган, шукландыра һәм тукландыра торган тансык һәм игелекле хәбәр бу.

Динә өйгә керү белән, юлдан кайткан киемнәрен салырлык хәл алганчы дип, бусагага утыра.

—Эт булдым, балалар... Бәрәңге авыр үтте, ике килосына егерме биш тиен сорап торалар. Бер капчыгын тоташтан алмасалар, Хаҗәр апагызда куныл кала идем... Йомырка әйбәт үтә... Тавык оясын борчымагыз, йөзгә тутырып булса тиз генә Питрәч аркылы барып кайтырмын. Сөт әйберсен дә ябырылып алалар. Сыерлы кешенең эше рәхәт ичмасам. Ат чишмәсенә суга килгән иште генә Казанга килеп керә дә без бер капчык бәрәнге бушатканчы ике чиләк маен-эремчеген сатып та бетерә... Атагыз мәрхүм, авыр туфрагы җинел булсын, ул барган җиргә мин дә барасы, соңгы сыерны да суеп ашап карады, терелә алмады... Хәерче төяп калдырды шул.

Динә сөйләнә тора, балалар Казаннан кайткан биштәрне актара тора. Өй эченә күрше апаларны сыйлар өчен күчтәнәч итеп алынган ысланган балык исе, мәк сибеп пешерелгән ак күмәч һәм чәйнек кадәр зур алма исе тарала. Нужа дигәнең төн узганчы гына булса да өй эченнән чыгып тора.

Динәнең каладан бәрәнге сатып алҗып кайтуы «ах-ух» булып икеөч көнгә сузылыр сыман, тик анлык вакыты, иркәләнеп утырырлык җае гына юк. Кала базарында үткән эш көне өчен бригадир Мөхәммәт болай да Динә тирәсендә тамак кыргалап йөрер әле. Динәне күргәч, аның гел тамак төбе кычыта башлый. Динә кара каеш сумкага яшереп алып килгән өч литр сыраны тарантасының алгы утыргыч астындагы печән вагына күмеп куйгач кына, Мөхәммәтнең тамак кыруы бетә. Гомумән, Сәләхие үлгәннән бирле Динә тирәсендә тамак кыргалаучылар күбәйде. Хөрши Фәрзетдине, Мөхәрләм Әхмәте, Ишем Нәгыйме дисеңме —барысы да Динәнең бикле капкасын ачтырып, тамак кыралар. Шөкер, кулларына банкы белән сыра чыгарып тоттыргач ник тамак кырганнарын оныталар үзләре. Онытмас иден, өч минуттан: «Әни, син кая, ник кермисең инде», дип, өч бала килеп чыга. Динә үзе балаларын орыша, үзе орышкан булып аклана:

—Сезгә рәхәт. Утыныгыз кайткан, бакчагыз казылган, оныгыз тарттырылган. Бөтенесе өчен дә миңа ялынасы. Алар кулында машина, алар кулында ат... Атагыз сез үсеп җиткәнне көтмәде бит. Һаман-һаман гөнаһлы булам инде, мәрхүм каршында. Искә алуым савап булыпирешсен...

Тагын шунысы сәер. Шәледә ялгыз, тол, сазамык кызларның чуты юк. Тик шулай да иреннән өч бала тотып калган Динәгә яучылар өзелми... Динәнең ризалыгы юк. "Үги ата кулында үскәнче лутчы ятим үссеннәр",— дия иде ул.

Гайбәткә ышанып берүк ялгыша күрмәгез, капкасын шакыган һәр хәсискә Динә сыра чыгарып тоттырмый. Ферма мөдире Гайзулла ишеләргә тәтеми ул сыра. Чөнки Гайзулла кулында ат та, трактор да юк, чөнки Гайзуллага сыра гына кирәкми. Утыздан узган кырыкка җитмәгән Динә сылу гәүдәле, көрәк-сәнәк-урак ише нәрсә кулыннан төшмәгәнгәме—

ине нык, тәнгә тыгыз иде. Өстенә бишмәт кисә дә, кожан бөркәнсә дә, биле уелып торыр. Ир кайгысыннан чем-кара чәче агармады, бит алмаларына иннекнең кирәге булмады, өс-башын көн саен алыштырыр, колхоз эшенә дә кершәндәй ак яулык бәйләп йөрер.

Фазыл исә, Хәйдәр абыйсы төзәтеп биргән чананы сөйрәп, пилорам тирәсенә йомычкага килә. Авыл зур булгач, пилорамда эш өзелми. Эчтә такта яралар, юналар, рамнар, ишекләр ясыйлар. Ә тышкы якта бура бурыйлар. Балта осталары бүрәнә башларын, бура чуплауларын үзләренә аерып өяләр. Ә вак йомычкалар Фазыл кебек ятимнәргә кала. Көн саен ике-өч чана алып кайткач, Динәнең абзарында йомычка тау булып өелә. Кабызгылыкка, коймак, көлчә пешерергә менә дигән вак утын бу.Динә Казанга бәрәнге сатарга барасы булса, Фазыл бигрәк тә тырыш балага әверелә. Ике чана йомычка алып кайткач, Гайзулла фермасына сыерлар астыннан коры килеш чыккан саламга китә. Фазыл аны тирескә дип ташланган күчтән сәнәк белән тарап җыя.

Бер көн шулай, кышкы кичтә, Фазыл әнисенең рәхмәтен ишетергә теләп, Гайзулла фермасына саламга китте. Урамдагы суык егерме градуслап булыр. Тирес шакаеп каткан, саламын тарап алулары җинел түгел. Чананы тутырыр өчен Фазыл бер сәгатьләп изаланды. Ниһаять, салам күчен кәҗә арканы белән тарттырып, сәнәкне бау өстенә кадап, чананы өйгә сөйрәмәкче иде, гомердә булмаганны, Гайзулла килеп бәйләнде.

—Кем кушты сина?—диде Гайзулла, чана бавын кулына алып.

—Кушмады, тирес ич ул, барыбер чыгарып түгәсе.

—Кырга түккәч ашлама була ул.

—Бакчага салам чәчмиләр ич?

—Бакчага чәчмиләр, ә кырга салам да ярый. Җитмәсә, теленә салынып маташасын. Саламынны чанасы белән конфисковать итәм.

—Бер литр сыра алып менимме?

—Сыраң үзенә булсын, хәерче тәре. Мин брага эчмим, ашказанын боза ул!—һәм ферма мөдире саламны бушатып, Фазылның чанасын каравылчы өенең чоланына кертеп бикләде.

Кичке савымнар беткән иде инде. Фермалар ябулы. Суыкның градусы арта башлады. Авыл эчендә җылыныр өчен генә бәйдәге этләр өргәли. Эңгер-меңгер куера төшкәч, салкын тынлык җанга үтеп керә икән. Әллә керфекләренә, кашларына кунган бәсләр эреп ага, әллә күз яше, Фазыл үзенең елавын сизмәде... Ямаулы бияләй аша иске чусынканың шахта калошыннан, чүпрәк тышлы бүрегенең колакчыныннан, өченче ел мәктәп профсоюзы бүләк иткән бушлатыннан үтеп кергән салкыннар бергә кушылып, бөтен тәнне калтыратса да, Фазыл аны туңуга санамады, ул аны Гайзуллага булган ачудан, чанасыз-сәнәксез кайтып кергәч әнисеннән эләгәчәк орыштан һәм үзен яклардай әтисенең юклыгына гарьләнүдән дип аңлады.

Гайзулла китмәгән икән әле. Ул каравылчы өе янындагы баганаың лампочкасын сүндерде. Караңгылык кинәт килеп төшкәндәй котны алды.

—Бар, кайт өенә! Әниең килсен чанаңны алырга. Бар, бар, йә катып үлерсең! Әниеңә әйт, Гайзулла абый көтә диген!

Фазыл бияләй ямавына эчендәге бар җылысын өреп, сүзсез басып торды. Гайзулла аны төртеп җибәрде.

—Бар диләр сина, хәрәсән!

Юк, Фазыл бу ферма хайванына әнисен әрәм итәргә теләмәде. Моның ише кешеләргә ялганласаң да ярый иде, изгелек хакына, нәфрәт, кимсенү хакына.

—Әни өйдә юк. Казанга кунарга китте.

Куркуы заяга булды Фазылның. Динә караңгы кичтә буш чана сөйрәп кайткан малаен кыйнамады, ахырынача тыңлагач, кырыс кына әйтеп куйды:

—Безнең язмышыбыз шушы, улым!—Әни кешенең юату сүзе иде бу...

* * *

—Әни, ничә көнгә кайттын дип ник сорамыйсың, әни?

—Без бу өйдә кунак кына синең белән. Сәгадәт апаннар килеп бүген дисә, бүген куып чыгара ала. Ишек ачылган саен менә килеп керерләр, әйберләрен китерерләр кебек. Аларнын урыннары түбәндә, өйләренә ел саен инеш керә. Өебез биектә иде...

—Әни, әйдә сәвиткә барыйк та договорны ертып ташлыйк. Сәгадәт апаның акчасын кире кайтарыйк.

—Авыл кешесе бер әйттеме—шуның белән «Амин» инде ул. Шәһәрдә бәлки судлашып йөрүләр бардыр. Авыл кешесе ике төрле сөйләшми.

—Әгәр тагын берәр атнага соңарып... өйгә кайтып керсәм—син юк, хужа булып чит кешеләр ыгы-зыгы килсә... йөрәгем ярыласы икән.

—Бер атнасын белмим. Бүген син кайтмасаң Хәйдәрләргә кереп кунасы идем.

—Инде нишлик, әни?!

—Алып китәрдәй нәрсәләрне барлап чык.

—Нәрсәне, кая алып китим?! Вагонда сөйрәп йөрергәме?

—Мин дә бер әйбер алмыйм. Кулындагы төенчегең дә Үзбәкстанга чаклы барып житкәнче алтын бәясенә төшәр.

—Ник ул кадәр еракка китәргә соң, әни? Әйдә, минем белән.

—Үзең әйтмешли, вагонында сөйрәлеп йөрергәме?

—Әни! Казанда фатирга урнашып торырбыз. Түләрлек кенә акча эшлим бит инде мин.

—Нәрсә соң ул, акча?! Кеше фатирында бикләнеп ятыйммы? Син бит хәзер ни шәһәр малае, ни авыл малае түгел.. Кыр малае син хәзер.

—Әни, Шәле малае мин, Шәле малае!

—Юк инде, улым, киттең син авылдан. Бөтенләйгә китүең шушы. Бер киткәч, кире кайтыр өчен агымга каршы йөзәргә кирәк.

—Алайса, ник китәсең, әни? Бүтән Шәле юк бит бу дөньяда!

—Гәүдәм әйләнеп кайтыр әле. Өч бала үстереп, гүремне читтә казытмаслар... Ана кеше бала үстергән бишек кебек кенә ул. Балаларың очып киткәч, бишекнең кирәге калмый...

—Алай димә, әни! Без үзебез ятим үссәк тә, син ятим түгел, әни, синең өч таянычың бар...

—Таянычлар аяныч... Авырып егылсам, вагонынны телеграмма белән дә куып тотарлык түгел.

* * *

Әйе шул,Динәнең гәүдәсе әйләнеп кайтмады. Шәле зияратында аның кабере юк.

## Язилә белән Галина

Тимер бура

**1969** елның декабрь аенда Әмир Әшраповның су бораулаучылар кәрваны тагын Актанышка килеп төште.

Агыйделнең аръягыннан килгән көпшәк кар җиһанны кыскан... Юллар тарайган, кырлар кечерәйгән, терекөмеш болытлар җиргә тигән , өйләр бастырылган... Югалткан юлыңны кар астыннан эзлисе, онытылган малыңны алыр өчен фанер көрәк белән казыйсы бар. Кулыңнан вак әйберләр төшеп китсә, яз житкәнче табарлык түгел. Авыл, мамык юрган астына сыеп бетмәгән гәүдәсен дерелдәтеп йокымсырый. Этләр, өрергә иренеп, баскыч астындагы сырмага сыланган...

Актаныш халкы кыш белән килешеп, саламын җәеп, сырмасын каеш белән буып, сулы мичкәләрне эт чанасына салып, себергә охшаш мохиткә күмелеп яшәп ята. Бораулаучыларның сигез күчәрле олавы үтеп киткәндә, җәй көнендәгечә кызыксынып, капка ярыгыннан, тәрәзә пәрдәсе артыннан карап калучылар күренми, бала-чагалар да арттан йөгерми.

Обсадка өчен диелгән юан торбаларны Уразай авылындагы Сәхипҗамал түткәйнең өй түренә өеп куйганнар иде. Казаннан чаклы прицеплы машиналар белән ташылган бер вагон торбаны хәтта кар да күмеп бетерә алмаган. Сумалалы баганалар сыман кап-кара өемгә карап, шаяртып китүчеләр аз булмады:

—Сәхипҗамал түткәй, әллә түбәнөй астыннан нефть чыктымы?

—Түткәй, сатасың мәллә бу торбаларны? Күпер салырга шәп алар!

—Бура буратып карыйсы иде бу тимер бүрәнәләрдән?!.

Сәхипҗамал түткәй өе —прораб Сафәровның Актаныш районында иң ышанычлы фатиры. Торба калса югалмый анда, цемент калса кимеми, су астына төшерә торган кызыл насос искегә алышынмый.

Куян авылы белән Илчебайны узгач, сул якта биек кар тавы озата бара. Тау өстендәге кирпеч заводы урманыннан астагы үзәнгә чаклы үсеп төшкән тыгыз каеннар аклыгы тауга купшылык өстәп, кар өемнәрен кабартып тора. Уразайның үзәнә килеп кергәч, күрер күзгә быел мәктәпне тәмамлардай бер кыз ак йон бияләйләре белән яшел көянтәсен кочаклап юл аркылы чыгып бара иде, Әмир машиналары туктап, ана юл бирде. Ерактан килгән мужиклардан мондый ук ихтирам көтмәгән кызый юл уртасына житкәч, адымнарын әкренәйтеп, егетләр ягына елмаеп карап торды. Фазыл Әмир янында утырып бара иде, кызның елмаюыннан йөрәге «жу-у!» итеп китте. Бәлки Әлфинә дә бу минутта чишмәдән кайтып киләдер. Аның да чайкалган сулары чиләк төбенә боз булып эленгәндер, бит алмалары кояш белән бергә баеп алсулангандыр.

Фазыл Әмиргә берни әйтеп тормады, тизрәк кабинадан сикереп төшеп кыз янына йөгереп килде.

—Сәхипҗамал түткәйнең өен күрсәт әле?

—Бәй, без бит инде ул! Сез су бораулаучылар мәллә? Казаннанмы?

—Әйе. Сәхипҗамал түткәйнең шундый зур кызы бар дип әйтмәгәннәр иде.

—Зур түгел әле мин. Инәйнең шәлен бөркәндем, итекләр дә инәйнеке. Шуна гына зур булып күренәмдер.

—Чишмәгез еракмы?

—Әнә бит, тау итәгендә, шаулап агып тора. Эчә күрмәгез, суы җәй көне дә тешне сындырырлык салкын аның.

—Без ияләнгән инде салкын чишмәләрдән су чөмерергә.

—Алайса, мин кайтып инәкәйгә әйтә торыйм, Казанныкылар килде диярмен.

Әмир кабина ишеген ачып, Фазылны ашыктырды.

—Кияү әйдә, күнелең булгандыр инде.

—Әмир абый, нишләп соң син мина чит кешеләр янында кияү дип дәшәсең?—диде Фазыл, машина янына килгәч.

—Нәрсәсе бар инде аның. Мине дә гомер буе «кияү» дип үртәп йөрттеләр. Шундый матур исемне истәлеккә сина кушып калдырабыз, Күчмә кызыл байрак кебегрәк итеп. Аннан соң минем кызым—Язиләне әйтәм, сине бик ошаткан. Гел сине генә сораштырып тора. Так шту, кияү инде син!

Мәдияр вагон таккан машинасыннан төшеп тормады, Әмир белән Фазылның Уразай чишмәсен карап йөрүләрен ишектәге ян көзге аша гына күзәтте.

Чишмәнең суын алырга җинел булсын өчен агач улакны озын итеп сузганнар. Шарлавык түтәл каләр жирнең кар-бозын эретеп куйган. Суны учлап йотып карагач, Әмир улак төбендәге, дөресрәге, чишмәнең тау

куенынннан чыккан урынындагы балчыкны кузгатты. Улактагы су бераз болганып алды, ләкин су агымы көчле булгач, ул бик тиз чистарды.

—Менә, кияү, игътибар ит: бу чишмә чуерташлы комнан саркып чыга. Безгә әнә теге тау өстендә, иске кирпеч заводын узыбрак унжиде скважина казырга кирәк. Шушы ук су катламыдыр әле анда —ерак ара түгел...

Су—сихәт, шифа, дару һәм ризык; су—юл, эшче көч, йөк ташучы һәм табигать сөенече; су—дәһшәт, хәвеф, дошман һәм сагыш; су—көчле, ягымлы, йомшак, каты һәм мәкерле...

Түбән Кама сусаклагычы күтәрелгәч, текә ярга урнашкан районнар су көченнән сизелерлек зыян күрмәс. Ә менә Чулман белән Агыйдел дингезенә ярымутрау булып кергән һәм Ык, Сөн елгалары белән телгәләнгән Актаныш илебездә Ильич лампалары балкып янсын өчен үзен суга батырып, корбан итәргә тиеш иде.

Әмир бригадасы әле яна гына буран туздырып үтеп киткән Илчебай, Куян, Уразай—су астында калачак авыллар исемлегендә. Уразайның балык шулпасына әверелгән Бәкилде күлләре, Яр буе болыннары, Әҗәкүл әрәмәләре, Актаныш халкының борынгыдан сабан туйлар үткәргән Агыйдел тугайлары, Чаллы плотинасын гаепләп, инде хөкем карарын көтеп калган җан иясеdәй өнсез яталар.

Әмир үзен бораулау агрегаты белән су төбендә, дөресрәге аквариум эчендә йөргән сыманрак хис итте. Әнә, Уразай белән Такталачык арасындагы борынгылар зиярәтын урыныннан куптарганнар—каберлектән чыккан изге сөякләрне конфет-печеньелардан бушаган әрҗәләргә салып, тау башына күчереп күмәләр. «Бер генә кабер дә сусаклагыч төбендә калырга тиеш түгел!» дигән обком карары бар.

Изгеләр зиярәтына соңгы йөз елда бер кешене дә күмгәннәре юк, шуңадырмы, Уразай белән Такталачыкның олысы-кечесе һич курыкмыйча, җирәнмичә археологлар төркеменең кабер чистартканын күзәтте. Дөрес, анысы, авыл халкы борынгы зиярәттән алтын-көмеш чыкканны көтә иде. Ләкин алпавыт болыны чаклы изгеләр зиярәтыннан өметләнгән хәзинә чыкмады. Һәр баш сөягенең зур чүлмәк эчендә ятуы—археологлар тиз генә аңлата алмаслык ачыш иде. «Ник алай?! Нәмә булган?!» дип, сорап интектергән авыл халкының авызына сүз булсын өченгә археологлар аңлатма бирде: бу тирәдә яшәүче борынгылар ни өчендер мәетнең башына чүлмәк кидереп күмгәннәр. Ни өчен икәне Казанга кайткач, галимнәр консилиумында ачыкланыр, диделәр. Күрәсең Актаныш ягының борынгы бабалары да байлык мәсьәләсендә оныкларыннан ерак китмәгәннәр. Борынгыларның акылы алтын булган!

Чулманның Агыйдел белән очрашкан төшендә биш мең кешелек Дербёшки бистәсе бар иде. Юк инде ул... Биш мең тәрәзәле эшчеләр, балыкчылар, һөнәрчеләр һәм колхозчылар белән гөрләп торган татар үзәге су астында калырга тиеш. Шыңгырдап торган борыслардан салынган ике катлы йортларны утынга ташып бетерделәр. Су басасына ышанмыйчарак торган кайберәүләр һаман да гомер бакый яшәгән өйләрен ташлап китәргә ашыкмады. Соңгы чиккәчә кузгалмады. Бары тик Партиянең Актаныш райкомыннан соңгы кисәтү итеп өч ай вакыт бирелгәч кенә, Дербёшкида мәхшәр башланды. Кемнең кайда туганы, барып урнашырдай өмете бар—шунда ашык-пошык төялеп чыгып качты. Гаиләсендә кул көче житәрлек булганнар ул өйләрне күрше авылларга күчереп салды. Ятим калган күпчелек биналарны, бөтен Актаныш халкы, бушлай урманга ябырылган кебек утын итте. Агыйделнең теге ярыннан чәере агызылмыйча ташылган нарат борыслар такта белән тышланганга күрә сап-сары булып сакланган. Китәсе кеше сүтелгән өйләрнең һәр агачын чемоданга салырдай булып кызганып карады, уфтанып саубуллашты, елап таралышты. Таш нигезләрне, ташпулатларны Чулман дингезе йотачак.

Һәр дәүләтнең су төбендә язмышы бар...

Су астында калырга тиешле авыллар исемлегендә Иске Актаныш

үзе дә бар иде. Тау башыннан 110 сайгаклы баскычлар буйлап аска таба төшсән, Иске Актаныш авылына, жырына-моңына, «Үзәк» колхозына, шифаханәсенә, ширбәтле конфетлар пешерә торган икмәк заводына, мәдәният сарае чаклы итеп салынган ашханәсенә, банк һәм почтасына— кыскасы, дүрт мен кеше яшәп яткан гүзәл атауга килеп керәсен. Һәм шушы яшел атау су астында калырга тиеш. 110 сайгаклы басмалар жырлары белән суга баткан Актанышка алып төшәчәк. Авыл уртасындагы тупылталларга ияләшкән чәукә-каргалар кешеләргә ияреп тау башына күчәргә тиеш. Жылы яктан Актанышны гына сагынып кайта торган сайрар кошлар нәүмизләнеп, тау ягыннан оя эзләргә тиешләр.

Актаныш халкы икеләнеп калды. Имеш, Агыйделнең су ярына дамба күтәреп авылга суны кертмәячәкләр икән, дип тә сөйлиләр. Ләкин бик кыйммәтле эш ди бугай, авылны яна жиргә күчереп салу арзангарак төшә, ди, ахрысы. Чөнки райком күченәсе халыкка менәр тәнкә акча белән транспорт бүлеп бирсә, яна нигезгә күченүнең бөтен авырлыгы— сүтү-кору, төяү-бушату һәм торгызуы, дукамент артыннан йөрүләре һәм кайгылары һәр гаиләнең үз жилкәсенә төшәчәк.

Шул ук вакытта, Актаныш басмаларының югары баскычларына бәрәңге бакчаларын терәп, тау башында ашык-пошык салынган фин йортлары калка башлады. Фин йортларының яна хужалары райком инструкторлары, башкарма комитет хезмәткәрләре, төрле чиновниклар, урта звено житәкчеләре иде. Шуңа күрәме, тау башындагы яңа йортларны Актанышның гади халкы өнәмичәрәк: «Нахаллар бистәсе» (Нахальный поселок) дип атады. Нахаллар бистәсенең ашыгыч төзелүе, тиз калкуы Иске Актаныш халкының икеләнүләрен-шикләнүләрен көчәйтте генә. «Нахаллар» Иске Актаныштан качалар икән—димәк, гомер кичергән нигезләрне саклап калыр өчен яр буена дамба өелмәячәк, димәк, район су төбендә калачак. «Нахаллар» барысын да алдан белеп тора... һәм Актанышлылар Агыйделнең иске үзәнендә яна йортлар күтәрүдән туктап, искеләре жимерелгәнче, ә бәлки күчеп киткәнче генә булса да искеләрендә яшәп торырга тәвәккәлләделәр. Плотинаның ябылып Чулман белән Агыйделне күтәрүен халык мордарларчы көтте. Муенга элмәк киелгән инде, кемнендер килеп аяк астындагы коры жир кисәген тартып алуы гына кирәк. Борчулы халыкны хәвефле хәбәрләр изде... Изгеләр зиярәтын күчерүләр тарихи тамаша булган икән ул. Ә син менә чирәм үсәргә дә өлгермәгән яна каберләрне ачып, өчесе, жидесе, кырыгы да үткәрелмәгән гүр ияләрен күчереп кара... «Йа, Хода, кем каргышы төште икән безгә?! Кайбер мәетләр ләхетләрендә йөзтүбән борылып яткан, соңгы елларда мәрткә китеп кенә күмелүчеләр күп булган, ди... Чиялек авылында яна каберне казудан туганнары баш тарткач, экскаватор белән актарганнар, самосвалга төягәндә әчәгеләре чүмеч тешләренә уралган, ди... Күреп торучыларның күбесе аңын югалткан, ди...» Шомлы хәбәрләр "дия-дия" телдән-телгә күчеп, Актаныш халкын тере мәеткә әвереллерде.

Ләкин, Куйбышев сусаклагычының Иделне тиешенчә күтәрергә көче житмәгән кебек, Чаллы ГЭСы эшли башлагач, Чулманның Агыйделне ярларыннан чыгарырга гайрәте житмәде. Симез борынлы инженерлар ике елганың мөмкинлеген исәпләгәндә ялгышканнар булып чыкты. Иске Актаныш әле бүген дә Агыйделнең иске үзәнендә яшәп ята. Хәер, монысы киләчәккә ишарәләү.

Ә бүген—1969 елның салкын декабрь ае.

### Нахаллар бистәсе

Яна Актаныш төзер өчен мәйдан итеп «Нахаллар бистәсе» белән Актанышбаш авыллары арасындагы иген кырлары, клевер һәм печән басулары бүлеп бирелгән иде. Яна урында «су басу» шаукымы

белән бүлеп бирелгән акча фондына мәһабәт административ бина, шәһәрчә универсаль кибет, ведомстволар өчен аерым йортлар, бюрократик конторалар һәм күпләгән оешмалар өчен заманча корылмалар төзелде. Житәкче оешмалар тау башына төпләнеп, гади халык аста Агыйдел үзәнендә утырып калды. Хәер, монысы да киләчәк эше...

Яңа Актаныш шәһәрен эчә торган су белән тәэмин итү өчен унжиде скважина кирәк иде. Күчергеч кәгазь аркылы сызылгандай унжиде проект буенча, бер үк тирәнлектән алынган унжиде коеның суы бергә кушылып, зур чанга жыелырга тиеш һәм Яңа Актаныш шәһәренә артыгы белән житәргә тиеш иде...

Әмирнең бригадасы вакытлыча Казандагы «Водстрой»га буйсынудан туктап, Актанышның партия райкомы карамагына күчкәндәй булды. Моннан ары ни эшләсәң дә, ни уйласаң да, иң әүвәл райкомның икенче секретаре Галимжанов белән киңәшләшергә кирәк иде. Шул ук вакытта бораулаучы егетләргә хокуклар да өстәлде: ихтыяж төшсә, районның теләсә-кайсы хужалыгына техника һәм ярдәм сорап керергә ярый! Хәтта су ташучы «ГАЗ-53» машинасының ике кешелек кабинасында Әмир, Фазыл һәм Мәдиярга өчәүләшеп утырып йөрергә рөхсәт бирделәр. Актаныш урамында өчәүләшеп бер кабинада йөргән бораулаучыларны күргәч, ГАИ инспекторлары гына түгел, гади халык та исе китмәс булды.

Унжиде кое борауланасы урынны күрер өчен газикны райком ишеге төбендә калдырып, Галимжановның «УАЗ»игы белән киттеләр. Эш мәйданы клевер басуы дип аталса да, юмарт бураннар бөтен кырларга көпшәк кар япкан, «вездеход» кушаматлы «УАЗ» «Нахаллар бистәсен» чыгып озак бармады, дүрт көпчәген бушка зыр-зыр әйләндереп, кар өстендә эленеп калды. Клевер басуының жәяүле бураны бәйдән ычкынган төсле аркылы-торкылы тузына, басу куенында кар кайнап тора.

—Бораулыйсы урынга кар ерып барып торуның кирәге юктыр, әнә, күренеп тора ул,—диде Галимжанов, машинада онытылып калган бүреген сагынып. Ул, очучыларныкы төсле эче мехлы күн курткасының биек якасын күтәрергә уңайсызланып, бармакларын тараксыман итеп, кар кунган озын чәчләрен әледән-әле артка сыпырып торды.

—Сырган чалбарны киясе калган,—диде Мәдияр, балак очларын итек куныччына тутырып.

—Шарф аркылы үтә бу жил,—дип сүзгә кушылды Фазыл.—Кыш көне бораулауны кем уйлап тапкандыр?..

Әмир райком секретаре янында жаваплылыкны онытмаска тырышты.

—Безнең якларда яз сулы, көз пычраклы, кыш көртле! Жәй өч кенә ай ул. Өч ай эшләп тугыз ай табан суырып ятарга аю түгел лә син! Бер башланып китсә, эш күңелне жылыта ул. Иртәгә бульдозерлар юл ярсын. Аннан агрегатны, вагонны алып килербез... Ут сузасы иде... Мондый жилдән качып жылынырлык урын булмаса, беренче скважинада ук кәкрәерсең.

—Юлны бүген үк ярып куярлар. Үзегезгә аерым бульдозер беркетербез, нишләргә кирәген үзегез әйтеп торырсыз. Тәк, бульдозер, кабель сузып ут бирергә. Тагын...—диде Галимжанов, егетләрне ашыктырып.

—Пока житеп торыр,—диде Әмир, УАЗикка таба борылып.

Егетләр килгәнче райком шоферы карны казып машинаны кайтыр юлга борып куйган. Әмир белән Галимжанов утырганнан соң, биш кешелек УАЗикка башкалар сыймас кебек калды. Сыйдылар. Әллә кабина артык иркен, әллә Әмир белән Галимжановтан кала башкалар гәүдәгә кайтышрак булганга—аңламассың. Фазыл тәрәзәдәге бозны әле өреп, әле уч төбе белән жылытып урам ягыннан нидер эзләгәндәй итте. Моны Галимжанов та сизеп алды.

—Исемеңне Фазыл диден бит әле... Нәрсәне дә булса оныттыкмы соң? Тәрәзәдән күренмәсә, әйдә, туктап төшеп карыйк.

—Онытмадым... Уйлап барам. Әгәр кичтән бульдозер юл ярып куйса, жәяүле буран төн чыкканчы күмеп ташлый инде аны. Ачылган

юлны кар тагын күмсә, тиз генә чистартам димә. Янәшәгә яна юл салуын мен тапкыр лутчы. Минемчә, бу клевер басуын кар тоткан кебек унышар полоса белән ертырга кирәк. Җәяүле буран төенчекләрен кырыйдагы юлларга өя тора, кар урталагы юлны тиз генә күмә алмый. Бульдозерның көннәр буе безне саклап ятуы да кирәк түгел.

Әмир, Фазылның үзеннән узып, райком секретаре алдында акыл сатып торуын ошатмады.

—Синен кыш көне бораулаганың юк бит әле. Каян беләсен сон син җәяүле бураннын нишлисен?

—Авыл малае ла мин. Тагылмалы сабаннын тимер утыргычына бәйләнеп буразналар сызган кеше.

—Әйе шул, кар тоту ысулын кулланып, басу өстен сызгаласак, юлыгыз һәрвакыт ачык булыр!

Фазыл райком секретаре белән башланган бу җайсыз әңгәмәне икенче якка авыштырырга теләде.

—Аккүз авылы еракмы ул моннан?

—Утыз чакрым!—диде Әмир, Фазылның кемнән җавап көткәнен белмәмешкә сабышып.

—Әйе, егерме жиде километр,—дип өстәде Галимжанов.—Әллә Аккүз авылында туганнарыгыз бармы?

—Туганнар өчен кем шулай өзгәләнә инде?—диде Мәдияр, тавышын шарф эченә яшереп,—Фазылның анда сөйгән кызы бар, дүрт ай инде күрешкәннәре юк!

—Сөйгән кызы?!—Әмир кинәт аптырап калды.—Кияү, синен белән безнен әле «Чишмә» колхозында, ну Аккүз авылында бораулаган юк ич, каян килгән ди ул сөйгән кыз?!

Фазыл өчен Мәдияр җавап бирде.

—Фазыл дөньяга бүген генә тумаган ла! Бәлки ул кызлар белән юлда таныша торгандыр, әйеме, кияү?!

—Сәер, Фазыл сезнен икегезгә дә кияү тиеш икән. Әллә сез бертуганнармы?

—Безнен белән берәр ай эшләсәгез, гафу итегез, сезгә дә кияү дип дәшә башлыйбыз әле без.

Әмир Мәдиярга усал итеп карап куйды:

—Син кем белән сөйләшкәненне азрак чамалап утыр инде, беспартийный дигәч тә...

—Зарар юк, егетләр. Яшьлек турында сөйләшү безне дә яшәртә!

Райком каршында калган су ташучы машина янына килеп туктагач, Галимжанов Фазылга УАЗиктан төшми торырга кушты.

—Минем машина белән Аккүзгә барып килегез. Шофер сине көтеп торыр, соңыннан үзенне Уразайга кайтарып куярлар.

Әмир тагын каршы чыкты.

—Сон, иртүк эшкә лабаса! Монда без кызлар куып йөрергә килмәдек!

—Зур эш алдыннан зур сөенеч булыр егеткә. Озак тормас ул Аккүздә, кичкә кайтып житәрләр. Кызынның исеме ничек сон?

—Әлфинә,—диде Фазыл, дәресен өйрәнмичә килгән укучы сыман каушап.

—Кем кызы икән ул Әлфинә?

—Самат абыйныкы.

—Ә-ә?! Самат кызымы!!! Фамилияләре Галимжанов икәнен беләсенме син аларнын?

Фазыл бөтенләй коелып төште, дөресрәге УАЗиктан ук төшә башлады.

—Әллә, сезнен туганыгызмы?

—Булса ни? Начар ният белән йөрмисеңдер ич?! Егет кешедер әле?

Мәдиярнын Фазылга ярдәм итәсе килде.

—Егет кенәме сон! Тәмәке тартмый, аракы эчми. Әлфинә—анын әле беренче сөйгән кызы.

—Ярар инде, Мәдияр!..

—Оялырлык берни ишетмәдем әле мин, Фазыл. Мондый кияүләр Актанышка да кирәк. Болай булгач, мин дә сине «кияү» дип атый алам.

Әмир белән Мәдияр Уразайга китеп баргач, Галимҗанов УАЗик кабинасындагы рациянең төймәсенә басты, аннан бер кыз тавышы ишетелде.

—Мәймүнә, миңа бирәр нәрсә бармы анда?

—Обкомнан телеграмма килде.

—Укы әле.

—Чаллыга тагын унике кеше җибәрүебезне сорыйлар. Дүртесе егет кеше—сигезе кызлар булсын диелгән.

—Дербёшкидан күченеп китүчеләр барып җитмәде микәнни? Алар анда егерме биш кеше иде. Егетләре-кызлары, ирләре-хатыннары, киңәш бирер торырга әби белән бабайлары да бар иде...

—Ул турыда телеграммада бер сүз дә әйтелмәгән.

—Ничә көн биргәннәр? Унике кешене эзләргә дим?!

—Бер атна эчендә!

—Вакыт бар икән әле. Мәймүнә! Мине бурильщиклар белән йөри диярсең. «Чишмә» колхозына киткәнемне үзең генә белеп тор. Алай-болай Первый сораса, әйтерсең, абыйсын күрергә китте диярсең. Пока, сенлем!

Аңлашылса кирәк, Галимҗанов «кияү « Фазыл белән бергә Аккүздәге Самат абыйсы янына, ягъни Әлфинәләргә китте.

—Һинд киноларында гына түгел, татар егетләре язмышында да очраклы хәлләр еш булып тора, кияү агайне...—Галимҗанов алгы рәттә утырган килеш, яртылаш борылып, Фазылга сөйләп барды.—Тыңлап торсаң, үземнең язмыш та кинодагычарак минем.

Галимҗанов, кондыз бүреген салып, гадәттәгечә бармаклары белән чәчен тарап алды һәм яңадан башына киде. Фазылның йотлыгып тыңлыйсын беләдер кебек иде ул. Чөнки райком секретаренең хатирәләре Әлфинәләр капка төбенә килеп җиткән шикелле...

—Өченче класста укыганда безне—башлангыч класс малайларын чаңгы ярышына алып бардылар. Чаңгыларны кузовка төядек. Колхоз биргән машинаның шоферы минем әти иде, шуңа күрә кабинага утырып бардым. Башка малайлар кебек кузовта утырып барсам туңармын дип түгел, әти машинасы булганга—горурланып утырдым мин кабинага. Ярышта әллә ни җиңә алмадык бугай. Ә кайтыр юлга чыккач, әти машинаны район больницасына борды... Тыңлыйсыңмы син, Фазыл?

—Әйе, әйе, тыңлыйм. Сөйләгез!

—Вәт, район больницасында Каенлыкның бер килене бәбиләгән дә аны алып кайтыр вакыт җиткән икән. Башка машина булмаганмы, райкомнан кушканнармы —анысын белмим, әти мине кузовка куып меңгерде. Минем урынга кызыл юрганга төрелгән, төймә борынлы кечтеки кызын күтәреп, Каенлыкның килене кереп утырды. Аның ире безнең белән кузовта кайтты. Әтисе кызга Фәйрүзә дип исем кушарга тели икән. Юл буе малайлар мине үртәп кайттылар: Каенлыкның кызлары усал, туып ике көн яшәмәгән—ә үзе Аккүзнең ун яшьлек егетен кабинадан куып чыгарды, диделәр. Каенлыкныкылар күршегә йөреп укыды, ул авылның мәктәбе юк, кечкенә ул. Мин унынчыга күчкәндә Фәйрүзә беренче класска килде генә әле. Ни өчен сөйләде дип беләсең син боларны?

—Фәйрүзә Әлфинәнең туганы булып чыгамы?

—Алай бик гади генә түгәрәкләмә әле, Фазыл. Фәйрүзә апан—Каенлыктагы Ниса кортканың кызы—минем хатыным булып чыкты. Ә Самат абыем Фәйрүзәнең апасына өйләнде, шулай итеп без абый белән бер-беребезгә бaҗайлар да әле.

—Ә Фәйрүзә апа?

—Нәрсә Фәйрүзә апаң? Аңа берни дә булмады. Баштагы мәлне

туганнары мина—син карт бит инде, кызыбыздан ун яшькә олы дип, ирек бирмәгәннәр иде. Еллар үткәч, дөнья тигезләп куйды... Хәзер Фәйрүзә апана 50, мина 60 тулып килә... Карт әби инде ул... Ә мин һаман унсигездә...

—Мина унтугыз шул инде...

—Һәй, кияү апаем, үзенә таман гына яшең!.. Самат абыйларның хәйран озак кына балалары тумый торды. Әлфинә берләнбер кызлары—олысы-кечесе берүзе. Самат аны борынгылар учак саклагандай саклый, җил-янгыр, тел-теш, ут-күз тидермичә генә. Кыз баланы өйгә ябып куя алмыйсын шул. Мәктәпне тәмамлагач, укырга дип китәр дә... вәссәләм. Гел әтисен иярте йөрмәс. Кыз бала үскән саен ата-ананың күз-колагыннан, үгет-нәсихәтеннән ерагая...

Әлфинәләрнен өе тыкрык буенда икән. Машина килеп туктагач, ян тәрәзнен пәрдәсе селкенеп куйды. «Әлфинә түгел микән?» дигән уй Фазылнын тәнен ток кебек яндырып үтте. Самат абый малахаен кыңгыр салып, бажай-братын каршы алырга чыккач, Галимжанов шундук Фазылның хәленә керде.

—Абый су ташырга ерак, буралап кое казытырга кирәк дип зарлана иден. Менә, чын кое казучы егетне алып килдем үзенә.

—Беләм мин бу Казан жулигын, казыган коеларын күргәнем бар,—дип жавап тотса да, Самат абый Фазыл белән күрешергә туганнарча ике кулын сузды...

### Әлфинәле багана

Фазылны беренче тапкыр күргәннән бирле Әлфинәнен рухи дөньясы икегә бүленде. Монарчы аның уе, Ленин бабай әйткәнчә: укырга, укырга һәм укырга иде. Ә хәзер укудан соң вакыт күп кала башлады, дәресләрне ашык-пошык әзерләп куя да билгесез тарафлардан килгән Фазыл хатларын укый башлый. Кыз аларга жавап яза язуын, тик жибәрергә адресы гына юк. Фазылларның вагонын эзләп табар һәм куып житәр өчен махсус хат ташучы тотарга кирәк бит ул. Фазылның һәр хаты мәхәббәт турындагы китаплардан ертып алынган өзек-өзек битләр кебек һәм алар мәңгегә аерыласы парның бәхилләшү сүзе кебек янгырый. Егет, ниһаять, бөтен илне аркылы-торкылы гизеп, табылган газиз ярын югалтудан куркып шулай өзгәләнәме, эше бик хәвефлеме, тагын житди сәбәбе бармы?.. Белми Әлфинә, белми-анламый, анлар өчен тәжрибәсе житми. Ул Фазылдан килгән хатларны класссташ кызына—ун ел буе бер партада утырып, инде тәмам аерылмас туганына әверелгән Долореска укытып бара. Долорес егетләрен еш алыштыра, күбесенчә клубта, нәкъ Фазыл яшендәгеләр белән чуала. Жәй көне генә түгел, көзге озын төннәрне кичеп таннар аттырганы бар, хәтта шул сәбәп белән укуына килмичә калган чаклары да еш була. Һәрхәлдә, Әлфинә алдында үзен кинәшкә ярардай дус итеп тоярлыгы бар анын. Ләкин Фазылның хатларын укый башлагач, Долорес каушап кала. Газета битләрендәге бер адрес белән хат алышкан иде Долорес. Кияүгә чыга алмый калган сазамык булып, юри кызык өчен. Газета таныштырган егет Долореснын фотосын сорап язгач, ул ана әнисенен яшь чагындагы рәсемен жибәргән иде. Газетадан беллерү алгач, Долореска ул адресны әнисенә күрсәтеп карарга кирәк булган. Ләкин кызнын әниләр белән кинәшеп тора торган чагымы? Әнисе, Долорес кулындагы конвертнын адресын күреп алгач, яна яуган Актаныш кары төсле агарып калды. «Кызым нишләден син!—диде ул өзгәләнеп—УЭ-148/3А дигән жир ул төрмәләрнен берсе ләбаса!» Ә Долореска килгән хатлар тылсымлы, гипнозлы иде. Аларны укыгач, шул хат юллары буенча китеп, хужасын эзләп табасы килә иде... Долорес Фазылның хатларын укыганчы иң әүвәл конверттагы штампларны жентекләп карап чыга иде. Жибәрүче кешенен адресы булмаса да, аларда авыл исемнәре гел үзгәреп тора.

Почта суккан дегетле түгәрәкләрдә Киндерле, Чыршы, Әлдермеш, Сая, Торнаяз, Күлбаш, Шәле авылларының исеме ачык укыла. Татарстан картасыннан да эзләп таптылар ул авылларны. Юк, төрмәдәге кеше алай еш урын алыштырмас, бер тирәдәге кечкенә татар авылларын тоткыннар оясы итмәсләр. Фазыл гади бер зимагур —эш урынын, йокы бүлмәсен үзе белән сөйрәп йөри торган ирекле егет булса кирәк.

Әлфинә бу хат алышуның азагы булмас, булса да хат алышудан ары китмәс, авыл егетләре бөтенләй кул селтәгәнче онытырга кирәк, ваз кичәргә кирәк Фазылдан дип, ничә тапкырлар җыенды. Ләкин нәкъ шул көннәрдә тагын хат килеп төшә. «Актанышка озаклап эшләргә киләсебез бар, көт мине, тынычлап укы", дигән сүзләр сүреләсе учакны дөрләтеп җибәрә. Килергә тиеш Фазыл, әгәр язган сүзләре чынлап булса, килергә тиеш. Әлфинә Фазылны яз көне килер дип көтә иде. Ул аны менә шушылай, бүгенгечә, декабрьнең 20 градуслы салкынында, үзләренең капка баганасына сөялеп, Әлфинәнең мәктәптән кайтканын көтеп алыр дип башына да китермәде. Өметләнергә кыюлыгы житсә житәр, әмма бүген күрешербез дип уйларга көче житмәс иде.

—Мин сезне урамда көтәрмен дип, Галимжанов белән саубуллашып чыгып киткән Фазыл, капкага кысылып калгандай булды. Өй түрендә торсаң, авылның күз алдына чыгасың, ишек алдында калсан—шикле кеше сыман. Урамда, әнә, букчаларын күтәреп, бала-чагалар йөгерешә. Аларга ияреп тунган, ачыккан, өй жылысын сагынган килеш Әлфинә дә кайтып житәр. Кыш көне ничегрәк икән ул?

Әлфинәнең мәктәпкә йөри торган үз сукмагы бармы—ул рәшәткә баганасы артында посып торган наян сыман кинәт пәйда булды. Биек үкчәле итекләре, иңенә ягылып торган драп пәлтәсе, жылылык бөркеп торган күпертмә ак төлке якасы аны бераз олыгайтып күрсәтә. Әгәр, менә хәзер Әлфинә белән өр-яңадан танышасы булса, Фазыл аннан: «Ничәнче класста укыйсың?» дип сорамас иде, кайда эшлисең дияр иде. Буйга үсмәсә дә, сынга үскән кызый. Яшел жирлеккә эре-эре чәчәкләр төшерелгән чуклы шәлгә төрелүе һәм шул чәчәкләр арасыннан төбәлгән самими карашы гына Әлфинәгә балалык кыяфәте өстәп тора.

Алар икесе бер капкада туктап калдылар. Башка сыенып урын юк: урамга төшсәң, көпә-көндез мәктәп баласына ияреп йөрүнең әхлакый ягын әйләндерерләр. Ишек алдына үтсәң, тагын кыен—зур тәрәзә күзеннән качып котылыр урын юк. Әле ярый, тар капканың баганалары ике баһадирсыман, егет белән кызны үзенә сыендырды.

—Әлфинә!.. Сагынып үләр дәрәжәгә житкән кешене күрәсең киләме?

—Мин бүген синнән хат булыр дип уйлаган идем. Шуңа ашыгып кайтып киләм.

—Җаваплар яздыңмы соң?—диде Фазыл, Әлфинәле баганага авышыбрак.

—Тапшырылмаган хатлар язып исәрләнергә мин—Галия, син—Искәндәр түгел. Адресың юк ич синең. Язмышың белән качышлы уйнаган кебек.

Якын килеп этешеп-төртешә басып торуларын күзәтүче булса—бер-берсенә юл бирергә теләмәгән кәжә бәтиләре дип үртәрләр иде инде аларны. Шөкер, күрүче юк.

—Әтинең күзенә күренергә куркып торасыңмы?

—Самат абый белән чүкердәшеп чәй чөмердек инде. Җәй генә житсен, мин сезгә килеп кое бораулап китәм.

—Әйе, китәрсең шул. Җәй житкәндә жилләр исәр әле үзеңнән. Кайдадыр җәһәннәмдә минем шикелле башка берәүнең башын әйләндереп йөрерсең. Хатларыңның авыл исемнәрен җыйсаң... Куып тотарлык түгел.

—Әлфинә! Мин Актанышка бөтенләйгә килдем.

—Ничек инде?

—Без бер урында унжиде скважина борауларга тиеш. Син укып бетереп, имтиханнарыңны тапшырып, аттестат алганчы мин гел Актаныштa

булачакмын. Чыгарылыш кичәнә дә киләм әле!

—Аннан тагын югаласыңмы?

—Сон, мәктәпне тәмамлагач, үзен дә китәсен ләбаса.

—Минем адресым булачак. Укырга керсәм, тулай торактан, керә алмасам, авылдан эзләргә мөмкин. Хәер, педка керә алмасам, авылга кире кайтмыйм—монысы точно инде! Сине каян эзләргә, Фазыл?

—Ерак китмәм.

—Пединститутның ишек алдында бораулап ятарсынмы?

—Әлфинә, әллә бу синен киләчәк турында сөйләшүенме?

—Билгесез киләчәк алдында торам ич мин, Фазыл.

—Мина да шулай инде ул. Киләчәгемне белер өчен сине эзләп киләм.

—Сирәк киләсең бит! Минем сине көн саен күрәсем киләдер бәлки, Долорес кебек көн саен клубка чыгып биисем, җырлыйсым киләдер...

—Әлфинә! Имтиханнарга әзерлән син лутчы. Мин хәзер еш килермен. Көн саен булмас, ләкин бик еш килермен. Тизрәк тәмамла шул мәктәбенне!

—Тәмамлагач ни?

—Мин бораулаучы эшен ташлыйм.

—Чынлап әйтәсеңме син, Фазыл?! Минем өчен, мин дигәндә яраткан эшеңне ташлый аласыңмы?

—Син әйт кенә, ике дә уйламыйм!

—Валлаhи, билләhи, аллам орсын, җир йотсын диген?

—Икмәктер, Әлфинә! Синен өчен яшисем килә минем...

Әлфинә чәчәкле башын капка баганасына сөяп, күзләрен йомды. Аның иннек якмаса да, иннек төсенә кергән иреннәрен үбеп алырга шундый җайлы минут иде бу. Ләкин әтисенен капка төбендә көпә-көндез мәктәп укучысын үбеп маташу Фазыл җинә алмаслык киртә иде. Тырналган язгы каен кәүсәсеннән саркып чыккан су тамчысы кебек, Әлфинәнен йомык керфекләре арасыннан бөртек-бөртек күз яшьләре сытылып чыкты. Ул бөртекләр кызнын бит алмасы буйлап йөгереп, Фазылдан оялгандай, тиз арада шәлъяулык чәчәкләре арасына кереп югалды. Фазыл ул бөртекләрнен берсен чак тотып, бармак сыртына алып тел очына тидерде. Каен суы тозлы буламы! Бу бит Әлфинәнен каргышлы, нәфрәтле, әрнүле, елаулы күз яшьләре түгел. Кызларнын моңарчы җыелып килгән шик-шөбhә бозлары, Фазылнын кайнар вәгъдәләреннән эреп, күнел дәрьясыннан тамчы-тамчы булып чәчелде. Сөенечле күз яшьләре hәрвакыт татлы була, Фазылның тел очындагы яшь тамчысы—Әлфинә белән беренче тапкыр үбешү бәрабәренә килгән татлы халәт иде...

Галимҗановнын ашыгасы билгеле, ләкин аны менә шушы минутта кайтыр юлга әйдәп чыгып басар дип уйламаган hәм теләмәгән иде Фазыл. Ярты ел буе зарыгып көткән, өметләрне аклаган, ниhаять, ягымлы тембрга күчереп сөйләштерә башлаган очрашу тагын аерылышуга алышынамы? Ник шулкадәр көчсез соң кеше?! Кал бүген кыз өендә, кунак бул. Самовардагы сурәтләренә карашып, төннәр буе сөйләшеп утырыгыз. Кулын җылыт, чәчен иснә, куенына кыс! Караваты читенә урындык куеп кызның йоклаганын карап утыр! Тынла, сөйлә! Соклан! Дулкынлан! Ярат!.. Юк, болар берсе дә тормышка аша алмый! Син туганчы язылган кануннар, Фазылны тыярдай горефләр, Әлфинәне саклардай йолалар... адәм баласын утлы газаплардан, яшерен өметләрдән чигенергә мәҗбүр итә. hәм юл тагын алып китә. Әле бая гына сине сөйгәнен янына ашкындырып алып килгән юл инде кайтыр юлга ашыктыра, аерылырга куша.

Әлфинәнен каушавын аңлап, Галимҗанов юатырга теләде:

—Йә, сеңлем, тагын сөйләшеп утыра алмадык инде... Китәм.

—Ник кунып китмисен, абый? Иртәгә чаклы партиягез синсез дә яшәп торыр.

—Һи, кызым. Синең күз төбендә кызыл кар бөртекләре эрегән. Көфер сүз сөйләми тор... Партия минсез яши алыр ул, мин партиясез яши алмам шул...

Кара куян бүреген кара кашларына чаклы батырып кигән Фазылны күргәч, Галимҗанов аны да юатырга теләде.

—Йә, Фазыл апаем! Әлфинәгә су алырга җайлырак булсын өчен коены кая казырга кирәк дибез инде? Менә бу өй түрендәге бакчаның рәшәткә эченәме?

—Юк. Безнең агрегат бу рәшәткәгә сыймый. Уналты метрлы вышканы күтәрер өчен электр чыбыклары да мишәйт итә. Минемчә, тыкрык ягыннан килеп «плугарь» бакчасына кереп урнашсаң ярый. Суын өйгә кертәсең. Кнопкага басу белән өй эчендә чишмә ага башлый.

—Әйбәт бит, ә! Абый, әйеме? Ә-ә, Әлфинә?—дип яшьләр өчен сөенүен белдерде Галимҗанов.

—Язлар житкәч инде,—дип, Фазыл эшлекле кыяфәт белән Самат абыйга кул биреп саубуллашты.—Кыш көне мәшәкате күбәя аның...

## Ташка кадак какканнар

Ун гектарлы үлән басуын, проектта күрсәтелгәнчә унжидегә бүлеп, беренчесенә бораулау агрегатын китереп урнаштыргач, кышкы мәшәкатьләр арта торды. Вышканы күтәргәч, озакка сузмыйча, кышның усал җилләрендә аумаслык итеп дүрт арканның очларын берәр метрлы тимер чөйләр белән дүрт якка кагып тарттырасы бар иде. Мәдияр беренче чөйгә олы чүкеч белән биш-алты тапкыр суккандыр—керми теге... Ташка кадак каккан кебек бозланып тунган жир өсте кире бәрә. Бер кулына чүкеч күтәреп, икенче кулың белән чөйне тотып торып кына майтара торан эш түгел иде бу. Фазыл белән кул алыштырып, зур чүкеч белән алмаш-тилмәш кыйный торгач, шактый тир түгәргә туры килде. Егетләрнең: «Керми бу! Әллә таш җәйгәннәрме монда? Зуррак кувалда кирәк безгә»—дип зарлануларына исе китмичә, арбадагы пычрак су насосы тирәсендә бөтерелгән Әмир баштарак: «Очы керсә, керә ул!» дип кенә котылмакчы иде, ләкин көчле кыйналудан тимер чөйнен түтәсе чәрдәкләнгәнне күргәч, үзе дә ярдәмгә кушылды.

—Ахырынача кагып бетерик, юкса кире чыга! Бозны чәрдәкләп кергән чөй нык тормый ул!

—Җәй көне булса, чөйләргә ике генә сугасың инде...

—Кияү! Буровойда җәй белән кыш дигән сүз юк. Эш рәте гел бер төрле. Просто күнегергә генә кирәк.

Мәдияр да Фазылны яклады:

—Бәлки өч аркан да житәр.

—Үзең мастер булгач берне генә кагарсың, яме, вышканы тартып аударыр өчен генә!.. Барыгыз, әнә пычрак насосны урнаштыра торыгыз, моны үзем кагып бетерәм!

Чөйне кагып бетергәч, Әмир уйга калды...

«Чөй кагуның ние бар... « Ким дигәндә сигез кубометрлы отстойник чокыры казыйсы бар бит әле. Дөрес, көрәү, казу, торба китерү кебек мәшәкатьләр заказчик эшенә керә... Ләкин, туң җирне казу кем жилкәсенә төшә дип кенә котыла торган афәт түгел бу. Вакыт кадерле, вакыт санаулы... Вакыт ул акча янчыгына ком сәгате аркылы керә.

Чокыр казылырга тиешле урында, карны көрәштереп, жирнең өстен ачкач, тунга тө ркәләп караганнар иде: көрәк кәкрәя, лом сикерә, балтадан утлар оча. Шакыраеп каткан жир очкын-очкын булып кителә, ләкин казылмый.

Актанышбаш авылында Казан егетләре авылга су кертеп яталар иде. Галимҗанов алар белән сөйләшеп көпчәкле экскаваторларын алып

килде. Ләкин экскаватор чүмече белән күпме генә сукмасын—жирне казу түгел, хәтта кыра да алмады, ахыр чиктә, чүмечнең тешләре сынмагае дип, экскаватор килгән юлыннан китеп тә барды.

Галимжанов каушады. Күр инде син, ә! Тигез жирдә Чаллы кебек шәһәрләр, очсыз-кырыйсыз тайгаларда БАМнар, Сургут-Нефтьюган кебек нефть промыселлары күтәрелгән бер чорда, Актанышнын ниндидер бер Нахаллар бистәсе кырыенда, клевер чәчәк ата торган болында ике метр буйга, ике метр аркылыга чокыр казып булмасын инде, ә?!.

—Әмир, син беренче ел гына эшләмисең бит инде, башка вакытларда кыш көнәнәре ничек жинә идегез соң сез мондый туң катламнарны?

—Килеп урнашкач, карын гына көрисе кала иде. Безнең киләсене көткән хужалар чокырны жәйдән үк казытып куйган булалар иде.

—Гел шулаймы? Гомерең буе эшләп бер тапкыр да үзенә казырга туры килмәдеме?

—Әгержедә Сокман авылында казыганыек. Башта утын өеп учак яктык. Дөрләп янгач, пычкы чүбе белән күмдек. Бер атна пыскыткач, туңы эреде. Көрәк белән генә казыдык.

—Атналар буе көтәрлек вакыт юк. Тагын да тизрәк казый торган ысул бар микән?—диде Галимжанов, уйга калып.

—Юк,—диде Әмир, исе китмичә генә.

—Бар бугай!—диде Фазыл, икеләнебрәк.—Багана төбе казый торган шнеклы трактор тапсагыз... Туңны тишкәләсен, аннан кантары белән куптарып-куптарып алырбыз.

—Ә сезнең бораулау станогы белән генә тишкәләп булмыймы?—диде Галимжанов, ачышка ачыш өстәп.

—Була!—диде Әмир, ургәүле төс белән.—Тик бораулау өчен башта чокыр казып куярга кирәк шул... Әле мин тишәсе тишек саен агрегатны күчереп, монтаж-демонтаж ясап азаплануларны исәпкә дә алмыйм.

—Алайса, багана төбе, дисең инде кияү?!.—һәм Галимжанов УАЗиктагы рацияне кабызды.—«Алло, Мәймүнә! Элемтәчеләргә шалтырат әле, шнеклы тракторлары бар микән? Шнек диген, берүк бутап әйтә күрмә. Бөке ача торган штопорга охшаган нәрсә ул, зур гына үзе... Мин бораулаучылар янында көтәм...»

Элемтәчеләәр кыш көне әллә ни багана утыртып изаланмыйлар икән. Тракторлары сүтелгән булып чыкты...

Икенче көн иртән иң әүвәл Галимжанов УАЗигы, аның артыннан шнеклы трактор, тагын ун минуттан урамнан сәрхүшләр жыя торган бөркәүле машина—«Луноход» килеп туктады...

Егетләр берни анламыйча, бер-берсенә карашып торган арада Галимжанов үзе бораулау остасы ролендә калды.

—Син,—диде ул тракторчы егеткә,—тиз генә менә шушы урында биш-алты тишек тишәсен, араларын якынрак ит, калган балчыкны каерып, китеп-китеп алырга жинелрәк булыр... Ә син, кияү, буровоегызда нинди үткен нәрсә бар—жыя тор, зубило, балта, төртке... очлы көрәк, кәйлә юкмы?

—Өч кешегә ул кадәр корал нәрсәгә,—дип, Мәдияр каршы төшеп маташкан иде, Галимжанов шундук туктатты аны:

—Кем әйтә өч кенә кеше дип! Әнә теге «Луноход»та тагын сигез әзмәвер эшкә сусап тора. Иртәнге ашны ашханәгә алып барып ашаттык үзләрен. Бөтен районнан жыелган «АС»лар.

—«АС» дигәнегез—эштән эшкә очып йөрүчеләрме?

—Юк, кияү, «АС» ул—Актаныш сәрхүшләре. Кем өч тәүлеккә эләккән, кем унбиш көнгә хөкем ителгән... Олы төзелешкә өлеш кертсеннәр.

Галимжановның тиз генә дигәне ике сәгатькә сузылды. Бер метр калынлыгындагы туңны кимереп, «балыкчылар бәкесе» тишү трактор өчен дә шактый азап булды. Инде трактор читкә китеп баскач, «Луноход»тан Галимжановның мактаулы «АС»лары коелды—кем көрәк, кем

кызыл буяуга манылган шахтер кәйләсе тоткан.

—Баштанаяк кораллландыргансыз сез боларны,—диде Әмир, кулындагы ломны ныграк кысып,—сәрхүшләрегез кул белән шаярмасмы?

Галимҗанов кеткелдәп көлде генә.

—Айныгач бөтенесе дә йорт куяны кебек алар, исергәч кенә әтәчләнәләр.

«Луноходтан» соңгы кеше булып озын муенсалы, йон свитер өстеннән кыска плащ-куртка кигән, сыланып торган чалбарлы, колакчынсыз козыреклы бүректән, кыска куныччлы ботинкалы бер агай сикереп төште. Сырган чалбарлы, киез итекле, телогрейкалы, шарфларга уралган иптәшләре арасында сигезенче агай бераз хөртиерәк, мәзәктәгечә Анталиягә дип киткән жиреннән Магаданга килеп эләккән исәр сәяхәтчене хәтерләтә иде. Сигезенче агай машинадан төшүгә барлы-юклы якасын күтәрде, жәһәт кенә курткасының өске төймәсен каптырды. Мәдияр белән Фазылның аңа исе китмәде, алар өчен ул сәрхүшләрнең берсе буларак кына билгеле. Ләкин Әмирнең аңа текәлүе тикмәгә генә түгел... Жәй уртасында да муенын яшереп бөкерәебрәк йөри торган, ике кулы кесәсенә оялаган пилмән бәбәкле Фәритне таныды ул! Фәрит тә, баштагы мәлне кәйлә белән Әҗәкүл пристанена тоз ватарга алып килделәр дип уйладымы, «Луноходтан» төшүгә бораулау агрегаты, яшел вагон, су ташучы мичкәле машина һәм алар янында өч егетне күреп, сискәнеп китте: «Таныдымы-юкмы? Таныргамы-сиздермәскәме?»

Алар бер-берсен танымаганга сабыштылар. Машинадан сигезенче булып төшсә дә, Фәрит беренче булып кулына кәйлә алды, туң жирне чүки башлады.

«Жылынсын, әйдә»,—дип уйлап куйды Әмир, ә үзе әкрен генә Галимҗановтан сораштырырга тотынды.

—Бу пилмән бәбәкле кеше Актанышныкымы?

—Юк, МСОга цемент китергән шофер ул. Колхозчылар йортында кунарга калгач, бер төнгә түзмәгән, кияүдән качкан Баняның мунча ишеген каерып кергән.

—Салкын мунчанынмы?

—Баныя үзе генә юынып яткан булган. Күршеләрен чакырган. Бәхете инде, эш зурга китмәде. Син әйтмешли, бу «пилмән бәбәк» унбиш сутка белән котылды.

—Унбиш көн буе күз алдымда балкыйсы бар икән әле моның...

—Әйе, унбиш көн буе боз ватса, акылга утырыр. Тол хатыннарны бимазалап йөремәс бүтән.

—Акылга утыра торган кеше түгел ул.

—Әллә беләсең үзен?

—Туганым түгел, моның ише дустым, күршем, танышым да юк...

Сигез агай хәлдән тайганчы кыйпылчыклап чокый торгач, кышкы кичнең эңгеренә сигез кубометрлы чокыр, Әмирчә әйтсәк, отстойник әзер булды. Кичке ашка, дөресрәге төнге ялга кайтып киткәнче сигез агай, чокыр ышыгыннан күтәрелмичә генә, тәмәке кабыздылар. Жинүчеләргә хас тавыш белән гәпләшергә тотындылар.

—Өч көнлек махмыр чыкты.

—Боз кыйпылчыгы әллә кайсы жирләремә керде.

—Чыраеңа карасаң, әрлән карьерында эшләгән кебек—гел кызыл ләпек кенә син.

—Мин бу концлагерьдан иртәгә үк котылам. Менә син тагын ундүрт көненне ничек түзәрсең?!

—Мәңге авызга аракы алмаслык иттеләр...

Исемен хәтерлисеңме?

«Нахаллар бистәсе» калын кызыл балчык өстендә утыра икән. Кызыл балчык дымлы, үзле булганга күрә, аның туңы кайсыбер кышларда метрдан артык тирәнгә төшә. Шуңа күрә отстойник казуны җир казу дип атау дөреслеккә туры килми, боз вату диярргә кирәк. Җылы тәнгә чәчрәгән һәр кыйпылчык эреп шундук кызыл кара төсле тимгел-тимгел җәелеп чыга. Икенче көнне эшкә килгәндә «АС»ларның икесенең киеме чиста иде. Җәзалы көннәрен җингән ирләр урынына әкренләп яңалары өстәлә торды... Ләкин... саннары да кимеде. Беренче көнне сигез кешедән торган «АС» бер атнадан ике генә кешегә калды. Бригада беренче скважинаны бораулый торган арада калган уналты урын өчен дә алдан ук отстойниклар казып куеп, авыр эшне җиңеләйтә торырга дип киңәшкәннәр иде. Алдан казып куелган чокырның зыяны юк, аны кар гына күмә. Кар чистарту—боз катламы кимерү түгел. Тик бер атна үтүгә Галимҗанов нибарысы пилмән бәбәкле Фәритне генә ияртеп, аны да үз УАЗигына утыртып, хөрмәтле эшче кулы итеп алып килгән иде. Галимҗанов ни акланырга, ни аптырарга белмичә, Әмир каршысына елмаеп килеп басты:

—Апаем, Актанышның исерекләре бетте. Нахальный бистәсендә концлагерь ачканнар, тоткын сәрхүшләрне туп-туры шунда җибәрәләр дип хәбәр таралган. Кулына кәйлә тотып караган агайлар сүзедер инде. Хәтта аек баштан яшәргә курка торган Иске Актанышның «Кәҗә кияве» дә туй кәчтүнен салмыйча кырынып, киенеп-ясанып йөри башлаган—шыр аек үзе! Бөтен карап торган булышчыбыз—менә шушы Фәрит!

—Унбиш көнен түзә алса, орден бирерсез үзенә.

—Сезнең агайне гомер буе шушындый эштә эшли, орден-медальләрегез күпме соң?—диде Галимҗанов көлемсерәп.

—Пенсиягә киткәндә бирәр нәрсә тагарлар әле.

Мәдияр исә Галимҗанов белән Әмир сөйләшкәндә үзенчә катышты:

—Тиздән «Татарстанның атказанган мелиораторы» диган исем булдырыла ди. Беренче номерлы катыргысын Әмир абыйга бирәчәкләр.

—Актанышны җинсә!

Галимҗанов, Әмирнең Актанышка килү тарихын бик анлап бетермәгәч, Фазылның ике сүзле җөмләсен үзенчә кабул итте.

—Актанышны җинеп булмый аны, егетләр! Хәтта Чулман белән Агыйдел икәүләшеп ярларыннан чыкса да, җинелмәс ул!

—Сез, берүк, гафу итегез мине,—дип, үзен-үзе төзәтергә ашыкты Фазыл,—Әмир абыйны бу юлысы Актанышка мәҗбүр итеп җибәрделәр... Пенсиягә чыгасы кеше эшендә кол хәлендә инде ул...

Кол дигән сүзне Фәрит бик ошатты, ахры—казый торган чокырын ташлап, бораулаучылар янына килеп җитте. Бораулаучылар арасында тәмәке тартучы булмаса да, Фәрит үзенең «Аврора»сын никтер гел агрегат янына килеп көйрәтә иде. Бүген аның соңгы көне. Иртәгә ул үзенең «ЗИЛ» ына утырып, Актаныштан мәңгегә югалачак. Һәм ул Әмир белән ачыктан-ачык сөйләшмичә китәргә теләми...

—Менә бүген бишенче каберемне казып бетерәм дә, прощай, Актаныш!

—Тәүбә диген, безгә казылган отстойникларны кабер итә калсаң, җир өстен зиярат каплар иде.

—Сезне дә минем шикелле мәҗбүр итеп китергәннәр дип ишеттем... Әмир бит әле син, әйеме?!

—Әмир! Ну «мир» мәсьәләсендә син үзенне миңа тиңләми тор. Авыл саен мунча ишекләре ватып йөргәнем юк минем...

—Юктыр шул. Вагонларыгызда бөтен шарты килгән ич! Кунакханә номеры кебек.

—Егерме ел буе тагып йөрим мин бу вагонны. Әмма шушы көнгә

хәтлек аның бусагасын бер генә кыз атлап керде әле. Анысын да син сөйрәп алып килден!

—Минем башыма тай типмәгән лә. Кыз булса, кагыламмы? Кем икәнен әйтеп, адресын кулга тоттырмасалар, Ижевка авылында андый яшь бичәнең барлыгын беләсем юк иде. Исеме кем иде соң әле?.. Карале, Әмир, син хет исемен хәтерлисеңме соң аның?.. Ну котны алдың син минем ул төнне, вагоннан тузанлы юлга сикереп төшкәндә тончыгып үләм икән дип торам. Менә күрерсең, шәп кенә бер егеткә кияүгә чыккандыр әле ул, чыпчык тезен күмәрлек балалар үстерәдер. Андыйларның бәхете тәгәрәп уңа. Ир сайлый беләләр алар. Исемен тәки искә төшерә алмыйм шуның...

Әмир икеләнеп калды. Суфиянның исемен дөресләп әйтеп бирергәме, ул минем хатыным хәзер, бишенче отстойникны каберең итәргә теләмәсәң, күземнән югал дияргәме? Ул чагында ике арадагы сөйләшүнең шаһиты булып утырган Мәдияр белән Фазыл, хәтта Галимҗанов... ни уйларлар?! Мескен Әмир, капкан икән бер азгынның тозагына дип, эчтән көлеп, тыштан кызганып йөрерләрме? Күзләренә ничек күренерсең... Әйе, шагыйранә ялган—матур ялган менә шушындый минутларда кирәк ул! Бәлки Фәритнең теле ныграк ачылыр һәм Әмир кичергән газаплы хакыйкатькә ул тагын ни дә булса өсти алыр. Һәм, ниһаять, яраткан кызы—Язиләсе үсеп җиткәнче генә түзәргә алынган гаилә башлыгына ир вазифасыннан вакытыннан алда котылырга этәргеч булыр...

—Ялгышмасам... исеме Мафия бугай аның. Мин аны Казанга китеп вахта автобусы йөртүче берәүгә кияүгә чыккан дип ишеттем.

Әмир әлеге сөйләшүне артык дәвам итәргә теләмәде. Дөресрәге, Фәритнең сорауларыннан курыкты ул. Зурдан кубып ялганлар өчен Әмир чынбарлыктан котыла алмый.

—Точно! Мафия бугай шул!.. Ул якта кеше исемнәре гел сәер бит...

—Ярый, Фәрит, син юлда миннән күбрәк йөрисең, берәр ары күрсәң, сәлам әйтергә онытма!

Берденбер Фәрит тә унбиш тәүлегеннән котылгач, бораулаучылар янына «Луноход» бөтенләй килми башлады. Сәрхүшләрне авылдан авылга йөреп тә таба алмыйлар ди. Хәер, әлеге биш отстойник кыш чыкканчы борауларга җитәрлек. Уразайга торбалар да мул ташылган... Бөтен материал бар. Тынычлап бораулыйсы гына... Ләкин Әмирнең күңел тынычлыгы Фәриткә ияреп китеп барды... Ул хәзер иртән иртүк эшкә килүгә вагон ишеге төбендәге баскычка менеп утыра да оеп кала. Егетләргә кычкырып әмер өләшүдән кызык таба.

«Мәдияр! Кулларыңны кесәңнән чыгар! Грязьнасосны җылыта башла! Соляркасына ут төрткәнче, чиләккә чүпрәк салырга онытма!»

«Фазыл, йоклап йөрмә, дизельнең картерына ике паяльный лампа куй, берсе генә җылыта алмас! Пускачның бензинын тикшер!»

Әмирнең кинәт кырысланы, буровойдагы эш ритмын, яшәү рәвешен үзгәртте. Бригада күбесенчә Уразайдагы фатирга кайтмыйча, вагонда гына кунып кала. Асбест торба кисәгенә уралган нихром чыбыклы электр миченең төне буе ажгырып януыннан вагон һавасы баш авырттыргыч ут исенә әверелә. Тәрәзә ачарлык түгел. Салкын дигәнең төн уртасында 25 градуска чаклы җитә. Иртән кабызып чиләнгәнче дип, Әмир хәзер платформадагы дизельне бөтенләй сүндермәскә куша, аның тырык-тырык эшләп торуы вагон эченә генә түгел, тәмле йокыга ук үтеп керә, бөтен төшләр дизель тавышында бара...

Фазылның ничә көннән бирле Әлфинәне күргәне юк. Буровойда эш көйләнгәч, барыбер җаен табармын, мичкәле машина белән барып килермен, дия-дия, инде унбиш көнләп вакыт узды. Оештыру эшләре рәткә салынгач, Галимҗанов та сирәк күренә хәзер, аны эзләрлек сәбәп юк.

Көн озынлыгы бер сәгатькә озынайды дигәндә, төнге салкыннар көнгә күченде. Казан тирәсендә эшләгән чак булса, 25 градуслы суыкта

эш киеме кидермәс иде Әмир: «Әнә, мәктәп балалары да укымыйча, «Ур-ра!» кычкырып кайтып киләләр. Безгә дә ял кирәк»,—дияр иде. Ә хәзер, «Нахаллар бистәсе»нә Янжегет урманыннан ташылган бүрәнәләрнең чатнап ярылуы да туктатмый Әмирне. «Актанышка су кирәк, тизрәк бораулап бетерсәк, тизрәк кайтып китәрбез», дип, Казаннан кушылган планга өстәмә йөкләмәләр табып тора. Бүрәнәләр генә түгел, тимер торбалар чатнардай суыкта бу кадәр агрегатны кеше кулы ничек жылытып бетерсен дә, туңган торбалар эчендә су әйләнешен туктатмыйча ничек бораууласын?! Бигрәк үҗәт җан шул син—кеше!

* * *

Югары уку йортларында каникуллар башлангач, Аккүз авылы «мәктәп карлыгачлары» белән ел саен очрашу үткәрә. Алган белемнәре, кылган гамәлләре, танылган исемнәре белән мәктәп тарихына дәрәҗә өстәрлек «карлыгачлар»ның Аккүзгә кайтып балалар белән очрашуы зур бәйрәмгә әверелә. Тантаналы җыелыш белән башланган кичәне концерт алыштыра, соңгы сәгатьләре танцылар белән бетә... Йола буларак, «карлыгачларга» бүләк өләшү дә бар. Бүләк дигәннәре китаплар белән куен дәфтәрләре, альбомнар белән кара суырта торган авторучкалар әлбәттә. Ләкин аларны җыяр өчен Актаныш универмагына барырга кирәк...

Класс җитәкчесенә ияреп, унынчы классның биш кызы колхоз автобусына утырды. Бишнең берсе Әлфинә иде. Унынчы класслар, нинди чара оештырсаң да, эштә беренчегә әверелә. Ә инде районга ялыныч төшсә, Әлфинәне ничек тә ияртергә тырышалар. Аның Галимҗановка туган тиешле икәнен һәр чиновник, һәр сатучы белә. Товар бервакытта да күз алдында өелеп ятмас, арткы ишектән кереп, таныш-белешне табып, тиешле кәгазьне күрсәтеп, аласы әйбереңне кем исеменнәндер сорый торган заман.

Бүләкләр җыюның әлләни мәшәкате чыкмады. Авылдан район үзәгенә килүнең тагын бер йоласы бар—автобус йөртүче егет һәркемгә Актаныш үзәге буйлап йөрергә ике сәгать вакыт бирә. Үзе, заправкага дип, Әҗәкүлгә таба китеп бара.

Көннең салкынлыгын исәпкә алып, кибетләрдә йөреп туйган балаларның очрашу урыны итеп ашханә төбен сайладылар, соңга калучылар җылыга кереп көтә.

Ашханәдән райком бинасына биш минутлык юл. Әлфинә кебек җитез кызларга өч минуты да җитә... Ул озак уйлап тормыйча, вакытын бөртекләп, туп-туры райкомга юнәлде. Икенче катка күтәрелеп, приемныйга керде. Беренче һәм икенче секретарьларның кара-каршы уелган ишекләрен саклап утыручы Мәймүнә Әлфинәне искәрми дә калды.

—Абый урынындамы?—диде дә кызый, күздән юк булды.

Мәймүнә Әлфинәне туктатмакчы иде, ләкин ярымачык ишектән Галимҗановның канәгать тавышын ишетеп туктап калды.

—Һай, кызым, шушындый суыкта нишләп йөрисең?! Әтиең ничек юлга чыгарды? Җылы мәктәбеңне ташлап...

—Очрашу кичәсенә бүләкләр җыйдык. Автобусыбыз җылы ич, тамчы да туңмадык. Ике сәгать вакыт бирделәр. Кызлар кибет карап йөри, мин сине сагынып килдем, абый.

—Сагынуыңа ышанам ышануын, тик минеме?..

—Сине абый, сине сагындым. Аккүзгә кайтканың да юк.

—Әйе, ике атна шул инде... Хатыным белән балаларымны да атналар буе күрмәгән чаклар була... Бик әйбәт, кызым. Сагына белгәч, рәхмәт... Мәймүнә, кайнар чәй керт әле, кызымның авызы бөрешкән, сагынам дигән сүзен дә юньләп әйтә алмый.

—Әй, абый, чәйләр эчеп вакыт әрәм итеп тормыйк. Ике сәгатьнең ун минуты үтте ич инде...

—Ә-ә-әйе! Мәймүнә, чәй эчеп тормыйбыз! Вакыт юк икән безнең.

Срочно объектларга чыгып керәсебез бар.

Галимжанов—башка сорау бирмәде, Әлфинә—кая барабыз, абый, димәде—УАЗикның арткы рәтенә утырды да сенде. «Нахаллар бистәсенә» житкәч кенә кызый зур серен сөйләгәндәй самими тавыш белән гозерен әйтте:

—Абый, буровойларына бик якын килеп туктама, мин барын әйтмә, риза-бәхил түгел әйтсәң. Үзе эзләп килгән, егетләр артыннан куып йөри диярләр, алла сакласын. Ни эшләгәнен генә күрәсем килә. Исән-сау микән...

Егетләрнең, квадрат валны ычкындырып, бораулау торбасы өстәгән чакларына туры килде Галимжанов. Кул биреп күрешерлек тә вакытлары юк, насосны туктатып торган арада су катканчы торбаны өстәп өлгерәсе бар. Бораулау торбалары читтә ята, аларны күтәреп уртагарак китереп куясы булган икән. Көн салкынлыгы белән жиренә житкерелмичәрәк калган эш берәр урыннан тәки бүселеп чыга. Торба башына эләктерәм дип, блок ыргагын читкәрәк сөйрәгән иде Фазыл, каерып күтәртә башлагач, лебедканың корыч арканы вышка башындагы роликтан ычкынды. Фазыл сырган чалбар кесәсенә 27ле ачкыч тыгып, вышка очына менеп китте. Әмир жикеренгәнче өлгерим дип ашыгуданмы, әллә тимер баскычларның өшеткеч бәсләнүеннәнме—киез итек табаны таеп-таеп китә. Аягы таеп, Фазыл өстәге баскычларга кисәк ябышкан саен, Әлфинәнең йөрәге ярылам-ярылам дип өзелеп-өзелеп типте. Кызый куркуыннан күзләрен чытырдатып йомды. Ул Фазылның уналты метрлы вышка башына утырып, ялан кул белән ниндидер гайка сүтеп алганын да, арканны урынына кидергәнне дә, бармаклары тотмагач, төшкән чакта баскыч тимерләрен кочаклап тотуларын да күрмәде. Ул бары тик ниндидер су атылган тавышка гына күзен ачты. Фазыл троссны көйләгән арада квадратлы вал эчендә су каткан иде инде, насосны жибәргәч, йөз атмосфералы басымга көйләнгән шланга өзелеп, кызыл балчык измәсен болгый-болгый егетләр өстенә бөркеде. Әмир хәлне абайлап, насосны туктатканчы, аждаһа кебек бәргәләнгән шланга Галимжановка да төбәлеп өлгерде.

Галимжанов муен арасына тулган балчык измәсеннән бөкрәеп, кабинага килеп кергәндә Әлфинә үкси-үкси елап утыра иде.

—Сиңа нәрсә булды тагын, кызым?

—Абый, өшеп үләр микән инде ул?

—Үлә! Бар, бәхилләшеп кал!

—Абый! Алай димә инде!

—Вагонга кереп кипшенерләр әле. Ну торбаларын утка салып жылытасы булыр. Эш түгел... фронт ич бу! Хотя... жәй көне жәннәттә яшиләр алар үзләре.

Автобуста Аккүзгә кайтышлый, Әлфинә бүгенге күнелсез хәлне онытыр өчен, гел жәй көннәрен күз алдына китереп барды. Ничегрәк килер икән быелгы жәй?! Ярты жәй имтиханнарны тапшырып Аккүздә үтәр. Ә жәйнең икенче яртысында ниләр көтә икән Әлфинәне?! Авылда калырга теләмәгән кыз баланың язмышы баштагы мәлдә күпләр кичергән язмышка хас булыр. Әллә ул Казанга барып Медицина институтына имтихан бирер микән? Укырга керә алганнар сөенешеп зур калага кушылыр, конкурстан үтмәгәннәр авылга кайтырга оялып, теләсә нинди шартка ризалашып, эшкә урнашып калырлар. Әлфинә укырга керә алмаса, Чаллы төзелешенә кайтачак. Ул инде моны ныклап уйлап куйды. Әтисе башта аны Казанга озата барыр, аннан соң Чаллыга илтеп куяр. Кызы тулай торакка урнашып, малярлар бригадасына ияргәч, тынычлап Аккүзгә кайтып китәр. Анда бораулаучылар бар дип, Әлфинәне Каенлыктагы әбисеннән мотоцикл белән ут очырып алып киткән Самат абый, мәктәп кичәләрендә тугыздан ары калса, жәнжал чыгарып эзләп йөри торган кырыс вә кайгыртучан әти кеше үлеп яраткан кызын, унжиде яшьлек баласын Чаллы дигән килмешәкләр каласына үз кулларь белән тапшырыр.

Клевер басуының бораулау агрегаты урнашкан жирендә кар таптальп,

кызыл балчык төсенә керде. Әйләнә-тирәдә исә кыш буе ятып та керләнмәгән аклык. Кояш чыккач жирле хәзинәгә әверелгән һәр кар бөртеге күнелне алгысытып жемелди. Кар яктылыгыннан куркып, гел керфек арасыннан карап йөри торгач, кысык күзле булып калмасак ярый инде, ди Мәдияр.

Беренче скважинанын суы тәме белән егетләрне сөендерсә дә, күләме белән проектка туры килмәде. Казаннын «Гипроводхоз» оешмасында Ятманский сызып биргән проект кәгазьләре буенча клевер басуынын һәр чишмәсе секундка биш литр су бирергә тиеш иде. Ә монда нибарысы литр ярым гына чыга. Өч көн буе куа торгач, сунын дебеты артыр әле бәлки, дигәннәр иде. Су бик тиз чистарды. Ул жир куеныннан мәжбүри чыккан су, язгы гөрләвеккә охшарга тырышып, скважина тирәсендә шаулап ала да ераккарак киткән саен кырыс кышнын бөтен бер жанына әверелеп, кар астына кереп югала.

Актаныштагы беренче скважинанын аз сулы булуы Әмир бригадасына кара тап булып төшәчәк. Әйтерләр: димәк проектта күрсәтелгәнне дөрес үтәмәгәннәр, йә су катламын үтеп киткәннәр, йә тиешле тирәнлеккә төшеп житмәгәннәр... Ә ул проектларнын Казаннан чыкмыйча, иске проектлардан күчереп кенә сызылганын бөтенесе дә белә, юкса...

Галимжанов каядыр югалды. «Водстрой» прорабы Сәфәров бригадага кул гына селтәде, жир токымы үрнәкләрен карагач: "Сез бу балчыкларны берәр канаудан тутырдыгыз мәллә—бөтенесе бер төрле?" дип, болай да ачу килгән чакта үпкәләтеп китте. Ятманский вәгъдә иткән тыгыз комнар да, чуерташлы су катламнары да юк иде клевер басуында.

—Ә бәлки без жир асты дингезенен чигенә туры килгәнбез. Каенлыктагы кебек...—диде Мәдияр,—икенче скважинага күчеп утырсак, жиде литр су чыгар әле...

Көннәр, ясап куйган рәсем кебек, гел бер төсле торды. Һава жылынмады, кар яумады.

Яна урынга күчеп вышканы күтәргәч, Әмир никтер бораyларга ашыкмады, тиз генә югарыдан нииндидер өстәмә хәбәр килер кебек иде ана.

## Нихәл, Фазыл, диде министр

Квадратлы валнын өске өлешендә, туктаусыз әйләнүдән бушый торган бер буыны бар, вакытында тыгызлап тормасан, аннан пычрак су аттыра башлый.

Фазыл, май сендерелгән киндер бауны кесәсенә тутырып, вышка буйлап үрмәләде. Иске сальникны йолкып, анын урынына кесәсендәге киндерне төйде. Ачкыч белән кыстырып, эше бетте дигәч тә, югарыдан төшәргә ашыкмады. Актанышбаш авылыннан буровойга таба бер кар көрте шуышып килә. Артыннан жәяүле буран уйнап бара сыман. Ак «Волга» иде ул...

—Нәрсә, Әлфинәләрнен моржасы күренәме әллә анда?—дип Мәдияр Фазылга астан кар ыргыта башлаган иде инде.

—Күренә. Ак «Волга»лы кунак килә.

«Волга» килеп житкәнче бер-ике минут вакыт узды. Әмир ул арада бензинлы лампа утына куелган корымлы чәйнеккә калай кружка белән дынгычлап кар өстәде. Чәй кунакларга да житсен, янәсе...

Машина якынайгач, Әмир аны шундук танып алды.

—Утыз елга бер балкый торган бәхет—безнен янга министр үзе килә.

—Хәерлегәме, хәерсезгәме?—дип төпчендә Мәдияр,—сагынып килгәндер дисезме әллә?

Алар машинадан икәү төштеләр. Кин каракүл якалы пәлтәсенә

туры китереп каракүл папаха кигәне—“Гипроводхоз”ның симез борынлы баш проектчысы иде. Ә тимер төсендәге якасыз драп пәлтә һәм купшы ондатра бүреклесе—мелиорация министры. Министр мәктәп директорлары шикелле ак фетр итек кигән һәм ул итекнең галош сыман кидерелгән күн табаны аңа җинеллек өстәп тора сыман.

Министр һәркайсы белән кул биреп күрешеп чыгар дип кем уйлаган, юкса, егетләр мазут катыш кызыл балчыклы кулларын кар белән булса да юып өлгерерләр иде...

Министрдан күреп симез борынлы кунак та якыннан исәнләшергә мәҗбүр булды. Ул егетләргә ришвәт биргән шикелле генә кул сузып чыкты.

—Ятманский, Ятманский, Ятманский,—диде ул өч егеткә дә аерым-аерым фамилиясе хәтердә калырлык итеп.

Әмир үзенең каушавын сиздермәскә тырышты, әйтерсең, министр аның янына көн саен бер килеп хәл-әхвәлен белеп йөри. Чәйнектәге кар кайнап чыккач, ул тыныч кына вагоннан бөртекле чәй алып чыкты, лампаның ялкынын кыскач, ул чәйне кашык тутырып чәйнек эченә салып болгатты. «Чиләктә пешкән чәй» шушы була инде.

Министр да, бер мәлгә тормыш ыгы-зыгысын онытырга теләгәндәй, чәйнек янына килеп басты. Ул Әмир белән генә сөйләште.

—Сельхозтехникада эшләгән елларда без дә шушындый паяльник белән су кайната идек. Кышкы юлда машинаң ватылып калса, кайнар чәй—әҗәл даруы инде ул. Сезне фатирга урнаштырдылармы, әллә вагонда гына яшисезме?

—Уразайдан килеп йөрибез. Төшке ашка кайтып вакыт әрәм итәсе килми. Чәй белән котылабыз.

—Актаныш чәе—тәнгә сихәт... Суны беренче скважинадан алдыгызмы? Миңа да салыгыз әле чәегезне!

Әмир министрга яшел калай кружка белән чәй салып бирде. Министр, иренен пешермәскә тырышып, кружка читенә өрә башлады.

—Кар чәе бу,—диде Әмир, читкә карап.

Министр бер мәлгә сискәнеп китте, ләкин үзен бик тиз кулга алды һәм еш-еш өрә-өрә бер йотым чәй йотты.

—Актаныш кары! Бердәнбер стерильный район!—дигән булды министр горурланып.

Әмир министрның шушы район кешесе икәнен белә. Шуңа күрә «Актаныш» сүзенең аерым яңгырашында сагыну чалымнарын бик тиз тоеп алды ул.

—Ник чәегезгә суны беренче скважинадан гына алмадыгыз?

—Сүндердек без аны. Рубильник куярга багана утыртырга тиешләр иде.

—Кунакка да чәй ясагыз!

Ятманскийның кружкалы чәйне чирканып кына тотуын күргәч, министрның йөзендәге елмаюы юкка чыкты.

—Җирәнеп эчмәгез! Шушы егетләр кебек сау-таза булырсыз. Бу системада үзем эшли башлаганнан бирле берәр бораулау остасының салкын тидереп авырып ятканын хәтерләмим мин. Ә сезнең борынга машина мичененң җиле дә ярамый.

«Алай, бу симез борынга томау төшсә, кульяулык урынына тастымал йөртергә кирәктер», дип уйлап куйды Мәдияр.

Министр Актанышка кунарга кайтмаган иде, чәйнек тирәсендәге әңгәмәне бик тиз генә эшлекле сөйләшүгә борып җибәрде.

—Ятманскийның иркенләп чәй эчәргә вакыты бар. Сезнең янда кала ул.

—Бөтенләйгәме?

—Икенче скважинаны бораулаганны башыннан ахырынача үз күзләре белән карап торсын. Өскә чыккан балчык катламнарын бергә җыйсын. Бөтен вак-төяк эшне аңа әйтеп эшләгез. Язып барсын. Бигрәк тә тирәнлек

мәсьәләсен, су катламының калынлыгын. Ну сезне өйрәтәсе юк, беләсез инде. Юкса суның азлыгына ышанмый ул... Дөресен генә әйткәндә, мин дә ышанмыйм. Агыйдел, Кама, Ык, Сөн елгалары бассейнында утырган Актанышның кайсы җирен генә тишсәң дә, су фонтаны бәреп чыгарга тиеш.

—Беренче скважинада безнең гаеп юк. Җир астының министрларга да буйсынмый торган катламнары бар күрәсең.

—Йә, ярый,—диде министр, эчелеп бетмәгән чәен кар өстенә куеп.—Сөйләштек, анлаштык. Ятманский кунакханәгә урнашыр. Оешмалары бай, түләп торырлар. Көн саен алып-килеп йөрерсез. Хәтта дизельне дә аннан башка кабызмагыз. Хушыгыз!

Киткән чакта министр егетләргә тагын кул биреп чыкты. Фазыл үзе дә сизмәстән, йола кушканча күрешеп: «Мин Фазыл булам!»—дип ычкындырды. «Нихәл, Фазыл?!»—диде ана министр.

### «Я» дигәне югалды

Нәүрүз кышны сындырды. Актанышка мәңгегә дип урнашкан салкыннарны кыйбла яктан килгән дымлы җилләр куып таратты. Кар тузаныннан өелгән көртләр, әкренләп пакьлеген югалтып, ярмаланды. Кар астына төшкән гөрләвекләр кичке кыркулыкта югалып калалар да иртән, кояш белән бергә торып, Агыйдел ягына йөгерәләр һәм көннән-көн куәтләнеп, быелгы кышның кире кайтмаслыгына инандыралар. Язның һәръяклы һөҗүменә түзә алмыйча, кар катламы бөтенләй сызып, күз алдында юкка чыкты. Көз көне үсүдән туктаган клевер толымнары яшәреп, тургайларны үзенә җыйды. Вышка эчендә квадрат валның шалтор-шолтыр килеп әйләнүе куркытты бугай аларны... Чөнки чакырылмаган арбалар, вагоннар, машиналар, чокырлар һәм скважиналар узган елгы тургай оялары өстендә иде. Тургайлар сер бирми—алар җылы дәүләтләрдән яңа гына килгәч, Актанышны сагынып кайтуларын яшермичә, баш өстендә сөенә-сөенә сайрашалар.

Өч игезәк кебек өч скважина борауланды. Өчесенең дә язмышы бер—тирәнлекләре тигез, катламнары уртак, су чыгышы секундына нибарысы литр ярым.

Казан инженер-төзүчеләр институтының гидрогеологлар бүлеген тәмамлап, ун ел эчендә баш проектчы дәрәҗәсенә үсә алган Ятманский үз гомерендә беренче тапкыр шушындый озын командировкада иде. Ул «сакау пәпә» кебек кыланды, артыгын ишетмәде, егетләргә кушылып сөйләшмәде. Йөзен һәм тавышын яшерергә теләгәндәй гел читтә йөрде. Бораулау барышында гына җиннәрен сызганып, җир астыннан циркуляция белән чыккан боламыкка тыгылып балчыкларны капшады. Үтелгән метрларны язып барды. Долото тирәнгәрәк төшкән саен үзенең гаебен танып, җавап тотарга әзерләнде. Ләкин Әмир ана хөкемдар түгел. Татарстанда бораулангaн барлык су скважиналарының проектын түрә буларак раслаган Ятманский беренче тапкыр җинелү кичерде. Дөрес, төзелгән проектларның җир астындагы чынбарлыкка туры килмәве—ул монарчы нарат урынына киселгән чыршы кебек кенә бик гади кабул ителә иде. Тирәнлеген үтеп китсән дә, суы азрак булса да, ул скважиналарны колхоз җитәкчеләре сөенә-сөенә кабул итә, процентовкаларда күрсәтелгән сумманы артыгы белән түләргә риза.

Ә монда, клевер басуында, тургай оялары өстендә, Кама сусаклагычы дәһшәтеннән качкан Актаныш халкы өчен яңа шәһәр төзелә. Димәк, гомер буе атау чишмәләрдән кәүсәр эчеп үскән халык яңа урынга күчеп утыргач, җитмәгән суны юан торбалар белән Агыйделдән китереп эчәргә тиеш.

Ятманский ашалып бетмәгән сарымсакларын, юылмаган оекларын

юлкапчыгына тутыргач, язгы челләдә кышкы киемнәренә төренеп, Казанга кайтып китте. Шушы китүеннән соң яна проектларда Ятманскийның «Я» дип башлана торган имзасы башка хәрефләр белән алышынды.

## Сикереп суларга төшәрсең...

Минзәләдәге Ык күпере сүтелгәнче дип, Актанышка тагын ике бригада җибәрделәр. Бүленгән акча ахырынача тотып бетерелсен өчен унҗиде скважинаны да бораударга кушылды. Ләкин бу инде эш түгел—ә кирпеч сугу ише ярыш кына иде. Өч җирдә өч агрегат тәүлекләр буе казый торгач, унҗиденче скважинага насос төшергәндә юл читләрендә тузганаклар чәчәк ата башлаган иде инде...

Янгын сүндерүчеләр каланчасыннан күзәтеп торган диярсең, вышкаларны егып, кәрваннарны Казан ягына борып куйгач, клевер басуының исән калган бер төшеннән Галимҗанов пәйда булды. Ул инде җәйгә күчкән—кыска ак плащының төймәләрен ычкындырган, чүпрәк козыреклы ак кепкасын кулына тоткан.

—Тагын беразга гына соңарсам, күрми каласым икән үзегезне. Казанга китеп барышыгызмы? Барыбер Минзәләдән кире борылып кайтыр идегез. Ык күперен сүткәннәр анда, ташу хәйран көчле быел.

—Ике ай өйдә булган юк. Без хәзер нишләргә тиеш?—диде Әмир Галимҗановның хәбәрен хәвефкә юрап...

—Бүген-иртәгә самолет килергә тиеш әле. Агрегатларны шушында гына калдырасыз да, очып кына кайтып киләсез. Сезнең начальство белән телефоннан сөйләштем мин бүген. Өч бригаданы да отпускыга чыгарырбыз,—диделәр,—Әмирләр ашыкмаса да ярый—Актаныш авылларыннан бик күп заявкалар бар, диләр.

—Начальство үзе килсен дә бораудасын. Мин бу сөргеннән качам.

—Кача алмыйсың әле, самолет өчләр тирәсендә генә килә. Хәзер бөтенебез дә җыелышып ашханәгә төшәбез. Анда сезнең өчен махсус өстәл әзерләнде. Хөрмәтләп озату мәҗлесе...

—Хөрмәтләп озатырлык эш эшләмәдек лә.

—Борчылма, Әмир, су аз чыкты дип, хәсрәтне үз өстеңә алма. Бездә һәр эшнең үз министры бар, Яңа шәһәрне сусыз калдырмаслар...

Ә Казаннан самолет килмәде. Дөресрәге килде ул, Актаныш аэродромының болынлы полосасы «ИЛ-14» төшеп утырырлык нык булмагач, 36 пассажирына район өстен ике тапкыр уратып күрсәтте дә, киредән Казанга алып китте. Сап-сары чәчәк аткан аэродромның тузганагы өлгермичә һава юлы ачылмаячак. Җирле халык өчен яңалык түгел инде бу. Аларның юл өзеклегенә исе китми. Актанышның ярты халкы шушында гомер бакый яшәп, Казанда гупчым булганы юк әле. Һәм бер күрмәгәч, Казанны сагынмыйлар да. Бораулаучылар гына менә Актаныш басмалары санынча сүгенеп, язгы Агыйдел кебек ярсып, Бәкилде бакалары кебек туктаусыз зарланып, Казанга кайту әмәлен эзләделәр. Чөнки анда тиздән получка көннәре, чөнки анда һәркемне шифалы су эчеп үскән үз Суфиясы көтә...

Кунакханәдә яшәп торыгыз, Бөгелмәдән «вахта» вертолетлары килми калмас, үзем берәмләп озатырмын дисә дә, Галимҗанов егетләрне кайту уеннан кире күндерә алмады. Ә кайту юлы бар—боз өстенә су төшкән Агыйдел аша ул.

Әҗәкүл артында юл өзелде. Боз аркылы салынган җәяүле кичү юылган. Ике яр читеннән инеш булып су ага. Уртада боз бүрткән—агым уңаена ярыкланып буеннан буена кабарып тора. Тагын бер-ике сәгатьтән буаз елга бәбиләр дә боз астыннан нарасый Агыйдел туып, тирә-юньне шаулатып аваз салыр...

Зурларны ун сумга, балалар туры килсә, өч тәңкәгә җилкәсенә

салып, теге якка ташып кәсеп итүче кайчандыр Әмир искә алган теге агай әзмәвердәй тугыз килмешәкне күргәч якын килмәде. Алла сакласын, сыртына утырып йөрергә иренмәсләр, өерләре белән булгач, акча да түләмәсләр, житмәсә ауга йөри торган озын кунычлы итегенне салдырып ялан тәпи калдырып китәрләр, дип уйлады бугай ул.

—Бил тинентен чишенеп, боз өстеннән яланаяк чыгабыз да, теге ярда коры киемнәрне киябез,—дигәч, Әмиргә халык дошманына караган ише акайдылар. Ләкин бердәнбер юлның шушы икәнен аңлагач, язмыш белән килештеләр. Гомергә гарип калдырырдай бозлы суны кичәргә мәжбүр иткән сәбәпләр чынлап та мөһимме сон дип, тагын бер кат утырып уйлансалар, бәлки тугызы да кире Актаныш кунакханәсенә кайтып егылырлар иде. Юк шул, кайтыр юлга чыккан егет уйлый белми, ул алга ыргыла гына белә.

Фазыл гына:

—Әйдә, калыйк, Мәдияр, яз көне кайда да рәхәт. Юл өзеге беткәнче яшик шушында,—дип әйтеп караган иде, ләкин Мәдияр икеләнмәде:

—Ростовка барасым бар. Йә алып кайтам Галяны, йә бөтенләйгә араны өзәм!..

Алар, урам аша чыккан ясле балалары кебек бер бауга тезелеп, бозлы суны кичтеләр... Яр читенә чыгып басканда Фазылның табан асты ут булып кызган, жир салкынын да тоярлык түгел иде. Ул Агыйдел өстенә борылып карады, аннан Әжәкүл пристанен, Актаныш авылын күздән кичерде—барысы да Фазылның китүеннән боегып калалар сыман. Әнә, Кашлакта Актаныш басмаларын кояш киптергән. Шул басмалардан менеп, аэродром читендәге иске юлдан йөгерсәң, чуерташ сибелгән кабартма юл сине туп-туры Аккүзгә—Әлфинә янына алып барачак. Нишләп соң әле Фазыл яшәешләре, күп очракта холыклары, үткәннәре һәм киләчәкләре белән бер-берсенә аерылгысыз охшаш зимагурларга тугызынчы кеше булып иярде?! Фазыл беренче булырга тиеш! Ул Әмир язмышын да, Гамил, Сәләхиев, Антонов, Кислов язмышын да кабатларга теләми! Фазылның киләчәге бөтенләй икенче ярда...

Фазыл, киемнәрен кабыл-тибел йомарлап, әле генә кичеп чыккан бозлы суга сикерде. Буаз Агыйдел тулгагын тыеп көтә иде аны. Фазылны бәхетле ярга чыгарганчы гына түзәрлек иде әле бозлы кичү. Егетләр күкшегән аякларына коры оекларын да кияргә онытып Фазылны күзәттеләр. Аның теге ярга исән-сау чыгып житкәнен күргәч, кинәт айныгандай булып, егетнең олы мәхәббәте өчен сөенеп куйдылар...

"Милый мой"...

Кызлар белән танышканда егет кеше иң әүвәл өч сорауга жавап эзли: «Исеме ничек? Кайсы яктан? Шәһәрнең кайсы төшендә тора?» Шушы өч сорау алга таба дуслашканда тел ачкычы буларак кирәк. Беренче сорауның бурычы билгеле инде—кызлар егетләр авызыннан үз исемнәрен еш ишетергә тели. Бер дә белмәгән кызга: «Ниме, син, теге...» дип ым кагып утырганчы: «Әлфинә!» дип, йә булмаса: «Язилә!»»Галина!» дип дәшсәң, алар кулга тизрәк ияләшәчәк. Ияләшергә теләмәгән кызлар исә исемен яшерер, бәйләнчек егетләрдән котылыр өчен хәтта үзенә ялган исемнәр дә уйлап табарга мөмкин... Монысы булды—бер... Икенче сорау кызның кайсы якта туып-үскәнен чамалап, мәхәббәтнең географиясен кинәйтер өчен, таныш атамалар, уртак дуслар эзләп, якташларча кыланып кыз белән жинелерәк уртак тел табар өчен кирәк... Бусы әлләни катлаулы түгел. Сирәк-мирәк кенә кулына гәзитә тотып, радиодан соңгы хәбәрләрне тыңлап барсаң: «Беләм мин ул авылны, ишеткәнем бар!»,—дип теләсә-кайсы төбәкне туган ягына тиң итеп искә төшерергә була. Икенче сорауның хикмәте шушы. Ә инде өченче сорау

яна танышкан кызыңны очрашудан соң өенə озатып куюу проблемасын үз эченə ала. Əйтик, син Киндерле саласында яшисең икəн—Дəрвишлəр бистəсенең кызын эзлə. Савин бистəсе егетлəренə Квартал, Үзəктəн, Бишбалта кызлары белəн танышу хəерлерəк. Бер дə булмаса, Социалистик шəһəрчек кызлары да ярап тора. Ə инде «Горки»да яшəп, «Жилка»да, «Мирный»дан килеп «Телевышка»да кызлар сөеп йөрсəң, тиз коелып бетəрсең. «Яңа Бистə» егете «Чыңгыз» бистəсе кызын өенə илтеп, янəдəн үз тулай торагына кайтып егылганда мехчылар фабрикасы беренче сменага дип яшел капкасын ачып куйган була. Төнге юлларның хəвефлелеген, безнең шəһəр транспортының дөньяда бер көйсезлеген дə исəпкə алсаң—кайда яшəсəң, шуннан берəр кыз табарга тырыш инде, агайне, кавышып яши башлагач, хатын була ул шунда... дип кинəш бирерлəр дөнья күргəн агайлар. “Яшь чагым кире кайтсамы?! Бу əбиеннең кайда торганлыгын сораган булыр идем башта... Бəлки исемен сорауга чаклы барып та житмəс иде”...—дип тə өстəрлəр өлкəнрəклəр...

Лəкин ике генə түгел, яшьлек жиде тапкыр əйлəнеп кайтса да, бер күрүдə гашыйк иткəн кызларны эзлəп җəһəннəмгə керергə дə əзер шул без...

Кулга акча кергəч, кем нишли торгандыр, белмим, ə менə Мəдияр самолет билетына йөгерə. Əлбəттə, Мамадышның Шүлəнгер авылына самолетлар очмый əлегə. Аның каравы «АН-24»тə ике сəгать буе канатлансаң—Ростов шəһəренə килеп төшəсең. Аннан 25 чакрымдагы Батайски шəһəрчегенə ярты сəгать саен маршрутлы автобус йөреп тора—ул нибарысы 25 тиен көмеш хакына ярсу йөрəкле татар егетен Александр Матросов урамының 16 нчы йорты янына китереп куя. Шулай итеп, Савин бистəсе егете «Квартал» кызы белəн Казанның Химиклар мəдəният сараенда кино карап чыкканчы, Мəдияр инде Кавказ кепкасын киеп, хохол кызы Галина Осадчая янына килеп житкəн була. «Арча кыры»нда яшəүче кызларны озата кайтырга иренгəн «Танкодром» егетлəре өчен Мəдиярның Галина янына йөрүе амбразура каплаучы Гафиятуллиннар, Матросовлар турында кино төшергəн режиссерларның да фантазиясе житмəслек батырлык, əлбəттə!..

Хохол кызы Галина Казанның кайда икəнен белмəсə дə, андагы «СМУ Водстрой»ның кайчан акча алганын белə. Шуңа күрə айның унысы житте исə сагыну өянəге кузгала башлый: аяз тəрəзəлəрдəн үрелеп күккə карый—самолетлар очамы-юкмы? Капкадагы кыңгырау төймəсен көнгə биш тикшерə—эшлиме-юкмы? Яңа кулмəген киеп үзе чаклы көзге янында бөтерелə—Мəдиярга ошармы-юкмы? Чəч толымнарын сəгать саен бер капшар—гүя урынындамы-юкмы?.. Мəдиярның получка көне—Галина белəн күрешү көне. Айдан айга кичегеп əллə нидə бер очрашкач, күрешү көннəрендə бəйрəмнəр дə күченə—югалып кала. Шуңа күрə Мəдияр килгəн саен йə үткəн бəйрəм белəн котлап, йə якынайганы белəн тəбриклəп бүлəк тоткан булыр, Галина ул бүлəкне рəхмəт əйтеп алган булыр. Аннан соң алар Батайски шəһəрчегенең бердəнбер мактаулы урыны—«Красный сад» рестораныңа кереп утырырлар. Өч сəгать буе күзгə-күз карашып та ныклы карарга килə алмыйча, Мəдияр өйлəнмəгəн егет булып, янə Ростов аэропортына китеп барыр. Галина исə кияүгə чыгарга телəп тə сөйгəненə тагылып китəргə кыймаган шартлы кəлəш булып, айның уннары житкəнче тагын көтə торыр. Дөрес, Мəдияр килми калган айлар да күп булды, кырда эшлəгəн кеше завод эшчесе кебек сəгатьлəргə буйсынып яши алмый шул ул... Мəдияр югалса, айның унбишлəрендə Киндерле бистəсенең «Водстрой» урамындагы тулай торагына хат килеп төшə: «Милый мой, Мадиярчик? Жив ли ты, мой ангелочек?!»

«Милый мой» дип, Галина кебек ягымлы итеп, бер генə татар кызының да əйткəне юк əле Мəдиярга. Казан кызлары аның матур исемен бозып, «Икарус» автобусы ише «Мадьярчик» дип дəшəрлəр, маржа кызлары өчен ул Миша гына... Ə Галина исə хат язганда гына түгел,

күрешеп сөйләшкәндә дә жае чыккан саен «Милый мой, Мадиярчик» дип иркәләргә тырыша.

Мәдияр кечкенәдән кызлар арасында үсте. Клубка чыгып торасы юк—өендә дүрт апасы үсә, ул дүрт кыз янына жае чыккан саен ким дигәндә дүрт иптәш кызы килә булыр. Күп балалы өйгә кеше күпме булса да сыя бит сон ул... Ялгыз балалы гаиләләргә генә беркем керми, кич утырмый—өй эчләрендә тәртип, жиһазлары жыйнак, урын-жирләре пөхтә, идән уртасына бассаң, табан эзенә чаклы күреп алалар, хужалар авыр сулый, ачык йөз күрсәтми... Ә күп балалы өйдә көн дә бәйрәм, көн дә жыен.

Мәдиярнын апалары: Энже, Мәржәния, Зөбәржәт, Алмазыя. Инде Мәдиярга да үзе туганчы кызлар исеме табып куйганнар иде—Рубинә атлы буласы иде ул. Асылташлардан муенса тезгәне өчен: «Малай ясау кулыңнан килми!» дип, Ярулланың күзен ачырмадылар. Жае килгән саен кызларынын язмышын мәзәкчә юрарга тырышып үртәделәр, исерек кияүләр, уйнаштан туган балалар, «төнге күбәләкләр» турында имеш-мимешләр телгә керсә, гел Яруллага таба борылып сөйли торган булдылар. Бер кыз бала, бер малай житә иде Яруллага. "Тукта, чү, монысы малай булмасмы..."— дия-дия, дүрт кызый алып кайтырга туры килде.

Малай дигәч тә ышанмый торды Ярулла, роддом бусагасын атлап чыкканчы ук ак биләүне сүттереп, нарасыйны жентекләп карады—чынлап та Рубинә буласы дигәне малай кеше иде—бөтен нәрсәсе дә үз урынында! Хәтта йөзлеге дә бар! Яруллага яшәү көче өстәлде, гәүдәсе тагын да турайды, йөзенә елмаю кунды. Гәрәбәне төенләп, асылташлар арасына төймә таккандай, малайга Мәдияр дип һич кем өметләнмәгән исем куштылар...

Апалары бәләкәч Мәдиярны курчак итеп уйнадылар, чәчәкле-чуклы күлмәкләр текteләр, укалы калфак кидерделәр, ул уканың ялык-йолык килеп торуы малайга сокланып вә гажәпләнеп караучы күрше-тирә апаларның каты күзеннән сакларга тиеш. Мәдияр елый башласа—Энжедән Мәржәнияга, Зөбәржәттән Алмазияга күчә. Кулдан кулга йөреп алжыгач, елаудан туктарга мәжбүр була.

Мәдияр киеп туган йөзлекне бөкләп, апалары чиратлашып чәч толымы астына тагып йөрде. «Сөйдергеч» тагып йөргән көннәрдә алар үзләрен Шүләнгернең иң сөйкемле кызы дип хис итәләр иде. Нәни чакта малайның кыз туганнардан исеме генә аерылып торды. Ул апалары белән бергә ашады, бергә уйнады, бергә йоклады, мунчага да бергә керде.

Бер көнне тимер аяклы чанасын өстерәп кайткан жиреннән Мәдиярны әнисе тотып алды.

—Бар, улым, мунчага йөгер, сине юындырыр өчен апаңнар чыкмый тора, ис тидерә күрмәсеннәр...

Мәдияр күп тә уйлап тормастан, туңып бөкшәйгән бармакларына сулыш өрә-өрә мунчага чапты. Килеп керүенә, юынган жирләреннән бүленеп апалары аны чишендерергә кереште; Энже бозлы бияләйләрне таш өстендәге бауга элде; Мәржәния карлы пәлтәсен салдырып, кадакка элде; Зөбәржәт юеш бүреген селеккәләп, тәрәзә төбенә куйды (ул аны мунча эче бераз караңгылансын дип шулай эшләде, юкса кызлар тәненә яктылык артык мул төшә); Алмазия бозланып каткан итекләрне мич алдына тезде.

Суыктан күшегеп, кисәк кызу мунчага кереп чишенгәч, малайның рәхәттән шаярасы килде. Ул салкын кулын тизрәк жылытырга теләп Энженең кайнар биленә үрелде... Энженең мунча төннегеннән ишетелерлек итеп чәрелдәве—кул салкыныннан чирканудан гына түгел, кытыгы килүдән дә иде. Зөбәржәт апасының кендегенә бармак тыккач малайны ләүкәгә төртеп менгерделәр.

—Дәү апаның тәне жылырак,—дип тәтелдәде Мәдияр.

—Чабынган арты шулайдыр.

—Син дә минем кебек—чабынырга яратмыйсың ич.

—Каян белим. Алайса, әнә, нәни апаңның тәнен тотып кара.

—Нәни апайның имие минеке хәтлек кенә.

—Гел безгә ияреп үссәң, синең имиең дә кызларныкы кебек булып үсәр әле.

—Үсми! Мин—малай кеше! Малайларның чәче дә озын булып үсми, имчәге дә юк.

—Теле генә үсәме?

—Теле түгел инде, бакбагы үсә.

—Ләүкәннән егылып төшә күрмә, хөрәсән! Телеңә бака ябышыр.

—Кая? Нинди бака?!

—Ике аяклы, ике куллы—ләүкәдә утыра.

—Мин бака түгел сезгә!.. Дәү апа, бармакларым сызлый...

—Кайнар таш тотып утыр.

—Алып бир...

Теленә салынган шул көннән башлап апалары Мәдиярны мунчага ияртмәде. Әтисе белән йөри башлады. Ярулла улын юындырып чыгара да үзе әниләрен көтеп кала иде.

Йокларга яткач та, Мәдиярны уртага түгел, ә агач сәкенең кырыена—нәни апасы белән стена арасына сала торган булдылар. Кайвакытларда ул апаларының йокыга киткәнен көтеп тора да, ияләнгән урынына—Энже белән Мәрҗәния арасына кереп ята. Ләкин күп чакларда апаларының йокыга киткәнен көтеп тора алмыйча, яткан җирендә үзе оеп китә иде...

Гел кызлар арасында үскәнгәме—Мәдиярның төшенә хур кызлары еш керә иде. Төн саен керә торган андый төшләрне әнисенә сөйләп тә арды инде ул. Хәзер сөйләми, җавапларын алдан ук белә имеш: «Тавык төшенә тары кергән—чыпчык чүпләп бетергән...»

Ә төшләре матур Мәдиярның... Каф таулары артында җәннәт бакчасы күренә, имеш... Капкасы бикле. Йозак алкасына: «Урын юк» дип язып элгәннәр. Җәннәт каравылчысы Мәдиярга бармак яный: «Сиңа түгел, председатель малайларына да урын юк әле монда!»—ди. Мәдияр озак уйлап тормый—капкадан читтәрәк бер койма тактасын кубарып, шуннан җәннәт бакчасына кереп китә. Керүгә урам-урам алма агачлары, хөрмә, кара җимешләр арасында кала. Алмага үрелгәндә генә Мәдиярны ак күлмәккә төренгән бер кыз эләктереп ала.

«Син кем?»—ди ул, Мәдиярны шундук кысып кочаклап.

«Мин—Ярулла малае Мәдияр! Ә син үзең кем?»

«Мин—синең хур кызың. Икебезгә тиешле бакчаны саклыйм».

«Әти әйтә, хур кызлары егет саен җитмеш җидешәр тиеш, ди».

«Әтиең дөрес әйткән».

«Алайса калганнарыгыз кая?».

«Сугышта бик күп ирләр үлде. Хур кызлары житкереп булмый. Китимме, янында калыйммы?».

«Кал. Түлке ул хәтле кысып кочаклама».

«Бүген оҗмахка имән утыны яктык».

«Исемең бармы синең?»

«Галя».

«Хур кызы маржа буладимени?!»

«Маржа да, поляк, румын, немец, француз кызлары да бар монда. Үзеннең исемең дә венгрлардан килә.»

«Әти кушкан. Сугыштан ишетеп кайткан.»

«Мадиярчик, милый мой!»

«Кочаклама дим шулхәтле! Пешеп үләм ич инде...»

Мәдияр нәни апасының куенында тирләп-пешеп уяна. Ләкин шушы рәвешле төш мичкә имән утыны якмаган көннәрдә дә, ялгызы гына йоклаганда да кабатлана торган иде.

Шүләнгердә татарлар гына яши. Мәктәпне тәмалап чыкканчы рус кызлары күрмәде ул. Хәтта җәйге каникулларда булсын, озын бәйрәмнәрдә,

сабан туйларына кайткан кунак кызлар арасында да Галя исемле кызлар очрамады ана.

Батайскида бораулау осталары әзерли торган мәктәптә укыганда Мәдияр геология укытучысының фамилиясенә игътибар итте. Хикмәт шунда... Мәдияр укудан бушаган чакларда тулай торакта туган якларны сагынып, озын төннәр кичерүе җинелрәк булыр дип, Г. Әпсәләмовның «Алтын йолдыз» романын үзе белән алып килгән иде. Ростов өлкәсендә Казан егетенә башка татарча юаныч булмас диде. Татарча тапшыруларны, концертларны, гәзит-журналларны, хәтта ана телендә сөйләшүләрне сагынган саен әлеге романны укый торгач, китап бик тиз укылып бетте. Әллә әсәрне артык яратып укыганга, әллә сирәк очрый торган фамилия булганга—белмәссен—бер батыр исендә калды... Геология укытучысыныкы кебек үк фамилисе Осадчий иде аның.

Мәдияр айлар буе дәшмичә йөрде дә, практик дәресләрнең берсендә «Ростовдонводстрой» полигонында җир токымнары өйрәнгәндә, егетләрнең тәмәке тарткан тынлыгыннан файдаланып, унайсызланып кына сүз башлады.

—Сергей Иванович, сез сугышта булдыгызмы?

—Әйе, башыннан ахырынача, җинеп кайттык,—диде Осадчий, сорауга педагогларча төгәл җавап биреп.

—Карелия фронтындамы?

—Әйе...—диде педагог, бу юлысы туры сораудан сагаеп.

—Татарлар бар идеме сезнең белән?

—Күп иде татарлар. Тик, энем, мин сине анда хәтерләмим,—диде Осадчий сүзне уенга борырга теләп. Сергей Ивановичның елмаюын күтәреп торган егетләр шаркылдап көләргә тотынды.

—Ә минометчы, военкор Абдурахман Абсалямовны хәтерләмисезме?

—Икебезнең бер котелоктан похлебка чөмергән бар...

Егетләрнең көлүе кинәт өзелде.

—Сергей Иванович, сезнең турыда роман укыдым мин. Татарча инде, билгеле, әгәр кызыксынсагыз, сезгә кагылышлы урыннарын русчалап сөйләп бирермен.

—Рәхмәт, әлбәттә. Ләкин автор миңа ул романның русча басмасын шәхси имзасы белән үзе җибәрде инде. Теләсәгез, күрсәтә алам. Исәнме әле ул язучы Абдурахман?

—Исән, әле безнең авылга очрашуга да килгән иде. Ябыккан, авыр сөйләшә.

—Яшь чагында да шулай чандыр иде лә ул. Трофей тушенкалары да тазарта алмады аны. Ә сез бүген кич килегез безгә. Өебезне бөтен кеше белә—мәктәп урамында гына, Матросов—уналты булыр.

Сергей Иванович безнең Мәдиярны зурлап кунак итте. Озатканда: "Теләгән чагыңда килеп йөр",—дип, чын күңеленнән чакырып калды. Шушы мәктәптә егерме биш ел укытып, Татарстанның ел саен берәр егетен күреп, әле һичкемнең бу темага сөйләшү башлаганы юк иде. Мәдияр Осадчийның иң изге хисләренә эндәште, сагындырган фронтовикларын исенә төшерде, аны белгән командирдан сәлам китерде. Һәм шуңамы, Мәдиярга ул—язучының малаен күргәндәй сөенде. Сергей Иванович үзе генә түгел, сугыштан исән-имин саклап алып кайткан мәхәббәтенең җимеше, бердәнбер кызы—Галина Осадчая да сөенде. Кыз Мәдиярны батыр татарларның кавеме дип кабул итте.

Галина Мәдияр кебек сугыштан соң бер ел үтүгә үк туган бала. Ул яследә концертмейстер булып эшли иде. Өйгә кайткач, бала-чага чырчуыннан котылган кызый өйне уртада калдырып җәелгән егерме сутыйлы бакчада әтисе утырткан груша, слива, алма агачлары арасында ял итә. Кичләрен урамга чыгарга бик яратмый, чөнки ел саен, октябрь аеннан май ахырынача СССРның бөтен тишек-тошыгыннан укырга дип җыелган рабочий класс Батайски урамнарына хуҗа була. Гаиләләреннән, өйләреннән, илләреннән-җирләреннән вакытлыча ирек яулаган ирләр күңел

ачарга тели. Һәм Галина алардан күпме генә сакланмасын, барыбер бер татар егетенә килеп капты... Галина—үзендәге мәхәббәт газапларын, яшьлек дәртен, сафлыгын, аклыгын беркемгә дә әрәм итмичә, хисләрен таушалтмыйча—кул тидертмичә саклый алган кыз—Мәдиярга кинәт ышанды. Егетнең татарлыгына исе китмәде анын, русчаны шәп белә ул. Йөзе—ясмык төйгән нәмәрсә—чын рус халкына хас чырайлы, амбразура капларлык кин җилкәле...

Мәдияр укулар бетәр алдыннан көн саен килде. Килгән саен бер сүз кузгалды: «Әйдә, языльшыйк, китик Казанга. Ростов белән ике арада ике сәгать ярымлык юл. Мин Казаннан Шуләнгергә дә дүрт сәгать кайтам. Әйдә, икеләнмә...»

Җавап та гел бер үк иде: «Ашыктырма. Килер бер көн, чакырганыңны көтмичә үзем барып төшәрмен!»

Ләкин еллар үтә торды, «ул көн» һаман килмәде. Мәдияр Казанга кайту белән тулай торакка йөгерә, бүлмәнең астын-өскә китереп хат-мазар, йә телеграмма-фәлән эзли. Ул югында килеп, вакытында тапшырылырга онытылган нәрсә караватт астында аунап ятадыр кебек. Галина Осадчая хат язмады, ашыгыч хәбәр җибәрмәде. Мәдияр килгәнне дөрес кенә көтеп тик ятты. Татар илен үз күзләре белән күрмәсә дә, бик яхшы беләдер кебек иде ул. Чөнки әтисе җае килгән саен, сугышны искә алган саен, татарлар турында искә алмыйча калмый торган иде. Карелия якларында сугышып йөргәндә буран чыгып кар күмсә дә, бүрәнәләр шартлап чатнардай суыкларда колак кикрикләрен уч төбе белән җылытканда да, ерып чыккысыз бөркү урманның канәчкеч озынборыннары белән сугышканда да язучы Абдурахман сугышчы дусларына: «Карагыз әле бу әкәмәтне, нәкъ безнең Татарстандагы кебек!» дип мактана торган иде. Шуна күрә Галина Мәдиярнын туган ягын, кышын—коры суыклы, җәен исә бөркү эсселе, черкиле урман арасындагы кыргый яклар итеп күз алдына китерә иде. Ә Ростов якларында, Галина туып-үскән Батайски каласында кыска һәм йомшак кыш, җылы һәм озын җәй, коры көз, чәчәкле яз гына. Урам уртасында матурлык һәм күләгә өчен тал, юкәләр түгел, ә груша белән сливалар үсеп утыра. Аларны беркем сакламый, беркем сындырмый, җиләк-җимешләрен пешеп җиткәнче үк өзеп таптап йөрми. Мәдиярнын Шуләнгерендә һәр алмагач-чияне чәнечкеле тимер чыбык белән урап, төбенә бозау чаклы эт бәйләп куй—барыбер урлап китәләр.

Татар арасында туып-үсеп яшәгән Мәдияр Галина өчен менә шушылай самолет белән очрашуларга гомер буе йөрергә әзер, әмма хохоллар арасына бөтенләйгә күчеп, Ростов якларына йортка керергә әзер түгел... Моның азагы булачак әлбәттә, кыз баланың һәрнәрсәгә вакыты чикләнгән. Ул эчтән янып-көеп кемнедер сөеп йөри ала, ләкин гомер буе түгел. Армиягә киткән егетен көтә ала икән—ул кайтып башкага өйләнгәнче генә; вәгъдәләшкән кешесенең вак-төяк мәшәкатьләрдән котылып кавышыйк, дип тәкъдим ясаганын сабыр гына көтеп йөри ала, ләкин кырык яшькәчә түгел. Чөнки хатын-кыз яшьләй сөйгән ярын онытып торып, армиядән кайткан егетеннән качып, гомер буе Мәҗнүн булырга вәгъдә биреп өйләнергә кыюлыгы җитми йөргән ярәшелгәнен куып җибәреп һич көтелмәгән берәү белән язмышын бәйләргә мөмкин—бала табу хакына! Хатын-кызның ана булу теләге мәхәббәт эзләүдән көчлерәк. Бала хакына ул Хәлиленнән, Таһирыннан, Мәҗнүненнән һәм Мәдиярыннан баш тартырга мөмкин. Яраткан кешеңне эзләп табу җиңел түгел. Ләкин саклап калуы тагын да кыенрак. Мәдиярның Галинага өметләнер көннәре санаулы. Белми түгел, белә ул моны. Хәтта күңеленнән генә бер хәйләсен дә корып куйды... Галина янына иркенләбрәк кайткач, ул яшәгән якта языльшырга. Ростовның «Кавказ» ресторанында шаулатып туй үткәрергә, вахта ысулы белән Себердә эшләүче татар нефтьчеләре кебек Ростовтан Казанга (Актанышка дисәк төгәлрәк булыр) кайтып-китеп эшкә йөрергә... Галинаның буйга узганын көтәргә. Инде ул корсак

ялына чыккач, минем туган якларны да күреп килик, дип, Шүләнгергә алып кайтырга... Бала Шүләнгердә туарга тиеш. Бала туган җирдә тамыр җәюе җиңелрәк. Әгәр инде руслар белән аралашып яшисем килә дисә, Мамадышка күчеп яшәргә була... Мамадыш саласында урыстан күп кеше юк...

Бораулау агрегаты Актанышта бер айга бүленеп калгач, Әмир Әшрапов бригадасын мәҗбүри ялга җибәрделәр.

Мәдияр—тагын Ростов самолетында. Гашыйкларны кавыштыру өчен егерме биш сумлык билет та житә икән бит, әй!..

## Кияү куенындагы кыз кем була?

Җирнен тундырмасы эреде. Табигатьнен холкы тәүлегенә ике-өч тапкыр үзгәреп тора. Якты көн эчендә кышы, язы, җәе—өчәүләшеп тәхет бүлешә. Бит алмаларын чеметерлек иртәнге дымлы салкын ашыгып туган каз бәпкәләре өчен ашыгып шыткан чирәмнәрне әрәм итә инде дигәндә генә Агыйделнең аръягыннан кояш килеп чыга да кыш чалымнарын җиргә сылый. Җирнең юеш бишмәте күзгә күренеп кибә башлый. Кар өемнәре арасында тунып яткан гөрләвекләр, кояшка чыгып җылынгач, елга-елга булып уйный. Әнә, чик буйлатып, кырыйдан-кырыйдан гына Сөн гөрләвеге Агыйдел ташкынына ашыга. Вак инешләрне үзенә сыйдыра алмыйча тармакланган Шәбез гөрләвегенең берсе Чулманга төшеп бара. Ык елгасына охшаган гөрләвек диңгезгә кою өчен үзенә иң кыска юлны тапкан... Һәр гөрләвекнең үзенә хас борылмалары, бусагалары, ярлары, һәм хәтта чүп-чары бар... Гөрләвекләр җир өстен бер кат юып чыккач, туфракның суркыганын да көтеп тормыйча тузганак чәчәкләре кабына. Сары төскә зәңгәр һәм кызыл төсләр килеп кушылыр. Актаныш болыннарында печән диган нәрсә юк—монда тыгызланып үскән чәчәк тә чәчәк кенә булыр...

Фазыл үзен су уртасында, Актанышның кеше яшәми торган бер утравында бүленеп калгандай хис итте. Машиналар туктаусыз йөри алырдай тапталган юлдан ике чакрым читтә, утсыз, сусыз һәм радиосыз калган бугай ул. Дөрес, иртәнге гөрләвекләрне савып, бар каләресе савыт-сабаларны тутырып куйган иде инде Фазыл. Ут яктысы кирәсен килсә, машинаны кабызып, фара яктысында утырып була. Төн куены кыркуланса, яшел вагонның чуен мичеңә ягып җибәрер өчен шактый гына торф брикетлары бар. Ә менә олы юлның өзеклеге кәефне борчый. Кул астында сигез цилиндрлы двигателен нәрсәгә җигәргә белми торган машина барында утрау тоткынына баш иеп яту хурландыра, җанны үрти. Олы юлның икенче башында Аккүз авылы... Әлфинә яз кояшына утыз чакрымга якынрак яши. Ул әле Фазылның Актанышта бүленеп калганын белми. Белсә, бәлки бораулаучы егетнең юл өзеген сылтау итеп күрешерлек чара эзләмәвен һич гафу кылмас иде. Фазыл үзе язны ашыктырырга тиеш...

Фазыл көне буе юлга әзерләнде. Арбадан унышар метрлы ике корыч аркан табып, су ташучы машинаның мичкә авызына урап куйды. Ике тимер чөй, кувалда, тирән эчле һәм очлы көрәкләр, куныч бот төбенә чаклы җитә торган резин итекләрне мичкә читенә беркетелгән озын тимер сандыкка тутырды. Машинаның арткы көпчәкләренә чылбырдан үрелгән «күлмәк» кидерде.

Иртән иртүк, сыер савучылар гына капкадан чыгар чакта машинаны кабызды. «Алга, язга таба!»—диде ул үз-үзенә һәм машина, гөрләвекләр өстендәге юка боз тәрәзәләрне ватып, кышкы юл эзеннән олы юл ягына үрмәләде. Көпчәкләр киезгә төрелгәндәй калынайды—канат астына сыймыйлар. Клеверлы утрау Фазылны үзеннән җибәрәсе килмәгән кебек кылана—ул машинаны сумаладай балчыкка ябыштырып куймакчы, көчәр

тиярлек буразналарга батырмакчы, сыек боламыкларда йөздермәкче. Двигательнең туктаусыз үкереп баруыннан кабинага кызган май исе тула, радиатордагы су кайнап чыгарга житешә, алгы тәгәрмәчләр, һай, әкрен әйләнә...

Кабинадагы кызуга кояш җылысы өстәлеп, инде кунак кызларның йокыдан уяныр чагы җиткәндә, Фазылның машинасы күтәртелгән юлга менәм дигәндә, соңгы сазлыкны кичкәндә, кинәт радиаторга су чәчрәүдән сүнеп калды. Әгәр сүнмәгән булса, килгән уңайга шушы тизлеге белән такыр юлга менеп җитәсе иде югыйсә...

Инде су чәчрәгән двигательнең кипкәнен көтеп утырырга кирәк. Ык аша күпер сүтелгәч ерак юлга чыгардай машина күренми. Кем әйтмешли, бөтен транспорт язгы техосмотрга әзерләнә—ямыйсын ямап, буйыйсын буяп, майлыйсын майлап куяр чак.

Тик торган машинаны боламык йота торды, кабынгач та урыныннан кузгалмыйча үкереп тик утырды... Менә шушы минут өчен кирәк иде инде ул корыч арканнар...

Фазыл арканның бер очын арткы куш көпчәкләр арасына монтажка белән эләктерде, икенче очын машинаның алгы ягына сузып җиргә тимер чөй белән какты... Ике арканны ике яктан тарттырып куйгач, мичкәле машина рельс өстенә баскан уенчык паровоз сыман күренде. Ниһаять, двигатель кабынып машинага җан кергәч, бер урында бушка әйләнеп утырган куш көпчәкләр арасына корыч аркан урала башлады, уралган саен «уенчык паровоз» аркан-рельс буйлап тимер чөйләргә килеп терәлгәнче алга тәгәрәде.

Олы юлга аяк баскач, Фазыл җиңел сулап куйды. Ул әле бер якны, әле икенче якны домкратка күтәреп, көпчәкләргә уралган арканнарны сүтеп алды. Юл читендәге карлы күлдән су ташып машинаны юды; комбинезонын, каеш итекләрен сандыкка бикләп, кабинадагы рюкзактан алып, теге ак кәчтүн-чалбарны киде; тар якалы ачык сары нейлон күлмәк өстенә ап-ак галстук элде; очлы башлы ботинкаларын бәрхет кисәге белән шомартып, ниһаять ишек яңагындагы көзгегә үрелеп чәчен тарады—болай ничава кебек инде... Аккүз кызлары кызыкмаслык түгел.

Туп-туры Аккүзгә кабаланып китеп бармады Фазыл. Актаныш почтасына телеграф белән җибәрелгән получкасын кереп алды. Аннан кибеткә юнәлде. Рюкзак тулганчы консервлар, прәннек, май, Актанышның икмәк заводы чыгарган конфет, ак күмәч, шоколад җыйды. Ике кило тынчыган селедка пакетына бәйләп бер кап Һинд чәе саталар иде, Фазыл алты кило балыкны алган җирендә үк ташлап калдырды... һәм универмаг ишеге төбендә кәсеп итүче җирле чегән хатыныннан 100 тәңкәгә эре-эре чәчәкләр төшерелгән яшел төстәге шакмаклы япон яулыгы алып ак кәчтүненең куен кесәсенә салгач, Фазылга Иске Актанышта ямансу булып тоелды, су ташучы машина кабинасыннан ак галстуклар тагып чыккан шоферның ялтыравык ботинкаларын ләпеккә тидерергә куркып кына атлавын күреп: «Исәрме соң әллә бу?»—дип борыла-борыла карап калган түткәйләргә исе дә китмәде аның... Ашыга Фазыл, Әлфинәле язга таба ашыга.

Аккүзнең ындыр табагы янында—таныш урында, озак көттермәде Әлфинә. Ниндидер биш минут эчендә килеп тә житте—зәңгәр джерси пәлтә кигән; башында үзе бәйләгән йон калфак; аягында «чулки-сапоги» дип аталган биек үкчәле сыланып торган юка күн читек; кулында кар бөртеге сурәте төшерелгән зәңгәр бияләй...

Фазыл, җиргә сикереп, Әлфинәгә утырырга булышасы иде, тегесе битеннән шөпшә куган кешедәй кулларын бутап такмакларга тотынды:

—Берүк, кабинаңнан чыга күрмә! Кар бабай килгән дип балалар җыелмасын. Ончы Фәхри мәллә син?!

Кабинага утыргач, Фазыл:

—Нихәл син, Әлфинә,—дип сорап өлгердеме, юкмы, тегесе ашыктырырга кереште:

—Машинанны өйдәгеләр күргәнче тизрәк качыйк моннан... Шушындый пычрак арасында актан киенеп йөрмәсән... Әллә танымаслар дисенме?

—Сина матуррак күренәсем килде, Әлфинә. Сирәк күрешәбез ич.

—Безнен әти гомер буе эш киеменнән йөри. Сабан туе көнне генә үзгәрә.

—Әти булгач мин дә гел дегетле комбинезоннан гына йөрермен.

—Шулай ук мыни?

—Аңынчы бу ак кәчтүмем тузар әле дип кенә әйтәсем килгән иде. Әллә ниләр уйлый күрмә.

—Карале, Фазыл, минем бит өйдәге телефонның номерын биргәнем юк иде сиңа, каян белдең?

—Кыз бала үстергән әтиләр кырыс була инде ул. Телефонны бикли, капкага эт бәйли, өй түренә малай-шалай китерми. Почтадан акча алганда өстәлдә район телефоннарының китабын күреп калдым да, туктале, минәйтәм, райкомда зур туганы эшләгән гаиләнең өендә телефоны булмыйча калмас... Аккүз авылы дигән битне ачсам—менә сина мә! Сезнең номер.

—Казаннан шалтыратасың дип уйладым. Коелып төштем, ярый әле, өйдә кеше юк иде.

—Юл өзегендә бүленеп калдым мин, Әлфинә. Казан ерак инде.

—Ә башкаларыгыз нишли?

—Алар Казанда.

—Ничек инде?

—Аларның Әлфинәләре Казанда.

Кызый серле бер сөенеч белән Фазылга карап алды.

—Без кая барабыз хәзер, Фазыл?

—Без кая барабыз хәзер, Әлфинә?

—Өйдәгеләргә мин Каенлыктагы әбиемә барып кайтам дидем. Язгы каникул бик кыска ул—эшләрем өелгән.

—Әтиең тагын матай белән куып тотар микән?

—Матайлар йөри торган чак җитмәгән әле.Юл төшсен.

—Мин дә Ниса кортканы сагындым.

—Барабыз бит инде... Күрерсең.

Күтәрелгән такыр юлдан машина Богады борылышына бик тиз килеп җитте. Ләкин Әлфинә Каенлык юлына төшәргә кушмады.

—Батып ятмабызмы, Фазыл? Ак кәчтүмең харап була бит.

—Син әле минем бүген иртән буровойдан ничек чыкканны күрсәң—Каенлыкның бөтен ләпеген җыйсаң да ул хәтле булмас. Дөрес, таң алдыннан су качкан иде.

—Әйе шул, без дә таң атканчы шушында утырыйк, салкын төшкәнне көтик...

—Тагын уникe сәгать түзәрсеңме соң, Әлфинә?! Ачтан үлмәбез анысы, капчык тулы.

—Кызык, синең белән күрешкән минутларны бергә кушып санасаң, ярты көнгә җыелыр микән?

—Һәм бүгенгесе белән нәкъ бер көнгә тула, әйеме?

Фазылның шул мизгелдә куены кызышкандай тоелды... һәм ул кинәт буләгән исенә төшереп кулын кесәсенә тыкты.

—Әлфинә, калфагыңны салып тор, күзеңне йом.

—Калфакны салам. Күзне йоммыйм. Авыл җире бу...

—Курыкма инде, Әлфинә. Мәктәп баласын үбеп маташмам, үсеп житкәненне көтәрмен.

—Нинди мәктәп баласы булыйм ди инде мин, Фазыл! Бу бит минем иң соңгы каникулым. Тагын өч айдан...

Әлфинә күзләрен йомды. Хәтта Фазыл аны бүләк яулыкка төреп куйгач та ачмады ул күзләрен. Егет түзмәде, шәльяулыкка ышыкланып кына кызның иреннәренә үрелде. Әлфинә чамасыз кайнар чәй йоткандай кинәт сискәнеп куйды. Ләкин Фазыл ул иреннәрдән аерыла алмады.

Егет җанындагы тынгысыз сусау, сөеклеңне очрату сөенече, сафлыкка орыну дәрте, кызның ризалыгы—барысы бергә кушылып, гәүдәләрнең хәлен алырлык татлы үбешүгә әверелде.

—Кайдадыр, җиде дингез аръягында, җиде мең чакрым ераклыкта, ниндидер япон кызлары синең өчен менә шушы яулыкны бизәп утырганнар.

—Рәхмәт...

—Әлфинә дим, Әлфинә!..

—Әйт сүзеңне.

—Уйларымны кычкырып әйтергә кушасыңмы?

—Әйт, Фазыл!

—Әлфинә, әйдә буровойга кайтыйк. Яшел вагон өебез булыр. Таң атканчы янында буласым килә. Анда бөтен техника хуҗасыз калды. Һич югы шушы кичне булса да миңа бүләк ит. Әле тагын кайчан шушылай күрешә алырбыз. Сөйләшәсе, аңлашасы, киңәшәсе бар. Әгәр без ешрак күрешсәк, син арабызга кеше кертмәс идең. Бәлки вәгъдәләр бирешер чак җиткәндер инде, Әлфинә?! Әйдә, китик Актанышка. Мин бүгенге очрашуга бозлы Агыйдел кичеп, юлсыз кырлар үтеп килдем, Әлфинә! Мин хәзер синнән башка яши алмаячакмын...

Фазыл, Әлфинәнең «Юк» дигән катгый җавабы күмелеп калсын, дигәндәй, сүз өстенә сүз, җөмлә өстенә җөмлә тезде... Әлфинә каршы дәшмәде. Фазыл әкрен генә машинаны кабызды, урыннан кузгалды. Әлфинә дәшмәде... һәм алар Каенлык юлыннан һаман саен ерагая бардылар... Машина да Фазылга ярдәм итәргә теләде, кыз кире уйлаганчы тизрәк яшел вагон янына илтеп җиткерим дигәндәй, очты гына. Сикәлтәләрне тоймады, борылышларда читкә кыймады, үр менгәндә акрынай-мады, иртән батып яткан карлы күлне йөзеп кенә чыкты, сыек бураз-наларны канатланып үтте. Инде яшел вагон фара яктысына килеп кергән иде... Әллә тизлекне киметү ярамады, әллә тагын карбюраторга су чәчрәде, машина, ыргылып очкан җиреннән бер-ике төчкерде дә, кинәт сүнеп калды. Ә яңадан кабынганда көпчәкләр бер урында әйләнә иде инде.

—Интектермә машинаны, Фазыл. Көн ачылгач берәр җае чыгар әле. Өстебездән явып тормый, урыныбыз йомшак, җылы.

—Әнә генә бит инде вагон, әнә!..

—Нәрсәгә кирәк соң ул вагон? Тик утыр машинаңда.

—Вагон өй бит инде ул, Әлфинә! Икебезнең өй!

—Бәләкәй чакта чәчәкле пыяла ватыклары җыйнап өй бизәшле уйный идек без. Ә бүген андый уеннар уйнарга иртәрәк әле. Минем укып бетерәсем бар.

—Озын куңычлы итекләрне киям дә сине кулларымда күтәреп вагонга илтеп куям.

—Вагонгамы, әллә караватка дип әйтәсең киләме, Фазыл?

—Белмим, Әлфинә. Яраткан кешеләр бер-берсенә андый туры сорау бирергә тиеш түгелләрдер.

—Яратуны иңне-иңгә куеп утырып та исбатларга була аны.

Двигатель йокымсырап кына эшли, аякларга җылы һава өрдереп тора. Фазыл кабина ишегенә сөялеп утырды, Әлфинә аңа авышты. Егетнең иреннәре кызның чәченә төртелде.. Гомер бакый яшәп, хәтеренә уелып кала һәм искә төшкәндә сагындырып җанны тетрәтә торган иң тәмле йокы—шушы инде ул. Дөресрәге, йокы түгел, йоклаганга сабышу бу.

Үсмер ай кызлар күзләргә чыккан, Актанышбаш өстендә үзенә урын таба алмый, ерактагы өй шәүләләрен нурга күмеп, әле моржага килеп утыра, өянкеләрдә яңа тормыш тергезгән карга ояларына килеп куна, анда озак тормый—адашып йөргән вак болытларга килеп бәйләнә, күзен кысып кына җирдәге гашыйкларның язгы авазын көнләшеп тыңлап тора...

Табигать бездән башка үзе генә яшәгән чакта, кешеләр туасыга

алдан кануннар әзерләп куйган. Әнә шул кануннар нигезендә Адәм белән Һәүва үзләренә яшәү шартлары тудыра башлаган. Бүгенге ялган пәйгамбәрләр исә, табигатьнең ошбу тәҗрибәсен инкарь итеп, әүвәл җәмгыять төзеп куярлар, аннан соң гына законнар тудыра башларлар.

Җан иясе үзен кеше итеп тоя башлагач, иң беренче яшәү шарты итеп мәхәббәтне эзләр. Гашыйк кеше өчен ашау-эчү, киенү, эшләү һәм яшәү гаме әллә ни мөһим түгел. Гашыйк кеше кавышуны төп максат итәр һәм кирәксә, бүтән яшәү шартларыннан—хәтта газиз гомереннән дә ваз кичәр...

Ләкин!

Ләкин Тәңрем, бизмәнне тигез тотар өчен, бер тәлинкәгә мәхәббәт салса, икенчесенә нәфрәт салыр. Берәү кавышса—икенчеләрне аерыр. Берәү килсә—икенче берәү китәргә тиештер. Әгәр диңгез өстендә алтын балык күреп, палубадагы барлык пассажирлар бер якка өелсә, ул кораб авып, батуга дучар булыр. Хәлбуки, планетабыздагы барлык кешеләр тоташтан бәхетле, мөлкәтле һәм парлы булсалар, Җир шары үзенең көчәрен югалтыр иде. Җир миллиард еллар буе тигезләгән имин саклый алган. Чөнки берне бирсә—берне алган; берәүне ашатса—икенче берәүне ач калдырган; кемдер киенсен өчен кемнедер шәрә чишендергән; көнгә—төнне, утка—суны тәкъдир иткән; бәхеткә—хәсрәт, елауга—көлү, битарафка—сагыну каршы төшкән; мәхәббәттән—нәфрәт, кавышудан—аерылышу, байлыктан сугыш азынган...

Табигать кануннарына буйсынмыйча, яшәеш эзеннән тайпылу очраклары берән-сәрән генә булган кебек, бер-берсен өзелеп сөйгән ике саф йөрәкнең кавышып гаилә кора алуы да бик сирәк күренеш. Тузганак мамыкка төреп йөз орлык очыра—шуның бары тик бер-икесе үсеп китә ала... Алма чәчәгенә меңәрләгән серкә коела—җимшәндә өч-дүрт орлык үсәр...

Якында гына ниндидер чит машина гүелдәве Фазыл белән Әлфинәнең «сандугач йокысын» бүлде.

—Бәлки безне тартып чыгарырга дип килүләредер,—диде кыз, һәм тиз генә чәчен-башын төзәткәләде, пәлтә төймәләрен каптырды.

—«Вездеход» булса көче җитәргә мөмкин!—Фазыл ян тәрәзәгә кунган салкын парны уч төбе белән сөртеп, ишек янагындагы көзгегә карады.—«УАЗик»ка охшаган. Галимҗановныкы, ахрысы.

—Абыймы? Абау... Кайтып әйтсә, әти үтерә мине...

—Сәгать кичке сигез генә бит әле. Нәкъ клубка чыга торган вакыт.

«УАЗ»ик юлсыз җирдә шәбрәк йөри бит әле ул—Галимҗанов, Фазылларны әйләнеп узып, алга кереп туктады. Ләкин кабинадан хатын-кыз чыкты.

—Әллә әни инде, ходаем!—дип шыңшыды Әлфинә.—Утыңны яндыр әле, Фазыл!

Фара яктысына таба, кыска балтырлы резин итекләрен балчыктан көч-хәл белән йолкып, Язилә килә иде. Аның башына япкан махер шарфы муенына төшкән, чәчләре тузгыган. Килә-килешкә үк Фазыл ягындагы ишеккә юнәлде.

—Кемең бу синең?—дип гаҗәпләнде Әлфинә, баягы гамьне бик тиз онытып.

—Беркемем дә түгел... Язилә ич ул... Безнең мастерның кызы...

—Әтисе кайтып китте дигән идең ич. Монысы нишләп йөри соң алайса?

—Каян белим? Казаннан юл юк килеш ничек монда килеп җитә алган дип аптырап утырам әле үзем дә.

—Аптырарлыгың бардыр. Сәбәбе булмаса, җәһәннәмнән тиклем эзләп килмәсләр иде...

Язилә ишек ачылып беткәнне дә көтмичә кабинага сикереп менде, Фазылның муенын ике куллап камыт урынына кочаклап алды да үкереп елый башлады:

—Мин сине эзләп таба алмам дигән идем инде. Бөгелмәдән вахта ташый торган вертолет белән килдем. Бораулау мастерының кызы мин дигәч, алдылар, акча да сорамадылар. Актаныштан бик күп кеше читкә йөреп эшли икән, моннан Бөгелмәгә, аннан Сургутка илтәләр ди. Фазыл! Кияү! Эшләр харап бит безнең... Сөйләшәсе бар синең белән. Икәүдән-икәү генә...

Әлфинә үзен өченче, артык кеше итеп тойды. Кабина ишеген ачты—сизмәделәр; җиргә төште—күрмәделәр; Галимҗанов «УАЗ»игына таба китте—туктатмадылар... Ул арада райком машинасы Фазылның хыялын алып, борылып китеп тә бара иде инде... Бүгенге кичнең хәвефен шунда гына тоеп алды Фазыл. Ул Әлфинә артыннан йөгерде—ак чалбарлары белән тездән бата-бата туфлиләре төшеп калганчы йөгерде, лутчы таптатыгыз мине, дигәндәй юлларына аркылы төште.

—Әлфинә, мин сине үзем илтеп куям, болай саубуллашмыйлар бит инде! Хәзер казып чыгарам машинамны бу алла каргаган баткаклыктан.

—Казы, казы, бәлки су чыгарырсың, барыбер коеларыгызның рәте булмады,—диде Галимҗанов, Әлфинә өчен дә үзе җавап тотарга теләп.—Ә сеңелкәшне калдырмыйм. Саф мәхәббәтнең үз кәмитләре бар аның, кем, Фазыл энем. Хәзер шушында, Әлфинә урынында күпне күргән туташ булса, җелегенә үткәнче аңлашыр иде, җылый-җылый ачуланыр, муенына асылыныр һәм ахыр чиктә, сине үзе белән алып китәр иде... Ә саф бала чык бөртеге кебек—җил кагылса да, кояш нуры кинәт бәрелсә дә коелып төшә, кибеп юкка чыга...

—Мине ордым-бәрдем ташлап китәрлек сәбәп юк бит әле монда.

—Юл өзеген ялгап, артыңнан килердәй кызларың булгач, Әлфинәне урларга ашыгасы түгел иде. Эзләп табалар шул алар, кем, Фазыл кияү!

—Абый, алай димә!—Монысы Әлфинәнең тоник тавышы иде.

—Ул бит әтисен эзләп килгән. Минем кыз түгел ич ул...

—Йә, йә, Фазыл, егет кеше була бел. Алар барысы да әти кызы. Юлда аркылы торма. Шәхси маҗараларыңны райком югарылыгында хәл иттереп ямьсезләнмә. Әлфинә өчен борчылма, яшь җәрәхәт төзәлә әле ул...

Клеверлы утраудан ерагая барган машинаның ян тәрәзә өлгесеннән агылып чыккан бүләк яулык җил кулына калды. Көнче җил, Фазылның җиңелүеннән тантана итеп, ул яулыкны түмгәктән-түмгәккә бәрде, балчыкка сылады, егет кулына истәлек булып әйләнеп кайта күрмәсен тагын, дигәндәй, Әлфинәне алып киткән машина эзендәге суга китереп каплады.

Фазыл, ак кәчтүме белән пычрак төнне ярып, яшел вагонга таба атлады. Яланаяк килеш бозлы суда йөргәне бар иде инде аның. Агыйделне ике кичмә икән ул... Әгәр Фазыл бозлы Агыйделне ерып чыккан килеш егетләргә ияреп Казанга кайтып киткән булса, Әлфинә юл өзеге беткәнче күрешүгә өметләнеп, бораулаучы егетне көтеп утырасы кеше иде. Хәзер беркем-беркемне көтми! Көтәр кешең юк икән, син тагын ничек итеп яшәргә тиеш?!.

Яшел вагонга Фазыл артыннан кабаланып Язилә килеп керде.

—Миңа багышланган төн иде бу, Язилә! Нәрсә эзләп йөрисең монда?! Кем чакырды? Син мине бүген гомергә буйдак калдырдың.

—Юкны сөйләмәсәнә! Сөйгән кызы ташлаган саен өйләнүдән ваз кичсә, бөтен ирләр ялгыз яшәр иде. Мәхәббәт—уйлап чыгарылган кино гына ул, кемнең фантазиясе көчлерәк—шуның киносы кызыграк.

—Ә менә бу вагон—тормыш дип аталамы инде?!

—Әлбәттә тормыш. Яланаяк кар суында йөреп салкын тидерәсең дә гомер буе урын өстендә гарип булып ятасың. Авызыңа дару салып торырга кешең бармы—юк!

—Син мине коткарырга дип килдеңме?

—Юк! Мин әтине эзләп килдем...

—Кайтып китте ич инде алар Казанга. Телеграф буенча, әнә, мина акча жибәрттергән.

—Кайтты ул... Ишектән керүгә гауга куптарды. Минем алда ызгышканнары юк иде монарчы. «БУ» дигән сүз сезнең телдә нәрсәне аңлата ул, Фазыл?

—«БУ»... Бывший в употреблении дигән сүз. Тотылган нәрсә, ягъни.

—Жыен килделе-киттеле сүзләр сездән чыга инде. Әти жүләр әниемә: «БУ!» син, «БУ!» «БУ!» дип, өч тапкыр әйтте. Мин аны әллә «Талак» дигән сүзме дип уйладым. Сез гел бергә идегез бит инде әти белән... Берәрсе котыртып кайтармагандыр ич аны. Әни жибәрде мине, әтиен эшенә килеп житте микән дип.

—Актанышка юл юк ләбаса!

—Мин килеп життем ич әле...

—Әтиең кайда инде хәзер?

—Безне ташлап чыгып киткәнен генә беләм.

—Әрләшү—сөешеп яшәүнең бер төре ул, Язилә. Беркая китә алмас әтиең, кайтыр.

—Ул бөтенләйгә ташлап китте безне.

—Күрәзәче булмасам да, мин Әмир абыйда үземнең язмышымны күрәм, ул миннән алданрак бара... Соңрак мин дә аның язмышын кабатлармын. Күрәсең, безнең профессиягә хас гадәти язмыштыр инде ул.

—Ник алай соң ул, Фазыл?

—Әнә, күрдең ич, мине пычрак уртасында калдырып китеп барды Әлфинә! Ул бит мәхәббәтнең үзе иде.

—Китәсе кешенең беренче көнне үк китеп баруы әйбәтрәк. Соңрак китсә, аерылышуы тагын да газаплырак булыр иде. Мәктәп баласының холкы кырыкка төрләнер әле... Авылдан киткәч, синең кебек романтик егетләр күп очрар әле аңа... Менә мин әтием исән килеш ятим калдым. Сөйгән кызларны алыштырып була—әти бер генә.

—Алайса, бүген мин сине юатырга тиешме?

—Юатма! Үзеңне кара. Аягыңны кайнар суга тыгып утырырга кирәк. Хәер, тиз генә кайнар суны каян алырсың аны? Аракы бармы монда?

—Бар! Әнә, сәке астында бер ящик.

—Салып ташла туй кәчтүмеңне. Пычрак чалбарыңны ыргыт—аракы белән аягыңны юам. Авыру егетнең беркемгә кирәге юк. Мәхәббәт аркасында башыңны әрәм итәләрме?! Мәхәббәттән дә көчлерәк наз бар әле бу дөньяда, кияү!.. Бер стакан тутырып эчеп куярсың—эчтән жылытсын. Вагонда кабымлыгың бармы?

—Машинада калды. Рюкзак белән.

—Хәзер... Хәзер тиз генә алып киләм... Әйтәм ич, синең гомереңне саклап калыр өчен ашкынганмын икән мин бу Актанышка!..

*(Беренче кисәк тәмам).*

*1999 ел*

# «ЧЫНЫГА ТОР...»

## ФӘЙРҮЗӘ ИСМӘГЫЙЛЕВА ШИГЫРЬЛӘРЕН УКЫГАЧ

*Моннан 7-8 ел элек Фәйрүзә Исмәгыйлева кем ул? дип сорасалар, мөгаен, шигырьдәгечә «таныйм да, танымыйм да» дип әйткән булыр идем. Үзен юньләп күреп белмим (беренче күрешеп-сөйләшү 1991 елның көзендә дип хәтердә калган. «Казан утлары» редакциясенең корректорлар бүлмәсендә какча гәүдәле, дымсу күзле, өлкән курс студенткасы кебек тере, шул ук вакытта сәер оялчан кызчык-ханымны күргәч, «бу күбәләк җан иясенең дә сагыш-моңы, нужа-хәсрәте бардыр инде, юкса шигырьгә ябышмас иде» диебрәк уйлап та куйган идем), язганнарын да матбугатта бик сирәк күреп барам. Шулай да, Р. Зәйдулла, Г. Морат, Л. Зөлкәрнәйләр белән бер үк чорда Шигъриятькә килүчеләр арасында Исмәгыйлева дигән өметле каләм иясе барлыгын белә идем, әмма аның хакында ачык, тулы фикерем юк иде. Хәзер Фәйрүзә ханым иҗаты турында беркадәр беләм дип исәплим. Китап итеп чыгарырга әзерләнгән кулъязмасын җентекләп укырга туры килде. Йөз иллеләп шигырь анда. Нигездә кыска шигырьләр. 1991 елда ук Татарстан китап нәшриятына тапшырылган, соңрак темпланга да кергән булган. Ә китап булып чыкмый калган. Заманаларның үзгәрүе дә йогынты ясагандыр, авторның да максатчан үҗәтлеге дә җитмәгән, күрәсең... Кулъязмада «шигырьгә кемнеңдер килүе, ә минем китүем хәерле...» кебек юлларның булуы очраклы түгелдер. Кызганыч, бер яхшы шигырь китабы үз вакытында чыкмый калган. Ә ун еллап вакыт—һәр заманда да байтак вакыт ул.*

*Әдәбиятчыга—башлап язучымы ул, классикмы—төп критерий бер: нәрсә турында язасың, ничек язасың? Әлбәттә, белгәнне язырга; әлбәттә, үзеңчә, шул ук вакытта, кешеләргә дә ирешерлек халыкчан итеп язырга тиешсең. Бу таләпләргә Фәйрүзә шигырьләре, нигездә, җавап бирә дип уйлыйм.*

*Ф. Исмәгыйлева—дипломы буенча журналист саналса да, асылы белән педагог-тәрбияче ул. Университет тәмамлагач, дистә еллар буе балалар бакчасында—нәниләр арасында (Миңа калса, хатын-кыз шагыйрә өчен, илһам өчен менә дигән җирлек!). Авылның әнә шул нәниләр дөньясында үзенең дә алма кебек өч баласы тернәкләнеп үсеп килә.*

Ни әвәләсәм—шул пешәр:
сигезле итсәм—сигезле,
кабартма итсәм—кабартма,
мөгезле итсәм—мөгезле.

Шундый уйлар белән бүген
юдым да онлы кулымны,
әвәли-әвәли сөйдем
елмаеп яткан улымны!

*Бәхәсләшмәсләр дип уйлыйм: мондый юлларны язу өчен белү генә җитми, кичерү кирәк, әйтү генә җитми, күңел кардиограммасын ачып салу кирәк. Мисалга тагын берничә юл:*

Алны-ялны белми елыйсың—
шулай җиңәм мин, дисең.
Чыныга тор: үскәч хәсрәтләрне
җылап та җиңә алмыйсың.

* * *

Нәни малай керде төшкә—
өлгерәлмәсәм да танып,
туп уйнаткандай, күкләргә
чөепләр сөйдем аны.

Ә аннары атындырдым,
утырттым да агач атка.
Малай күккә томырылды—
Акбүз атка канат чыкты!

*Ярый, Фәйрүзә белгәнен белеп яза дидек, ә «ничек яза?»ны ничек дәлиллибез? «Үзенчә яза» дию бик абстракт сүз. Шулай да әнә шул «үзенчә»гә керә торган, минемчә, бик әһәмиятле бер сыйфат—чама хисе. Без заманында шигырь-поэма дип аталган су буе фикерсез язмалар укып үстек. Ялыктырды алар безне. Кыска формаларның соңгы дистә елларда лаеклы урын даулавы әнә шул мәгънәсез (мәнсез) озынлыкка бер протест-гамәл булгандыр, күрәсең. Егет сүзе—кыска булыр. Шигырьдә кызларның егет булуы ошый миңа. Фәйрүзә дә озынга сузмый шигырьләрен. Сүз—эпик колач җитмәүдә түгел, хикмәт—үз (сүз) кадереңне белүдә, фикер җегәрен анык белүдә, әдәп-тактта, һәм, ниһаять, укучыны хөрмәтләүдә.*

Сирәк язам шигырьләрне
алданган чакта гына,
өзелгән чакта гына,
ялганган чакта гына.

*Шигырь Дөньяны үзгәртә аламы? Шагыйрьләр (шул исәптән без дә) әйе, шигырьшлаһи сүз күпмедер дәрәҗәдә үзгәртә, яхшырта ала дип, шул ышаныч белән гомер кичкән кешеләр. Әмма ялган пафос, фальшь белән Дөньяны яхшыга үзгәртү түгел, киресенчә, бозасың гына. Карлыгач томшыгы белән балчык ташып оя сылаган, кырмыска бөек архитектура үрнәге түмгәк-храмын корган кебек, шигырьче дә фәкать үзе күтәрә алган идея-фикерне, шуңа кешеләр алдында җавап тота алырга лаек булып, бөтеннәргә җиткереп иҗат итәргә тиеш. Бу—әле беренче китабын яңа чыгарып килә торган Фәйрүзәдән бигрәк, үзебезгә—шагыйрәдән яшь буенча күпкә өлкән каләмдәшләргә дә кагыла. Фәйрүзә бу хакта уйланамы, уйлаганмы, белмим, әмма эчке тоемы, интеллекты моны, ягъни, алда әйтелгәнне интуитив рәвештә яхшы аңлый кебек.*

* * *

Мөлдерәмә күңел белән
Вакыт дәрьясында агышым.

* * *

Үзем генә каласы бар...

* * *

Гөлчәчәкле алан булыр
күз яшьләрем тамган урын.

* * *

Ярамый икән иртәгә
язларның кичке акылы...

*Фәйрүзә ханым ерак Азнакайда—әдәби хәрәкәтнең үзәгеннән (хәер, бу төбәктән дә шактый кызыклы шагыйрьләр үсеп чыкты соңгы 20-25 ел эчендә: М. Галиев, Ф. Гыйззәтуллина, Н. Әхмәдиев, И. Гыйләҗев...) шактый еракта яши. Шаулы, бәхәсле мәдәни-әдәби «казанда» аралашып яшәмәү сизелә. Инде мәгълүм мотивларны кабатлаулар очрый. Техник яктан эшләнеш—рифма-ритм төгәлсезлекләре дә юк түгел. Самимилек, ихласлыгы белән алдыра да, күбесен кичерәсең. Иң мөһиме—иҗатта очу биеклекләрен бутамау. Бөркет чыпчык булып, чыпчык бөркет хис итеп, очыш юлларын бутаса көлке...*

*... Элек әдәбиятка керү кыен иде. Күпме киртә-капкалар! Һәм... көндәлек матбугатта—ничаклы талант иясенә—кульяулык чаклы мәйдан! Партия органнары*

*житәкләгән басмаларда 10-15 юл чын шигырь чыгару үзе бер вакыйга иде. Ә хәзер хөррият! Сүз ирәгән тыючы юк. Ә хәзер кемнәр генә чыгармый китапны! Яз да яз! Фәйрүзәнең үзе әйтмешли, әвәлә дә пешер! Юк шул! Беренче карашка гына җиңел кебек. Хәзер ул кыен чын әдәбиятка юл яру! Ни өченме? Беренчедән, моңарчы җыелган (һәм тыелган!) Бөек Мирас безгә ирешә. (60 еллар башында яхшы китап таба алсаң, төлке тоткан кебек сизә идең үзеңне). Икенчедән, китап укучы кимеде, гавәм китаптан бизде. Базарың булмый торып, чүлмәк ясап яшәп кара! Өченчедән, язу-сызу эшендә (әдәбиятта дип язасы килми) бик болганчык заман. Тәҗрибәсез укучыга ориентлашу кыен. Шәп тышлы, ялтыравыклы бизәкле китаплар тулып ята. Кайсы җәүһәр дә, кайсы ком-балчык (һәммәсе буяп бизәлгән!)?.. Шуңа күрә дә, хәзер Зур Әдәбиятка кереп, үзеңә урын даулау бик кыен. Мондый хезмәткә алыну—сабый батырлыгына тиң.*

... Сүз әйтмәгез  
хис канатында  
оча белүче бу хатынга.

Оча бирсен  
Җирдәге тормышны  
үз генә булса да  
матурлап.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН**  
*Июль, 1999.*



# Фәйрүзә Исмәгыйлева

## ЧАТЫРТАУНЫҢ КУЕНЫНДА

### Юрау

**Нәни малай керде төшкә—**  
**Өлгерәлмәсәм дә танып,**  
**Туп уйнаткандай, күкләргә**  
**Чөепләр сөйдем аны.**

**Ә аннары атындырдым,**  
**Утырттым да агач атка.**  
**Малай күккә томырылды—**  
**Акбүз атка канат чыкты!**

**Юрый торгач уйлап таптым:**  
**Агачы—шигъри аттыр ул.**  
**Тылсымлы төннәр иркенә**  
**Очалмасые талпынып!**

Малае—Илһам атлыдыр—
Каләмемне сихерләде.
...Күңелнең пәрдәсен ачып
Сибелделәр шигырьләрем!

## Алар...

Тормыш әсәрләре арасында
Сере бетмәс гаҗәп китап бар:
Ни өчен соң күзләренә кергәч
Сөйкемлерәк була ир-атлар?!

Җыерчыклар түгел—нур балкышы
Күзләр читендәге сызыклар.
Шул нурлары белән хикмәтле дә,
Мавыктыргыч алар, кызыклар...

## Гайбәт түгел

Сөйли авыл: имештер лә
Бер ир кулын тыймаган.
Чишмә юлында бүген дә
Ул хатынын кыйнаган.

...Тапталган һәм канаган ди
Ул төнне чыклы үлән.
...Хатын исән. Ә көянтә
Урталай сынып, үлгән.

Иртәгесен, имеш, хатын
Караса күтәрелеп,
Көянтә җаны әйләнгән
Салават күперенә...

И сөенгән хатын: димәк,
Күктә дөнья ямьлерәк!
Шуңа күрә җирдәгеләр
Китәләр ди Мәңгегә...

## Әнкәй

Балерина кебек йөри әнкәй—
Балам йокысы бүленмәсен!
Әллә ничә торып яңарта—
Самавырым, ди сүрелмәсен.

Моңаеп кала, календарьның
Ертып алган битенә карап.
...Шомырт чәчен хәтерли әле
Мич киртендәге сөяк тарак.

Сабый күзләре күк беркатлы—
Әнкәйдән китү бигрәк читен.
...Юлдан күмелгәнче озата
Күзләрен сөрткән яулык чите...

## Ә асылы...

Кеше холкы үзгәрми ул—
Минем инде сынаган бар.
Аңлап шушы хакыйкатьне
Сөенгән бар, елаган бар...

Кырыс холык була, әйтик,
Салкын кышка ул охшаган.
Ләкин ягымлы яз кебек
Буласына да ышанам.
...Ә асылы барыбер кыш аның!

Язга охшаш холык була
Ява яңгыры, кары да.
Гөрләвекле көннәре бар,
Көзгә тиң боек чагы да.
...Ә асылы барыбер яз аның!

Йомшак холык бар җәйгә тиң.
Ул бертөрле: яшел, яшел.
Тик кайчагында күңелендә
Дөрләп ала язгы яшен!
...Ә асылы барыбер җәй аның!

Күзләр сыман бай рух бар—
Ярлы чорның хакиме ул.
Ләкин кайчак нәүмизләнә,
Гүя дөнья фәкыйре ул.
...Ә асылы барыбер көз аның!

Мине аңларлар дип уйлыйм,
«Үзгәрер»,—дип чыдаганнар.
...Асылда үзгәрми холык—
Әллә ничә сынаган бар

## Без

Йөгерепләр килә каршыга—
Кылганнары безне таныды.
Чатыртауның җил оясы бу,
Оясында—тупыл мамыгы.

Җан шифасы була күрешү—
Хиссезләнеп калса күңелең.
...Кош баласыдай утырабыз
Тупыл мамыгына күмелеп.

* * *

Яшьлек белән очрашуга—
Казаныма барам.
Озата баручы кояш
Минем утта яна.

Җилдә уйлар җилгәрелә
Яктылары кала.
... Ерак юлда үзем белән
Якыная ара.

## Читәнгә читен микән

Белмим, кайчан, кемнәр үргәннәр—
Монда бит читән иде.
Ул агайлар күптән үлгәндер—
Ә читән исән иде!

Зәңгәр койма белән капланган
Борынгы иске читән.
...Каршысына киртә какканда
Тарих сискәнде микән?

* * *

Ирен читең белән көлеп кенә
Нигә соң ул шигырь, дисең дә,
Яшьлек белән генә сизмисеңдер,
Сискәнерсең әле бер—син дә!

Әйе, кеше малга омтылганда
Кирәкмидер шигырь. Шулай да—
Бабайлардан калган гүзәл җирдә
Хиссез булу—гонаһ бугай ла!

* * *

Киләсең ерактан—
Яшьлекнең үзеннән.
Дөньям чуалып, син
Күренгәч күземә.

Томалар да аңны,
Күңелдә чыңлар
Айлы кичтә икәү
Иҗат иткән җырлар.

Тик сулыш бер булмас,
Кушылса да тыннар.
...Чик сакчысы кебек
Сакта тора еллар...

## Мин

Күзләремә дөнья сыйган,
Гамьнәрем—тирән.
Тузанлы иске юлымнан
Болынга киләм.

Болынның хикмәтле ханы,
Син изүне яп.
Дилбегә—хуҗам кулында,
Мин—җигүле ат...

* * *

Биек ярдан суга чумулар
Саклангандыр инде холыкта.
...Офык читләренә басып
Сикерәсе килә болытка!

Әйләнә баш рәхәт уемнан—
Кучкән кебек дөнья кучәре.
...Иркәли-иркәли тирбәтә
Күпертелгән болыт түшәге.

Өрфиядәй дымсу мамыгы
Иреннәрең булып тоела.
...Җиргә йолдыз түгел, сөюдән
Чәчрәп-чәчрәп очкын коела!

## Илаһи мизгелдә

Мин—мәшәкатьтән качып
Вакытлыча күчкән утрау.
Үз-үземә төренеп
Хис диңгезендә утырам.

Тарафым—зәңгәр-зәңгәр,
Ирек төсенә буялган.
...Сизсәләр минсезлекне,
Үз урыныма куярлар.

## Апрельдә фасыллар очрашуы

Чатыртауның куенында
Карлар бетмәгән эреп...
Ә имәндә тыйнак кына
Елмая бөре.

Зәңгәр, сары гөлләр инде
Җәйләргә киткән кереп.
Сипкелләнгән тау битләре
Дөньяга карый көлеп!

Дүрт фасыл очрашуы бу—
Табигать җыйган барын.
... Юл читендә басып тора
Көзләргә кергән ханым...

* * *

Безнең яшьлек ничек сыйгандыр—
Мәллә бүген бигрәк тар сыман.
Утырам мин ярда уйланып
Балтам суга төшкән карт сыман.

Шушы төштә янды уртак хис—
Истә түгел көне, елы да.
...Эз сакламаганга үкенә
Сөзәк ярның кайнар комы да.

Суда икәү. Гүя, икебез—
Моңнарыма ничек җан чыдар?!
...Тәгәри дә төшә яңактан
Син чәчрәткән шаян тамчылар...

* * *

Әнкәй мине ни өчендер
Әткәм күлмәгенә биләгән.
Бишек җырын белмәгәнгә
«Герман көе»н күлмәк көйләгән.

Нәни яшьләремне сөрткән
Аның күпне күргән җиңнәре.
Шуңа күрә бишектән үк
Тоеп яшим әткәй иңнәрен.

Кысыбрак мине кочкандыр
Албастылар керсә төшемә.
Өнемдә дә юлдаш миңа
Әткәм кебек изге кешеләр.

Аз тырышканмы соң алар
Гөлләр итәр өчен илләрен?!
...Биләүдән үк сеңгән җанга
Әткәемнең тозлы тирләре...

## Их, сез ирләр...

Картайгандыр бу бичара—
Карт усак ауган сынып:
Бармаклары бар, мөгезе—
Тора шүрәле сыны.

Чакырса да янына ук
Орыныргa кыймадым.
Ләкин якты хисем белән
Дәваларга уйладым.

Их, ир заты... ни сөйлисең—
Ник калмаган якты моң?!
... Тукай куйган мөгез, дими,
Ә гаепли хатынын...

## Мин һәм Сез

Терелтегез, мин өшедем,
Бик озак очтым, дидем...
Учыгызга сыенучы
Күшеккән кошчык идем.

Киткәч белдем: үткәнемдә—
Иң якты хисләрем Сез.
...Минсез калгач үз дөньягыз,
Сез дә бер сискәнерсез.

Тыпырчынган кебек нидер,
Тетрәп куяр учыгыз.
Тоелыр гына шул... мин бит...
Бөтенләйгә...
Хушыгыз!

## Нәфис карым син

Үзеңә дип сузылган учка
Кунмый калган нәфис карым син.
Назлы куеныма сыенып
Атмый калган иркә таңым син.

Төшләреңә кереп йөдәтмиме
Үбелмичә калган иреннәр?!
...Куагында килеш сулдылар
Бүләк ителмәгән сиреньнәр.

Мәхәббәтнең уртак төенен
Язмыш бездән никтер качырган—
Сокланса да кыргый чәчәккә,
Үрелмичә киткән асыл яр!



**Илдус Хуҗин**

# ТАЙГАДАГЫ ФАҖИГА

хикәя

Көнбатыш Себер тайгасы.

Февраль аеның зәмһәрир суыклары хакимлек иткән вакыт. Әмма палатка эчендә җылы, юка тимердән эретеп ябыштырылган мичнең кабыргалары уттай кызган. Мичнең өстендәге чуенда аш кайный. Түрдәрәк, палатканың алгы казыгына, керосин лампасы беркетелгән. Аяк аска калын итеп түшәлгән нарат һәм кедр ылысы хуш ис тарата.

Бүген укучыларыбызга тәкъдим ителә торган бу хикәясе авторның Төмән геологоразведкасында эшләгәндә күргән һәм ишеткән вакыйгалар тәэсирендә язылган.

Палатканың эчендә өч кеше. Шуларның берсе—Урал егете Равил Тимербаев. Ул, сарык тиресеннән тегелгән йоклау капчыгыннан яртылаш чыккан килеш, шахмат тактасына карамыйча гына, Геннадий Менешевка мат куярга маташа.

—Филне а-бердән с-өчкә күчер,—ди ул тегенә.

—Бик шәп!—ди Геннадий, Равил өчен фигураны күчереп куйгач.— Мин корольне а-биштән а-алтыга йөрим.

Геннадий да татар егете, Саратов өлкәсенең Аткарск шәһәреннән. Ул ана телендә бөтенләй сөйләшми һәм шуның белән горур да шикелле.

Палаткадагыларның өченчесе—Виктор Харищенко, Краснодар ягыннан килгән олы гына кеше—ашарга әзерли. Ара-тирә мич капкачын ачып, коры нарат утыны өсти. Мичне ачу белән үк, аннан, чатыр-чотыр итеп, очкыннар сибелеп чыга. Шундый ук, нарат утыны якканда гына була торган очкыннар, морҗа аша тышкы якка да очып чыгалар. Аларның кайсылары палатка өстенә куна да, бераз кызарып торгач, сүнә. Шуна

---

Илдус Хуҗин (1942)—*Свердловск өлкәсенең Кызылъяр (Красноуфим) районында Бишавыл дигән авылда туган. Югары белемле. Әдәби иҗат белән байтактан шөгыльләнә. Аның беренче әсәре—«Егетнең кайтуы» исемле фантастик хикәяте 1997 елда журналның беренче санында басылып чыккан иде. Хәзерге вакытта Кызылъяр районының Урта Бәяк авылында яши.*

күрә палатканың өске өлеше бик күп урыннан янып тишелгән.

—Җитеп торыр, башка өстәмә!—ди Равил Викторга.—Өйне яндырырсың.

Равил, арада иң яше булса да, бу төркемнең башлыгы. Өч ел элек кенә Мәскәү Геодезия һәм Картография институтын тәмамлап, ул Төмән геология идарәсенә эшкә килде. Шуннан башлап, нефть һәм газ эзләү экспедицияләрендә катнаша.

Геннадий Менешев та геодезист. Ул бу сейсмик партиягә* колледж тәмамлаганнан соң җибәрелгән.

Виктор Харищенко исә топографик отряд** эшчесе, ул инде утыз елдан артык геология экспедицияләрендә йөргән кеше. Кайчандыр техникум тәмамлаган геолог буларак, Төмән нефтен эзләүчеләрнең тәүге төркемнәрендә катнашкан. Ләкин соңгы елларда эчүгә бирелеп, квалификациясен югалткан адәм.

—Әгәр, вәгъдә иткәнчә, бер елның эш хакын биреп сөендерсәләр,—дип хыялланды Виктор,—Кубаньга кайтып, берәр авылда кечерәк кенә йорт сатып алырмын, җимеш бакчасы үстерермен, өйләнеп җибәрермен. Җитәр инде, болай да җәен тайгада озынборын һәм кигәвеннәр туйдырып, кышын палаткаларда туңып үтте гомерем.

—Кай җирдә көтәләр соң сине?—диде ана Геннадий, һәрвакыттагыча төрттереп.—Синең бит ни йортың, ни гаиләң—беркемең дә юк. Туганнарың синең дөньяда барлыгыңны да белмиләрдер инде, мөгаен. Ул шахмат тактасына иелде:—Йә ярый, Равил бирелəм. Мастерлыкка кандидат белән көрәшүе авыр икән.

Геннадий, сибелеп яткан шахмат фигураларын җыеп алып тартмага салды да, идәнгә Виктор янынарак чүгәләде.

—Аннан соң,—дип дәвам итте Менешев,—син бит тагын «Зур җир»гә барып җиткәнче акчаңны эчеп бетерәсең дә, ачлый-ялангачлай, ябыгып-бөтеренеп кире монда кайтып керәсең.

—Анысы шулай!—дип, шаркылдап көлде аның әңгәмәдәше.—Минем кебекләр Төмәнгә дә барып җитә алмый, бөтен акча Салехард, Сургут яисә Нижневартовск рестораннарында торып кала шул, калалгыры.

—Их, егетләр!—дип дәвам итте, кинәт кәефе үзгәргән Харищенко.—Ә шулай да, без бит ул—Себер тайгасын башлап буйсындыручылар! Без ачкан беренче нефть ятмаларының исемнәре колакларда музыка кебек яңгырый иде: Сургут... Шаим... Березово...

—Мин бит гел генә эчкече түгел идем!—дип, өзелеп калган сүзен дәвам итте Виктор.—Минем тәртибем бозылганга биш-алты елдан да артык түгел. Ә нигә эчә башладым соң мин? Әйтсәм-әйтим: гомеремне багышлаган, тырышып эшләгән эшләремнең нәтиҗәсе мәгънәсез рәвештә юкка чыгуы, төрле әрсез аллакчылар кулына эләккәненә ачу килгәнгә эчәм мин!

Бераз тын утырганнан соң, Виктор дәвам итте:

—Элек без ачкан ятмаларның нефте халыкны туйдырачак дип уйлап, үзебезне бәхетле итеп сизә идек. Без бит төньякка сезнең кебек «озын берлек» эзләп килмәдек, безне бу якларга романтика әйдәде. Ә сез беләсезме соң ул сүзнең чын мәгънәсен? Алтмышынчы еллар романтикасы нәрсә ул, ишеткәнегез бармы? Халыкка эчкерсез хезмәт итү, шуның өчен бөтен авырлыкларга түзү, кеше аягы басмаган тайгала, тауларда йөрү һәм, ниһаять, учаклар тирәсендә төн уздыру—менә нәрсә ул—романтика. Әй!—дип, кулын селтәде бөтенләй сөмсере коелган Виктор.—Бетте тормышның мәгънәсе!

---

* Геологиянең геофизик ысулларын кулланып нефть һәм газ ятмаларын эзләүче белгечләр һәм эшчеләр төркеме. Өч-дүрт сейсмик партия экспедиция тәшкил итә.

** Сейсмик партиядә топографик төшерүләр алып баручы геодезистлар һәм эшчеләр төркеме.

—Эш нәрсәдә соң?—диде Равил.—Хәзер нәрсә үзгәрде соң? Без әле дә шул син яшь чагында яшәгән, эшләгән шартларда түгелбезмени? Шулай ук палаткада кышлау, нәрсә эләкте, шуны ашау, аркаларга кырык-илле килограмм йөк алып, кар яки саз еру...

—Анысы дөрес,—дип, бераз йомшарды Виктор.—Ләкин менә әйт син: геологоразведкага акча өчен килмәдем, дин—гомергә, ышанмаячакмын.

—Соң, элек шулай булган, дип, без дә чабата киеп йөрикмени инде?—дип куйды Геннадий.

—Киярсез әле анысын да, ашыкма. Мәскәүдәге демократлар гына сау булсын. Нәрсә соң әле мин сезнең белән авыз суы корытып утырам? Үзегезгә күрә—түрәләрегез. Безнең гомер үткән инде.

—Ләкин бит, Виктор Моисеевич,—дип каршы төште Равил,—элекке түрәләр дә безне яхшы тормышка алып килмәделәр. Без бит алдынгы илләргә караганда күп тапкыр начаррак яшәдек. Ә хәзер бөтен кешегә дә тигез хокук бирелде: телисең икән, хәлеңнән килә икән—бае...

—Әйе, әйе! Телисең икән, кеше тала. Әле эшләп баеган кемсәләр юк әле: алдап та, талап кына байлык җыю бара.

—Анысы төзәтелер. Күп тә үтмәс, бу яңа тәртипләргә күчү этабын үтеп китәрбез, иншалла. Бар нәрсә дә рәтләнер.

Рәтләнсә дә, кырык-илле елсыз булмас әле ул,—дип, каршы төште Виктор.—Ләкин нәкъ рәтләнеп җитте дигәндә генә, тагын берәр акыллы баш реформатор табылыр да, яңабаштан үзгәртеп кора башлар, илне янә кирегә таба өстерәр.

Гәпнең нәкъ куерып җиткән чагында гына тышта ниндидер тавышлар ишетелә башлады: башта эт өрде, аннан соң кеше тавышлары килде. Палаткадагылар шундук аптырап, колакларын торгыздылар: кемнәр булыр икән бу кыргый тайгада?

Тавышлар көчәйде, килүчеләр ягыннан да, бу яктан да этләр өрде.

—Бу—боланнар куган авазлар,—дип аңлатты Виктор.—Ишетәсезме, хант Коля тавышына охшаган.

Палаткадагылар, көтелмәгән кунакларны каршыларга дип, тышка чыктылар. Чыннан да, база ягыннан болайга таба ике нартага җигелгән боланнар атлый иде. Йөкләре авыр иде, ахрысы: болан куучылар нарталар артыннан җәяүләп киләләр, ә хайваннар арганнар, еш-еш тын алалар.

Викторның палатка янында әйләнгәләп өреп торган бүре аулаучы эте Пират янына килүчеләр ягыннан Федор Чусовитинның Найдасы чабып килеп җитте, һәм ике таныш эт күрешү сөенеченнән «һау-һау!» өргәләп, бер-берсен сәламләргә, үзара иснәшергә тотындылар.

Ниһаять, төнге юлчылар үзләре дә палатка янына килеп җиттеләр. Болар, чыннан да, геолог Федор Чусовитин һәм үзенең боланнары белән экспедициягә йөк ташырга ялланган хант кешесе Коля булып чыктылар.

Болан караучыдан башкалар бары да палатка эченә керделәр, ә Коля исә малларын карап калды. Ул аларны туарды, махсус нык баулар белән боланнарның артына сөйрәлеп йөри торган нарат кискәләре такты. Бу агачлар боланнарга иртәнгә чаклы артык ерак китәргә ирек бирмиләр иде. Боланнар шундук, тирән карны чокып, мүк һәм лишайник эзләп, туеныргә тотындылар.

Хуҗалар кунакларны кайнар аш һәм чәй белән сыйлагач, тегеләр үзләренең нинди эш белән йөргәнлекләрен сөйләп бирделәр.

—Икенче отрядка* барышыбыз,—дип аңлатты хуҗаларга Чусовитин,—Моргун тагын бер урында таптана бит, тәүлегенә ике чакрым да үтә алмый. Имеш, приборлар чыгымчылый. Көз көне дә ноябрь аеның графигын бозган иде бит. Анда да үзем барып кына эшне җайга салган идем. Станцияне** атна буена төзәтергә туры килде. Ә Иван Моргун,

* Сейсмик отряд. Партия берничә сейсмик һәм топографик отрядтан тора.

** Җир тетрәвенең дулкыннарын осциллограф тасмасына язып баручы катлаулы прибор.

кырын ятып, минем эшләгәнне карап торды. Ник шунда булышсын...

Чусовитин кинәт кенә Равилгә борылды һәм:

—Ә сина, Равил, башлыгыннан сәлам хаты,—дип, ана бер кәгазь кисәге тоттырды.

Бу—топоотряд башлыгы Чувашовның яна күрсәтмәсе булып чыкты. *«Равил, сәлам!—дип язган иде ул, үзенең хәттатларныкыдай тигез һәм матур кульязуы белән. —Чусовитин килеп җиткәч үк, бер җигем боланнарны ал да, базага кайт. Каюр* белән бу турыда сөйләшенгән. Бик ашыгыч эш бар. Менешев эшегезне дәвам итәр. Житәр инде аңа синең канат астында гына йөрергә, үзе белеп эшләсен. Бер нартадагы азык-төлекне аларга дип җибәрдек. Чувашов.»*

Иртәнге тугызларда тышта карангы булуга карамастан, Чусовитин белән Коля дүрт болан жигелгән нартага икенче отрядка дигән азык-төлекне төяп, жиденче профиль** буйлап ары кузгалдылар. Менешев һәм Харищенко теодолит, үлчәү рейкасы һәм бер көнлек азык алып, Пиратны ияртеп, төньяк юнәлешендәге профильгә кереп киттеләр. Равил өч болан жигелгән нартага утырып, база ягына юнәлде. Анын өстендәге калын, ләкин шактый жинел мех куртка, шундый ук чалбар. Аякларында жылы киез итекләр, башында кондыз тиресеннән тегелгән колакчын бүрек иде.

—Курыкма,—дип кисәтте аны юлга әзерләнгәндә хант Коля,—минем боланнарны ничек йөреткәнне күргәнең бар бит. Тауларны төшкәндә, егет, нартанны тота төш, нарта сина чана түгел, анын тәртәләре юк бит. Текә һәм борылмалы жирдә нартаң кызып китеп, боланнарынны куаклар арасына этеп кертмәсен. Юкса, жигем бауларын буталып, чуалып бетәр.—Ярты юлны үткәч, туктап төн үткәр,—дип өйрәтүен дәвам итте болан хужасы,—көн кыска, дүрт-биш сәгать кенә, якты-күздә базага кайтып житә алмассың.

Башта бераз каушый төшкән Равил, боланнарның иплә генә баруын күргәч, тынычланды. Ул, хәтта, малларны куалый да башлады. Монын өчен Равил нык коры агачтан шомартып эшләнгән жинел озын таяк-хорей белән боланнарның аркасына тидереп ала иде. Сулга борыр өчен шул ук таяк белән ун як читтән баручы олы боланның башына уң яктан төртә. Унга борылырга кирәккәндә шул ук боланның йөгәненә ун яктан гына бәйләнгән нечкә нык дилбегәдән тарта. Бүтән боланнар уңнан барган әйдәманнары артыннан элдертәләр.

Иксез-чиксез тайга урманы. Шуны ярып, сейсмоотрядлар эшләү өчен һәм техника йөрү өчен урман ызаны—профиль салынган. Юл әле кедр катнаш наратлар үскән утраусыман калкулыкларга менә, әле коры яки черек вак наратлы дистәләрчә чакрымнарга сузылган тигезлекләргә килеп чыга.

Нарта өстендә Равилнен үзеннән һәм анын мылтыгыннан башка йөкнең булмавына карамастан, боланнар тизлекне киметә баралар, чөнки аяк астында кар тирән һәм йомшак. Боланнарның жәенке тояклары да, нартаның киң табаннары да бер карыштан тирәнрәк карга батып баралар.

Равил, Чусовитин килгән эз белән бармыйча, юлны унбиш-егерме чакрымга кыскарту максаты белән, базага таба бөтенләй икенче профильләр буйлап китте. Бу очракта өйгә ул жиде-сигез сәгатьтә кайтып житәргә тиеш иде.

Төнге сәгать уникедә алда, агачлар арасыннан жемелдәп, утлар күренде. Бу—Равилләр эшләгән егерменче сейсмик партия урнашкан урын—Охотбаза дигән бер жир иде. Кайчандыр монда аучылар яшәгән, ял иткән, жәнлек тиреләрен туплаган. Ул заманнардан зур гына, әле дә эшкә ярарлык ике өй сакланып калган. Хәзер исә партиядә эшләгән

* Болан йөртүче.

** Геологларның эзләнү алып бару өчен һәм техника йөртергә дип, агачларны кисеп салынган дүрт метр киңлегендәге юллары.

илле-алтмыш кешене урнаштыру өчен, искеләренә өстәп, юнылмаган бүрәнәләрдән сигезәр бүлмәле дүрт өй салынган. Тиздән, сейсмиклар икенче базага күчкәч, тайгада торып калган башка йөзләрчә авыллар кебек, монысын да ташлап китәчәкләр.

Охотбазаның утлары күренсә дә, анда барып житәр өчен әле ике як яры да урман белән капланган Пандым-Юган елгасын үтәргә кирәк иде. Равил күзгә төртсән күренмәслек караңгы төндә аны-моны абайлаганчы боланнар текә таудан аска—елгага таба төшә башладылар. Менә шул чакта хант Коляның сүзләрен искә төшерергә туры килде дә инде Равилгә: нарта кызып китеп, боланнарның артыннан китереп төрттерде. Тегеләре, әлбәттә, куркудан алга ыргылдылар һәм, дөм караңгыда юлның туксан градуска унга борылыш ясавын күрмичә, агачлык арасына кереп киттеләр, ә нарта юан гына бер агачка килеп терәлеп, боланнарны тып туктатты.

Чуалган жигем бауларын Равил бик озак чиште. Ниһаять, боланнарны баулардан азат итеп юлга чыгарып бастырганчы, аларны яңадан жигеп Охотбазага кайтып житкәнче, базада дизель—моторлы генератор эшләвеннән туктатылып, бөтен Охотбазаны караңгылык баскан иде.

* * *

Иртәгесен иртүк торып, Равил топоотряд башлыгы Чувашов янына керде. Юрий Николаевич Чувашов—Новосибирск шәһәрендә туып үскән һәм шунда геодезистлыкка укыган. Геологоразвезкада катнашуына инде биш-алты ел. Тыштан кырыс күренсә дә, урта буйлы, төсе-килбәте белән татар кешесенә охшаган бу кеше, асылда, йомшак күнелле, классик музыканы һәм туган шәһәрен үлә язып яратучы, хезмәттәшләре арасында абруйлы шәхес иде.

—Син, Равил, безнең сейсмик партиянең яна базага күчәргә тиешлеген беләсең шикелле. Ун көн элек нәкъ менә шул эш буенча, ягъни база буласы урынны эзләп, Степанишин белән Стакай безнең көньяк профильләр ягына киткәннәр иде. Менә кара...—дип, Чувашов егерменче партия эшләгән жирләрнең көньягындарак булган, ләкин әле геологларның аягы басмаган урыннарның картасын өстәлгә жәеп салды һәм сөйләвен дәвам итте:—Башта безнең профильләр белән көньякка, сигезенче профильгә чаклы барырга кирәк. Бу юнәлештә, үзең беләсең, илле чакрымлык юл. Аннан сон тагын алтмыш-житмеш чакрым яна юл ярып, көньяк-көнчыгышка юнәлергә һәм Ева-Тор күлен барып табарга тиешсең. Менә ул күл, озынлыгы мең дә ике йөз метр, киңлеге жиде йөз метр булыр. Шуның ярында безнең яна база булачак.

Бу сөйләшүдән Равил тагын шуны аңлады: Степанишин белән Стакай, куак кистергеч белән китеп, шул юнәлештә юл сала башлаганнар икән. Ләкин адашып, төп юнәлешне югалтканнар. Костя Степанишин базага әйләнеп кайткан, ә юлдашы анда торып калган.

—Сина, Равил,—дип аңлатты Чувашов,—Костя белән китәргә, дөрес юнәлешне табып, тиз көндә Ева-Торга барып житәргә кирәк. Баргач та, озакка сузмыйча гына, күл читенең иң унайлы жирендә база өчен урын әзерләгез, вертолет төшәр өчен мәйданчыкны агач-таштан арындырыгыз. Сина бу эшне башкару өчен бер атна вакыт бирәм, чөнки атна-ун көннән партиянең бөтен мөлкәтен, бигрәк тә техникасын, төзәтү базасын яна урынга күчерә башларга тиешбез. Бүген ял ит, мунчага барып чабынып ал, ә иртә таң белән юлга чыгарсыз.

Эшләрен бетергәч, Равил үзенең тагын бер якын иптәше—Мусин Камил гаиләсенә кереп чыгарга булды һәм бер читтәрәк торган, Охотбазада «татарлар йорты» дип йөртелгән өйгә таба атлады.

Базадагы башка өйләр кебек ике-өч ел торырлык кына итеп салынган бу өйдә дүрт гаилә яши. Алар барысы да Төмән өлкәсенең Вагай районыннан булып, акча эшләп алу максаты белән берничә ел инде

экспедицияләрдә йөриләр. Үзләре генә түгел, балаларына да «нужа бабайны» күрсәтәләр иде.

Равил бу дүрт гаиләгә кереп-чыгып йөрсә дә, өчесе белән аның әлләни дуслыгы юк, ә менә Камил белән Рауза Равил өчен аһ итеп торалар, ә аларның ике кызы—биш яшьлек Әлфия белән җиде яшьлек Әминә—аны бөтенләй үз абыйлары кебек күрәләр иде.

Экспедициягә килгән айларны Равил Себер татарлары телен аңламый интекте. Аларның янгырау тартыкларны саңгырауга әйләндереп сөйләшүе, фигыльләргә әллә нинди ят кушымчалар өстәп әйтүе Равилне аптырата иде. Ләкин тора-бара, тегеләрнең «чын» татар телен аңлауларын, ул гына да түгел, «Сарман», «Рамай» кебек саф татар җырларын яратып җырлаганнарын белгәч, хәтта янарак җырлардан да хәбәрдар булуларын ишеткәч, Себер татарларының «татарлыгында» Равилнең шиге калмады. Сонрак, бер-бере белән аралашканда, алар татар телен үзләре белгәнчә сөйләшсәләр дә, бер-берен җинел аңлаштылар.

Камилнең өенә барышлый, Равил складка сугылды һәм соңгы көннәрдә нинди азык-төлек китерелгән булуы белән кызыксынды. Ләкин склад мөдире аны шатландырмады: геологларның азык-төлеге бетеп бара, ә өстәп китерүче күренми икән.

Аннан чыккач, ул радист янына кереп, соңгы яңалыкларны белеште, телеграмма килергә тиешлеген әйтте. Моңа каршы радист Вася Козлов башын гына чайкады.

Аннан соң Равил кар белән күмелеп калган тракторлар, тягачлар, «Буран»нар яныннан узды һәм гаҗәпләнеп тел шартлатты: аның әле беркайчан да шулкадәр техниканың тик торганын күргәне юк иде.

Равил барып кергәндә, Камил белән Рауза да, аларның кызлары Әлфия белән Әминә дә өйдә иделәр. Хуҗалар егетне бик җылы каршы алдылар, ә кызлар исә абыйларының муенына ук килеп асылындылар.

Камил озакка сузмыйча гына мунча әмәлләргә чыгып китте (бөтен Охотбазага бер генә мунча бар иде). Рауза исә тиз генә ашарга әзерләргә кереште. Равил моңа каршы булса да, хуҗабикә үзенекен итә бирде, чөнки буйдак ир-атның ничек эләкте—шулай гына туенып йөрүен ул яхшы белә иде.

—Иртәнге ашны юньләп ашамагансыңдыр бит әле син,—диде ул кунагына,—ә кичкесе бөтенләй эләкмәгәндер. Кереп йөр безгә, юкса ашказаның бозылыр бит. Яшь чакта ул турыда уйламыйсың шул, тазалыгың гел генә шундый нык булыр кебек тоела. Баксаң, бераз олыгая төшү белән, әллә ничә төрле чирең килеп чыга.

Кызлар Равилгә үзләренең курчакларын, китап-дәфтәрләрен, рәсемнәрен күрсәтү белән мәшгульләр иде.

—Рауза апа!—диде Равил, кызлар белән бераз мәш килеп алгач. Әминәнең мәктәпкә йөрер вакыты җитә бит. Нишләргә уйлыйсыз?

—Быелдан калмый илгә кайтырга кирәк иде инде,—диде Рауза, төшенке тавыш белән.—Анда кайтып, нишләрбез икән тагын? Авылда эш тә юк, хуҗалыгыбыз да пран-заран китерелгән, яңадан торгызырга кирәк булачак. Монда да әллә ни акча эшләп булмады. Аз-маз җыйганы да инфляция белән юкка чыкты. Өч елдан артык шушында озынборыннар туйдырдык бит. Ә хәзер, җитмәсә, эшләгән акчаны да алып булмый.

Шундыйрак зарлану-уфтанулар белән ярты сәгатьләп вакыт үткәч, Камил килеп, мунчаның сәгать икеләрдә әзер булачагын белдерде.

Шуннан соң ул яңабаштан Равилнең хәл-әхвәлен сорашты, аның эше турыда белеште. Егетнең яңа база урынын эзләп китәсен белгәч, ул шундук:

—Мине дә ал үзең белән,—дип, күтәрелеп чыкты.—Әле генә тайгада бер ай ятып килдем, тугызынчы профильдә ызан агачлары кистек. Инде бер ай ял итә алам. Базада нәрсә эшлим ди мин? Беләсеңме, мина аучы йөреп алырга кирәк иде. Сез барасы җирдә, әле җәнлек куркытылмаган булырга тиеш.

—Ярый, Камил абый, мин сине үз бригадама алам, ичмасам тиккә йөрмәссең. Хәзер үк Чувашовка кереп, приказ яздырам.

Икенче көнне иртәнге сигездә кабинасына өч кеше утырткан, сазда йөри торган киң чылбырлы авыр трактор, тапталган юллы профиль буйлап, көньякка таба юл тотты. Бу вакытны иртә дип атау шартлы рәвештә генә әйтү иде, чөнки тышта әле дөм карангы, сәгать унберләрдә генә яктырачак.

Трактор йә авыр гүләп кар астында калган агач төпләренә барып менә (андый чакта кабинада утыручыларның хәлләре бик мөшкел була), йә ачык сазларга, коры, черек наратлы тигезлекләргә килеп чыга.

—Нинди тизлек белән барабыз?—дип сорады Равил Степанишиннан, трактор гүләвен басардай тавыш белән. Тегесе аңа ун бармагын күрсәтә. «Димәк, яңа юлга житкәнче алты-жиде сәгать вакыт узачак»,—дип уйлап куйды Равил.

Чыннан да, төш вакыты үтеп, сәгать өчләрдә, ягъни тышта карангылык үзен сиздерә генә башлаган вакытта, әзер профильләр бетеп, Степанишин салган юл башланды. Костя иптәшләренә карады да, ияге белән алга ымлап:

—Күрәсезме юлны? Ничек туры итеп салынган, ә!—дип кычкырды.

Равил аңа тракторны туктатырга кушты һәм алар өчесе дә жиргә сикерешеп төштеләр.

—Нинди азимут буенча салынган инде синең бу туры юлың?—дип сорады Равил Костядан, сумкасыннан карта һәм буссоль* чыгара-чыгара.

—Йөз житмеш ике градус белән,—дип жавап бирде Степанишин, шул юнәлешне алдык та, бер градус та читкә тайпылмадык.

—Хәзер, туган, тикшереп карыйбыз,—дип, Равил буссольны яңа салынган юл буенча борды һәм приборның магнит угына карап әйтте:

—Шулай булыр дип уйлаган идем аны. Костя! Сез йөз житмеш ике градус белән бармагансыз, ә йөз сиксән дүрт градуслы азимут** буенча салгансыз юлны.

—Ничек инде ул алай!?—дип, Степанишин буссольга килеп тотынды.—Менә бит йөз житмеш ике градус тора, күрмисеңмени, Равил?

—Син, «бөек географ», магнит авышлыгы турында оныткансың,—диде Равил.

—Нинди магнит авышлыгы ул тагын? Нишләп баш катырасың?

—Костя! Жир шарының төньяк полюсы белән төньяк магнит полюсы бер үк ноктада түгел, аларның арасы шактый ерак. Шуңа күрә магнит угы чын полюсны күрсәтми. Шулай итеп, магнит авышлыгы барлыкка килә. Көндәлек тормышта безнең өчен аның әһәмияте юк диярлек, ә геодезиядә, азимут билгеләгәндә аны исәпкә алмыйча булмый.

—Алай булгач нишлибез соң?—дип сорады Степанишин.—Юлны яңадан салырга туры килер микәнни?

—Ю-у-ук!—дип, тынычландырды аны Равил.—Алай итмибез. Сезнең барып туктаган урынга житкәч, яңа, төзәтелгән азимут алып, юл салуны дәвам итәрбез.

—Булды, Равил, аңлашылды,—дип сөенде Костя.—Моның өчен сыйлау миннән.

—Алга!—диде Равил һәм алар тракторга утырып, юлларын дәвам иттеләр.

Ике сәгать чамасы вакыт узгач, ниһаять, алда зур тимер чана өстенә беркетелгән цистерна күренде. Унике тонна сыешлы бу олы мичкәдә техника өчен ягулык йөртелә иде. Тагын да якынайгач, юлчылар цистерна артындагы балокны да шәйләделәр. Монысы—шундый ук чана

* Горизонталь яссылыкта юнәлешләрнең азимутын билгели торган прибор.

** Төньяк полюс юнәлеше белән бара торган юнәлеш арасындагы сәгать стрелкасы әйләнеше буенча үлчәнгән почмак.

өстенә такталардан кагып жылытып эшләнгән кучмә өйчек иде. Анын өстендә калай мич моржасы сураеп тора, моржадан күнелне рәхәтләндереп төтен чыга иде. Балокнын бердәнбер тәрәзәсеннән яктылык сирпелә.

Трактор балок янына килеп туктаганда, Степанишин белән бергә эшләгән һәм, базага кайтмый, монда калып торган Стакай Леонид тышка чыгып, килүчеләрне көтеп тора иде.

—Мин сезнең трактор тавышын инде бер сәгать элек ишеттем,— диде ул, тегеләр белән исәнләшкәч,—сез килеп житкәнче ашарга да пешереп өлгердем.

Костя тракторнын суыту сыекчасын агызып тормады, чөнки система-га су урынына солярка салынган иде. Чөнки суга куша торган туңдырмаучы махсус матдә—антифриз күптән китерелми.

Ашап-эчеп, бераз ял иткәч, Равил карта алып, өстәл янына утырды. Барысы да анын тирәсенә жыелдылар.

—Инде карыйк, кай жиргә килеп туктадыгыз икән? Димәк, яна юл белән без егерме чакрымлап килгәнбез,—диде Равил һәм моны картада билгеләп куйды.

—Егетләр, безгә кирәкле күлгә барып житәр өчен утыз сигез-кырык чакрым жир үтәргә туры киләчәк. Яхшылап эшләгәндә, бу өч-дүрт көнлек юл. Ә азимут хәзер йөз житмеш ике түгел, ә йөз алтмыш бер градус булырга тиеш. Ә хәзер монда килеп житүебез турында базага хәбәр итәргә кирәк.

Костя бер почмактан рация алып, өстәлгә утыртты да, аппаратны кабыза торган тумблерга басты, ләкин рациянен индикатор лампасы беразга гына кабынды да, тоныклана башлады һәм тиздән бөтенләй сүнде.

—Тьфү, шайтан алгыры! Әллә инде аккумулятор батареялары утырган!—диде Костя.—Леня! Нишләп боларнын көчләре болай тиз беткән? Без бит синен белән өр-яна батареялар алып чыккан идек.

—Мин каян белим ди!—дип башын читкә борды, битараф кыяфәтле Стакай.—Мин бит радист түгел. Үзен нинди хәлдә калдырдын, бары да шулай инде.

Равил Стакайнын күзләрендә ниндидер яшертен мәкерле шатлык билгесе сизенгәндәй булды, ләкин ул мона әһәмият бирмәде.

Костя рацияне төрлечә боргалап, баскалап карады, әмма берни дә чыгаралмагач, аны үз урынына алып куйды.

Ул кичне бүтән истә калырлык вакыйгалар булмады; алар, керосин лампасын өреп, ике як диварда икешәр катлы итеп эшләнгән дүрт ятакка авып, йокыга талдылар.

Иртән торгач, озакка сузмыйча гына Равил яна азимут билгеләде дә, шул юнәлештә юл сала башларга кушты.

Степанишин тракторнын алгы ягына агачкистергечне тагып алды. Ул—алгы ягы очлы итеп калын корычтан ясалган, ике як чите пычак сыман үткен кырлы жайланма—тракторнын моторын һәм хәтта кабинасын да ауган агачлардан саклый иде.

Кичкә кадәр агачсызрак урыннарны сайлап, алынган юнәлешне тотып, яна база ягына юл ярдылар. Стакай балокта ашарга пешереп торырга калган иде.

Кичен кире балок янына кайттылар һәм ике чананы бер-бер артлы тракторга тагып алдылар да, бүген ясаган юл беткән жиргә чаклы барып, анда төн кундылар.

—Унике километр үттек!—диде канәгатьлеген яшерергә дә тырышмаган Равил.—Шулай эшләсәк, тагын ике-өч көннән Ева-Торда булачакбыз.

—Бүген эре агачлы урманнар аз әлекте, шуна күрә жинел бардык,— диде Костя.

Иртәгесен балокта Камил калды. Өченче көн кич белән балокта Равил тагын үткән юлны картага төшерә башлады.

—Бүген азрак үттек,—диде Равил,—җиде генә чакрым булды.

—Ничек инде җиде чакрым!—дип гаҗәпкә калды Костя.—Минем исәп буенча унөч булырга тиеш.

—Тукта! Син балокка таба кире килгән чакта нинди тизлектә килдең соң?—дип сорады аптыраган Равил.

—Дүртенчедә.

—Соң, юлда мин сорагач, син миңа трактор тәрәзәсеннән өч бармагыңны күрсәттең бит,—диде Равил.

—Юк! Мин синең соравыңны аңламаганмын,—диде тракторчы.—Без дүртенче тизлек белән килдек. Юл тигез иде бит.

—Алай булгач, Ева-Торга барып җитәргә 2-3 чакрым гына кала. Моннан ерак та түгел, бер зур ачык саз булырга тиеш,—дип йомгаклады Равил.—Иртән тикшереп карарбыз, дөрес киләбезме икән.

Иртән торып, ашап-эчкәч Равил, бераз гына яктыра башлаганны көтте дә, үткән кич белән әйткән сазны эзләп китәргә булды.

—Безгә юнәлешне төгәл алып барырга кирәк хәзер,—дип аңлатты ул, югыйсә күлне күрми узып китүебез бар. Моның өчен иң элек кай җирдә булуыбызны тәгаенләргә кирәк, ә саз монда күзгә бәрелердәй бердәнбер ориентир.

—Мин дә синең белән барам,—дип, урыныннан торды Леонид Стакай, башлыклары юлга әзерләнә башлагач.

—Юк!—дип кырт кисте Равил.—Минем белән Мусин бара.

Равил белән Камил, аякларына киң аучылар чаңгысы киеп, Камил мылтык асып, ә иптәше сумкасын алып, теге саз булырга тиешле якка атладылар.

Тирә-якта кедр урманы, ә ике-өч йөз метр киткәч, зур ачык саз башланырга тиш иде.

Урман көтмәгәндә диярлек бетеп, тирә як яктырып китте: алда диаметры өч чакрымга сузылган түгәрәк саз җәелеп ята иде. Уртасында кечерәк күле дә булган бу саз картада да күрсәтелгән иде.

—Егет икәнсен, Равил!—диде Камил.—Маршрутың төп-төгәл икәне инде ачык күренде.

Равил картасын чыгарып, үзләренең басып торган урынын билгеләп торган чакта, Камилнең үтә дулкынланган тавышы яңгырады:

—Кара!!!

Равил аптырап аңа борылганда, Камил дулкынлануыннан сүзен дә әйтәлмичә, кулы белән сазның бер читенә күрсәтә иде. Равил дә шул якка борылды һәм... үзләреннән 120-150 метрда гына яртылай кар белән күмелгән вертолетны күрде.

Равил белән Камил сүзсез-нисез генә шул якка ашыктылар һәм минут эчендә очкыч янына барып та җиттеләр.

—МИ-4,—диде Равил, вертолет тирәли әйләнеп чыккач,—әле кар төшкәнче һәм җир туңганчы ук төшеп утырган бу. Күрәсеңме, тәгәрмәчләре бер метрдан да тирәнгәрәк батып, мәңгелек бозлыкка барып терәлгәннәр. Җир өстендә корпусы гына калган, анысының да яртысын кар күмгән.

Алар ашыга-ашыга вертолет тирәсендәге карны көри-арчый башладылар, чөнки машинаның ишеген ачарга кирәк иде. Ләкин көрәксез-нисез эш авыр һәм озак бара иде.

—Бу вертолет егылып төште микән, әллә үзе утырды микән?—дип сорады Камил эш аралаш.

—Үзе төшкәнгә охшый: күрәсеңме, туры гына төшеп утырган, бер ватылган-кырылган җире күренми, дип аңлатты Равил иптәшенә.—Аннан соң, утырган урынын кара: беренчедән, агачсыз ачык урын, икенчедән, очучы сазның читен, урманга, коры җиргә якын урынны сайлаган.

Тырыша торгач, ниһаять, вертолет ишеген ачтылар. Ләкин салонда бер җан иясе яки күзгә бәрелердәй бер әйбер дә юк иде. Кирәк чагында йөк ташый алучы, туры килгәндә кешеләр дә йөртә торган, экспеди-

цияләрдә зур хезмәт күрсәтүче гади бер вертолет иде бу.

Камил белән Равил соңгы вакытта һәлакәткә эләккән яки бөтенләй рейстан әйләнеп кайтмаган вертолетларны искә төшерә башладылар, чөнки андый хәбәрләрне тайгадан кешеләргә даими җибәреп торалар иде.

—Сон, август аенда, былтыр...!—дип кычкырып ук җибәрде Камил.—Акча төяп киткән вертолет юкка чыккан иде бит.

Чыннан да, үткән елның август аенда сейсмопартияләрдә эшләүчеләргә акча алып килергә чыккан вертолет хәбәрсез югалган иде. Дүрт сейсмопартиядә эшләгән 250 кешенен ярты еллык эш хакын илтәчәк вертолетның, экспедиция бухгалтерының һәм ике очучының язмышы әле дә билгесез.

—Күпме акча юкка чыкты дип әйттеләр әле ул вакытта?—дип сорады Равил.

—Ялгышмасам, 10 миллиардтан артык.

—Күп акча!—дип куйды Равил.—Алай да моның борт номерын язып алыйк әле. Равил карандаш һәм кәгазь чыгарды.

Шулвакыт Камилнең очлы күзләре тагын нәрсәнедер күреп алды.

—Карале, Равил, монда күптән түгел кемдер булып киткән ләбаса! Әнә бит, чаңгы юлы беленеп тора.

—Стакай йөргәндер, монда ул калган иде,—дип җавап бирде ана Равил, кулындагы кәгазь кисәгенә вертолетның номерын төшерә-төшерә.

—Ләкин аларның туктаган җире моннан бик ерак иде бит. Балок яныннан монда килеп китү өчен ана ике көн вакыт кирәк була иде.

—Булса сон,—дип, язуын дәвам итте Равил һәм кинәт әлеге хәбәрнең бик тә мөһим икәнен төшенеп алды.—Туктале, тукта! Нигә соң әле ул безгә үзенең монда килеп йөрүе турыда әйтмәде?

—Ә ничек ул, гомумән, монда килеп эләккән?—дип, шикләнүен дәвам. итте Камил.—Моның өчен бит тайганы бик тә яхшы белергә кирәк. Икенче яктан, андый оста тайгачы булгач, алар нигә адашып алга барудан, юл салудан туктаганнар.

—Кыскасы,—дип йомгаклады Равил,—сораулар күп, ә җавапны, бирсә, Стакай бирер.

Иптәшләре янына әйләнеп кайткач, Равил белән Камил тегеләргә вертолет турында сөйләп бирделәр. Степанишин һәм Стакай бу хәбәрне ишеткәч, гаять гаҗәпләнделәр, ләкин икенчесенең аптыравы Равилгә ничектер ясалмарак чыккан кебек тоелды.

—Леонид! Син дә булгансың бит анда. Нигә соң безгә бу турыда әйтмәдең?—дип, турыдан-туры сорады Равил Стакайдан.

Тегесе үзенең саздагы вертолетны күрүен инкяр итәргә уйласа да, озак кына уйлап торгач, ул моның файдасыз гамәл икәнен аңлады булса кирәк:

—Мин онытканмын бу турыда,—диде ул, караңгы чырай белән.

—Бик сәер. Син монда килеп ике көн вакытыңны һәм көчеңне әрәм иткәнсең, сазда утырган вертолетны күргәнсең, ләкин бу «вактөяк» турында безгә белдерергә оныткансың,—дип, башын чайкады Равил.

—Нигә миңа бәйләнәсең!—дип, гаять тупас җавап бирде ана Стакай. Мин чыннан да тайгада ауда йөрдем. Нәрсәсе килешми моның? Адашып, бу якларга килеп чыкканмын. Әле ярый балок янына әйләнеп кайта алдым. Ә вертолет!... дип кулын селтәде ул.—Беткәнмени тайгада ватык техника?

—Алай түгел!—дип, каршы төште Равил.—Ташландык техника очрый, ләкин вертолет тапканыбыз юк иде әле. Бигрәк тә кеше аяк басмаган җирләрдә.

Стакай бүтән сүз катмады, бары тик иңбашларын гына сикертеп куйды, сез миннән күбрәк беләсез, янәсе.

Әмма озаклап гапләшеп утырырга вакыт юк иде: әле бит Ева-Тор табылмаган. Дөрес, аның моннан ике чакрымда гына икәне инде

ачыкланды. Димәк, ашыгырга, көн яктысында анда барып житәргә, анысын-монысын, әйләнә-тирәне караштырырга кирәк бит әле.

—Көндезге ашны анда ашарга тиешбез,—диде Равил иптәшләренә, кузгалып китәр алдыннан.

Трактор, ниһаять, алга ыргылды, ә калганнар аның артыннан атладылар. Күл тирәсендәге калын нарат һәм кедр урманын кистерә-кистерә, өч сәгатьләп тырмашкач, агачлар арасыннан күлнең үзе күренде. Чиктән тыш сөенгән юл салучылар, ашыга-ашыга, кар белән капланган боз өстенә килеп керделәр. Картада күрсәтелгәнчә, бер чакрымнан озынрак, ә киңлеге шуннан бераз гына кимрәк бу күлнең бер як яры камышлы саздан торса, каршы як яры калку һәм коры күренә иде. Равил шул якка кулын сузып әйтте:

—Әнә безнең яңа база шунда булачак.

Күл читендәге урманны ярып, теге калку урынга кадәр тагын 400 метрлап юл үттеләр. Ә инде барып житкәч, аларга бераз гына гажәпләнеп алырга туры килде: ярдан 70-80 адымда, биек-биек кедрлар астында, жиргә сеңеп бетә язган бер алачык тора иде. Шунда ук 4-5 метр биеклегендәге баганалар башында сәндерә эшләнгән. Аның өстендә юнылган агачлардан бурап ясалган, өсте нык капкач белән ябылган зур гына тартма урнашкан.

—Бу алачыкта кайчандыр аучылар яшәгән,—диде Камил.—Тайгада алар еш очрый. Ә тегесе,—дип, агачлар башындагы тартмасыман нәрсәгә күрсәтте ул,—кечкенә лабаз—аучыларның азык-төлек һәм әзерләгән тиреләрне саклау урыны. Лабаз бик нык һәм рәтен белеп эшләнә, анда аю да, тычкан да керә алмый. Калган жәнлекләрне әйтмим дә инде.

Аучы алачыгына керделәр. Бу өйчекнең ине-буе дүртәр метрдан артмый иде, түшәменә биегрәк кешенең башы тиеп торырлык. Кызыл балчыктан салынган учагы инде ягарлык түгел: чыбыктан үрелгән һәм эче-тышы кызыл балчык белән сыланган моржасы жимерелеп төшкән. Мич алдында бераз утын, чыра, ә матчага кыстырылган чүпрәк эчендә тоз табылды. Ләкин иң хикмәтлесе—почмакта эленеп торган кыр сумкасы иде. Бурсып таркалыр хәлгә житкән бу сумка эченнән ниндидер Кирилл исемле кешегә килгән хатлар, гамәлдән чыккан кәгазь акчалар һәм башка төрле әйберләр чыкты. Хатлар һәм кәгазьләр алтмышынчы елларга карыйлар иде.

—Бу бәндәнең язмышы ни белән бетте икән?—дип куйды Камил, уйчан гына.

—Карагыз әле, ә бу сигарет тартмачыгы бөтенләй бозылмаган,—диде кечкенә тәрәзә алдында торган Костя Степанишин.

—Чү әле,—дип башын чайкады Равил,—ул вакытта мондый сигарет тарттылар микән соң? Икеле. Моны, күп булса, ярты ел чамасы элек калдырганнар монда...

Көндезге ашны ашагач һәм бераз ял итеп алгач, дүртесе дә эшкә тотындылар: яңа база урынын билгеләргә, агачларын кисеп,вертолет төшеп утырыр өчен урын әзерләп куярга кирәк иде.

Техника ярдәмендә эш бик тиз һәм жайлы барды. Агачларны кул көче кулланып, пычкы һәм балта белән кисәргә дә туры килмәде: көчле трактор аларны тамырлары белән актарып, бер читкә өя барды. Икенче көнне вертолет утырырлык, ине-буе илле метрлы, мәйданчык һәм тагын Охотбазадан килгән йөкләрне бушатырлык урын әзер иде инде.

—Шабаш!—диде Равил, ниһаять, арыган һәм ачыккан иптәшләренә.—Безнең монда эш бетте, иртәгә иртә белән кайтыр юлга чыксак та ярый.

Иртәгесен таң белән торып, дүрт иптәш соңгы тапкыр иртәнге ашны әзерли башладылар. Шулвакыт балокка тракторын карарга тышка чыккан Костя Степанишин керде һәм:

—Равил! Ике-өч сәгатькә юлга чыгуны кичектерергә туры килер, чөнки радиаторны карап аласы бар: системадагы солярка агып беткән

бит, әллә инде радиаторга ялгыш агач-мазар калалган. Әле тышта караңгы, эшләп тә булмый.

—Алай булгач,—диде Камил,—мин чаңгыда, килгән Юл белән, алдан китә торыйм. Бәлки, берәр җәнлек-фәлән очрар. Юлдан урманга бик ерак кермәм, сезнең тавышыгызны ишетү белән, каршыгызга чыгармын.

Биш-алты минуттан Камил караңгылыкка кереп тә югалды.

Степанишин тракторны караган арада Равил белән Стакай корал-яракны һәм башка алып кайтасы нәрсәләрне кирәкле җирләргә урнаштыра башладылар. Алар бу эшне бетерүгә, Костя да кереп, тракторның кайтырга әзер икәнен белдерде. Тышта трактор моторы гөрелдәп эшләп утыра иде инде. Бар да тышка чыктылар.

Шулвакыт Стакай тыныч кына:

—Егетләр, мин монда калам,—диде, ә үзе аның бу сүзләренә гаҗәпләнеп калган иптәшләреннән бер читкәрәк барып басты.

—Ничек инде монда каласың? Син ни сөйлисең?—дип сорады Равил.

—Нәрсә ишеткән булсаң, шуны сөйлим!—дип җавап бирде Леонид.

—Сиңа монда калырга кем рөхсәт бирде әле?—диде Равил, кырыс тавыш белән.

—Миңа рөхсәт кирәкми, мин иректә кеше, кайда телим—шунда яшим, аңлашыламы?—диде Стакай, тупас итеп.

—Сәер!—дип гаҗәпләнде Равил.—Син бит эштәге кеше.

—Ә мин монда да эшсез ятырга җыенмыйм, агач кисәрмен, балтам бар. Беләсез бит, безгә монда яңа йортлар салу өчен күпме агач кирәк булачагын.

—Леня! Синең бит бары өч-дүрт күнлек азыгың бар,—дип, үгетләп карады аны Степанишин.

—Мин яхшы гына аучы да бит әле. Курыкмагыз, ачтан үләргә җыенмыйм,—диде Стакай, үз фикерендә һәм ниятендә нык торып.

Равил бераз уйланып торды да:

—Юк, Леонид! Мин сине монда калдыра алмыйм. Начармы-яхшымы, ошыймы бу сиңа, юкмы—мин монда баш кеше һәм мин сезнең өчен җаваплы!—дип кырт кисте.

—Мин үзем өчен үзем җавап тотам, ишеттеңме шуны!—диде Стакай, шактый гайрәтләнеп.

—Костя!—диде Равил, балок ишеге янында торган Стакайга якынлаша башлап.—Теге ягыннан кер һәм тот бу үзсүзлене! Тракторга бәйләп салып булса да алып кайтачакбыз без аны.

Степанишин да Стакайга таба бара башлады.

Шул мизгелдә Стакай җәһәт кенә кесәсеннән пистолет тартып чыгарды.

—Йә! Йә! Күгәрченкәйләрем!—диде ул зәһәр көлеп.—Кайсыгыз якын килә? Кайсыгызга—беренче пуля?

Равил Стакайның йөзенә һәм күзләренә карагач, тегенең бу мизгелдә бик тәвәккәл булуын аңлады. «Монда бер-бер хәл бар. Атуы да мөмкин моның»,—дип уйлады ул.

—Бер! Ике!—дип боера башлады ул арада Леонид.

—Йә, йә! Исәрләнмә!—дия-дия, Равил белән Костя балок эченә керделәр.

Шунда ук балок ишегенең тышкы яктан шалтырап бикләнүе ишетелде.

—Тинтәкләр!—дип һәм тагын әллә-нәрсәләр әйтеп сүгенә иде тышта Стакай.—Минем юлыма аркылы төшүегез өчен хәзер үкенерсез!

—Равил, синең мылтыгың кайда?—дип сорады Константин.

—Тракторга салып ныгытылган әйберләр арасында.

—Их!

Ике тоткын балокның бердәнбер тәрәзәсе янына ташландылар.

Стакай трактор кабинасыннан ике мылтык алып чыкты да, аларны

куаккистергечнең кырыена сугып, ватып ыргытты. Аннан соң, бераз уйлап торгач, Леонид кайдандыр чиләк алып килеп, цистернадан солярка агызып алды һәм балокка таба килә башлады.

—Нишләмәкче була ул?!—дип кычкырып җибәрде курка төшкән Степанишин.

Тыштан җинаятьченең балок стеналарына сибелгән солярка шыбырдавы ишетелде.

—Әй! Балоктагылар! Сезгә барыбер үлем! Тышка чыга алсагыз да, эчтә калсагыз да. Валлаһи, мин моны теләми идем, ләкин сез үзегез минем юлыма аркылы төштегез.

—Вертолетның очучыларын да син юк иттеңме?—дип кычкырды аңа Равил.

—Ә-ә-ә! Әле син алай дисеңме?!—диде Стакай.—Алайса, мә, ал кирәгеңне!

Шулчакны ишектән ачы төтен бәреп керде, тышта шытырдап ут янганы ишетелде, ә тәрәзәдән очкыннар күренде.

—Ул бит безне чыннан да яндырырга җыена!—дип кычкырды Степанишин, тәмам коты алынып.

Балок эчендәгеләр тагын тәрәзә янына ташландылар, ләкин тәрәзә бик кечкенә һәм аның аша чыгарлык түгел иде.

—Костя! Кара!—дип кычкырды Равил.

Кечкенә тәрәзәдән күренеп кенә торган лабаз янында Стакай күренде. Ул кайдандыр җинелчә генә итеп ясалган баскыч китереп, лабазга сөяде дә, баскыч буйлап өскә үрмәләде. Менеп җиткәч, ниндидер тимер кисәге белән каерып тартманың капкачын ачты һәм... тәрәзәдән карап торучыларның күзләре дүрт булды: Стакай иелеп, тартмадан инкассатор капчыгын тартып чыгарды.

—Вертолеттагы акча,—диде Равил, ни өчендер пышылдауга күчеп.

Стакай, чыннан да, сумкадан бер-ике капчык алып, әйләндергәләп карады да, сумкага кире тыгып, аны тартмага ыргытты. Аннан соң җинаятьче чәнчә бармагын төбәп, тартмадагы капчыкларны санап чыкты.

«Ун данәләп бар, ахрысы»,—дип уйлап куйды тегенең хәрәкәтләрен күзәтеп торган Равил.

Ул арада Стакай баскычтан төште дә, ялкынга уралган балок янына йөгерде.

—Әй, сасы көзәннәр! Тересезме әле?—дип кычкырды ул эчтәгеләргә. Тиз генә бетегез дә, мин Мусинны юк итәргә китәм.

Тәрәзәдән, янган ишек аша, балок эченә ялкын үрли башлады. Ачы төтен тыннарны буа иде.

—Равил! Нишләргә? Бетәбез бит!—дип кычкырды Костя.

Шулчакны тышта гөрселдәтеп мылтык аткан һәм Стакайның ачыргаланып кычкырган тавышы ишетелде.

Ярты минут та үтмәде, кемдер, тимер кисәге белән, балок ишеген каера башлады: ишек тыштан йозакка бикләнгән булып чыкты. Балок эчендәгеләр дә соңгы көчләрен җыеп, ишекне тышка бәрдерә башладылар. Ниһаять, ишек чыдамады, тышкы якка актарылып төште. Ләкин тышка чыгу барыбер мөмкин түгел иде: ишек урыныннан балокка көчле ялкын бәреп керде.

Тыштан тавыш ишетелде:

—Равил! Сикерегез тизрәк тышка! Юкса янып үләсез бит!

Бу—Камил тавышы иде.

Балок эчендәгеләргә озак уйлап торырга вакыт юк, аларның мизгелләре дә санаулы гына иде. Башта Костя, аның артыннан Равил туп-туры ут эченә сикерделәр һәм... балоктан очып чыгып, карга мәтәлеп төштеләр.

Равил шундук сикереп торып, башын боргалап, Стакайны эзли башлады. Ул исә моторы үкереп утырган трактор янында катлы-катлы итеп сүгенеп, аягын угалап ята иде.

—Пистолетың мин алдым,—диде Камил һәм кесәсеннән Стакайның

коралын чыгарып, Равилгә бирде.—Мә, тот!

—Син монда ничек килеп чыктың?—дип сорады Равил. Мин инде сине ун чакрымлап алга киткәнсеңдер, дип уйлаган идем.

—Киткән дә булыр идем,—диде Камил,—ләкин юлда минем исемә, беләсеңме, нәрсә килеп төште: былтыр җәй мин Стакайны бөтенләй язмаган җирдә күргән идем бит...

—Кайсы төш инде ул—язмаган җир?

—Тыңлап тор. Җәй көне мин Вагайга кайтып килгән идем бит. Август аеның нәкъ 25 ендә мин культбазада экпедициянең самолетын көтә идем. Шул чакта Стакайның бер адәм белән «Волга»га утырып китүен күреп калдым. Автомобильгә утырган чакларында теге кешенең Стакайны кисәтүе дә колакка чалынды. «Эшеңне эшләгәч тә, шым бул. Ярты ел бөтенләй тынныңны да чыгарма...»—Калганын ишетеп булмады.

—Стакай сине күрдеме соң?

—Юк, ул мине күрмәде. Ә бит Леонид ул чакта Касьянов белән бергә профильләрдә агач кисәргә тиеш иде. Нишләп соң әле ул Культбазага барып эләккән? Менә бүген шушы хәлләр искә төште дә, кире борылып килдем.

—Һәм безне үлемнән коткардың,—диде Равил.

—Болай гына Стакайны кулга алып маташыр вакыт юк иде инде,—дип тәмам итте сүзен Камил,—сез куркыныч астында идегез, мина аның тезенә атарга туры килде. Коралы шундук бер якка очты.

Әле генә үлемнән котылган Равил, Константин һәм Камил Стакай янына килделәр.

—Йә, хәшәрәт! Нишләтергә инде сине?—дип, Костя җинаятьчегә төкерде.

Стакай тешләрен кысып, сызланып ята бирде.

—Костя!—диде Равил, Стакайның аягындагы җәрәхәтне караштырып.—Ярасын бәйләргә кирәк. Дарулар токчасын кай җиргә тыктың, бар алып кил!

—Нәсә-ә-ә-ә!—дип, чиктән тыш гаҗәпләнде Степанишин.—Әле аны тагын бәйләргә дәме?

—Бар, бар!—дип боерды Равил.—Безгә бит аны тере килеш алып кайтып житкерергә кирәк: җинаяте өчен җавап бирергә тиеш ул.

Өчәүләшеп Стакайның ярасын эшкәрткәч, аның кулларын бәйләп, трактор кабинасына мендерделәр. Ахырда лабаздан акча токчаларын төшереп, аларны бер зур киндер капчыкка тутырдылар һәм кабина түбәсендәге матрацлар арасына тыгып, ныгытып бәйләделәр.

Шулвакыт кул-аягы бәйләнгән Стакай янә телгә килде:

—Шакаллар! Сез үз акылыгыздамы? Кая алып барырга телисез бу акчаны? Алар турында оныттылар бит инде, күптән оныттылар. Сез нишлисез! Мондагы акча сезгә гомерлеккә җитә бит, тайгада гомер буе череп ятмассыз!

Тегеләрнең эндәшми бер-беренә карашуын үзенчә аңлады булса кирәк, дәвам итте:—

—Сезнең өчегезгә дә берәр миллиард, калганы миңа һәм... үзегез аңлыйсыз, мин бер үзем генә түгел...

Стакай боларның һаман да дәшмәвен азсыну билгесе дип аңлады бугай:

—Ярый, һәрберегезгә икешәр миллиард булсын! Ант итәм, бу турыда беркем дә белмәячәк. Вертолетның очучылары инде табыла торган урында түгел, бөтен җинаять аларга ябылачак. Йәгез, егетләр, тәвәккәлләгез! Ә минем җәрәхәтне очраклы хәл диярбез.

Беренче булып Равил телгә килде:

—Димәк, син безнең намусыбызны ике миллиард сумга бәяләдең? Арзан. Арзан!

—Булса, күбрәк тә бирер идем, триллионын да кызганмас идем!—диде Стакай, өмет чаткылары кабынган күзләрен ялтыратып.—Башыгыз

эшләсә, киләчәктә күпме кирәк, шулкадәр булыр.

—Подлец!—диде Равил, нык тавыш белән.

Стакай өметле карашын Степанишин белән Мусинга төбәде:

—Костя! Коля! Аңлатыгыз шул башсызга, сез бит тинтәкләр түгел. Хәзер бит бөтен Россия шулай яши: кем ничек һәм күпме эләктерә ала. Бөтен сәясәт шундый, өстән аска кадәр.

Камил белән Константин Стакайның бу сүзләренә илтифат итмичә, үз эшләре белән мәшгульләр иде.

—У-у! Каһәр суккан романтиклар!—дип ысылдады Стакай.—Бер без генә түгел бит, бөтенесе дә шулай яши.

—Барысы да түгел,—дип җавап бирде ана Равил.

—Их! Кабахәтләр! Мисезләр!—дип, ажгыруын дәвам итте Леонид, ачы сүгенде.—Болай булгач, үзегезгә-үзегез үпкәләрсез. Сезгә базага кайтып керү юк, гомумән, дөньяда яшәү бетте сезгә.

Ун минуттан артына цистерналы чананы таккан, эченә дүрт кеше сыйдырган трактор Ева-Тордан чыгып, Охотбазага таба юл тотты. Өч сәгатьләп үзләре салган әзер юл белән баргач, юлчылар, тракторны туктатып, җиргә сикерешеп төштеләр, тәмәке кабыздылар.—Шулай да, Камил дус, әйт әле: теге вакытта Стакай кем белән «Волга»га утырып китте.

Көтелмәгән бу сораудан Камил башта аптырабрак калды, ләкин шундук исенә килеп:

—Ә-ә-ә, җәй көнеме? Округ Югары Советының рәисен сайлау буенча агитацион плакатларда Борошнин дигәне бар иде бит? Менә шуның белән.

—Ке-е-ем? Борошнин?—дип исе китте Равил.—Ул бит район милиция башлыгы, ә хәзер рәислеккә кандидат. Син ялгышмыйсыңмы соң, Камил абый?

—Икмәктер менә!

Шулвакыт трактор моторы тавышына тагын ниндидер бер ят гөрелте кушылды. Юлчылар, башларын тирә-якка боргалый-боргалый, карана башладылар. Ике-өч секунд үтүгә инде чак кына караңгылана башлаган һавада самолет күренде. Экспедицияләрдә төп транспорт берәмлеге булып хезмәт итүче, җәен—су өстенә һәм корыга, кышын карлы ачыклыкларга утырырга сәләтле кечкенә Ан-2, биек кедр башларына тия язып, нәкъ алар өстеннән очып үтте.

Юлчылар, башларын күтәреп, аптырап калдылар.

—Монысы нинди галәмәт булды тагын?—дип куйды Камил.

—Моны син күргән рәислеккә кандидат Борошнин җибәргәндер,—дип җавап бирде Равил.—Ычкындык, егетләр, бәладән башаяк.

Өч-дүрт минуттан әлеге самолет тагын бер мәртәбә, инде кире якка узды да, югалды.

—Бу самолет Ева-Тор ягыннан килде бит, ул синең янда лабаздагы таланган акчаны алырга килгән иде түгелме соң?—дип сорады Равил Стакайдан. Ләкин тегесе дәшмәде.

—Алар күл өстенә утырып, лабазны караганнардыр да, акчаны тапмагач, безнең эз буенча куа киткәннәрдер,—диде Равил иптәшләренә.

—Аларны бүгенге көнгә Стакай чакыргандыр, алай булгач,—дип төшенде Костя.

—Алар белән ул үзегезнең рациягез аша сөйләшкәндер дә инде,—дип, Камил дә сүзгә кушылды.

—Ә аннан соң, безне рациясез калдыру максаты белән, аның батареяларын бозып куйган,—дип фикер йөртте Костя.

—У-у-у-у! Эт!—дип, Камил Стакай ягына борылды, ләкин бертөрле дә җавап алмады.

—Безне алар болай гына калдырмаслар, дип уйлыйм,—диде Равил иптәшләренә, башы белән һавага ымлап.

—Юк! Самолеттан безне ала алмаслар,—дип, башын чайкады Камил.

—Самолет җибәрергә хәленнән килгән кешенең вертолет җибәрергә дә мөмкинлеге булыр. Күр дә тор, бер сәгать тә үтмәс, вертолет монда булыр. Безгә ана кадәр үзебезнең профильләргә барып җитәргә кирәк: анда качу өчен юллар күбрәк.

Чыннан да, тракторны илле минутлап кугач, Равил кабинадан башын тыгып унга, сирәкләнә төшкән вак наратлар арасыннан офыкка таба карады һәм ярыйсы гына карангыланган күктә якынаеп килүче вертолетны күрде.

Җир өстендәге кар яктысы һавадагыларга да ярдәм итте: вертолет мөмкин кадәр түбәнәеп, нәкъ трактор өстеннән оча башлады. Һавадан мегафон аша кычкырган көчле тавыш ишетелде:

—Әй, трактордагылар! Туктагыз! Сезнең белән милиция капитаны Лукьянов сөйләшә! Хәзер үк туктарга боерам!

Степанишин башын Равилгә таба борды:

—Нишлибез, туктыйбызмы? Милиция ди бит.

—Юк, юк! Туктама! Без аларның документларын карый алмыйбыз бит. Милиция безнең белән базада да сөйләшә алачак.

Кинәт алда нәрсәдер шартлады, тирә-якта кыйпылчыклар сызгырып куйды, ләкин аларның берсе дә кабинага тимәде: тракторны алгы яктан куаккистергеч каплый иде. Бер үк вакытта диярлек өстән автомат тавышлары да ишетелде, ләкин пуляләр тракторның эченә үтмиләр иде: кабинаның өстенә дә, мотор өстенең ачык урынына да төрле әйбер, савыт-саба салып бәйләнгән.

—Костя! Ку шәбрәк!—дип кычкырды Равил тракторчыга. Тегесе куркуыннан бөтен көченә акселераторга басты, трактор тагын да ярсыбрак алга ыргылды.

Шулвакыт тагын (инде артта) шартлау тавышы ишетелде. Бу юлы кабинадагыларны арттагы цистерна коткарды: кыйпылчыклар шыбырдашып аның арткы өлешенә бәрелделәр, мичкәнең нык тимере чыдады, тишелмәде.

—Граната төшерәләр,—дип кычкырды Равил.—Камил абый, мылтыгыңны кор да, ат корсак асларына! Синең баш бармак кебек юан пулян тисә, вертолет үзе үк егылып төшәр.

Бу вакытта коты алынган, күзләре акайган Стакайның тавышы ишетелде:

—Сез ни эшлисез, тинтәкләр! Бетәбез бит! Шулкадәр акча... Аларга да җитәр, сезгә дә, әйдәгез туктап, бүлешеп алыйк!

Равил Стакай ягына кулын гына селтәде. Ә бу вакытта Камил мылтыгының ике көпшәсенә дә пулялы патрон тыгып, кабинадан яртылаш чыгып, вертолетка корал төби башлаган иде. Менә ул тиз генә мылтыгының ике көпшәсеннән дә бер-бер артлы вертолетның нәкъ аскы өлешенә төбәп атып җибәрде. Вертолет шундук кискен генә өскә менеп китте дә, тагын туктады.

—Әһ-һә! Шүрләденме?!—дип кычкырды Равил, һавага йодрыгын күрсәтеп.

Камил мылтыгын яңадан корды да, вертолетка янә берне гөрселләтте. Очкыч унга табарак китте дә, параллель курска ятты. Бу урында урман калынаеп, агачлар биегәйгәнлектән, вертолет кайвакытларда бөтенләй күздән югала иде.

—Шәп булды егетләр!—диде Равил. Шул кирәк ул һава пиратларына!

Шулчак Костяның: «Профильләргә җитәбез!»—дигән шатлыклы тавышы яңгырады.

—Инде нишләрләр дип уйлыйсың?—дип сорады Камил Равилдән.

—Алар безне ничек булса да әле бүген үк кулга төшерергә тырышачаклар. Юкса, алты-җиде сәгать эчендә без базада булачакбыз. Ә бу исә, алар акчадан колак кагалар, дигән сүз. Икенче яктан, алар җиргә төшмичә, безне тота алмыйлар. Мин болай уйлыйм: хәзер, алар унайлырак урынга бер төркем «десант» төшереп, безне каршы алырлар.

Артыбызга да төшүләре мөмкин. Менә шул чакта инде безгә авырга килер. Юлсыз-нисез урманга качып котылып булмаячак.

Шул ук секундта вертолет, Равилнең сүзләрен раслагандай, аларны узып, алга очты.

—Күрдегезме!—диде Равил һәм картасын чыгара башлады.

Нәкъ шул мизгелдә алда боларның килгән юлын аркылы кисеп чыккан, тапталган нык юллы профиль күренде.

Равил:

—Сулга борыл!—дип әйтүгә, трактор тизлеген дә киметмичә профиль буйлап шул якка омтылды.

—Кая барабыз соң?—дип аптырады Камил.

—Кайдадыр шушы тирәдә беренче отряд эшләргә тиеш, Глухихныкы,—дип кычкырды Равил.—Базага безне барыбер үткәрмәячәкләр, алар инде бу вакытта безнең юлга «десант» төшерәләр булыр. Ә сейсмоотрядта унбиш-егерме кеше эшли, рация дә бар.

—Аларга кадәр ничә чакрым булыр соң?—дип сорады Костя.

—Төгәл генә әйтә алмыйм, чөнки беренче отряд соңгы вакытта яхшы гына алга китте.

Ул арада ярыйсы гына караңгы төшеп, барасы юл ачык күренми башлады. Ләкин Равил тракторның утларын кабызудан тыйды. Вертолетның аларны эзләп кире килүендә аның һичбер шиге юк иде. Чыннан да, ярты минут та үтмәде, өстә тагын гөрелдәгән тавыш ишетелде.

—Ничек уйлыйсың, ул тегендә кешеләрен төшергән идеме икән?—дип сорады Камил.

—Шулайдыр, дип уйлыйм,—диде Равил,—әнә вертолет тагын кире, килгән ягына борылды, ул анда калган кешеләрне алырга китте түгелме соң?

Тагын ун-унбиш минут вакыт үтүгә, Костя унга таба аерылып киткән жиденче профильгә якынаюларын хәбәр итте.

—Шул профиль белән кит, Костя, уңга борыл!—дип боерды Равил.

—Нигә анда? Без инде беренче отрядка бармаска булдыкмыни?

Шулвакыт һавада тагын вертолет гөрелтесе ишетелде. Өстәгеләр, тракторның унга борылып, яңа юл белән киткәннәрен күргәч, трактор өстеннән бераз гына бардылар да, тагын алга ашыктылар.

—Инде кирегә борыл!—диде Равил яңа профиль буйлап ике йөз метрлап кына китәргә өлгергән Степанишинга. Хәйләне аңлап алган иптәшләре, үзләренең бик хөртиләнгән хәлләрен онытып, шаркылдап көлеп җибәрделәр. Чыннан да, әгәр вертолеттагы кораллы кешеләр төркеме янадан боларның алдында «десант» төшерсә, качып баручылар тагын ярты сәгатьләп вакыт отачаклар иде.

Равилнең уе дөрескә чыкты, ахрысы, егерме минутлап трактордагыларны беркем дә борчымады. Ләкин шул вакыт үтү белән һавада яңадан нидер гөрелди иде. Бу—әлбәттә, әлеге вертолет тавышы иде.

—Менә бу нарат астына тукта!—дип, Равил ызан читендәрәк үсеп утырган җәенке ботаклы агачны күрсәтте.

Вертолет алга узды да, ниһаять, юкка чыкты. Качкыннар моны кич житеп, караңгы төшү белән аңлаттылар. Инде бернидән дә курыкмыйча, тракторның утын кабызып, профиль буйлап ярты сәгать баргач, алда утлар күренде. Бу—беренче отрядның төнгелеккә урнашкан урыны иде.

Чиктән тыш гаҗәпкә калган отряд халкы яңа килүчеләрне балоклардан чыгып каршыладылар. Куллары бәйләнгән Стакайны күргәч, алар бөтенләй таң калдылар. Равилгә үз башларыннан кичкәннәрне отряд эшчеләренә сөйләп бирергә туры килде.

Отрядның радисты шундук Охотбазаны чакырды һәм ачык текст белән Крючковка—партия башлыгына булып үткән хәлләр турында хәбәр итте. Тегесе үзенең экспедициядән вертолет чакырып, иртә белән үк отрядка килеп житәчәген белдерде.

Төнгә өч дусны бер балокка урнаштырдылар, ә Стакайны бер танышы үз янына алды.

Өч иптәш әле озак йокыга китә алмый яттылар. Көндезге галәттән тыш булган хәлләрне яңадан искә төшерделәр, киләчәккә зур өметләр баглаган ниятләр кордылар, хыялларында ел буе күрмәгән хезмәт хакын да алдылар. Әмма, бераз вакыттан соң Камил әйтә салды:

—Ә бит, егетләр, безнең эшләр хөрти.

Тегеләре аптырап, ана борылдылар һәм икесе берьюлы:

—Син ни сөйлисең?—дип сорадылар.

—Мин,—диде Камил,—эш моның белән генә бетмәс дип уйлыйм. Артык ишле акча эләктердек без, һәм бик зур кешеләр катнашкан булырга тиеш бу җинаятьтә. Без каты каптык, егетләр. Әгәр яктырып җитү белән безне алырга килеп җитсәләр, исегез китмәсен.

Равил белән Константин Камилгә каршы төштеләр. Кирәкле органнар Стакайның җинаятен җентекләп тикшерерләр һәм ана тиешле җәза бирелер, дип исәплиләр иде алар.

—Беркатлы булмагыз,—диде Камил аларга, төшенке тавыш белән,—сез бөтен нәрсәне алсу пыялалы күзлек аша күрергә күнеккәнсез. Голливуд боевикларында гына ул бөтен нәрсә әйбәт тәмамлана, җинаятьләр ачыла, җинаятьчеләр тиешле җәзаларын ала...

Равил һәм анын иптәшләре уянганда тышта караңгы иде әле, әмма алар үзләрен тәртипкә китергәнче, ашап-эчкәнче, тайгада яктыра башлады. Ләкин отряд кешеләре тракторларын кабызып эшкә башларга ашыкмадылар: барысы да әлеге дә-баягы акча вакыйгасының ни белән бетәсен көтәләр иде.

Озак та үтмәде, һавада вертолет тавышы ишетелде. Отрядтагылар якындагы саз янына ашыктылар. Аларга ияргән Равил, Константин һәм Камил дә кар бураны күтәреп җир өстенә төшеп утырган борт янына якынлаштылар. Барысы да вертолеттан кемнәр төшәрләр, дип, кызыксынып көтәләр иде.

Менә вертолет ишеге ачылды һәм борт-радист эленмәле баскыч төшерде. Беренче булып, ишектә партия башлыгы, олпат гәүдәле Юрий Яковлевич Крючков күренде. Анын артыннан колгадай озын торыклы экспедиция башлыгы Подшибякин иелеп-бөгелеп килеп чыкты, аннан соң... район милиция начальнигы Борошнин күренде. Анын артыннан вертолет эченнән автоматлар тоткан дүрт ОМОНчы сикереп төштеләр.

Камил яшертен генә Равилнең кабыргасына төртеп куйды. Өч дус үзләренең алдагы билгесез язмышларын уйлап, бер-беренә сыендылар...

# ШИГЪРИЯТ



## Марис Нәзиров

### ИҢНӘРЕҢДӘ КАНАТ БАРДА...

#### Йорт казлары

—Кыйгак... Кыйгак...
Кыр казлары оча җырлап,
Кайтаваздай тынлык ярып,
Канатларын көчле кагып,
Юл алалар еракларга,
Югалалар офыкларга.

Кыйгак... Кыйгак...
Алар киткән якка карап,
Йорт казлары йөри чабып,
Канатканчы канат кагып.
Омтылганда болытларга,
Бәреләләр кыекларга.

Кереш чөйгән таш-ук сыман
Төшү белән килеп җиргә,
Каурыйларын чәчеп җилгә,
Ыңгырашып, сыкрап, елап,
Ярсып, соңгы көчен җыйнап,
Каңгылдыйлар:
—Кыйгак... Кыйгак...

Казлар, казлар, аңлыйм Сезне,
Мин кушылам сезнең зарга:
—Очмыйча син түзеп кара
Иңнәреңдә канат барда.

... Яшәп кара!..

---

Марис НӘЗИРОВ—*1949 елда туган, татар һәм башкорт телләрендә берничә шигырь китабы, күп популяр җырлар авторы. Уфада яши.*

## Әфгани*

Чүл күккә үрмәләде. Барханнар аягүрә,
Варан булып вараннар ашыгып яшеренә.

Күк чүлгә тәгәрәде: котыра, җикеренә,
Ишәкләрне бакыртып Әфгани килә.

Әфгани килә...

Ком бурап коеда да өермә бөтерелә,
Танк көчәнгән шикелле казарма дер селкенә.

Ут йөрәккә итек табанын кисеп менә...
...Газраил кисәтүе кайсыбыз исеменә?!

Әфгани килә...

## Мамык бураны

Тупылның да, ахры, киләдер
Бер ак булып күренәсе—
Коепмы коя йон-мамыгын,
Әйтерсең лә каз өмәсе.

Каз өмәсе? Юк, түгел лә,
Әле бит кыш башы түгел.
Бер чәчәксез... шомыртлар да—
Язның йөзек кашы түгел.

Түгел каен аклыгы да,
Ни дип күңел алданса да.
Тузганаклар гына бит бу,
Чәчләреңә капланса да.

Кар кебек учта эреми,
Җил үрелеп тартып ала.
Таптап узгач,—әй кызганыч...—
Ала-кола булып кала.

Карала җиргә сыенып,
Туфрак төсе йога микән?
...Барлыйм чәчем караларын,
Минем дә җәй җиткән икән.

* * *

Кояш, гүя, яралы кош,
Ярдан күлгә кадалды.
Әлсерәгән зирекләргә
Каны ягылып калды.

Сискәндерде яфрак шавы:
—Зинһар, түбән сикермә!
...Йөрәгемне кысып тотып
Торам кыя читендә.

* Коточкыч гарасат, Әфганстан ягыннан дөнья актарып килгәнгә Төрекмәнстанда шулай атап йөртәләр.

* * *

Ир чорына керү мәлендәмен,
Тоям кебек инде әрем тәмен.

Авыз тулып кан—юк түкергәнем,
Нигә сыкрый әле җаным-тәнем?

Туган җирем, туган илемдәмен:
Канаты сынык кош хәлендәмен.

Дуслар «телем кискән» дәвердәмен,
Бер аягым белән кабердәмен...

* * *

Кил, шатлык, кил,
Йә тизрәк җил булып
Яныма йөгер.
Кар кебек керфеккә кагыл,
Муенга сарыл,
Куеныма кер.

Кил, шатлык, кил,
Җанымны ачыштлар,
Табышлар түре ит.
Әмма элекке булсаң,
Шул ук утта җылытсаң—
Кирәкми, кире кит!

## Күнегелә...

Корый шәфкатьлек агачы
Ир-егет күңелендә.
Тайганны төртеп үтүгә,
Таптауга күнегелә.
Аккошны атып алганны
Аклауга күнегелә...

Ишелә шәфкатьлек тавы
Хатын-кыз күңелендә.
Сөюгә атылган гайбәт—
Ташларга күнегелә.
Коега күкрәк баласын
Ташлауга күнегелә...

«Ак карга» булып төркемгә,
Көтүгә күрен генә—
Йолкына тән, күмелә җан
Каһәрләү күбегенә.
Күкрәгеңә чәпәлә боз
Күмәклек көбәгеннән...

Сүнә шәфкатьлек уты;
Залимлык күрегеннән

Сибүгә күңел шәменә
Көл генә, күмер генә
Бүген дә күнегелә...
Ах, һаман күнегелә
Ваемсызлык сазына
Күңелләр күмелүгә...

* * *

Ярып Димнең күк томанын,
Ярда учаклар яктык.
Мине дә як, дигән төсле
Калды усаклар ятып.

Хәтта шушы усакларның
Янмый үләсе килми,
Күзге төн карасын ерткан
Каен язмышын көнли...

Ярга ауган усакларның
Ялкыны инде сүрән...
...Уйлый-уйлый үз хәлемне
Янә утларга керәм!

## Күпер

*Әмирхан ага Еникигә*

Әйтте әдип, үзен бик чакыргач
Күз күргәнне бергә туйларга:
«...Җәй көлгәндә кайтып килим әле
Туган якның тынын тоярга...»

Туган туфрак ифрат газиз икән,
Олыгайгач инде бигрәк тә.
Йөрәктә бит дәрт тә, дәрман да бар,
Көч бетсә дә күптән беләктә.

Каләм очларыннан тама әле
Ак кәгазьгә бакый рух нуры.
Күңелдә бит ажаганнар түгел,
Ләйсән яңгырлары җәйгоры*.

Башкортстан белән Татарстанны
Тоташтырган күпер бу җәйгор...
Ул бит туган җир вә торган җирнең
Җәүһәрләрен бергә җыйгандыр.

Шул җәүһәрләр җанда балкыганда
Җимерелә зиндан, киртәләр.

* Салават күпере.

Әдип рухы салган бу күпердән
Үтәр атлап якты иртәләр.

Без кабаттан җыелырбыз әле
Аксакалның сүзен тыңларга:
«...Җәй көлгәндә кайтып калыйм әле
Туган якның тынын тоярга...»

## Мин ышанам

Мин ышанам:
Гәүдә үле булганда да
Тере, исән кала адәм җаны.
Ул очалыр Галәм иңләп,
кетеп янә
Кемдер сурәтенә керер җайны.

Ничек инде
Кеше дигән җимеш—илаһи көч!—
Бөтенләйгә юкка чыксын, имеш.
Мин ышанам:
Табигать—ул Гали Гакыл,
Эшләмәскә тиеш көнлекле эш.

Мин ышанам:
Үзебездән фәкать нәсел
Калдырырга җиргә яралмыйбыз.
Җан кунганда карындагы
яралгыга,
Кабынадыр күктә яңа йолдыз.

Аның күктән,
Изгелекләр кылсаң гына,
Җиргә җылытучы уты килә.
Мин ышанам:
Гәүдә үлгәч—фәкать җаһил,
Явыз затлар җаны юк ителә.

Мин ышанам:
Тәнем гүргә кергәндә дә
Садә җаным очар Галәмендә:
...Зинһар, Тәңрем, кичерә күр,
Нур коймасам
Гомерем юлын сызган каләмеңнән!

*Уфа.*

❋



# Мөхәммәт Мирза

## БЕЗ МӘҢГЕЛЕК ЮЛЫНДА

* * *

Без туфрактан яралганбыз
үләннәр, гөлләр кебек.
Гомерләр үрмә гөл кебек,
димәк, яшәү—мәңгелек!

Без тамчыдан яралганбыз—
таңның энҗе чыгыннан.
Тамчыдан—күл, дәрья, диңгез,—
гомер йөзеп чыгылган!

Без Кояштан яралганбыз,
Илаһының нурыннан.
Нур очында мәңгелек сер:
без Мәңгелек юлында!..

* * *

Ук алмаслык арада
зәңгәр күк ник карала?
—Кыйгак, кыйгак!—тавышлары
бар дөньяга тарала...

Йөрәгемне телеп-телеп,
уеп-уеп ала ла...
Күкне дерелдәткән тавыш
бар гамәлгә тарала:

—Килүләр бар—кыйгак-кыйгак!
—Китүләр бар—кыйгак-кыйгак!
—Калулар юк, калулар юк—
булсаң да ак, булсаң да пакь!—
Калулар юк бу дөньяда...
Мәңге шулай! Кыйгак, кыйгак...

* * *

—Арын арык уйларыңнан,
йом да күзләрең,
онытылып кал беразга:
мендәр—тезләрем.
Арын тутыккан хисләрдән,
искенең исе
исертмәсен, йөз суыңны
бирмә иблискә...

Тик, бер төндә онытылчы
дөнья гаменнән,
исертәсем килә сине
хис шәрабемнән.
Сулышымның бәлзәменә
саласым килә,
йөрәгеңә ут кабызып,
үзем дә сүнмәс ут булып
янасым килә!..

* * *

Кайда да бер Кояш,
Кайда да бер үк Ай,
Кайларда торсак та,
Иманлы ит, Ходай!..

* * *

Сиңа килдем утлар-сулар кичеп,
Өметемне кысып учларыма...
Ялкыныңа сулар сибим ничек,
Ут тергезим ничек учагыңа?!.

* * *

Көннең кашын сызган кара күмер,
Сөрмәсен дә тарткан карадан.
Көн белән төн арасында—гомер,
Йә кем чыгалган шул арадан?..

## Ике газәл

1

Көн уртасы, туктап калды сәгатем,
Юк иде лә кинәт туктау гадәте.

Соңга калдым килер-барыр юлымда
Шул сәгатем туктап калу сәбәпле.

Сәгатькә ни? Аның һичкем алдында
Юк аласы, йә бирәсе әҗәте.

Без генә ул, баш күтәрми көн-төнен,
Гомер буе үтибез кем хаҗәтен?

Вакытны кертермен димә тәртәгә,
Җитсә дә күпкә акылың, сәләтең.

...Кабат дивар сәгатем йөреп китте,
Туктап калыр беркөн—гомер сәгатем...

2

Күзгә күз багып бирәмсең сәламең,
Туганым,—дип, өзеләме кәмәлең?

Нәсел-ыру, ил-йорт йөге иңендә—
Нык будыңмы биleңдәге кәмәрең?

Дога, бәддогамы вәгазь-таләбең,
Вәгъдәңә таңгәл-ятышмы гамәлең?

Яктыртмакчы күңлең—күгең күпләрнең,—
Кояш-Айлы, йолдызлымы галәмең?

Искәндә дулап җаһиллек җилләре,
Имангамы чакыра бу әләмең?

...Уңмас, җуелмас Илаһың нурына,
И Мирза, манып язамсың каләмең?

# Татарстан язучыларының XIII корылтае

28 майда Татарстан язучылары үзләренең чираттагы XIII корылтаена җыйналды. Аны кереш сүз белән халык язучысы **Әмирхан Еники** ачты. Ике корылтай арасында эшләнгән эшләр турында идарә рәисе **Ринат Мөхәммәдиев** хисап тотты. Аннары язучылар алдында Татарстан Президенты **М. Ш. Шәймиев** чыгыш ясады. Жанрлар буенча докладларны **Фоат Галимуллин** *(проза)*, **Фәрит Яхин** *(шигърият)*, **Фәүзия Бәйрәмова** *(публицистика)*, **Владимир Корчагын** *(урыс әдәбияты)*, **Юныс Сафиуллин** *(драматургия)*, **Равил Рахмани** *(әдәби тәнкыйть)*, **Галимҗан Гыйльманов** *(балалар әдәбияты)* ясады.

Журнал укучыларга корылтайда ясалган берничә чыгышны тәкъдим итәбез.

## Әмирхан Еники,

**Татарстанның халык язучысы:**

Хөрмәтле каләмдәшләр һәм замандашлар!

Тагын биш елыбыз үтеп китте. Менә яңадан нәүбәттәге зур сөйләшүгә җыелдык. Сез беләсез инде, 1985 елдан соң заманыбыз бик нык үзгәрде, көтелмәгән дәрәҗәдә начар якка табан үзгәрде. Ельцин режимы урнашкач, без моны аеруча үз җилкәбездә татып белдек.

... Әлбәттә, бу тирән үзгәрешләр язучыларны да читләтеп узмады. Элек, совет заманында, без уртак бер идеологиягә буйсынып, бөтен бер коллектив булып яши идек. Матди яктан да тормышыбызда зур аерма юк иде. Хәзер исә идеология урынына акча килде—без акча колына әйләндек. Акчага табыну мораль кагыйдәләрне җимерде. Без бер-беребездән ераклаштык, кемнең ничек яшәгәнен белмибез, бары үз мәнфәгатебезне генә кайгыртабыз, байга һәм ярлыга аерылдык... Мәгәр тук, мул яшәүчеләр бик аз булса кирәк—аларны хакимият тирәсендә генә күрергә мөмкин. Иң зур күпчелек исә тирән бөлгенлектә, ачлы-туклы яшиләр.

Кыскасы, алдау һәм талауга корылган Ельцин режимына хас тигезсезлек, гаделсезлек, ялагайлык, әшнәлек язучылар арасына да керде. Без моны китап чыгару эшендә бик ачык күрәбез. Кечкенә бер төркем язучыларның ел саен диярлек китаплары, хәтта томлыклары да чыга... Ә бик күпләр 10 елда бер китабын да чыгара алмыйча интегә. Язучы химаясыз, аның хокукларын яклаучы юк, иҗади язмышы чиновниклар кулында.

Менә шундый шартларда безнең бу язучылар берләшмәсе нишләргә тиеш? Кирәкме ул, кирәк булса, аның вазифасы нидән гыйбарәт булырга тиеш?.. Бүгенге зур җыелыш бу хакта үзенең ачык, туры сүзен әйтер дип уйлыйм. Миңа калса, безнең берлекнең иң төп, иң мөһим вазифасы язучының икътисадый һәм иҗтимагый мәнфәгатен яклау булырга тиеш. Президенттан алып барлык хакимият структуралары алдына куелырга тиешле таләбе аның әнә шулар!.. Кеше хакын яклауда язучылар күп авырлыкларга түзгән халкыбыз өчен дә үрнәк булсын иде... Әйе, язучыларның ил алдында, халык алдында да бурычлары бик зур... Без бит халыкның рухи терәге. Ә халкыбызның бүгенге язмышы бик катлаулы. Татар—бөтен бер милләтме, әллә төрле милләтләр арасында әкрен генә эреп югалуга дучар ителгән халыкмы?! Әйтик, Русия үзәгендә яшәгән татар-

мишәрләрнең урыслашып бетүе шикелле...

Русия империясендә яшәүче татар халкын бөтен бер милләт итеп саклау, аларның милли мәнфәгатьләрен, кайда яшәүләренә карамастан, тулысынча тәэмин итү, Татарстаныбызның мөстәкыйльлеген яклау һәм ныгыту әдәбиятыбызның ин изге бурычы!.. Безгә сүз һәм фикер хөрлеге килде—бу гаять көчле корал безнең кулыбызда. Менә шуны оста куллана белергә кирәк, мәгәр һәр төрле вак җәнҗаллардан өстен торып...

Милли мәнфәгатьләрне гамәлгә ашыруда без Президентыбыз мөхтәрәм Минтимер Шәрипович белән дә уртак тел табарга тиешбез. Аның бөтен ил күләмендә танылган көчле дәүләт эшлеклесе булуын барыбыз да бик яхшы беләбез. Халкыбыз язмышын хәл итүдә Президент эшчәнлегенең әһәмияте гаять зур... һәм бик авыр йөк тә булса кирәк... Шуна күрә без, фикер иясе язучылар, сәбәбе чыкканда тәнкыйть сүзен әйтү белән бергә, кирәк чакта аңа теләктәшлек тә күрсәтә белергә тиешбез. Менә бу, ичмасам, гаделлек булыр!

Бүгенге зур сөйләшүдә биредә әйтелгән һәм әйтелмичә калган мәсьәләләрнең һәммәсенә дә өлгергән каләр кагылып узарбыз дип ышанам. Ачык, туры сөйләшү чын демократик рухта үтәргә тиеш, әлбәттә! Без яна гасыр бусагасында басып торабыз. Ышану һәм алданулар белән тулы үткәнгә кайту юк. Ә яна гасырда киләчәгебез нинди булырга тиеш—төп бәхәс тә шул хакта барыр дип ышанасым килә.

Изге сәгатьтә!

## Минтимер Шәймиев,

**Татарстан Республикасы Президенты**

Хөрмәтле язучылар, корылтай кунаклары!
Уважаемые участники и гости съезда!

Позвольте мне от имени Государственного Совета, Кабинета Министров и от себя лично сердечно приветствовать и поздравить вас с началом съезда писателей республики! Общение с художественной интеллигенцией, в том числе и с мастерами пера, для нас всегда большое и полезное событие, которое позволяет взглянуть на жизнь, на ее многие проблемы по-иному. Надеюсь, что и сегодняшняя наша встреча будет обоюдополезной.

Хөрмәтле каләм осталары!

Сезнең иҗатыгыз әдәби, сәнгати процесс белән, иҗтимагый тормыш белән бик тыгыз бәйләнгән. Сезнең соңгы корылтаегыздан соң бик күп сулар акты, бу чор туган республикабыз тормышында да тирән үзгәрешләр чоры булды. Бүген минем республикабызның барлык иҗат интеллигенциясенә, шул исәптән язучыларга да җәмгыятьне нигездән үзгәртеп коруга керткән күпкырлы хезмәтләре өчен ихлас күңелдән рәхмәт әйтәсем килә.

Татар халкы өчен—әдәбиятчылар һәм тулаем әдәбият—рухи һәм әхлакый чисталык, байлык чыганагы ул. Татар әдәбиятының борынгыдан килә торган күркәм традицияләре бар. Аның мең еллык тарихын күздән кичерсәң, без үзебезне бай халык дип әйтә алабыз. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре генә дә ничәмә-ничә буын кешеләренә олы рухи, әхлакый, эстетик тәрбия чыганагы булган.

Бүген без Утыз Имәни, Мөхәммәдьяр, Габделҗаббар Кандалый, Риза Фәхретдин, Гаяз Исхакый һәм башка бик күп олы шәхесләрнең исемнәрен халыкка янадан кайтару бәхетенә ирештек.

Безгә замандаш акыл ияләре арасында минем олы ихтирам белән Гомәр Бәширов, Әмирхан Еникиләрне атыйсым килә. Гомәр ага Бәшировның безнең

арадан китүе белән күңел һич тә килешә алмый. Әмирхан ага Еникинең иҗатын мин бүгенге әдәбиятны Тукай, Ибраһимов, Исхакый эпохасы белән бәйләүче күпер дип әйтер идем. Халкыбызга, туган телебезгә, динебезгә хезмәт итүдә без менә кемнәрдән үрнәк алырга тиеш!

Хәзерге тормыш никадәр генә авыр, китап чыгару никадәр генә кыен булмасын, яна шартларда да, тулаем алганда, әдәбиятыбызның матур казанышлары бар. Соңгы елларда туган җиребезнең, халкыбызның гыйбрәтле, бай һәм бер үк вакытта фаҗигале тарихын чагылдырган байтак кына чәчмә әсәрләр дөнья күрде, драматургия яңа баскычка менде. Вакыт шигърияткә дә яңа сулыш өрде. Бу мөнбәрдән мин горурлык белән Аяз Гыйләҗев, Гариф Ахунов, Илдар Юзеев, Равил Фәйзуллин, Гамил Афзал, Туфан Миңнуллин, Ренат Харис, Ринат Мөхәммәдиев, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Әхсән Баянов, Нурихан Фәттах, Зөлфәт Хәким, Нәбирә Гыйматдинова, Геннадий Паушкин, Владимир Корчагин һәм кайбер башка талантларыбызның исемнәрен атыйсым килә.

Демократия һәм сүз ирегә ачылу сезгә җәмгыятьне борчый торган көнүзәк проблемаларны күтәрү мөмкинлеге бирде. Рухи азатлык ягыннан килсәк, дөнья хәзер бөтенләй бүтән. Бүген идеология басымы, фикри берлек һәм цензура юк. Бу зур казаныш һәм аның кадерен белергә кирәк. Бүген язучы хезмәтен билгеләгәндә фәкать бер бәя генә бар дип уйлыйм. Ул да булса—әсәрне укучылар укыймы, ул җәмгыять һәм вакыт сынауларын узарга сәләтлеме? Минемчә, әдәби иҗатта иң мөһиме—ныклы иман, йөрәктән һәм җаннан кайнап чыккан кыю фикер. Әдәбият, сәнгать нинди максатка хезмәт итә соң? Алар кешенең әхлакый камиллеккә ихтыяҗын канәгатьләндерә аламы? Кешенең тормышка мәхәббәтен уятамы, аның иң мөкатдәс эчке хисләрен ача аламы?

Бүгенге катлаулы чынбарлыкта безнең замандашларны гына түгел, киләчәк буыннарны да дулкынландырырлык темалар һәм образлар бармы? Булса, аларны кемнәр күтәреп чыга, ничек яктырта? Матур традицияләргә, данлыклы шәхесләргә бай әдәбиятыбыз, сәнгатебез XXI гасырда кемнәр кулына күчәр? Бүгенге корылтайда сүз әдәбиятның, тормышның әнә шундый төп проблемалары турында барыр дип уйлыйм.

Олы әдәбият, сәнгать милли кысаларда бикләнеп калмый, гомумкешелек мәйданына чыга, бөтен кешелек хәзинәсенә әйләнә. Бөек Тукай иҗаты шуны раслап тора.

В этой связи вспомним великого русского поэта Александра Сергеевича Пушкина, 200-летие которого отмечает весь мир. Поэзия гениального Пушкина не знает никаких границ и проникает в душу и сердце каждого, кто соприкасается с его творчеством. Как бы ни менялись в течение столетий литературные направления, кумиры, вкусы, и даже государственное устройство, Пушкин остается величиной всеобъемляющей. Потому что в силе исторических причин он сосредоточил на себе художественные и общественные интересы. На юбилейном вечере, посвященном 100-летию Тукая, поэт Сергей Михалков назвал его выдающимся представителем российской поэзии и говорил о принадлежности Тукай к мировой литературе. На примере одного из стихотворений великого англгийского поэта Байрона «В альбом» Сергей Михалков показал, как «три великих юноши мира—Байрон, Лермонтов, Тукай—в течение одного века, но будучи в одном и том же возрасте, мыслили, любили, терзались, горели поэтическим огнем одинаково, как родные братья».

Так литература соединяет воедино великие для наших народов имена.

Әйтә башлаган фикеремне дәвам итеп, безнең халыкның гасырлар буе хыялында яшәгән бик тә милли һәм изге бер тема бар, диясем килә. Ул да булса—дәүләтчелегебезнең яңадан аякка басуы, яңадан торгызылуы, күтәрелүе. Мина калса, көн мәшәкатьләре белән без аның мөһимлеген, әһәмиятен күреп бетермибез кебек тоела. Ә бу тема бездән соң да олы тема булып калачак. Киләчәк буыннар аңа кабат-кабат әйләнеп кайтачаклар. Бүгенге сәяси, икътисадый, социаль кыенлыклар безнең бөек халкыбызның акрынлап булса да тормышка аша баруын һәм ашачагын каплап калдырмасын иде. Тормышның негатив ягын гына күрергә өйрәнгән кешеләргә дә республика җитәкчелегенең, кайчан һәм нинди генә басым ясалмасын, һәр адымы, һәр омтылышы шушы бөек максатка

юнәлгәнен аңларга теләүне бик мөһим дип саныйм. Соңгы 10 ел эчендә халкыбызның бу өлкәдә кылган гамәлләре аның дәрәҗәсен бөтен дөньяга күтәрде, аңа тирән ихтирам хисләре уятты. Безнен халык тарихында бу үзе бер зур казаныш.

Хөрмәтле язучылар!

Мин сезнең корылтайда сүз ачыктан-ачык барасын белеп, тагын бер фикер әйтәсем килә.

Мина әдәбиятка-сәнгатькә, нәшриятларга матди ярдәм кирәк, дигән сүзләрне ишетергә туры килгәли. Кирәк, әлбәттә. Һәм без аны эшли торабыз. Бу сезгә мәгълүм. Уйлашыйк, тагын нәрсә эшләргә кирәк? Тик мәсьәләнең икенче ягы да бар—пенсияләргә, хезмәт хакына акча җитмәгән заманда, бик теләсән дә, тулысынча сәнгать белән генә шөгыльләнеп булмавы да аңлашылырга тиеш.

Моңа карап, без күңелебезне төшерергә дә, кул кушырып утырырга да тиеш түгелбез. Тукайлар, Насыйрилар, Дәрдмәндләр заманында Русия хөкүмәте, дәүләт органнары татар әдәбиятын, сәнгатен үстерү хакында күпме генә кайгырттылар икән соң? Булмаган бит ул, юк—булмаган. Совет чорында кайгыртучанлык булды, дисәк тә, нишләп соң яшьләрнең әдәби журналын ачу өчен дистәләрчә еллар вакыт таләп ителде? Моңа карап әдәби, сәнгати процесс



*Президент Минтимер Шәймиев һәм шәһәр мэры Камил Исхаков язучылар арасында. Казан, 1999 ел, 28 май.*

тукталып калмады ич, үсте.

Иҗтимагый тормышта казанышлар, чигенешләр һәм борылышлар чиратлаша. бу һәрчак шулай булган. Шуңа күрә без булган көчебезне, тырышлыгыбызны куеп, уртак хезмәт белән һәм, үпкәләмәгез, шунысын да әйтим—шыншымыйча—әдәбиятыбызны, сәнгатебезне, мәгърифәтебезне үстерү турында кайгыртыйк.

Шыншу дигәннән, әгәр мин шыншый башласам, бу ничек кабул ителер иде икән? Яна дәүләт туып килгәндә миңа да бит шыңшырлык сәбәпләр җитәрлек!

Барлас Камалов «Мәдәни җомга»да әйткәнчә, Моабит шартларында да дәвам иткән илһамлы иҗат, бүгенге тормыш авырлыкларыннан сыкрап, тукталып калырга тиеш түгел. Чыннан да, беркем дә, менә бүген иҗат өчен бөтен мөмкинлекләр бар, дип әйтә алмас. Ләкин иҗат әһелләренә генә түгел, гомумән, кешегә кайчан соң бөтен мөмкинлекләр булды?

Кеше—җәмгыятьтә хакимлек итүче иҗтимагый мөнәсәбәтләр җимеше.

Телисеңме, юкмы, бу—шулай. Кешене җәмгыять тәрбияли. Бүгенге җәмгыятьне ничек кенә каһәрләмә, ул яши. Димәк, тормыш дәвам итә. Ә сәнгать, әдәбият—тормышны чагылдырырга тиеш. Нишләп соң безнең күп кенә язучыларыбыз аптырабрак калды әле? Хәзерге каршылыклы, көрәшле тормышны чагылдырган олы күләмле әсәрләр күп дип әйтеп булмый бит.

Бу уңайдан шунысын да әйтим, кайбер язучылар иҗатны тормыш кимчелекләрен кабат-кабат фаш итү белән алыштырды, шуның белән канәгатьләнә. Дөресен әйткәндә, олы күләмле яшәешнең бик күп, катлы-катлы проблемаларын чагылдырган әсәрләр менә шушындый катлаулы чорларда туарга тиеш сыман тоела.

Кызганычка каршы, бүгенге көндә миһербансызлык, эгоизм тәрбияләүче, тарихи, әхлакый тамырларыбызга балта чабучы, кеше мәнфәгатен, рухи халәтен шаблонга салучы арзан мәдәният киң тарала бара. Ә безнен әдипләребезнең күп кенә әсәрләренә моңа каршы торырлык, нык фәлсәфи нигез җитешми.

Төптән уйлаганда, бүгенге чор—мона кадәр күрелмәгән гаҗәеп чор. Без әле мөстәкыйль үсешебезнең башлангыч этабында гына торабыз. Алда безне бик зур эшләр көтә. Зарланып торудан файда юк, без эшлисен башкалар эшләмәс. Шушы бөек омтылышны һәрьяклап уйлап, уртак уй, уртак теләк һәм уртак эш белән тормышка ашырырга тиешбез.

Форсаттан файдаланып, шунысын да әйтәсем килә: идеологик басым беткәч, иҗат мөмкинлекләре киңәйде. Беркем сезне, ник тегесен тегеләй, монысын болай яздың, дип тинтерәтми. Ләкин моның негатив ягы да күренә шикелле. Бүгенге сәхнәдән, экраннардан, концерт мәйданнарыннан янгыраган җырларны гына тыңлап карагыз. Аларның күпчелегендә төче мәхәббәт, яисә сай хисләр, төшенкелек, язмыштан зар елау ярылып ята. Шуна күрә алар йөрәккә сеңми, тиз онытыла, күңелдә канәгатьсезлек тудыра.

Җыр нигезендә көй белән шигырь ята. Нишләп соң безнең композиторларыбыз начар шигырь белән килешә? Нишләп без мона юл куябыз? Мин монда административ көрәш ачыйк димим. Эстетик көрәшне, зәвык көрәшен ник онытабыз? Сәнгатьнең олы бер функциясе матурны матур итеп күрсәтү, ана соклану уяту, ә начарны бетерүгә өндәү ләбаса!

Мин бу көрәшне һәрвакыттагыча иҗат интеллигенциясен әйдәп баручы каләм осталары җитәкләргә тиеш дип саныйм.

Кадерле дуслар!

Шунысы куанычлы, иҗат берлекләренә яңа көчләр килә. Бу янарыш иҗат коллективларындагы татулыкны киметмәде, аларны бүлгәләнү-яргалануга китерми. Димәк, республикабызда традицияләргә зур хөрмәт яшәп килә. Бер үк вакытта бу—һәр яналыкка да бәрәкәтле җирлек бар, дигән сүз.

Һәр өлкәдәге шикелле, әдәбиятның да киләчәге—яшьләрдә. Язучылар берлегенең бу өлкәдә эшләгән эшләре һәрвакыт күркәм һәм максатчан булды. Бу эш киләчәктә дә уңышлы дәвам итәр дип ышанасым килә.

Сүземне тәмамлап, мин һәркайсыгызга яңа иҗади казанышлар, күңелләрегездәге илһам чыганагының саекмавын телим. Сау-сәламәт, бәхетле булыгыз!

## Ринат Мөхәммәдиев,

**Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе:**

Гадәттән тыш катлаулы һәм каршылыклы дәвердә яшибез. Бер карасан, иҗат кешесе өчен офыклар бермә-бер киңәйде, сулыш алу иркенәйде. Безнең туган бишегебез—суверенлы Татарстанның бүген үз Конституциясе, Гимны һәм башка дәүләт атрибутлары бар. Иң мөһиме, аның Россия һәм дөнья каршында абруйлы исеме һәм җитәкчесе бар. Татар теле—дәүләт теле буларак

игълан ителде. Җитмеш ел дәвамында каһәрләнеп килгән исемнәр, онытыла язган әдәби һәм мәдәни мирасны бүлеп торган киртәләр дә төбе-тамыры белән йолкып атылдылар. Тарих буразналарыннан никадәр тирәнгә һәм еракка үтәсен килсә дә—рәхим ит, күтәр, өйрән һәм яз гына...

Күнелен ни тели—шуны эшлә. Дәрманыннан килә икән, үзен яз, үзен бастыр, үзен тарат һәм үзен сат. Чынлап та, уйлый калсан мөмкинлекләр чикләнмәгән икән ич!

Ә шул ук вакытта без берөзлексез зарланабыз. Хыял һәм өметләребезнен тормышка ашмавын күреп кәефсезләнәбез, тынгысызланабыз. Елдан-ел гына түгел, көннән-көн матди мөмкинлекләребез тарая һәм чиклөнә барганны күреп кәефебез кырыла...

Россияне ни көтә? Анын саташкан җитәкчеләре иртәгә тагы нинди саташуларга бирелер. Һичкем белми.

Әнә шундый шартларда без иҗат итәбез һәм үзебезнең чираттагы Корылтаебызга җыелдык. Бары тик әдәбиятыбыз, анын бүгенгесе һәм киләчәге турында гына сөйләшергә иде дә бит. Әмма бу проблемалар һәм каршылыклы уйларны онытып, алардан котылып булмый. Алар безне, ни турында гына уйлансак, язарга алынсак та, әкияттәге албасты яисә җиде башлы аждаһа кебек, артыбыздан калмый эзәрлекләп килә.

Язучынын төннәрен йокысыз, көннәрен тынгысыз иткән һәм кулга алып карардай бәхете—ул анын фидакарь хезмәте нәтиҗәсендә иҗат ителгән китабы. Китап безне дөньяга чыгара, укучы белән очраштыра. Димәк, китап язмышы—ул безнең язмышыбыз. Әнә шуна да килеп туган шартларда татар китабы һәм, гомумән, китапның җәмгыятебездәге урынына без битараф кала алмыйбыз. Чөнки җәмгыятьнең әдәбиятка булган мөнәсәбәте генә түгел, мәгърифәт дәрәҗәсе, зыялылыгы, әхлак чисталыгы һәм рухи камиллеге дә анын китапка булган мөнәсәбәте белән билгеләнә.

Ике Корылтай арасында Татарстан китап нәшрияты гына ике йөз илле чамасы матур әдәбият китабы бастырып чыгарды. 1994 елда 46 исемдә, 1995 елда 40 исемдә, 1996 елда 44 исемдә, 1997 елда 43 исемдә, 1998 елда 51 исемдә. Күренә ки, заманалар һәм икътисади мөмкинлекләр ни кадәрле генә кыенлашмасын, Татарстан хөкүмәте һәм китап нәшрияты ике Корылтай арасында шул бер чама эшләп килгән, әдәбиятыбызга булган ихтирамын киметмәгән. Шул ук елларда «Мәгариф» нәшриятының да, дәреслекләр бастыру юлында мәшәкатьләре никадәр генә зур булмасын, агымдагы әдәбиятка игътибары һәм ихтирамы арта барды. Ул балалар һәм яшүсмерләргә 35 исемдә китап бүләк итте.

Чаллы һәм Әлмәт язучылар оешмасы тырышлыгы белән эшләп килгән җирле нәшриятлар да шактый игелекле һәм зур эш башкарды. 1994-1998 еллар арасында Чаллыда 52, Әлмәттә 87 исемдә агымдагы әдәбиятны тулыландырып торган матур әдәбият китаплары дөнья күрде.

Әле 1996 ел урталарында гына теркәлгән «Татар китабы» нәшрияты да республикабыз укучыларына 15 исемдә китап тәкъдим итергә өлгерде. Татар телендә китап бастыру эшенә «Рухият», «Казан», «Мирас», «Раннур» кебек тагы дистәгә якын нәшрият хәл кадәри өлеш кертеп килә. Тулаем алганда, китап бастыру елдан-ел кыенлаша һәм кыйммәтләнә барса да әлегә каравыл кычкырыр хәлдә түгел. Һәм, әйтергә кирәк, татар китабының сыйфаты һәм полиграфик эшләнеше күзгә күренеп яхшырды. Тик менә әле март башларында гына кәгазь бәяләренең һәм типография чыгымнарынын чираттагы мәртәбә бермә-бер артуы болай да матди файда китермәгән бу игелекле эшне, зур авырлык белән генә очын-очка ялгап килгән китап нәшриятларының хәлен сон дәрәҗәдә авыр хәлгә куйды. Киләчәктә безне ни көтә—әйтү кыен.

Без еш кына «китаплар юк», дип зарланырга яратабыз. Авыл һәм шәһәр китапханәләрендә һәм бигрәк тә мәктәп китапханәләрендә, турысын әйтергә кирәк, хәлләр шәптән түгел. Без язган һәм без дөньяга чыгарган яна китапларның бик сирәкләре генә һәм бик зур кыенлыклар белән генә барып җитә ул китапханәләргә. Татарстан районнарында бишәр-алтышар ел дәвамында татар телендә бер яна китап та кайтмаган авыл һәм мәктәп китапханәләре бар. Уйландыра, уйландыру гынамы, тетрәндерә торган факт бу!

Ә китап бар! Бар гынамы соң, китап нәшриятларының складлары шыплап безнең китаплар белән тулган.

Аларга ихтыяҗ беткәнме, аларны алмыйлармы? дигән сорау туа. Китапханәләрдә алар юк, дидек. Кызганыч ки, китап сату белән шөгыльләнүче санаулы гына кибетчеләребезгә дә барып ирешми күпчелек татар китабы. Ә авылларда исә үзгәртеп кору башланганнан бирле китап белән һичкем сату итми. Аның каравы аракы саталар. Порнографик фильмнар... Һәм наркотиклар...

Менә шундый хәл килеп туды. Кая барма: «Татарча китап юк, китап кайтмый»,—диләр. Ә наширләр китапны сата алмый аптырый. Бу уйландыра торган факт. Базар дисәк тә, базарга сылтасак та, бу эш—дәүләт кайгыртуына мохтаҗ. Китап язмышы бүген махсус кайгыртучы дәүләт программасына мохтаҗ. Һәм, әлбәттә, язучыларның да шундый хәлне күрә торып кул кушырып утырулары килешә торган эш түгел.

Бу хәл Татарстанда шулай. Ә Татарстаннан читтә яшәүче татар халкының исә хәле бермә-бер мөшкелрәк. Анда бу хәлне күрүче дә, күреп зарланучы да юк. Патша самодержавиесының купгасырлык басымыннан һәм СССР ның бердәм Совет халкы формалаштыру юлындагы гамәлләреннән исән-аман чыккан татар халкының Татарстаннан читтә гомер кичергән купчелеге демократия һәм базар шартларында кызу темплар белән милли йөзен югалтып бара, телен оныта, китап һәм Казанда чыккан газета-журналларны укудан туктады. Без җиде миллион дип, күкрәк сугып йөргән җирдән, миллион ярымга калып барабыз түгелме икән?!

Әйтик, моннан 50-60 еллар әүвәл әдәбиятка Россиянең кайсы гына төбәкләреннән килмәгәннәр. Һ. Такташ, М. Җәлил, К. Нәҗми, Г. Кутуй, Г. Әпсәләмов, Н. Арслан... Ә бүген Такташның Сыркыдысында балалар татарча сөйләшмиләр, Пенза, Рязань, Мордвадагы татар авылларында да шул ук хәл. Ул гынамы, әле кайчан гына бетмәс-төкәнмәс талант чишмәләре булып ургып аккан Башкортстаннан да килүчеләр сирәгәйде. Бу—бик җитди һәм аяныч күренеш, бу—чынбарлык. Бу хакта Бөтендөнья татар конгрессы да уйлана булса кирәк. Әмма без—язучылар да кул кушырып утыра алмыйбыз. Минем бүген сайланачак идарәгә шушы уңайдан ике тәкъдимем бар. Беренчесе, Язучылар берлегендә бер яисә ике «Газель» яисә микроавтобус булдырып, аларның даими рәвештә татарлар яшәгән төбәкләрдә, авылларда китап сатып йөрүен тәэмин итәргә. Үз заманында кул чанасы тартып та китап сатып йөргәннәр бит әле. Бу чара бәлки безгә матур әдәбиятны пропагандалау бюросын да яңадан җанландырып җибәрүгә мөмкинлекләр ачар иде.

Икенчедән, Язучылар берлегендә чит төбәкләр белән эшләүче бер штат берәмлеген булдыру ихтыяҗы гаять зур. Ул китап тарату һәм әдәби багланышлар белән бергә чит төбәкләрдә сүнеп баручы әдәби түгәрәкләргә җан өрү, яшь талантлар эзләү белән дә мәшгуль булыр иде. Дөрес, бу эш өстәмә чыгымнар сорый. Әмма башкарылачак эш ул чыгымнардан бер түгел, мең мәртәбә әһәмиятлерәк булса кирәк. Әдәбият өчен, туган телебез өчен һәм соң чиктә халкыбыз өчен фидакарь хезмәт турында бара ич сүз.

Мин әле яхшы хәтерлим. Сез дә онытмагансыздыр. Без үзебезнең чираттагы Корылтай һәм ел йомгакларына җыелсак, дәррәү күтәрелеп мәйдан житмәүдән—бердәнбер «Казан утлары» белән чикләнеп яшәргә мәҗбүр ителүебездән, тарлыктан зарлана идек. Бүген исә татар телендә чыгып килгән газета һәм журналларыбызны күздән кичереп барырга да җинел түгел, аларның саны шактый ишәйде.

Әмма «Казан утлары» үзенең әдәби процессны әйдәп барган үзәк булуын, мәртәбәле урынын югалтмады. Г. Ахунов, З. Нури, Р. Харислар баш мөхәррир булып эшләгән заманнардан тупланып килгән иң матур традицияләрне дәвам итеп, яңа заманда да үз укучысын саклап кала алды журнал. Монда «Казан утлары» коллективы һәм иң әүвәл аның баш мөхәррире Р. Фәйзуллинның ролен аерым бәяләү кирәктер.

Татар һәм рус телләрендә чыгып килгән «Идел» журналы да (баш мөхәррире язучы Р. Низамиев) әдәби һәм иҗтимагый тормышыбызда үз урынын яулап алды. Ә инде «Мирас»—ул безнең хыялыбызда гына йөргән журнал. Язучы һәм галим Ә. Сәхәпов башка һичбер эш һәм гамәл кылмаган тәкъдирдә дә, бары шушы журналны нигезләп, кыска гына вакыт эчендә аны чын академик журнал итеп күтәргәне

өчен генә дә татар әдәбияты һәм мәдәнияты тарихында аерым хөрмәткә лаек. Чаллыда чыгып килгән «Аргамак», Уфада «Тулпар», Казанда «Салават күпере» (баш мөхәррире Зиннур Хөснияр), «Сабыйга» (баш мөхәррире Ә. Сәхапов) журналлары да әдәби мохитебезнең таянычына әверелделәр. «Сөембикә», «Чаян», «Татарстан», «Ялкын», «Сабантуй», «Ватаным Татарстан», «Шәһри Казан» кебек әүвәлге, бай һәм мул традицияләргә ия газет-журналларыбыз сәхифәләре дә безгә һәрчак ачык һәм йөз белән борылган. «Мәдәни җомга» да (баш мөхәррире З. Мансуров) әкрен-әкрен үз укучысы өчен көрәштә яңа җиңүләргә ирешә.

Аз мәйдан түгел бу. Ә бит әле без татар телендә чыгучы һәм язучыны иҗатка әйдәп торган газета һәм журналларның бер өлешен генә искә алып уздык. Тиражлары тагы да үссен, гомерләре озын булсын дип телисе кала. Һәм, әлбәттә, тиешле гонорарларын да вакытында түли алсыннар иде.

Гонорар, дигәннән, язучы хезмәтенә түләү соңгы елларда онытылып бара диярлек. Китап чыгарыйм дисәң, үзеңнән акча сорыйлар, газета-журналлар «рәхмәт»кә эшли.

Соңгы биш-ун ел вакытны хәтердән кичереп, үткән юлга борылып карасак, ул дәвер дә җиңелләрдән булмады кебек. Буранлы да, давыллы да булган ул көннәрдә татар әдәбияты һәм Татарстан Язучылар берлеге байтак сынауларга дучар ителде. Иң элек СССР җимерелү белән бергә, аның Язучылар оешмасы да таркалды. Россия җимерелмәде жимерелүен, әмма аның да Язучылар оешмасы парә-парә бүленеп, үзара көрәшүче вак һәм эре группаларга аерылды. Ул гынамы, милли яисә идеологик каршылыклар нәтиҗәсендә Чуваш, Якут-Саха, Калмык, Таулы-Алтай Республикаларында һәм Башкортстанда берничәшәр язучылар оешмасы барлыкка килде. Һәм билгеле инде, бүлгәләнгән, таркалган җирдә милләт һәм аның язмышы турында уйлыйсы урынга, төп көч үзара көрәш, мин-минлекне раслауга сарыф ителә. Хәтерегездәдер, бездә дә булды андый омтылышлар, булмады түгел. Башка милләт вәкилләрен аерып чыгарып бары тик татар язучылары оешмасы кору идеясы калкып чыкты чираттан тыш җыелган Корылтайларның берсендә. Бүлгәләү, таркату яисә һич булмаса иҗат берлеген бөтенләй бетерү турында күпме сүз сөйләнде, мәкаләләр язылды. Союз кирәкме-юкмы дип, төкерек чәчеп йөрүчеләребез әле дә бетмәде.

Ләкин без ил таркалганда да ул йогышлы чиргә бирешмәдек. Бу безнең төп казанышыбыз. Халкыбыз бердәмлеге, республикабыз иминлеге хакына без бер бөтен иҗади оешма буларак яшәвебезне дәвам иттек.

Алай гынамы, кемнәрдер «дөньялар болайга киткәч бу Союз барыбер таркала инде» дип кул кушырып яисә чәбәкләргә әзер булып шул кысыр фикерләрен матбугат аша җәмәгатьчелеккә көчләп тагарга омтылган бер дәвердә Татарстан Язучылар берлеге үзенең эшен яңадан үзгәртеп корып бермә-бер җанландырып җибәрде. Үткән Корылтайда сайланган идарә даими рәвештә җыелып агымдагы әдәби процессның барлык проблемаларын хәл итүдә зур активлык һәм принципиальлек күрсәтеп эшләде. Идарә әгъзаларына бу фидакарьлекләре өчен рәхмәттән башка сүз юк.

Хәтерегездәдер, үткән Корылтайда иҗат секцияләре урынына остаханәләр оештырган идек. Проза һәм драматургия, балалар әдәбияты һәм рус телендә иҗат итүчеләр остаханәләре. Бу яңалык үзен тулысынча aклады дип әйтергә нигез бар бүген.

Остаханәләр—иҗат берлегебезнең үзәгенә әверелде. Иҗат процессын оештыру, жанрларның үсеш тенденцияләрен һәм перспективаларын билгеләү, әдәбиятка яшь алмаш тәрбияләү—болар һәммәсе остаханәләребезнең даими рәвештә күз уңында булды. Һәр ай саен гына түгел, айга икешәр-өчәр мәртәбә җыелган чаклары булды аларның. Остаханәләрнең уңышы, әлбәттә, аларның җитәкчеләре кем булуга бәйле иде. Проза һәм драматургия остаханәсен Гариф Ахунов, шигърият остаханәсен—Илдар Юзеев, балалар өчен әдәбият остаханәсен—Шәүкәт Галиев, рус әдәбияты остаханәсен Владимир Корчагин җитәкләде. Бу фидакарьләрнең тынгысыз хезмәте аерым хөрмәт һәм ихтирамга лаек.

Ике Корылтай арасында Татарстан Язучылар берлегенә 54 яңа әгъза кабул ителде. Беләм, бу санны күпсенүчеләр дә бар. Әмма мин алай уйламыйм.

Үз-үзең белән генә мавыгудан арынып әдәбият язмышы, аның киләчәге

турында да уйларга кирәктер. Бүген Язучылар берлеге әгъзасы булу—байлык, мал-мөлкәт китерми, ә җаваплылык өсти. Милләт язмышы, күпгасырлык әдәбиятыбыз һәм туган телебез өчен җаваплылык. Ә бу өлкәдә исә эшлим дисән, эш һәммәбезгә дә җитәрлек. Шуңа күрә әлеге катлаулы һәм авыр чорда үз халкына каләме һәм күңел җылылыгы белән хезмәт итәргә омтылып арабызга, сафларыбызга килгән һәр каләмдәшебез өчен шатлана, ихластан куана һәм бер-беребезгә ярдәмләшә белсәк иде.

Яшь алмашны тәрбияләүдә остаханәләрнең әһәмиятен билгеләү белән бергә кабул итү коллегиясенең дә олы эшчәнлеген ассызыклап узарга кирәк. Шәүкәт Галиев җитәкләгән кабул итү коллегиясендә Гөлшат Зәйнәшева, Тәлгат Галиуллин, Мәгъсүм Хуҗин, Харрас Әюпов һәм Марк Зарецкийлар биш ел дәвамында фидакарьләрчә эшләп килделәр. Биш ел эчендә берничә йөз китап һәм кульязма укып татар әдәбиятына килергә омтылган йөздән артык каләм иясенең профессиональ дәрәҗәсенә, талантына һәм киләчәгенә принципиаль бәя бирде алар. Бу искиткеч зур эшне күп вакытта рәхмәт тә ишетмичә башкарган каләмдәшләребезгә без ихтирам күрсәтергә тиешле.

Жанрлар турында Корылтаебызда аерым-аерым сүз булачак. Шуңа мин аерым әсәрләргә бәя биреп, докладчыларга үз фикеремне көчләп такмыйм, каләмдәшләребезнең уңыш һәм җитешсезлекләрен билгеләүне аларга калдырам. Әмма соңгы елларда проза һәм шигъриятебезнең әдәби осталык һәм тема күзлегеннән өзлексез үсештә һәм камилләшү юлында булуын искәртми китә алмыйм. Прозаикларның халкыбыз үткән юлга, аның тарихына елдан-ел тирәнрәк керә баруы һәм зур кыенлыклар белән булса да, тора-бара заман проблемаларына да алынулары куандыра. Бу юлда Ә. Еники, А. Гыйләҗев, Г. Ахунов, Н. Фәттах, М. Хәбибуллин һәм Т. Галиуллин прозабызны әйдәп баралар. Ә шагыйрьләребез, татар поэзиясенең мең гасырлык олы традицияләрен дәвам итеп, бу катлаулы һәм каршылыклы елларның үз поэтикасын табу һәм эзләү юлында. Аллага шөкер дип әйтәсе килә, шигырьгә булган тартылу, шигъри сүзнең кадерен, олылыгын аңлау, тою бар әле безнең халыкта. Димәк, аның киләчәге дә бар, дигән сүз бу.

Соңгы елларда җыр сәнгате һәм эстраданың күзгә күренеп активлашуы куандыра. Иң яхшы җырларның профессионал шагыйрьләр сүзләренә язылуы күзгә бәрелеп тора. Алар белән бергә үзешчәннәр активлыгын да билгеләргә кирәк. Дөрес, аларның җыр сүзләре күп вакыт шигърияттән бик ерак тора. Бу безне җитди уйлануларга чакыра торган факт. Кызганыч, җыр тәнкыйте бездә юк, ә шагыйрьләр ни өчендер битараф яисә, янсалар да, эчтән генә яналардыр...

Драматургиябез дә эзләнүләрдә дип әйтәсе килә. Әмма театрларыбыз репертуарын карасак, шактый фәкыйрьләнә дә барабыз кебек. Театрларыбыз булган драматургларны саклау һәм аларны ишәйтү юлында бик акрын кыймылдыйлар түгелме? Юктан уен-көлке ясап, буш ыгы-зыгыны кәмиткә әверелдерү чиренә бирелмәдекме икән, дигән сорау туа. Халкыбызның үз язмышына тиң тирән драмалар, Г. Исхакый, М. Фәйзи һәм К. Тинчуриннар мирасының дәвамы булырлык Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр»е белән янәшә торырлык олы драматургиябез бармы безнең?! Булырга тиештер ләбаса!

Балалар өчен әдәби әсәр язу гомер-гомергә иң игелекле иҗат саналган. Аллага шөкер, бүген дә балалар әдәбияты йөзгә кызыллык китерми. Соңгы елларда гына да шигырьдә булсын, прозада булсын коеп куйган балалар өчен язучылар үсеп чыкты.

Әдәби тәнкыйть язмышы авыр хәлдә. Үз жанрына тугрылыклы калып, даими эшләп килгән тәнкыйтьчеләребез бер кул бармакларын да тутырмый кебек. Бу—тирән уйга салырга тиешле хакыйкать.

Ә тагы да аянычлырагы, ул—әдәби тәрҗемә язмышы. Монда хәл башкарак, безнең зур тәҗрибә туплаган менә дигән тәрҗемәчеләребез бар. Әмма бүгенге әдәби мохитта алар эшсез калды. Үз әсәрләребезне рус теленә тәрҗемә итүчеләр дә, дөнья һәм рус телләреннән татарчага тәрҗемә итү осталары да эшсез калды бүген. Тәрҗемә кайгысымы, (?) диярсез. Хак анысы, агымдагы әдәбиятны бастыру өчен дә акча җитми. Ә шулай да, тәрҗемәсез—без көннән-көн тарая, кысыла, үз кысаларыбызда чикләнә баруыбызны да онытмаска тиешбез. Тәрҗемә ул—әдәби

офыклар киңлеге, үсеш өчен перспектива һәм өметле киләчәк тә дигән сүз иде бит.

Наш творческий союз является многонациональной. Огромный вклад в дело взаимопонимания и дружбы между писателями и представителями разных национальностей Республики вносят наши братья по перу пишущие на русском языке. Их творческий успех и каждое новое произведение становится явлением нашего общего дома. Желаю новых творческих высот Вам, друзья, и надеюсь, что в год 200 летия А. С. Пушкина мы еще укрепим наше взаимопонимание и единство. При этом хочется с благодарностью подчеркнуть вклад В. Корчагина, а также Г. Паушкина, Р. Кутуя, Н. Орешиной, Ольги Левадной, Р. Кожевниковой и других в наш единый литературный процесс, стабильности во взаимоотношениях.

Әдәбият—әдәп сүзеннән диләр. Мин соңгы ун ел дәвамында Татарстан Язучылар берлеген житәкләгән кеше буларак, әдәбиятыбызда әдәплелекнең үрнәге булган фидакарь хатын-кызларыбызга аерым хөрмәтемне белдереп узарга кирәк саныйм. Алар талантлы гына түгел, аналарча кайгыртучан, түземле һәм сабыр, тыйнак та була беләләр. Шуна да, форсаттан файдаланып, хөрмәт һәм ихтирам, зур ижат уңышлары һәм бәхет юллыйм үзләренә.

Әлмәт һәм Чаллы шәһәрендә, мәгълүм булганча, ижат берлегебезнең бүлекләре эшләп килә. Һәм, Аллага шөкер, алар үз-үзләрен саклап калдылар. Ул гына да түгел, яңа шартларда бермә-бер активлаштылар. Бу бүлекләр әүвәлгедәгечә Казаннан килгәнне көтеп ятучылар түгел бүген, үзләре эзли, үзләре таба. Чаллыда һәм Әлмәттә китап нәшриятлары булдырылу, әдәби журнал нигезләнү, әдәби бүләкләр барлыкка килү, язучыларга матди ярдәм фондлары оешу—болар һәммәсе тынгысыз һәм фидакарь эш нәтижәсе. Шушы эшне тормышка ашыруда Әлмәт оешмасынын элгәрге житәкчесе күренекле шагыйрь Нур Әхмәдиев, һәм Чаллы төбәгенең тынгысыз эш аты, Исхакый бүләге лауреаты Рахмай Хисмәтуллинга аерым рәхмәт белдерү урынлы булыр. Бүген исә бу фидакарьлек эстафетасын Әлмәттә шагыйрь Разим Вәлиуллин, Чаллыда талантлы прозаик, Г. Исхакый бүләге лауреаты Вахит Имамов дәвам иттерәләр.

Язучылар берлеге идарәсе һәм аның житәкчелеге, еллар нинди генә авыр булмасын, халык һәм кин жәмәгатьчелек белән элемтәнең яңадан-яңа формаларын эзләүдә булды. Ике Корылтай арасында гына да Татарстанның 17 районында Татар әдәбияты көннәре узды. Бу көннәрнең кайберләрендә егермешәр әдип һәм шагыйрь катнашты. 17 район үзәге һәм алтмышлап авылда, мәктәпләрдә узган ул очрашуларда халкыбызның бүгенге хәле, әдәбият, туган телебез язмышы хакында эчкерсез сөйләшүләр булды. Тормышны өйрәнү күзлегеннән генә түгел, әдәбиятны пропагандалау юлында да зур әһәмияткә ия андый бәйрәмнәр. Шундый ук очрашулар соңгы биш ел эчендә Ульяновскийда, Оренбургта, Ижевскида, Екатеринбургта, Пермьнең Барда районында, Самараның Мәләкәс һәм Камышлы районнарында, Казакъстанда, Мәскәүдә һәм Башкортостанның күп кенә районнарында булып узды.

Татарстан Язучылар берлеге идарәсе аппаратының эшләгән эше бармы соң? дигән сорау куя кайберәүләр. Ашаган белми—тураган белә, дип әйтергә кала. Ел саен илле-алтмыш юбилей яисә түгәрәк даталарны билгеләп узуның ни икәнлеген аңлаучы болай димәс. Ә инде тарихта беренче мәртәбә Мөхәммәдъяр, Кандалый юбилейларын үткәрү, Ш. Мәржани һәм Р. Фәхретдинов, Г. Исхакый һәм Ф. Кәрим юбилейлары, Г. Бәшировның 95, Ә. Еникинең 90 еллыклары, Г. Афзал, Г. Ахунов, А. Гыйләжев, Ш. Галиев, Н. Фәттах, Т. Миннуллин, Ф. Шәфигуллин юбилейлары һәм башка бик күп кичәләр республика күләм зур бәйрәмгә әверелделәр. Казанда гына түгел, бу әдипләрнең туган якларында, мәктәпләрдә, бөтен республиканы колачлап үткәрелде боларның һәммәсе. Телевидение, радио аша күрсәтелделәр, фондка язылдылар. Бу эшләрнең һәммәсен башлап йөрергә, оештырырга һәм үткәрергә дә кирәк бит әле... Атна туса—бер бәйрәм яисә юбилей туры килә. Аны кайда һәм ничек уздыру, кемнәрне чакыру, әдәби-музыкаль ягын кайгырту, соңыннан ул кичәләрдә катнашучыларга булмаган акчаны табып түләү—жиңел эш түгел. Һәм, нигездә, бу мәшәкатьләр аппаратта эшләгән жиде-сигез кеше һәм идарә рәисе жилкәсенә төшә.

—Ул юбилейны нигә үткәрәсез?—ди, кайберәүләр.

—Алар әдәбиятны, язучының иҗатын һәм, соң чиктә, туган телебезне пропагандалау чарасы.

—Талымлырак булырга кирәк,—диләр.

—Талымнарга иде дә бит, мөмкинме? Кайсыбызның үз иҗат бәйрәменнән баш тартканы бар? Бу бит мөмкин түгел.

—Юбилейлар бик күбәйде бит,—диләр.

—Куаныырга гына кирәк. Ул бәйрәмнәрне без үзебез генә түгел, укучыларыбыз да зарыгып көтеп ала. Кайсы гына залда үткәрсәк тә, кагыйдә буларак, халык шыгрым тулы була. Тарсынмыйк, күпсенмик, булдыра алсак.

Шулар өстенә соңгы араларда яңа китап чыгаруны билгеләү, ягъни презентацияләү дә гадәткә кереп бара. Бу да әдәбиятны, язучыны пропагандалауның заманча үтемле бер чарасы ләбаса.

Ел да бөтен республикабызны шаулатып Тукай көннәрендә шигырь бәйрәме уздырабыз. Алар соңгы елларда халыкара бәйрәмгә әверелде. Чөнки соңгы биш елда, һәр елны дип әйтерлек, Татарстан шагыйрьләре белән беррәттән ул бәйрәмнәрдә Төркия, Үзбәкстан, Кырым, Мәскәү, Башкортостан, Чувашстан шагыйрьләре дә бик теләп катнашты һәм чыгыш ясады.

Быел да бәйрәмдә катнашкан рус шагыйрәсе Людмила Щипахина Мәскәүгә кайткач болай дип язып чыкты: «Элгәреге Советлар берлегендә искиткеч матур, традициягә кергән шигъри бәйрәмнәр бар иде. Боларның күбесе инде онытылды. Базар оныттырды диләр. Ә мин Татарстанда Тукай туган көнгә багышланган ел да үткәрелгән бәйрәмдә булып кайткач, Татарстанны сагынып әле дә төшләр күрәм. Бәйрәм онытылмаган. Тукай һәйкәле каршындагы зур мәйданны тутырган халык диңгезен күргәч минем күзләремә яшьләр килде. Ике сәгать дәвамына басып тыңлады һәм алкышладылар үзебезне. Әнә ничек була ала икән. Мин Татарстанны сагынып төшләр күрәм...»

Тукай көннәрендә Татарстанда йөреп кайткач танылган төрек шагыйре Айхан Инал Стамбулда сәяхәтнамә китап чыгарды. Ә Диләвер Җәбәҗи зур тиражлы «Тарих» журналының рәттән 4 санында Татарстанны һәм татар әдәбиятын күләмле истәлекләре белән олылады һәм «Татар кызы—Гүзәл» атлы шигырьләр циклы бастырды.

Соңгы биш елда без Тукай һәм Җәлил көннәрен уздыру белән генә чикләнмичә, Г. Исхакый, Р. Фәхретдинов һәм Ф. Кәримнәрне дә ел саен диярлек теге яисә бу формада олылап искә ала башладык. Риза Фәхретдинов мирасын пропагандалауга Әлмәт хакимияте һәм Татарстан Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеге зур игътибар бирә.

Язучылар берлеге идарәсе инициативасы белән Гаяз Исхакый, Абдулла Алиш һәм Фатих Хөсни исемендәге махсус әдәби премияләр булдыру да байлыктан түгел, әдәби мирасыбызны пропагандалау һәм стимуллаштыру максатыннан чыгып башкарыла. Якын көннәрдә әдәби тәнкыйтебезне җанландыру максатыннан Җамал Вәлиди исемендәге бүләк булдыру уебыз да бар.

Халыкара «Мирас» фонды инициативасы белән Кол Гали исемендәге премия һәм шулай ук Фатих Кәрим, Шәйхи Маннур, Сөббух Рафыйков, Рафаэль Төхвәтуллин исемендәге бүләкләр—болар һәммәсе татар әдәбияты урамындагы олы хәрәкәт хакында сөйли торган вакыйгалар. Болар һәммәсе изге теләктән башкарылган эшләр.

Ул премияләрне санап китү генә җиңел. Әмма алар өчен дәүләт бюджетыннан бер тиен дә акча бүлеп бирелми. Һәркайсы өчен эзләнергә, юк мөмкинлекләрне бар итеп сорарга һәм табарга туры килә. Җиңел эш түгел бу. Бигрәк тә соңгы көннәрдә...

Әмма үткәндәге әдәби мираска мөнәсәбәттә уйландыра торган мәсьәләләр дә аз түгел. Мәсәлән, без әүвәлге елларда мирасыбызга мөнәсәбәтнең шактый чикләнгән булуыннан зарлана идек. Инде чикләүләр юк, һәммәсе дә кайтты—үзебезнеке. Кол Гали һәм «Идегәй» дә кайтты. Г. Исхакый, Р. Фәхретдинов һәм Дәрдмәнд тә. Әмма бу бай мирас әдәбиятыбыз һәм халкыбыз үзаңының аерылмас өлеше булып актив яши башладымы? Укучыларыбыз, мәгариф һәм театрларыбызның ул бетмәс-төкәнмәс бай мираска мөнәсәбәте үзгәрдеме? Кызганыч, алга китеш бик күренми, акрын бара әлегә. Уйланырга урын бар безгә...

Соңгы елларда язучылар сәяси вакыйгаларга мөнәсәбәттә дә зур активлык күрсәттеләр. Мәгълүм булганча, Татарстанның мөстәкыйльлеге өчен көрәш идеясы, татар теленең дәүләт статусы һәм латин әлифбасы хакындагы сүзләр иң элек без—язучылар авызыннан чыкты. Шуннан соң аларны сәясәтчеләребез күтәреп алды.

Хәтерегездәдер, шул бәйсезлек өчен көрәш дәверендә чираттан тыш Корылтайга җыелып без үзебезнең иҗат берлеген суверенлы дип игълан иттек. Без бүген дә Россия Язучылар берлегеннән аерым иҗат оешмасы булып яшибез, халыкара Язучылар берлегенә һәм төрки әдәбиятлар берлегенә мөстәкыйль оешма буларак кердек. Татарстан Язучылар берлеге Россия Язучылар берлеге белән дә иҗади хезмәттәшлек турында килешүгә кул куйды. Төрек һәм Кытай әдәбиятлары белән дә үзара мөнәсәбәтләребез рәсмиләштерелде. Халыкара Әдәби фондның чираттагы Конгрессы Казанда узу һәм Татарстан Язучылар берлеге каршындагы Әдәби фондның аны нигезләүче оешма буларак керүе шулай ук игътибарга лаеклы факт. Элемтәләребез җитәрлек. Акчаң була икән, бүген бөтен дөнья әдәбиятлары белән аралашырга, дуслашырга мөмкин. Әмма халкың очын-очка ялгый алмый изаланган, әби-бабайларыбыз пенсияләрен, хезмәт кешесе эш хакын вакытында алмаган бер дәвердә урынлы-урынсызга дәүләттән акча сорау да әхлакый күзлектән бик килешә торган нәрсә түгел. Бу унайдан без болай да зарланырга тиешле түгел. Россиядә һәм СНГ илләрендә Татарстан, Башкортостан һәм Әзәрбәйҗан Язучылар берлекләреннән башка һичбер оешма бүген дәүләттән ярдәм алмый, яр буена чыгарып атылган балык сыман, һәркайсы үзалларына чәбәләнә. Республика җитәкчелегенә рәхмәт, әлбәттә. Әүвәл заманнарда акча Мәскәүдән килә иде һәм Әдәби фондтан. Шуна йортлар төзи идек, иҗат йортларына йөри, матди ярдәм күрсәтә идек. Боларның берсе дә юк хәзер. Мәскәү үз Корылтайларына чакырганда да «масрафлар сезнең тарафтан» дип искәртергә ярата. Хәтта Әдәби институтта уку өчен дә акча түләү кирәк бүген. Хакыйкать шундый. Ә безнең кайбер каләмдәшләр, табигый ки, моны аңларга, моның белән килешергә теләми. Һәм шуна, урынлы да, урынсыз да, Язучылар берлеге җитәкчелегенә үпкә, дәгъва һәм ачу барлыкка килә. Ә инде Союз эшеннән гел читтә торып, ягъни Союзга арка белән торып, аны берөзлексез тәнкыйтьләргә үрсәләнүчеләр турында әйтеп тә торасы юк. Көнчелек һәм хөсетлектән дә арына алмый кайберәүләр. Үзләренә алганда, кирәктә генә искә төшерә алар иҗат берлеген.

Идарә рәисе һәм идарә әгъзаларыннан канәгать булмыйча көн-төн матбугатта сүз куертучыларга да гаҗәпләнергә ярамый. Бер эш майтармыйча сүз сөйләнеп йөрүчеләр алар элек-электән булган, бар һәм булачак та. К. Нәҗми дә ярамаган андыйларга, Г. Бәширов та, М. Әмир дә, М. Җәлил дә ярамаган. Ибраһим Газины, Зәки Нурины да көн-төн таладылар. Г. Ахунов һәм Т. Миңнуллин да ярап бетмәде һәммә кешегә. Бер Мөхәммәдиев кына әүлия була алмас... Әмма, ни генә булмасын, Татарстан Язучылар берлегенең үзәген чикләвек төшедәй таза һәм фидакарь милләтпәрвәрләр тәшкил итә.

Дөресен әйтим, мин бүгенге докладта Пенклубны искә алырга җыенмаган идем. Чөнки бу оешманы Татарстан Язучыларының Корылтае да, идарәсе дә нигезләмәде. Ләкин шушы көннәрдә генә газета аша игълан ителгән рәсми «Белдерү»гә игътибарсыз узсам сез мине аңламассыз. Республикада үткәрелә торган күпсанлы әдәби вакыйгалардан да алар, нигездә, принципиаль рәвештә читләшеп килә. Ул гынамы, Пенклубның аерым әгъзалары беренче көннән үк Язучылар берлеге идарәсе һәм аның рәисенә оппозициядә торып, даими рәвештә матбугатта канәгатьсезлекләрен белдереп киләләр. Ике сүзнең берендә Язучылар берлегенең Советлар тарафыннан оештырылуын, үз заманында коммунистик идеологиягә хезмәт итүен касыкка тәрткәндәй тәкрарлап торалар. Әлеге «Белдерү»ләрендә дә Пенклуб теоретиклары шул хакыйкатьне чираттагы мәртәбә гаепкә бәгәргә кирәк тапканнар. Әйе, Язучылар берлеге Совет хөкүмәте чорында төзелгән. Әмма татар халкы, татар әдәбияты Язучылар берлегеннән зыян күрмәде кебек. Алайга киткәч, Пенклубны кемнәр нигезләгән дә, сез үзегез кемнәр соң? дип сорыйсы килә килүен, әмма дошмәвең—мең алтын. Хәер, Пен-үзәкнең башкаручы директоры Ә. Мушинский «Мәдәни җомга» газетасында бу сорауга үзе үк җавап та бирә: «Беренчедән, теләгән һәр кеше, әйтик, безнең таләпләргә

туры килми. Югарырак штиль белән әйткәндә, бар кеше дә әдәби-ижади, демократик һәм әхлакый... цензларга җавап бирми». Әйе, бу—әлеге дә баягы, 90 еллар башында, без суверенлык өчен җан атып йөргән дәвердә Матбугат йорты каршындагы мәйданга «Журнал «Идел»—рассадник национализма» дип урамга лозунг күтәреп чыккан Әхәт Мушинский. Әнә ничек! Үзләрен зур талант иясе санаган демократ каләмдәшләр (Ә. Мушинский, Г. Моратов, Т. Бариев, В. Юныс һ. б.) ил таныган татар әдипләрен «штиль һәм ценз» дигән әллә ниткән борынгы татар сүзләре табып рәнҗетербез дип уйлап та карамыйлар. Ул гынамы, телевидение тапшыруында (10.05.99) үзен хокук сакчылары (Пенклуб—нәкъ шул максаттан төзелгән оешма) лидеры санаган Разил Вәлиев Пенклубта булмаган язучыларны «Сарык көтүе, Дуңгыз көтүенә» тиңләп ишарә ясаудан да тайчынмады.

Пенклубның Белдерү һәм Мөрәҗәгатьләрен укыгач шундый фикер туа—әллә алар үзләрен әдәбият барышында Политбюро итеп күрәселәре киләме?! Юбилейлар, әдәбият көннәре, төрле бәйрәмнәр уздырганда, язучыларны соңгы юлга озатканда ни өчендер Пенклуб активлык күрсәтми? Быел Тукай туган көнне һәйкәленә һәм каберенә зур төркем язучылар һәм республика җәмәгатьчелеге чәчәкләр куйганда, Пенклубтан кем килде икән?! Ә өйрәтү, һәм күрсәтмәләр бирергә көннән-көн остара баралар. Игътибар иткәнсездер, ике Съезд арасында башкарылган эшкә дә беренче булып алар нәтиҗә ясап, Татарстанда нәшер ителгән һәммә газеталарда да бәя куеп чыктылар инде. Юк, җәмәгать, ашыкмагыз, без иң әүвәл Съезд фикерен тыңлыйк, берөзлексез фидакарьләрчә халыкка хезмәт иткән, хәл кадәри эшләгән, иҗат иткән тыйнак һәм аз сүзле каләмдәшләребезне дә тыңлап карыйк.

Аннан бит әле милләт һәм туган телебез сагында торган язучыларның кирәксә-кирәкмәсә бертуктаусыз «яшерен тавыш... ачык тавыш...» дип бөтен Республика каршында тарткалашуы да килешеп бетә торган нәрсә түгел. Игътибар иткәнсездер, ул мәкаләләрнең берсенә дә җавап бирелмәде. Әйтер сүз булмаганнан түгел, татар теле һәм татар китабы язмышы өчен ут йотып яшәгән көннәрдә халык каршысында татар язучыларының дәрәҗәсенә тап төшерүдән куркып дәшмәдек.

Татарстан Язучылар берлегенә һичкемне мәҗбүр итеп алмадылар, анда һичкемне мәҗбүр итеп тотмыйлар. Кирәксә-кирәкмәсә матбугат битләрендә «Союз кирәкме-түгелме? Ул—язучылар колхозы. Совет иленең калдыгы...» дип, сафсата сатучыларга башкача җавап табу мөмкин түгел.

Татарстан Язучылар берлеге—ул безнең мәсләк берлегебез. Халыкка хезмәт, әдәбиятыбызны үстерү һәм туган телебезне саклау мәсләгебез берлеге.

Язучы өчен, татар язучысы өчен болардан да изге һәм игелекле бурыч булырга мөмкинме?! Шуңа күрә дә мин бу Корылтайда, һәркайсыбызда да булган шәхси үпкә һәм канәгатьсезлекләр, мин-минлекләребезне онытып торып, әдәбиятыбыз һәм туган телебез, татар язучысы һәм татар китабының бүгенге аяныч хәле, аларны саклап-яклап калу юллары хакында җитди һәм конструктив фикер алышуга чакырам.

Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

---

## ЯҢА ИДАРӘ САЙЛАНДЫ

23 июльдә корылтай үзенең эшен дәвам иттерде. Язучылар берлегенең яңа рәисе итеп әдәби тәнкыйтьче, филология фәннәре докторы **Фоат Галимуллин** сайланды. Идарәгә язучылар **Харрас Әюп, Мансур Вәлиев, Мөдәррис Вәлиев, Разил Вәлиев, Разим Вәлиуллин, Әхмәт Гадел, Марсель Галиев, Галимҗан Гыйльманов, Җәүдәт Дәрзаман, Вахит Имамов, Рәфкать Кәрами, Владимир Корчагин, Ләбиб Лерон, Зиннур Мансуров, Газинур Морат, Шаһинур Мостафин, Рашат Низами, Гәрәй Рәхим, Равил Рахмани, Данил Салихов, Нәҗибә Сафина, Равил Фәйзуллин, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Айдар Хәлим, Солтан Шәмси, Фәрит Яхин** үтте.

Корылтай шулай ук Татарстан Язучылар берлегенең яңа Уставын кабул итте.

# ОЛУГ ИСЕМ ИЯЛӘРЕ

Әдәбият үсешенә аеруча зур өлеш керткән әдипләргә «Татарстанның халык язучысы», «Татарстанның халык шагыйре» исемнәрен бирү 1985 елның 9 сентябрендә ТАССР Верховный Советы Президиумы Указы карары белән билгеләнде. 1990 елның 30 августында Дәүләт Суверенитеты турында мәгълүм Декларация кабул ителгәч, Республикабыз атамасы да үзгәрешләр кичерде. Әлеге мактаулы исем дә—берәүләргә ТАССР Верховный Советы Президиумы исеменнән, берәүләргә ТССР Югары Советы исеменнән, берәүләргә, Президент идарәсе барлыкка килгәч, Президент Указы белән бирелде. Һәрхәлдә бу югары исем Татарстан Республикасы җитәкчелеге тарафыннан әдәбиятыбызны үстерүдә олы казанышларга ирешкән иң лаеклы әдипләргә бирелә. 1986 елдан бүгенге көнгә бу мактаулы исемгә ия әдипләрнең исемлеген тәкъдим итәбез.

## Халык язучылары

1986 ел

**Бәширов Гомәр Бәшир улы** (1901-1999).
**Исәнбәт Нәкый Сиражи улы** (1899-1992).

1989 ел

**Еникеев Әмирхан Нигъмәтҗан улы**—Әмирхан Еники (1909).

1993 ел

**Хөснетдинов Фатих Хөснетдин улы**—Фатих Хөсни (1908-1996).
**Ахунов Гарифҗан Ахунҗан улы**—Гариф Ахунов (1925).
**Гыйләҗев Аяз Мирсәет улы** (1928).
**Мәһдиев Мөхәммәт Сөнгать улы** (1930-1995).

1998 ел

**Фәттахов Нурихан Садрилман улы**—Нурихан Фәттах (1928).

## Халык шагыйрьләре

1986 ел

**Хәкимов Сибгат Таҗи улы**—Сибгат Хәким (1911-1986).

1991 ел

**Афзалов Гамил Гыймазетдин улы**—Гамил Афзал (1921).

1993 ел

**Юзеев Илдар Гафур улы** (1933).

1995 ел

**Идиятуллин Шәүкәт Гали улы**—Шәүкәт Гали (1928).

1999 ел

**Фәйзуллин Равил Габдрахман улы** (1943).



**Миргазиян Юныс**

# АЛЬБАТРОС ЯЗМЫШЫ

НИЧӘ ЕЛ йөртәм икән мин бу шигырьне йөрәгемдә? Күптән инде, күптән. Шигырьнең исеме «Кичке кошлар», ә мин аны нигәдер үзгәрткәнмен, «Төнге кошлар» дип атаганмын. Ниһаять, аңладым:

Яңгырлы кичләрдә, эңгер төшкәндә,
күмәк кошлар төркемедәй,
әнә шулай
кайталар минем уйларым...

Ә минем уйларым төн урталарында, таң алдыннан кайталар. Шуңа күрә, «кичке» сүзен мин «төнге» сүзенә үзгәрткәнмен. «Үзгәрткәнмен» дә түгел әле ул, ихтыярсыз, минем белән исәпләшеп тормыйча, кайдадыр аңымның базында, күңелемнең караңгы бер почмагында үзеннән-үзе, уйланулар җаена карап үзгәреп куйган.

«Кичке кошлар»—Роберт Әхмәтҗановның шигыре. Ул минем күңелемә кереп оялаган, яши дә яши—суырып та, кисеп тә алып булмый аны, һәм минем белән китәчәк... Китәчәк һәм, ышанасым килә, югалмаячак, чөнки бер миндә генә яшәми торгандыр бит инде бу дәрәҗәдәге шигырь? Киләчәк буын вәкилләренә дә кереп кунакласа иде «... эңгер төшкәндә күмәк кошлар төркемедәй» кайтучы уйлар. Безне никадәр биздерергә тырышсалар да, нинди генә чаралар күреп, әллә нинди ысуллар белән уйланулардан, фикер йөртүләрдән тыярга тырышсалар да, бөтенебезне дә манкортлаштыра алмадылар. Һәм алмаячаклар да. Шушы хәл өметләндерә мине «Кичке кошлар»ның гомере озын булачагына:

Эңгер төшкәндә,
кичке шәфәкъ балкышында
күмәкләшеп, тезелеп,
кайта башлый кичке кошлар төркеме;
кайталар, кайталар...

Нәрсә турында соң бу? Аңлатыгыз әле... Гади көнкүреш

сүзләре әдәбият фәненең еш, урынсыз хәрәмзәле кулланудан җанын югалткан терминнары белән генә аңлатып буламы шигырьне? Ярты гасыр аңларга тырышам: әдәбият белеме белән әдәбият үзе бер-берсенә якынлаша алмыйча, янәшә баралар. Ә инде шигърият... Чәчмә сүзнең көче бетеп туктап калганнан соң башлана шигырь. Чын шигырьдәге сүз тылсымы каян барлыкка килә? Шигъриятнең кануннарын дөрес кулланып, оста, төгәл, гаҗәеп матур сүзләр белән язылган шигырь. Укыйсың. Дулкынландырмый. Син битараф. Сүз көченең илаһилыгын, аның шифалы тәэсирен аңлап та, аңлатып та булмый томана бәндәгә. Ә шагыйрьнең (чын шагыйрь турында бара сүз) үзен аңлап буламы соң? Нәкъ шуңа күрә дә без аларга тизрәк тамга сугарга, түшләренә бәләкәйне зурайтып, зурны бәләкәйләтеп күрсәтә торган калай тагарга ашыгабыз. Такмакчыны берничек тә шагыйрь итеп булмый. Шигырь дәрәҗәсенә ирешә алмаган такмакны да, нилләр генә эшләмә, барыбер коткарып булмый. Юк, ялгышам икән... Безне наданлык, тоташ зәвыксызлык коткара. Көндәлек ыгы-зыгыгыздан арынып, фани дөнья мәшәкатьләренә кул селтәп, тыңлагыз әле:

Шундый кичләрдә,
һич югында,
туа җанда шундый сораулар:
кайда куна икән соң алар?
һәрберсенең үз оясы бармы?
һәркайсының үз талы?
Төнне кайда үткәрәләр тукталып?

Югыйсә, сүз кошлар турында бара шикелле? Кошлар турында гынамы? Газиз балаңны армиягә йолкып алып киттеләр. Дедовщина оясына. Бердәнбер кызың колхоздагы акчасызлыкка, авылны инде каплап китә язган сәрхүшлеккә гыйсъян йөзеннән шәһәргә бәхет эзләп китте ди... Нинди сораулар тырный башлый бәгырегезне? Нигә сыкрый, нигә сызлый сезнең күкрәк эчендәге иң сизгер, иң нәүчәләк урын?

Адәм баласы яшәр өчен дөньяга килә. Бәхетле булыр өчен. Дөнья көтәр өчен. Буыннарны буыннарга, ата-бабаны балаларга-оныкларга тоташтырып, милләтнең мәңгелеген тәэмин итәр өчен. Нигә аның баласын алып китеп, Әфган тауларында үтерәләр дә мәетен әнисенә җибәрәләр. Нинди сораулар тууы мөмкин бу очракта? АКШның «демократ фашистлары» Гыйрак халкы өстенә мегатонналап бомба бушатып киттеләр. Шушы хәбәрне ишетү белән нинди сорау туа сезнең иманыгызда? Мәңгелек сорау ул әдәбият глобаль масштабта алганда. Таушалмый, көчен югалтмый торган кайнар сорау ул әдәбият. Шагыйрь Роберт Әхмәтҗанов шушындый сорауларны куя алган. Бу эшкә аның көче, җегәре җиткән. Вазифам җиңеләйде...

Көнбатыш әдипләреннән минем иң яраткан, иң нечкә тойгылы язучым Дэвид Сэлинджер. Аның «Арыш арасында упкын өстендә» әсәренең герое Һолден Колфилд—җәмгыятькә борын төртә алмыйча газапланучы нонконформист. Ул атлаган саен ялганга, күз буяуга, юхалыкка, ярашуга бәрелеп борынын канатучы—Роберт Әхмәтҗановның шигырендәге лирик геройның игезәк җан кардәше. Ул да нәкъ «Кечкә кошлар»дагы сорауларны дога урынына кабатлый: «Күл өстен боз каплаган,—ди ул ут йотып,—ә үрдәкләре? Күлнең үрдәкләре кая китте икән? Бармы икән кунаклар, кунар җирләре? Тук микән тамаклары? Атмыйлар микән аларны аучылар?» «Арыш арасында...» повесте «Кичке кошлар»дан соңрак басылып чыкты. Сэлинджер Казанга килеп, Әхмәтҗанов белән очрашып йөрмәгән. «Кичке кошлар» авторы шикеллеләрне чит илләргә йөртмиләр... Ә ничек соң Сэлинджер белән Әхмәтҗанов, үзара сүз куешкандай, лирик геройларыннан бер үк сорауны әйттерәләр? Без әдәбиятның кодрәтле тылсымына килеп җиттек. Совет чорында без милләтләрне интернационаллаштыру

турында авыз суы киптердек. Асылында аның гап-гади урыслаштыру идеясы ятса да. Ә менә ялган, гаделсезлек, ерткычлык—интернациональ категория. Гаделлеккә, игелеккә, хакыйкатькә омтылу да нәкъ шундый. Талантлары тигез. Иҗатны пәйгамбәрлек вазифасы итеп кабул иткән әдипләр, бигрәк тә аларның шигъри җанлылары, әхлакны таптауны тигез тоя. Аларның эчке омтылышлары, тойгы-кичерешләре дә бер юнәлештә була. Шуңа күрә, Америка язучысы белән татар шагыйре, үзара сүз куешмастан, геройларыннан бер үк сорауларны бирдерткәннәр. Сорау гына да түгел бу, гуманистик багланыш...

Хакимияттә генә түгел, фәндә дә шигърият белән махсус идарә итүче кеше бар икән бездә. Мин бу хакта әле күптән түгел генә белдем. Әгәр шул бәндә үзенең сөекле аспирантына Роберт Әхмәтҗановның иҗатына багышланган диссертация язарга кушса, аспирант шул язманың бер бүлеген «Роберт Әхмәтҗанов иҗатында кошлар темасы» дип атар иде. Тирәнтен тикшерә, анализлый башласаң, тема гына түгел ул аның шигъриятендәге кошлар. Кошлар гына да түгел. Роберт Әхмәтҗановның очар кошлар мәсьәләсен фәлсәфи-символик, әхлакый-психологик категория итеп күтәрергә көче җиткән. Һәм аның үзе уйлап тапкан нәрсә генә түгел бу кошлар шигърияте. Татарлар үзләренең язмышларын, яшәеш проблемаларын кошларныкына бик күптәннән, ерак гасырлардан бәйләп фикер йөртә башлаганнар. Әле минем гомеремдә генә дә татар тарала-таркала башлау белән «Һаваларда очкан кошлар кебек, ярсый-ярсый канат кагынып...» җыры иң популяр, татар халкының иң әрнүле җырына әверелде. Ә Рәсәй сугыш оештырып, халыклардан туп ите ясый башлау белән «Сак-Сок» бәетенең яңарып китүләре... «Сак-Сок» сугыштан сугышка яңарып, кабатланып тора торган бәет.

* * *

КЫЗГАНЫЧКА каршы, минем кулымда Роберт Әхмәтҗановның бары бер генә китабы—«Хәтер елгасы» гына бар. Менә мин «Хәтер елгасы»н актарып, кошлар турындагы юлларны укып барам. Тугызынчы бит: «Җилгә йотылып капшый күңел туган якның зәңгәр үрләрен. Әтәч тавышы шул ук, читән тутырып өнкәй элгән ап-ак керләрен». Унберенче бит: «Үкенгәндәй, иске ярын ташлап, күке үкси якын урманда». Унбишенче бит: «Торналар быргысы тетрәтә һаваны: «Язларын—юл башка, юл башка, юл башка. Көньякны калдырып, бу якны сагынып, моңлана торналар кәрваны». Егерме алтынчы бит: «Тыныч кына туды бу таң, уйсу җиргә томан ятты, шул таң белән канат җилпеп, оясына лачын кайтты. Очып кайтты житез лачын, балаларын сагынганга. Шатланды ул ана булып, алар канат кагынганда». Кырык бишенче бит: «Яшь тургайлар менә—яңа буын—туган ягым күгенә алмашка. Күгем тулы тургай. Яздан көзгә... Мөмкин түгел җырда янмаска». Кырык җиденче бит: «Су буенда тургай көтүләре таудан-тауга оча, таудан-тауга... Бу яңгырлы-җилле таңда ямансурак язны көтүләре». Кырык сигезенче бит: «Агач коштай син талпындың озак яңгырларда карап еракка очып киткән кошлар артыннан...» Илле икенче бит: «Кояш төшә үлән арасына, сулар менә ярга. Җилләр китә күчеп тау артына, кошлар төшә ялга...» Илле өченче бит: «Кырларымда, әни, иминлекме, агарамы борчак басулары?.. Тәрбеләдә йөргән торналарым, кайтты микән быел? Барсыдамы?» Алтмыш җиденче бит: «Тургай үрли-үрли биеклеккә менә тырпылдап... Минем кебек ул да илһамланган туып-үскән җирнең языннан». Кабат тургай. Бусы йөз дә ундүртенче биттә: «Тургай, дога укыгандай, ап-ак болыт каршысында тибрәп тора, тибрәп тора».

Роберт Әхмәтҗановның иҗатындагы кошларның барысын да саный башласаң, чыннан да, бик озакка китәр иде. Торналардан мисал китерәм дә, туктыйм. Бер йөз сиксән алтынчы бит: «... Иделем тонык. Күгем Идел төсле. Үксемәгез, һава бурлаклары. Җәем янды монда... Күзем дөрли. Көчле булып дөрли яфраклары. Уз офыкка кояш

быргычысы, биеклеккә чакыр Җир-ананы...» Янәшә биттә: «Тезелешеп күк юлында җилфердәшеп очкан чакта, таралдылар торналарым, таралдылар төрле якка... Туган җирнең алтын чыңын онытылып тыңлый сыман».

Татар әдәбияты—бүгенге көн әдәбияты турында сүз бара—гаҗәеп көчле, үзенчәлекле шагыйрьләргә бай. Шигърият өлкәсендә беренче яңа сүз, яңа сулыш өстәп булмас сыман тоела, уйлап карагандa. Әхмәтҗановның шигырьләрен укый башлау белән аңлыйсың: шигърият дөньясының чиге дә, чикләнгән чамасы да юк булса кирәк. «Хәтер елгасы»ндагы метафораларның үзенчәлеге, алардагы сыйфат, андагы сүз музыкасы, моң, тылсым, мистика—нәрсә генә тапмыйсың бу китапта. Һәм шунысы хәйран калдыра, шагыйрь чынбарлыктан бер генә микронга да читкә тайпылмыйча тудыра шушы шигъри хәзинәләрне. «Торналар оча» поэмасындагы метафораларга күз ташлап алыгыз: «...ава бурлаклары»—телисеңме-юкмы, Илья Репинның «Бурлаклар Иделдә» исемле картинасы күз алдына килеп баса. Һәм бурлак язмышы. Бурлакның Рәсәй чынбарлыгында гына, бары тик шунда гына барлыкка килә алганлыгы тамакка төер булып утыра. Китте уйланулар... «Кояш быргычысы»—менә кайда ул светомузыка. Ә бит чыннан да, төсле музыканы Казанда уйлап табалар. «Туган җирнең алтын чыңы» һәм шушы метафораны дәлилләп, автор: «Җирдә—әбиләр чуагы, без бу җәйдә бары кунак...», «Торна тавышы кагылса да, яфрак коя алтын куак...», торналар тавышы күзгә килеп тоташты һәм бер җөмлә белән, бары тик кыска бер җөмлә ел фасылларының иң күркәм өлеше—көзнең бөтен палитрасын сурәтләп тә куйды.

Мин—педагог түгел. Белмим, юктыр миндә остазлык сәләте. Шуңа карамастан, Әхмәтҗановның шигырьләрен укыганда, эчләремне ачыттырып, әдәбият укытасым килеп китте. Тыңлагыз әле: «Хушлаша җәй, ак яулыклар болгап, агыла болытлары... Хушлаша җир, яфракларын җилпеп, шаулаша юкәләр». Күрдегезме? Бер селтәнүдә шагыйрь җәйнең күзгә әверелүен сурәтләде дә куйды. Нинди динамика! Болытлар. Юкәләр шаулашуы. Калган детальләр күңелдә генә һәм җәйнең күзгә алышынган вакытындагы йөзләгән, хәтта меңләгән нюанслары кердә дә бетте шушы сурәтләргә. Һәм шунысы хәйран калдыра, һәр шагыйрьнең үзенчәлекле сурәтләү ысулы була. Берәүләр төс белән рәссамнарча эш итәләр, икенчеләре—сүзнең музыкасын эшкә җигәләр, өченчеләре хиссә басым ясыйлар. Робертның шигырьләрендә шушы ысулларның барысы да бергә укмашкан. Тагын бер могҗиза: «Таралдылар торналарым, таралдылар төрле якка», корылыктан карлыккан каргалар оча баш очыннан». Төрки телләрдәге бер бөек, кабатланмас нәфис сыйфат барлыгы турында аңлатып торасы юктыр дип уйлыйм. Сингармонизм дип атала бу сыйфат фәндә. «Хәтер елгасы»ның авторы сингармонизмны куллану белән генә чикләнеп калмыйча, шушы илаһи яңгырашка тартык авазлар хоры—аллитерация көчен китереп куша. Һәм нәтиҗәдә... юк, аңлатып торуның кирәге дә юк, мисал итеп китерелгән юлларны кычкырып кабатлап карау да җитә нәтиҗәне исбатлау өчен.

Мин бит инде җыентыктагы кошларга кагылышлы мисалларны китерүдән туктарга сүз биргән идем. Гафу ит, кадерле укучым! Тыела алмыйм. Ике йөз бишенче бит: «Ак канатлы күңел кошларымны озаттым мин сиңа...» Битнең икенче ягында: «Акчарлаклар шомлы давылда да ташламый диңгезен». Һәм янәшәдәге биттә: «Бытбылдык такмаклый яшел тау артында яшьлекнең үзе күк кыска җәй хакында». Әгәр тургай «турр-турр, колоротур сопрано», яисә «Тургай, дога укыгандай, ап-ак болыт каршысында тибрәп тора, тибрәп тора» булып яңгыраса, торна тавышы «туган җирнең алтын чыңы» булып таралса, бытбылдык бары тик такмаклый гына ала. Телисеңме-юкмы, татар әдәбиятында соңгы елларда пәйдә булган бер гаҗәеп феномен—юбилей бытбылдыклары искә төшә. Әдәбиятыбызда тәнкыйть бетте. Юбилей бытбылдыклары аңлый башладылар: нахак тәнкыйтьнең ясалма мактаудан йөз тапкыр көчлерәк, мең мәртәбә нәтиҗәлерәк икәнлеген.

Бытбылдыклар мактыйлар бер-берсен күкләргә чөеп. Нәтиҗә—бер. Алар теләнә әләккән шәхеснең, кем генә булуына карамастан, хәтта зур ихтирамга лаеклыларына да, ышанмый башлыйсың. Чөнки юбилей бытбылдыкларының такмаклаулары җансыз, шаблон такмаклау...

Роберт Әхмәтҗановның иҗатындагы кошлар тематикасының (махсус шаблонлаштырып әйттем) ачкычы, бәлки, менә шушы шигырьдәдер (сиксән өченче бит): «Бу ояда сиңа да канат чыгар тиздән. Ничек сине сакларга, тидермичә ятлардан? Китәсең кереп күк асларына,— тере нокта. Ничек сине сакларга шушы олы дөньяда? Син—бөҗәк түгел, керергә яфрак астына, син балык түгел, посарга дулкын арасына, син—киек түгел, күмелергә урманнарга. Син—кояш астында. Заманага—туры. Ничек сакларга җырлы йөрәгеңне кыраулардан, нәни кешем?» Ниһаять, аңладык, бусы кош шикелле итеп сурәтләнгән адәм баласы икән ләбаса. Ә тегеләре—кош итеп сурәтләнгән кешеләр турында булуын. Кем белгән, бәлки иҗат белән канатланып яшәгән шәхесләрне шагыйрь кош сурәтендә бирә торгандыр? Яисә хакыйкать канатына ышанып, камикадзе хәлендә, ялганга, глобаль хәрәмзәгә, җәберегә, талауга каршы баш күтәргән потенциаль корбаннарны кошка тиңли торгандыр? Кош—шагыйрь Әхмәтҗановның иҗатында тоташ символ, шигъриятенең доминанты. Минем гипотезамны шагыйрь үзе менә ничек дәлилли: «Җирдә һәрни оча. Оча язгы күбәләк... Оча башаклар... Оча бала төштә... оча юллар... Оча күңел сөю килгән юлдан. Оча төтен, ак болытлар, корым... Оча мәңгелеккә, йолдызларга—җырың».

* * *

«ХӘТЕР ЕЛГАСЫ» авторының кошлар дөньясына мөрәҗәгать итүе, минемчә, очраклы хәл түгел. Чын-чыннан күзәтүчәнлекнең иң югары ноктасына ирешкән шагыйрь генә аңлый булса кирәк кошларның безгә, бигрәк тә татарларга, үрнәк, акыл бирерлек җан ияләре икәнлеген. Әхмәтҗанов махсус орнитология фәне белән шөгыльләнмәгәндер. Кошларның яшәешләрен аңлар өчен бик күп белергә, көндәлек тормыштан читтә яшәгән өлкәләргә кереп китәргә туры килә. Кошларның күзен җылы якка, язын кире туган якларына кайтып йөрүләре татарның гасырлар буе бөхет эзләп йөрүен хәтерләтмимени? Башка җан ияләре үзләрен ерткычлардан саклап калу өчен бөтенләй башка юлны эзләгәннәр. Берәүләр ерткыч җанварга (әйтик, агрессорга, колонизаторларга) каршы торырлык теш-тырнак белән коралланган. Икенчеләр йөгереп качу өмәлен үстергәннәр. Өченчеләр поса, яшеренә белүне алга куйганнар. Җан ияләре арасында сасы ис чыгарып котыла белүчеләргә кадәр бар. Бары тик кошлар, Роберт Әхмәтҗанов иҗатының геройлары гына, бөтенләй башка юлны—иреккә ябышып котылуны сайлаганнар. Бу бит иң авыр, иң катлаулы юл. Һәм иң дөрес, иң ышанычлы юл да. Ерткычлар, аяусызлар дөньясын бөтенләйгә ташлап китү. Биеккә, йолдызлар һәм фәрештәләр яши торган түбәкләргә (ареалга) күтәрелү. Үрнәк түгелмени бу татарларга?

Тозакка эләккән кошның күзенә караганыгыз бармы сезнең? Үзенең ирегеп тартып алган, язмышын ерткычларча буып торткан бәндәнең күзенә шундый ачы, тетрәндергеч нәфрәт белән карый галиҗәнап кош... Үземне мин куркаклардан санамыйм (батыр дип тә уйламыйм), ләкин минем кош тотарга көчем җитми, рухи көчем, билгеле. Түгел генә хәтеремдә калмаган, кошларның йөрәкләре кешенекеннән ике тапкыргамы тизрәк тибә. Аларның каннары да безнекеннән кайнаррак. Ә инде кошларның чагыштырма көчләренә килгәндә... Әйтик, җирдә атлап йөрү өчен безгә түгәл бер берәмлек кирәк булса, кошларга гәүдәләрен өскә, биеклеккә күтәрү өчен, аска төшермичә һавада тоту өчен дистәләгән көч берәмлеге кирәк була икән. Ә инде ерактан күрү, ишетү сәләте буенча кошлар белән җир йөзендәге бер генә җан иясе дә ярыша алмый. Очу тизлеген

йөгерү, чабу тизлеге белән чагыштырып торасы да юк. Ә менә җырлау (сайрау) сәләтенә, аның мөмкинлекләренә килгәндә... Былбыл сайравы. Торналар тавышының офыктан офыкка таралган саубуллашу матәме. Күке тавышы. Мәче башлы ябалакның төннәрен бәгырьләреңне туңдырырлык дәрәҗәдә елаган тавышлары. Бу өлкәдә дә кошларга тиң җан ияләре җир йөзендә юк диярлек. Һәм шагыйрь Роберт Әхмәтҗанов силлогизм җепләренә тотынып, логика (логика мантыйкка тәңгәл түгел) белән коралланып, кошларга багышланган (асылда алар кошларга түгел, безнең рухиятыбызга багышланганнар) шигырьләрен язар алдыннан шушы мәсьәләләрне тикшереп, анализлап чыкмаган. Шагыйрьнең төп, ышанычлы коралы белү түгел—тоемлау. Һәм шигъри тоемлау көнкүреш тоемлавыннан күпкә катлаулырак, тирәнгәрәк, ераккарак омтыла алган илаһи бер көч. Ул безнең бабаларыбыз «күрәзә», «кам» дип атап йөрткән жрецлык, сивиллалык сәләте. Бу мәсьәләне мин менә нинди максат белән кузгаттым. «Кечкенә кошлар»ның һәм, гомумән, Роберт Әхмәтҗанов иҗатының кошлар дөньясы белән даими элемтәдә хәрәкәт итүе татарда суверенитет көрәше алдыннан иреккә омтылу хисләренең уяна башлавы белән бәйле. Башка кайсы символ ирекне шул кадәр колачлы, тирән, тәэсирле икърар итә ала? Һәм очар кошларның ирек символы булуы һәр тарафтан ышанычлы рәвештә, фәнни дәлилләнгән.

Җир йөзендәге җәберден, көчленең көчсезләрне рәнҗетеп кенә түгел, даими рәвештә юкка чыгарып торуыннан котылырга омтылу миллион еллар дәвамында беркайчан да тукталып тормаган булса кирәк. Әнә, соңгы елларда вак милләтләрнең мөстәкыйльлеккә омтылулары нинди хәлгә җитеп көчәйде. Татарстанның мөстәкыйльлеге турында сүз чыгу белән, «татарстанский модель» сүзен китереп кыстыралар. Искиткеч иблис, икейөзле сүз. «Модель»ны татарлар бер төрле, урыслар бөтенләй икенче төрле аңлау белән генә чикләнми әле бу аңлатма. Аны төрле урында төрлечә, бөтенләй капма-каршы максатларда куллана башладылар. Азатлык, ирек турында сүз чыкканда, мин «кошлар моделе» дигән термин куллануны тәкъдим итәр идем. Ни өчен?

Җирдәге көчлеләр золымына, ерткычлыкка каршы көрәштә башка барлык җан ияләре җайлашу юлын (нәкъ безнең «татарстан моделе»н) сайлаганнар һәм даими рәвештә җәберләнеп, юкка чыгу куркынычы астында яшиләр. Кошлар исә бөтенләй башка модельне (чечен моделе дисәк, бераз примитив яңгырар иде) сайлаганнар һәм аларга ерткычларның буе җитми. Дөрес, ерткычлар мохитыннан (ареалыннан) бөтенләйгә аерылу-арыну өчен искиткеч зур корбан бирергә туры килгәндер кошларга. Чыннан да бит, җирне ташлап китеп һавада яшәр өчен нинди фантастик күләмдәге җегәрләр кирәк булган. Хәрәкәт өчен түгелгән көч, күрү, ишетү сәләтләре, йөрәк тибүенә кадәр көчәйтү. Билгеле, очу бәхетенә ирешә, шушы авырлыкларны күтәрә алмаганнарның күпмесе юкка чыккан эволюция дәвамында. Чыннан да, кешелек дөньясы тарихында ирекне китереп кулыңа тоттырулары турында бернинди мәгълүмат юк. Ирек һәр очракта кан түгүләр, корбаннар биреп, фидакярлек аша гына яуланып киленгән. Кошлар үрнәге моңа иң ышанычлы дәлилнең берсе.

«Кечкенә кошлар»да иреклелекнең юридик, дөньяви ягы турында гына сүз бармый. Шигырьдә азатлыкка ирешүнең халәте, ансыз ирекле фикер йөртергә, үз акылың, үз иманың белән яшәү мөмкинлеге булмаганлыгы турында бар. Бу проблема «Кечкенә кошлар»да чын-чыннан умыртка сөяге булып тора.

Кечкенә кошлар төркемедей
әйләнәләр минем сорауларым.
Кечәләр тагын
кыен вакыт сынауларын...

Мең яшәп тә чигенә чыгалмаслык

бу дөньяга
күп очырдым бугай мин аларны...
Табарлармы кыйблаларын?..

«Кичке кошлар»ның финалын дикъкать белән укып карыйк әле:

Яңгырларда кичке кошлар кайта,
кичке кошлар—
бу тормышка сабый чактан
җыелган сорауларым...

Газаплы сорауларга җавап эзләмичә яшәп буламы икән бу дөньяда? Кызганыч ки, аларның күбесе мәңгегә җавапсыз кала. Без бу дөньяга нинди максат белән килгәнбез? Яшәешнең төп бурычы нидән гыйбарәт? Кешелек дөньясының иң даһи фикер ияләре шушы сорауларга гасырлар буе җавап эзли. Җавап юк. Бәлки мондый сорауларга җавап табу мөмкин дә түгелдер? Адәм баласы—ялгыз. Һәркем үз бәхетенә омтыла. Адәм баласы соңгы чиккә кадәр бер-берсен аңлый да алмый. Ә омтылышлар уртак—бәхетле буласы килә. Кеше бәхете сиңа ярамаса да... Бәлки шул, мәңге табылмас сорауларга җавап эзләп яшәүчеләр генә Кеше дип аталган бөек исемгә лаеклыдыр?

* * *

ШИГЫРЬ СҮЗЕ—Коръән сүзенә якын. Бәлки шигырь сүзе, борынгы җырлар шикелле, адәм балаларының тойгыларын уртаклаштыра алалардыр? Һәркемнең йөрәгендә шигъриятькә сусау яши дип әйтеп булмый. Зур шагыйрьнең шигырьләрендә җан әрнүләргә дәва яши. Ә эзләүчеләр калдымы әле бездә?

Мин үзем күп еллар көзге карлы яңгырларда, диңгездәге давылларда кошларның геройларча һәлак булуларына җавап эзләдем. Шундый куркыныч, хәтәрле юлга нигә чыгарга? Нигә шулай ашкынырга, ашыгырга? Давыл басылганын яр буенда көтеп утырсалар исән калырлар иде бит. Ә алар күрә салып үлемгә ташланалар. Соңгы сулышларына кадәр үлем белән көрәшәләр һәм геройларча һәлак булалар. Кошларның мәңгелеккә сузылган давылларда үлем белән көрәшә белүләре диңгезчеләргә үрнәк булып торгандыр дип уйлыйм мин...

Мин инде бер тапкыр Александр Матросов турындагы мифка анализ ясап караган идем һәм... сугышчан томаналыкка маңгаем белән килеп бәрелдем. Ул «бөек героизм» фәлән җирдә, фәлән көнне, төгән чәсттә булган», дип кәҗүннәй гәҗит корреспондентының бармагыннан суырылып чыгарылган агитпроп мәгълүматын колагыма китереп элде бер патриот пенсионер. Гәҗиткә язып пропаганда-коткы итеп таратыр өчен кошлар үлемне эшләмиләр. Хәтта алар белмиләр дә үзләренең геройларча, кошлар милләтенең яшәешен дәвам итү юлында шәһид китүләрен.

Диңгездәге давылның төрлесе була. Су өстендә дулкын купкан, дулкыннарның яллары һавага күтәрелеп, җир белән күк арасын су өермәсе баскан каты шторм. Бусына кошлар бирешми. Алар су тамчылары ыжгырып очып йөргән җирдән өскәрәк күтәреләләр дә, рәхимсез каты җил белән көрәшеп очуларын дәвам итәләр. Менә шушындый зилзилә котырынуына чиләкләп койган яңгыр өстәлгән чак була. Бусы белән көрәшү авырырак, билгеле. Бусына да баш бирмиләр очар кошлар, чөнки кышка туган якта калу—бары тик үлем генә, көрәштә әле җиңеп чыгу мөмкинлеге бар. Кошлар өчен иң куркынычы—тугыз-ун баллы штормга өстәлгән карлы яңгыр. Менә нәрсә кыра зәңгәр күкнең фидаиларын.

Мин—орнитолог түгел. Махсус кошлар тормышы белән шөгыльләнмәгәч, хилафлык ычкынуы бар. Әмма күп еллар кошларның давыл белән көрәшкәннәрен күзәтү дәверендә маршрутларыннан

борылып, коры җиргә, таулар, урманнар өышыгына кайтып киткән кошларны хәтерләмим мин. Күк йөзе аяз, һава тыныч чакта кошлар, бигрәк тә торналар, кыр казлары бер-берсенә тавыш биреп, җырлап баралар. Давыл вакытында аларның тавышлары үзгәрә. Башкаларныкыннан аерылып торган тантаналы-матәм тавыш—юлбашчыныкы. «Бер-берегездән ерак китмәгез, якынрак очыгыз, адашып кала күрмәгез» булса кирәк ул сөреннең эчтәлеге. Әле беренче генә талпыр ерак юлга чыккан, канатлары катып җитмәгән яшьләрнең тавышы бөтенләй икенче. «Бетте хәлем, юк, бара алмыйм, мин аска төшәм», булса кирәк бәгырьләрне көйдереп ташларлык кызганыч тавыш. Мондый тавышка ана кошлар җавап бирә, гадәттә. Мондый киңәшне бала чыгарган, айлар буе үз авызыннан өзеп ашаткан, үстергән, очарга өйрәткән, килечәген шушы газиз бала дәвам итәчәгенә инанган җан иясе генә шундый тавыш чыгара ала. Соң бит очар кошларга гына түгел, синең үзеңә дә куркыныч бу гарасат. Син үзең дә бит үлем белән качышлы уйныйсың. Чираттагы шашкан вал корабыңны бөреп егар да икенчесе караңгы упкын карынына озатыр дип уйлыйсы урынга, җаның-тәнең белән кошларны тыңлыйсың. Һәм үзеңне онытасың. Бу бит инде гасырларда сыналган нәрсә—башкалар кайгысын йөрәгеңә ала белү үз кайгы-хәсрәтләреңнән арындыра, сиңа көч, өмет бирә.

Эре кошлар беркайчан да кораб өстенә төшмиләр. Каян белә торганнардыр ике аяклы җан иясенең иң каты штормнан да куркыныч булуын. Аларның һәлак булганнарын упкын йота. Давыл басылганнан соң палубага чыгасың. Анда дистәләгән гарип кошлар. Берәүләренең канатлары сынган, икенчеләре титаклыйлар, өченчеләре кешеләрдән качып палуба механизмнары астына посарга тырышалар. Болары вак кошлар: сыерчыклар, бүдәнәләр, җөен бөҗәк чүпләп яшәүче урман сакчылары. Шторм вакытында алар корабның утын күреп, алданалар. Җир дип уйлыйлар корабны һәм очып килгән җирләреннән мачталарга, антеннага, корабның рангоутларына бәрелеп имгәнәләр. Һәм якын килеп кара әле шул инвалид җан ияләренә! Күзләрендә ачы нәфрәт. Ышанмыйлар алар синең ярдәм күрсәтә алуыңа. Кеше дип аталган мәкерле җан иясенә ышанмау аларның каннарында, күзәнәкләрендә.

Без, ирек даулаучы татарлар, тарихтан, тирә-юньдә ирекле яшәүче халыклар тәҗрибәсеннән үзебезгә үрнәк эзлибез. Мин, мәсәлән, бары тик бер генә ышанычлы үрнәк беләм—очар кошлар үрнәге. Әгәр мин сезне ышандыра алмадым икән, Роберт Әхмәтҗановның шигырьләрен укыгыз, бигрәк тә «Кечкe кошлар»ны...

* * *

ДӨРЕС, шагыйрьнең иҗатын тулысынча аңлар өчен кай очракта аның бер шигырен дикъкать белән, төбенә төшеп җиткәнче уку җитә. Мәсәлән, Тукаебызның «Туган тел»ен, яисә «Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч—шул булды эш; керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым»га беткән шигырен, Хәсән Туфанның «Агыла да болыт агыла...»сын. Роберт Әхмәтҗановның татар шигъриятендә билгән урынын «Кичке кошлар» билгели ала торгандыр? Ә безне инде ничәмә еллар язучының дәрәҗәсен юбилей вакытында тоттырылган бүләкләр ярдәмендә, аның түшенә таккан калайларга карап билгеләргә өйрәтәләр. Дөресме соң бу? Мондый сорауны бәлки укучыга бирергә ярамый да торгандыр? Ә кемгә бирергә соң? Әдәбият галимнәренәме? Тәнкыйтьчеләргәме? Кая соң алар? Әдәбият белгечләре шул үзара бүләк бүлүчеләр түгелме соң?

Соңгы елларда татар әдәбиятын урта кул туфаны басып китте. Иҗат кешесенә совет чоры нинди генә киртәләр куймады. Агитпроп золымы. Цензура богаулары. Әзерләкләүләр. Бәлки шушы әшәкелекләргә каршы тору телэге ул чордагы татар әдипләрен рухи яктан, әхлак өлкәсендә берләштергәндер? Ул чорда әдәби әсәрнең сыйфатына таләп көчлерәк иде. Бәлки критерийның югарырак булуын рухи яктан,

иман, вөҗдан ярдәмендә берләшү генә тәшкил итмәгәндер? Фатих Хөснилар, Сибгат Хәкимнәр буынына Тукай чоры да, халык иҗатының шифалы сулышы да якынрак иде. Урта кулның өстенлек итүенә телевизор бик көчле этәреш ясады. Фатих Хөснилар чорында әдәби әсәрнең сыйфатын әсәрнең үзенә карап бәялиләр иде. Хәзер инде әсәрне укымыйча да, әсәргә һәм аның авторына телевизордан реклама ясап оештырырга була. Урта кул золымына ярдәмгә тагын бер көчле стимул барлыкка килде. Сүз иреге, фикер хөррияте бер яктан хакыйкатьне яклау мөмкинлеге бирсә, нәкъ икътисад, сәүдә өлкәсендәгечә шәүлә (теневой) иҗаты, әдәби рэкет, гөрләп чәчәк аткан ришвәтчелекне тудырды. Без әле ришвәтчелекнең нинди өлкәләрдә, нәрсәләр артына яшеренеп хәрәкәт итүен, мин—сиңа, син—миңа ысулының әдәбият, сәнгать өлкәсенең нинди тармакларына үтеп кергүен күз алдына китерә дә алмыйбыз. Шушы әхлакый шапшаклыкның милләтнең рухиятен агулауны да тулысынча аңлап бетерә алмыйбыз әле без. Роберт Әхмәтҗанов шикелле каләм осталарының иҗат процессының ындыр артына куылуы уртакулның чик-чама белмичә котыруының төп дәлиле.

«Хәтер елгасы»ның авторы татар шигъриятенә зур өлеш керткәнлеген, әдәбиятның үсүенә этәреш ясаганлыгын аңлар өчен «Җәяүле күбәләк» исемле шигырьне укып карарга кирәк. Чынбарлыкка гаҗәп тирән үтеп кергән романтик реализм ята шигырьнең нигезендә:

Безнең сагынуыбыз шундый—
ашкынабыз җир үзәге булган төбәккә.

Шулай башланып китә шигырь. Сагыну һәм моң. Шушы ике күңел вәзгыяте, тойгылар сыкравы татарда башка халыкларныкы белән чагыштырып булмас дәрәҗәдә көчле. Ул әле дә, ассимиляция, рухи сукбайлыкның елдан-ел көчәюенә карамастан, татарның шигъриятендә, җырларында көчле яңгыраш таба. Аңлашыла торгандыр дип уйлыйм, шигырьдәге «җир үзәге»нең нәрсә икәнлеге? Шул «җир үзәге» дип аталган туган туфракны сагыну, даими шуңа ашкыну да татарга хас әрнүле тойгы булып гасырлар буе даими сулкылдап торды. Шул чыдап булмаслык әрнүне укучының йөрәгендә уята, җанландыра алырлык метафора таба алган шигырьнең авторы. Сагынуларга түзә алмыйча ашкынганда: «Йөрәгебез болытларга тигәләп тора», дип аңлата Роберт Әхмәтҗанов. Метафоралар үзенчәлеге, аларның чиктән тыш тәэсирле булуы, шигырьнең эчтәлегендә романтик күтәренкелек хәрәкәтләнеп торуы белән генә дә чикләнеп калмаган автор. «Җәяүле күбәләк»нең нигезендә экзистенциаль философия ята. Бу сүзне өнәп бетермиләр татар язучылары. Ошыймы, юкмы, баш тарта алмыйбыз без экзистенциализмнан. «Җир үзәге булган төбәгебездән» чыккан нефть бөтен СССРны туйдырып торган чакта мескен татар ачка үлүдән куркып Норильск шахталарына, Коми урманнарындагы совет чоры лашманчылыгына, тагын әллә кайларга олага торды. Нәкъ шул таралу-таркалу тудыра торды татар кешесенең сагыну-ашкынуларын, йөрәге болытларга тиеп, җир үзәге булган төбәккә омтылуын. Сагынырлык булгач, нигә китә ул туган туфрагыннан? Менә шушы сорауга марксизмның «диалектический» методы да, тарихи материализмы да җавап бирә алмый. Шушы капма-каршылыкны аңлыйсың килсә, телисеңме-юкмы, экзистенциаль философия белән коралланырга кирәк. Һәм мин ышанам, киләчәк буын татар язучылары үзләштерәчәкләр шушы философияне... Экзистенциализм, әйтерсең, махсус татар чынбарлыгын өйрәнер өчен барлыкка килгән алым ул.

Әйе, «Җәяүле күбәләк»—тетрәндергеч шигырь. Тукайның «әйт әле, күбәләк, серләшик бергәләп» дип башлаган шигыре белән чагыштырып карагыз:

Ә түбәндә
таулар, урманнар артына,
чакырымнар аша,

жилне жиңеп, жилфер-жилфер килеп,
кайта
бер күбәләк.

«Күбәләк җәяүли аламыни?—дип сораячак конформист бәндә.— Ул соң ничек таулар, урманнар өстенә менә алган? Күбәләк җилгә каршы оча аламыни?..» Чыннан да, халык җырларында, Роберт Әхмәтҗановка кадәр иҗат иткән шагыйрьләрнең иҗатларында күбәләк болын чәчәкләре, тәрәзә төбендә үскән гөлләр тирәсендә генә оча иде. Таулар, урманнар масштабы ярдәмендә, һава лайнерларын күрсәтү гадәткә кереп оялаган. Ә монда сәгатенә икешәр, өчәр мең чакрымны каплый торган корыч кошлар—самолетлар юлыннан күбәләк оча:

Кайта: Болытлар астыннан,
давыл сукмагыннан,
каршысына урманнардан
сибелә сары яфрак,—
сары күбәләкләр күч-күч
ятып кала кырда.
Ә бу—кайта...

Нигә тетрәндерә безне, хәйран калдыра, әллә нинди мистик, төшләрдә генә күренеп китә торган тылсымнар уята гади бер күбәләкнең таулар, урманнар артына болытлар астыннан, давыл сукмакларыннан кайтып баруы? Белмим, бүгенге чор балаларына урыс телле әниләр адашып өйгә килеп кергән күбәләкне шушы йорттан зираткә—әрвахлар дөньясына киткән гаилә әгъзасының җаны икәнлеген сөйлиләрме икән? Аңа тияргә ярамаганны һәм күрү белән, соңармыйча шул гүр иясенә багышлап хәер бирергә, Коръән укытырга кирәклеген балаларына аңлаталармы икән? Безгә аңлаталар иде. Бәлки шуңа күрәдер мин Роберт Әхмәтҗановның күбәләген адәм баласының җаны итеп кабул итәм. Һәм ул шулай да бит. Меңәр кеше сыйдырышлы, бер килүдә Грозный шәһәрен хәрабәгә әйләндереп китүче һава крепостьлары, «мерседес»лар, шәхси коттеджлар—боларның барысы да адәм баласының тәнен, аның нәфесен, хәсетлеген генә тәэмин итә ала. Андый кыйммәтле индустриал техника җимешләре кешене бары тик тышкы яктан гына күтәрә, гайрәтле итеп күрсәтә ала. Нәкъ атабыз Адәм белән анабыз Хаува чорындагыча, безнең җаныбыз һаман күбәләк хәлендә.

Зур талант сүзендәге тылсым ул шуннан гыйбарәт: Роберт Әхмәтҗановның шигырьләрен укыганда, андагы җөмләләрдән һәр укучы үз язмышын таба, җанын сыкраткан сорауларына җавап ишетә. «Җәяүле күбәләк»не укыганда, мин үземнең язмышымның тормыш таулары, көнкүреш урманнары каршында күбәләк дәрәҗәсендә генә көчсез, мизгел саен һәлакәткә юлыгырга торган итеп кабул итсәм, башка укучы шул ук шигырьне Тукай әсәрләрендәге, халык җырларындагы гөлдән-гөлгә кунып йөрүче нәни җан иясе итеп тә тоя ала.

Белмим, бәлки бу шагыйрьнең иҗатына багышланган зур фәнни хезмәт бардыр? Бәлки мин аны очратмаганмын гынадыр? Чыннан да бит Робертның һәр шигырендә поэзиянең нәрсә икәнлеген, күңелне пакьләндерү (катарсис) өчен нигә без беренче чиратта кулыбызга шигырьләр җыентыгын алуның серен ачабыз. Һәр битте диярлек классик фәнни эш язарлык мисаллар очрап тора. «Чал платан төбендә дә—көз. Утыра шунда бер карт—нәкъ Мәрҗани. Бирелә гүя гыйлем мөгарәсе... Чал платан—манма кояш». Кайсы төбәкне сурәтли икән шагыйрь, дип баш ватасы да юк. Шушы дүртьюллык шигырьгә сыеп беткән хисләрдә Мәрҗанинең кем икәнлеге дә тулысынча аңлатылган һәм яшәешнең нинди бөек, нинди матур куаныч икәнлегенә кадәр ача алган «Хәтер елгасы»ның авторы.

Инде мәкаләне күптән тәмамларга вакыт. Ә мин һаман туктый алмыйм, үземнең шатлыкларымны, татар шигърияте белән горурлануымны

укучы белән һаман бүлешәсем килә. «Бәхеткә барыр юлларның тузаннары—соры... Тереклекнең суын эчеп, арта маңгай сыры...», «Бәхеткә илткән кырларның тәҗрибәсе—куе. Йөрәкләрдә—өрем төме—шул кырларның сые. Офыкларны безнең күзләр эчә гомер буе». Гомеремнең күп өлешен күзем белән офыклар эчеп яшәгәнгәме, бу юллар миңа догадан да кадерлерәк булып яңгырый. «... Ярты юлга житеп, сау теләкләр егыла. Ак өметләр сүнә тау артына китеп. Хыялларым—ярты, тулы бәхетем—китек». Шушы сыкрауларга битараф калган бәндәләр бармы икән? Күңелем куануыннан болытларга талпына, ә салкын акыл мыштым гына колагыма пышылдый: «Бар. Хәтта күп. Көннән-көн күбәя...»,—дип. Туган районым Баулыда татарча сүз әйтер алдыннан, кеше тыңлап тормыймы икән, дип як-якларына каранып алалар. Бәлки без туган телне коткара да алырбыз? Дөрес, телебезне коткарып калу өчен Прометей түземлеге кирәк булачак. Бәлки торгыза алырбыз? Туган телнең төмен, аның тылсымлы яңгырашын кире кайтара алырбызмы? Менә нинди газаплы сораулар борчый мине. Сулкылдап торган тере рухият—безнең туган телебез бит инде. Ят тел аралашыр өчен генә ярый.

Әлмәтнең бер китапханәсендә китап укучыларны язучылар белән очраштырдылар. Беренче класс балалары концерт белән килделәр. Килделәр һәм пыр туздырып үзара урысча сөйләшә башладылар. Татар мәктәбендә укучы татар балалары бер-берсен туган телдә аңлый алмыйлар. Ниһаять, сәхнәгә чыгып җырлый башладылар. Тыңлап утыручыларның чәчләре үрә торды: моң юк, җыр йөрәктән чыкмый. Әйтерсең, роботлар җырлый. Бу балалар татарча өйрәнә алсалар да татар теле алар өчен туган тел була алмаячак.

* * *

ТАЛАНТ мохитка җайлаша алмый. Сыймый аның офыклары көндәлек тормыштагы прагматиклар калыбына. Зур талант һәр өсәрен бәгъренең иң сизгер, иң әрнүле почмагыннан сыгып чыгара. Һәм тынгы бирмичә сызлый торган бушлык барлыкка килә талант иясенең күкрәгендә.

Шарль Бодлер зур шагыйрьнең көнкүрешкә яраша алмавын менә ничек исбат итә. Ул шагыйрьне альбатрос белән чагыштыра (тәрҗемә итмичә, русчасын бирәм):

Когда в морском пути тоска грызет матросов,  
Они, досужий час желая скоротать,  
Беспечных ловят птиц, огромных альбатросов,  
Которые так любят суда провожать.

Альбатросның очканын күргән кеше бу күренешне мәңге оныта алмый. Кайвакыт без романтика турында сүз куертабыз, ә үзебез аның нәрсә икәнлеген күз алдына да китерә алмыйбыз. Альбатросның океан киңлеге өстендәге зәңгәр күктә йөзгәнен күргән кешегә романтиканың нәрсә икәнен аңлатуның кирәге калмый:

Быстрейший из гонцов, как грузно он ступает.  
Краса воздушных стран, как стал он вдруг смешон.

..................................................

Поэт, вот образ твой. Ты также без усилья  
Летаешь в облаках, сред молний и громов,  
Но исполинские тебе мешают крылья  
Внизу ходить, в толпе, средь шиканья глупцов.

*(П. Якубович тәрҗемәсе)*

Альбатрос тәкъдирен кичергән иҗат талантларын эзләп әллә кайларга барып та йөрисе юктыр. «Булды юлда киртәләр, эттән күбәйде дошманым... Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч—шул булды эш: Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым»,—

Тукайның шушы өрнүле, үзәкләреңне өзәрлек сүзләрендә шул ук альбатрос язмышы сурәтләнмәгәнмени? Ә соңгы көннәрендә Һади Такташка суд ясап, селәгәй комсомолларның аны мыскыл итүләре шул ук альбатроска иткән һөҗүм түгелмени?

* * *

МИН ИҖАТТАГЫ бер-берсенә капма-каршы ике көч көрәшүен аңларга тырышып эзләнүләремдә ялгыш юлдан бардым. Талант белән уртакул көрәшү ачыктан-ачык бармый. Аны күрүе дә, аңлавы да чиктән тыш кыен, катлаулы. Әнә, хәтта уртакулдан да түбәнрәк, ачыктан-ачык халтура өмәлләүчеләр тарафыннан оештырылган «мыльная опера» телефильмнарын ничек йотлыгып карыйлар. Сан ягыннан ничә процент телевизор караучы аңлый ала ул фильмнарның Борынгы Рим чорыннан башлап, болгавыр елларда гавәмгә сөяк итеп ыргытылган «хлеб и зрелище» икәнлеген? Шушы яшерен җинаятькә каршы көрәшеп кара әле! Әдәбиятта да нәкъ шул ук хәл. Уртакул золымы, уртакул әдәбият галимнәре ярдәмендә, мәктәп дәреслекләренә, вуз программаларына оялаган. Әдәби тәнкыйть юк. Зәвекъле укучыларның язмышы белән кызыксынсагыз, «Мирас» журналының 1998 елда чыккан 7 нче санын укыгыз. Әдәбият галиме таләпчән, зәвекъле укучыны бүре куган шикелле эзәрлекли. Һәм шушы җаһил кыргыйлыкны халыкка аңлатуы чиктән тыш катлаулы. Халыкның үз кайгысы. Аны ачлык, хәерчелек белән куркыталар. Әдәбият кайгысымыни шушы гарасатта, дип кенә җибәрә ул. Югары культурага, чын әдәбиятны аңлау дәрәҗәсенә күтәрелә алмаган халык мәңге шул ачлык, ялангачлык белән көрәшеп яшәячәк. Шушы хакыйкатьне киң күләм массаларга җиткерүе ай-һай авыр.

Уртакул белән талант арасындагы мәңгелек көрәшнең тормыш-көнкүреш өлкәсендә бөтенләй башкача чагылышын мин бик соң аңладым. Талантның иҗаты газаплы сорауларга бәйле. Без нигә болай яшәргә мәҗбүрбез? Безнең бәхетсезлегебез каян килә? Ниһаять, адәм баласының яшәештәге төп вазифасы нидән гыйбарәт? Һәм шушы сорауларны бирүче яшәештәге хакыйкать белән ялган, игелек белән әшәкелек, савап һәм гөнаһ көрәшенә килеп юлыга. Һәм җиңелә хакыйкать эзләүче. Кыйнала. Нужа күрә. Яшәве—тоташ газап. Ләкин бер шушы юлга баскач ул тайпыла алмый. Җәмгыятьтәге өстенә пәйгамбәрлек вазифасын алган көрәшчеләр язмышы бу. Һәм шушы каһәрле язмышны сайларга талантны иман үҗәтлеге мәҗбүр итә.

Уртакул сорау биреп тормый. Ул башта ачыклый, иң зур файдага нинди юл белән ирешеп була? Бай яшәр өчен, дан-шөһрәткә ирешер өчен иҗатны ничек корырга кирәк? Иң отышлы тема кайсы? Менә шушы салкын акыл белән өлкән буын тәҗрибәсе ярдәмендә ачыклау «уртакулны» хакимият җирлегенә алып килә. Власть—максатка ирешүдә төп таянычы, иң отышлы көч. Һәм көчең җиткән кадәр син үзең дә әдәбияттагы җитәкчелеккә, түрәлеккә омтылырга тиеш. Ирешә алсаң, бу инде хакимият белән бергәләп эшләргә, аралашып яшәү бәхетенә ирештең дигән сүз. Менә шушы ачышымны мин татар әдәбияты тормышындагы мисаллар белән дәлилләп, иҗат өлкәсендә нинди манзаралар тудыруын, кемнәр өстә, кемнәр аста, кем кыйный, кем гел кыйналып тора—менә шуларны бәйнә-бәйнә сурәтләп һәм дәлилләп күрсәтер идем. Бу турыда махсус язарга кирәк. Әле болай да озынгарак китте Роберт Әхмәтҗанов шигырьләренә ясаган анализым.

Бу язмам минем риясыз анализ. Мактамадым да мин «Хәтер елгасы»ның авторын, хурламадым да. Роберт Әхмәтҗановның нәрсә язганын, ул язмалар чынбарлыкка барып тоташа алганнармы, тоташа алган очракта, нинди экзистенциаль тойгылар уята алганнар? Бары тик шул гына.

*1999 ел, февраль. Әлмәт.*

# ӘДӘБИ МИРАС

* * *

*Танылган әдип Афзал Шамовның (1901-1990) әдәби мирасы алай әлләни зурдан түгел. Озын гомер юлының шактый өлешен казна һәм җәмәгать эшләрендә үткәргән бу язучы, чагыштырмача аз язса да, үзенчәлекле хикәяләре һәм повестьлары белән билгеле иде. Аның «Рәүфә» повесты, «Миңнур карт» һәм башка байтак хикәяләре үз вакытында, мәктәп программаларына кертелеп, өлкән сыйныфларда укытылды. Без аларны укып үстек.*

*Афзал Шамов тәрҗемә остасы да иде. Аның тәрҗемәсендә татар укучылары дөнья һәм рус классикасының бик күп әсәрләре белән таныштылар. Барысын да санап тормастан, Жюль Верн, Эрих Мария Ремарк, А. Пушкин, Н. Гоголь, Л. Толстой, А. Чехов, М. Горький, Н. Островский, А. Фадеев исемнәрен атау да җитәдер.*

*Афзал Шамов - үз-үзенә дә, башкаларга да бик таләпчән һәм шул ук вакытта үтә итагатьле, сабыр, тыйнак шәхес иде. Шуңа күрәдер дә, төрле җаваплы һәм дәрәҗәле урыннарда кәнәфидә утырса да, ул башкалар кебек кирпеч-кирпеч томнарын бастырып чыгару артыннан йөрмәде. Аның аерым китапларыннан тыш, нибары бертомлык «Сайланма әсәрләр»е генә берничә мәртәбә дөнья күрде.*

*Укучыларыбызга тәкъдим ителә торган «Картлар» әсәре (автор аның жанрын билгеләмәгән, повесть шикелле) гасырыбызның илленче еллары башында язылa башлаган булырга тиеш. Әсәрдә сүз сугыштан соңгы колхоз авылы турында бара. Геройлары—авыл кешеләре, нигездә өлкәннәр, әсәрнең исеме—«Картлар» да шуны искәртеп тора.*

*Бу әсәр, шул еллар әдәбиятына хас булганча, тормышны «алсу төсләрдә», буяп-бизәп күрсәтергә омтылуы белән характерлы. Шулай да Афзал Шамовның әдәби зәвыгы, үзенчәлекле таланты әсәрдә ачык чагыла: ул үз геройларын психологик кичерешләр аша ачарга омтыла, алар җанлылар, терелэр, һәркайсының үз холкы-табигате төсмерләнә. Колхоз эшеннән уллары тарафыннан читләштерелгәннән соң, эш сөючән җанына тынгы таба алмый тинтерәүче Садыйк карт белән аның кордашы, әле һаман эштә-хезмәттә кайнаучы гадел һәм бераз хәйләкәррәк Сәләхи картның үзара мөнәсәбәтләре дә, Садыйк картның карчыгы Бибисаҗидә образы да сәнгатьчә матур итеп сурәтләнгәннәр.*

*«Картлар» әсәренең тел-стиль ягына да тел-теш тидерерлек түгел. Ул шактый камил, ятышлы дип әйтер идек. Өлкән буын әдипләребезнең байтагы шикелле, Афзал Шамов та әдәби сүзгә таләпчән, ул һәр җөмләсен җиренә җиткереп, шәрехләп язарга тырыша. Шуңа күрә әсәрнең баш өлешләре ялыктырмыйча укыла.*

*Әмма соңга таба сюжет сыегая, автор геройларын нишләтергә белми башлый, аптырап кала сыман: колхозчыларның озын-озын нотыклы, «кызыл» - күңелсез җыелышларын егерме-утыз биткә сузып сөйләп бирүләр башлана. Бәлки шуңадыр да, Афзал Шамов бу әсәрен, биш табаклар чамасы күләмдә язгач, тәмамламыйча өстәл тартмасына салып куйган. Язылган елын да күрсәтеп тормаган. Ә бит югыйсә әдипнең әле көч-куәте ташып тора, ул әле илле яшен тутырган гына чак. Шул ук елларда аның «Көннәрдән бер көнне», «Яңгырлы кичтә», «Бер мәхәббәт турында» кебек югары кимәлдә иҗат ителгән әсәрләре дөнья күргән иде.*

*Афзал Шамовның «Картлар» әсәреннән беренче ике бүлекне без, автор текстына каләм тигезмичә, бүгенге укучыларыбызны үзебезнең элгәрләребез—өлкән буын әдипләребез иҗаты белән таныштыру максатыннан тәкъдим итәбез.*

*Кульъязманы журнал редакциясенә Афзал Шамовның кызы Әлфия ханым тапшырды. Без аңа рәхмәтлебез!*

**Марс ШАБАЕВ.**

# Афзал Шамов

## КАРТЛАР

### 1

Кеше бер картайса—картая икән... Әле моннан ике ел элек кенә Садыйк абзый авылдагы иң таза картларның берсе булып санала иде. Колхозның истә калырлык, иң кирәкле, бернечә ун ел эчендә телгә алып сөйләрлек бер генә эше дә аның катнашыннан башка үткәрелми иде. Андый эшләрне ул, яратып, эчке ләззәтен табып, бөтен жаны-тәне белән бирелеп эшли иде. Юк, андый эшләрдән генә түгел, колхозның гади, көндәлек эшләреннән дә ләззәт таба иде ул. Ә инде озак еллар яшәячәк хезмәтнең һәркайсы аның тормышына тел белән әйтеп бирергә мөмкин булмаган яңа бер нур өсти иде.

Әнә «Ирек» колхозы яныннан дугаланып уза торган, киң көмеш тасма кебек ялтырап яткан Нурлы елгасын күрәсезме? Аның буенда, үзәнлектә, хәзер карасу булып, дингез кебек дулкынланып яткан болын урынында, кайчандыр бик зур сазлык иде. Бәлки, ул сазлык Нурлы ага башлаганнан бирле шулай, бөтен үзәнлекне басып, тынчып, сасып яткандыр. Әш аның кайчаннан бирле сасып ятуында түгел, ә Садыйк карт ата-бабалары гомерендә кешеләргә зарардан башка бернәрсә дә китермәвендә. Кешеләрне бизгәк белән жәфалау дисеңме, көтүдән качып кергән, андагы агулы үләннәрне ашаган сарыкларның, сыерларның эчләрен киптерү дисеңме,—барысы да шул каһәр төшкән сазлыктан килә иде. Ә жәйге тын кичләрдә инде ул бөтен авылны үзенең сасы исе белән дә, тынгысыз озынборыннары белән дә тутыра иде. Озынборыннарның никадәр үзәккә үткәнен «Ирек» колхозчылары бик яхшы беләләр. Әгәр белми торган кешеләр булса, рәхим итеп, үзләре шундый урында торып карасыннар,—булмаса, жәйге кичләрдә ачык һавада бер генә кич кунсыннар. Ачык һавада түгел, тынгысыз бөжәкләр төтәсләп чыгарылган өйдә яисә келәттә куну да житә.

Менә шул сазлыкны «Ирек» колхозчылары сугышка кадәр бернечә ел элек киптерергә уйладылар һәм киптерделәр.

Сазлык бетте, жәйге көннәрдә жил белән дулкынланып торган ямь-яшел болынга әверелде, ә болын өстендә буйдан-буйга сузылган, бер-берләре белән тоташкан канаулар калды. Хәзер ул канауларны да инде үлән басып бара. Канауларны үлән басар, бәлки, алар кайчан да булса жир белән дә тигезләнерләр, әмма ул сазлыкны «Ирек» колхозчылары киптерде дигән истәлекне бертөрле дә үлән баса алмас. Менә шул онытылмас хезмәткә Садыйк абзыйның да көче салынган. Көче салынган дип әйтү генә аз! Ул аңа жанын салды, шул эшне башлап йөрүчеләрнең берсе булды. Никадәр ләззәт, никадәр шигърият, никадәр жан азыгы тапты ул аннан.

Булмаса, Түгәрәк таудагы алмагач бакчасына күз төшерегез. Ул бакчаны Садыйк карт утыртышмадымыни? Жәй көннәрендә, ямь-яшел яфракларын ярып, авылга таба көлеп карап торган, ә кыш көннәрендә әлегә саламнарга төрелеп утырган ул яшь алмагачларның бик күпләре Садыйк карт кулыннан үтмәдемени?

Әнә Нурлы буенда, тегермән янындагы текә яр кырыена утырган алты почмаклы бер йорт бар. Ул йорттан колхоз фермаларына һәм авылдагы өйләргә таба шәм кебек төз баганалар, бер-берләрен куып баргандай, тезелешеп киткәннәр. Ә баганаларга колак алкаларыдай ак изоляторларын тагып, электр чыбыклары тартылган. Ул чыбыклар жәй көннәрендә кояш нурлары белән жемелдиләр, ә кышкы салкын төннәрдә ачы жилләр көенә сызгыралар. Менә шул электр чыбыкларын сузып жибәргән әлеге алты почмаклы йортның нигезендә Садыйк карт кулы белән салынган ташлар да бар. Кай төннәрдә Садыйк карт, кулына чөмәкле артыш таягын тотып, урамга чыгып баса һәм

авылның бер башыннан икенче башына кадәр сибелгән яп-якты тәрәзәләргә, урам буйлап сирәк кенә тезелеп киткән лампочкаларга балаларча шатланып, горурланып карап тора. Чаткыланып янган бу якты утлар аңа гидростанциядән түгел, ә алар салган нигез ташларыннан чыккан көч белән шулай якты янадыр шикелле тоела.

Бар иде бит заманалар, Садыйк картның кулы тимәгән, аның киңәше кермәгән бер эш тә юк иде. Ул көннәрдә Садыйк карт ике кеше кадәр, хәтта өч кеше кадәр эшли иде. Ул чагында аруда-талуда да җанны рәхәтләндергеч ниндидер бер ләззәт бар иде. Ул ләззәт, эшенне бетереп, аңа бер күз ташлап алганнан соң башлана иде... Ә хәзер инде ул колхозның эшкә ярамый торган картларыннан санала. Ничек картаеп китте соң ул? Шул каһәр төшкән картлыкның килгәнен ничек сизми калды?

Аның янына кайчакларында дус-ишләре, кордашлары килгәләп утыралар. Алар, өйгә кергәнче, башта йә тәрәзәне шакылдаталар, йә ишекне дөбердәтәләр, тик шуннан соң гына бусаганы атлап үтәләр. Нигә менә картлык та шулай, йә тәрәзәне шакылдатып, йә ишекне дөбердәтеп, рөхсәт сорап килми икән?

Чыннан да, ул ничек болай тиз генә картаеп китте соң? Ничек итеп ул шундый җанны рәхәтләндергеч, күңелне сафландыргыч эшләрдән кул селтәде соң? Аның шулай, кешеләрнең шау-гөр килеп эшләп йөрүләренә читтән генә, картларча пошынып, хәтта аз гына мыгырданып, вакчылланып карап торуы кайчан башланды соң?..

Аның ике улы да Бөек Ватан сугышыннан исән-сау кайтып керде. Дөрес, алар икесе ике вакыт кайтып керде, ләкин алар икесе дә бер үк шатлык һәм дөньяны янадан корырга хәзер торган бердәй күтәренке күңел белән туган йортларының ишекләрен ачтылар. Һәм озакламыйча алар, җиңнәрен сызганып, колхоз эшенә тотындылар. Менә шул көннән башлап алар Садыйк абзыйны ничектер сиздермичә генә колхозның көндәлек эшеннән читкә тайпылдыра башладылар, аның эш белгән куллары кирәксез була башлады. Кайчандыр ул таптаган юлдан аның уллары һәм аның уллары шикелле үк фронтовиклар нык-нык басып йөри башладылар. Садыйк абзый кулыннан эш килмәгәнгә яисә колхоз эшендә артык булганга түгел, ә аңа карата халыкның хөрмәте зур булганга һәм сакал-мыеклары шикелле үк чигә чәчләре дә, түбә чәчләре дә көмештәй җемелдәп торганга хезмәткә чакырылмый башлады. Бәлки, әле үз улларының сүзен тыңламаган да, аларның «әти, сина инде ял итәргә вакыт» дигән, тынлыкка, картлыкка өнди торган сүзләренә колак та салмаган булыр иде. Каяндыр, һич тә уйламаганда, бөтенләй икенче яктан, бу мәсьәләгә колхоз председателе дә килеп кушылды. Ул үзен сайлап куйган халык каршында бик авторитетлы, дөрес сүзле, гадел кеше иде. Аннары ул бөтен сугыш еллары буенча Садыйк абзыйны колхоз җыелышларында да, хәтта район җыешларында да, үрнәк колхозчы итеп, мактап килде. Дөресен әйтик, Садыйк абзый тышыннан сиздермәсә дә, әмма эченнән бу мактауны бик ярата иде. Шундый салпы ягы бар иде аның. Менә шул председатель колхозның өлкән кешеләре алдында аңа, сугыш елларында үз-үзен аямыйча эшләгән өчен, бик олылап рәхмәт әйтте һәм:

—Сина инде, Садыйк абзый, тынычлап ял итәргә дә мөмкин,—дип өстәде. —Ял итәргә хакың бар синең.

Садыйк абзый председательнең һәр сүзен тыңларга һәм аны төгәл үтәргә күнеккән иде. Ун еллап бергә эшләгән вакыт эчендә аның күңелендә председательгә карата шундый буйсынучан бер тойгы урнашкан иде. Аның шундый җанны эреткеч рәхмәтеннән соң, инде ял итәргә дә мөмкин дигән фикергә килә башлады. Әйе, ул ял итү хокукына, тыныч, бәхетле картлыкка үзенең эшчән куллары, агарган һәм сирәкләнгәннән-сирәкләнә барган чәчләре белән ирешә.

Шулар өстенә йорт тирәсендә дә янадан-яңа эшләр килеп чыга башлады. Арт буйны төзәтергә, бакча тирәсен янадан тотарга, келәт идәне такталарын алыштырырга кирәк булып чыкты. Әле ул гынамы соң! Садыйк абзыйның кулына балта белән пычкы гына алырга кирәк булган икән. Төзәтелергә,

янартылырга кирәк нәрсәләр үзләреннән-үзләре көтеп, авызларын ачып тора башладылар. Сугыш елларында аларны ул ничек күрмәгәндер, менә үзенен дә исе китте. Кем белә, бәлки, алар да сугышнын бетkәнен, аның жиңү тантанасы белән тәмамланганын көтеп ятканнардыр. Нәрсә булса да булды, Садыйк абзый үзеннән-үзе шулай, колхозның гөрләп торган көндәлек эшеннән бер читкә китте. Юк, аның йөрәге бу читкә китүне тыныч кына кичерә алмады. Башта ул, ничектер, ятим калгандай, сыкранды, сызланды... Ләкин менә шул тынгысыз, борчулы йөрәк аны йорт тирәсенә бөтенләйгә бәйләп куйды да.

Көз көннәренең берендә ана салкын тиде. Ул берничә көн бик югары температура белән кызышып ятты. Әлеге, аны мактый торган председатель аны күрсәтергә районнан доктор алып килде. Кара чәчле, ниндидер яхшылык, ышанычлылык анкытып торган зур соргылт күзле, урта яшьләрдәге доктор Садыйк абзыйның пульсен капшап карады һәм, үзенең ак, салкын бармаклары белән аның күкрәген озак кына каккалаганнан соң, стетоскопын тереп, берничә урыннан тыңлады. Суларга һәм суламый торырга да кушты. Гомерендә нинди авырулар белән авырганлыгын да сорашты. Кеше үз гомерендә нинди генә авыруларны кичермәс! Садыйк абзый да белгәнен әйтте, ә белмәгәннәренә кулын гына селтәде. Нигә кирәге бар аларның! Узганнар бит алар!

Тик шуннан соң гына доктор аның грипп белән, ягъни салкын тиеп авырый икәнен әйтте, ничек дәваланырга, даруны кайчан һәм ничек эчәргә икәнен өйрәтте. Садыйк абзый салкын тигәнен үзе дә белә иде. Шулай да ул докторның авыруларны дәвалый белгәнлегенә чын күнеленнән ышанып калды, чөнки Садыйк абзыйның бер үзе генә белә торган сызлануларын кулы белән тотып карагандай дөрес әйтеп чыгып китте.

Нәкъ шул вакыттан башлап Садыйк абзый шул каһәр төшкән картлыкның килгәнен сизде...

Менә бүген дә Садыйк абзый, ишек алдындагы эшләрен бетереп, өйгә, мич буендагы скамьягә, жылыга кереп кенә утырган иде. Шул вакыт кемдер өйалды келәсен шалтыратып ачты, ишекне дөбердәтте. Садыйк абзый керүченең аяк тавышыннан һәм ишекне каты итеп шакылдатуыннан ук аның яшьтәше Сәләхи карт икәнен сизеп алды. Алар өенә аяк басучылардан бары тик Сәләхи карт кына ишекне шулай кискен һәм каты итеп шакылдата иде.

Садыйк абзый «керегез» дип әйтергә дә өлгермәде, ишек, нәкъ ул көткәнчә, кискен генә ачылып китте, аннан өстенә шактый кыршыла төшкән кыска кара тун, башына колаклары тырпаеп торган йонлач бүрек, аягына олтан салган, берничә урыннан ямалган киез итек кигән, биленә саргылт эзәр бәйләгән, яртылаш агарган очлы сакаллы, ябыграк гәүдәле бер кеше килеп керде. Керүче чыннан да Сәләхи карт иде.

—Керергә рөхсәтме?—диде ул, инде өйгә кереп, ишекне ябуына карамастан.—Бик исән-сау гына торасызмы!—Садыйк абзыйның мич янында утырганын күргәч, бераз көлемсери төшеп, дусларча өстәде:—Нәрсә, яшьтәш, мичне жылытып утырасыңмы әллә? Өй сакларга калдырдыларммы? Әллә үзең генәме?

Садыйк абзый керүчегә ихтирам йөзеннән урыныннан торды:

—Әйдә, хуш киләсең, яшьтәш, рөхсәт, түрдән уз,—диде һәм кулы белән ана урын күрсәтте.—Үзем генә түгел, карчык та өйдә әле.

Карчыгының өйдәлеген расларга теләгәндәй, почмак ягыннан савыт-сабаларның шалтыраганы ишетелеп китте. Сәләхи карт шул якка таба карап, тавышын бераз күтәрә төшеп, аның карчыгы белән дә исәнләште.

Почмак ягыннан башына ак яулык бәйләгән, өстенә борчак-борчак ак төшкән, киң, озын зәңгәр күлмәк кигән, бик мөлаем йөзле, түп-түгәрәк гәүдәле бер карчык, йомшак кына, вак-вак кына басып, тәгәрәгәндәй килеп чыкты:

—Үзегез бик исән-сау гына торасызмы? Кечкенәләрегез нихәл? Үсәләрме? Нигә Фәрхекамалың бер дә күзгә-башка күренми? Әллә авырып-мазар итеп торамы?—дигән сорауларны бик ягымлы, хәтфәдәй йомшак,

күкрәк тавышы белән бер-бер артлы яудырырга тотынды һәм, кунакның җавап биргәнен дә көтмичә, аны түргә узарга, утырырга чакырды.—Нигә бик сирәк кергәләп чыгасың? Садыйкны бөтенләй оныттыгыз лабаса. Алай ярыймыни инде ул...

Карчык, кунакның түргә узарга теләмәгәнен күреп, аның янына урындык китереп куйды һәм, тузан-фәлән була күрмәсен дигәндәй, утыргыч өстен кулындагы тастымалы белән сөртеп алды.

—Булмаса, утырып тор, бераз ял ит, аргансың... Садыйкка да көнозын бирүзенә бик күңелсез...

—Юк, рәхмәт, Бибисаҗидә, утыра алмыйм, вакытым юк,—диде Сәләхи карт һәм урындыкны кулы белән бер читкә этеп куйды. Аннары, Садыйк абзыйга карап, өстәде:

—Сыер фермасыннан кайтып киләм әле. Менә, балтаны кайрап алып булмасмы икән дип кергән идем. Тимергә тиеп, бераз кителеп китте каһәр. Анда кул кайрагы гына. Ала алмый.—Артка, биленә кыстырган балтасын алып, кителгән җирен күрсәтте.—Китеге болай зур түгел түгелен, шулай да...

Бибисаҗидә карчык, инде үзенең бурычы үтәлгәнен һәм сүзнең эш турында башланганын төшенеп, шундый ук вак адымнар белән тәгәрәп, үзенең почмагына кереп китте. Шулай да кереп китәр алдыннан әле ул:

—Буш вакыт табып, Фәрхекамалың белән килеп утырыгыз,—дип әйтеп өлгерде.—Ни әйтсәң дә, замандашлар бит, бергә-бергә уйнап үскән кешеләр...

—Саф корыч икән, каты булса кирәк,—диде Садыйк абзый, балтаның кителгән җирен капшап карап.—Әйдә алайса, кайрап алыйк.

—Киленең өйдә юкмы әллә? Әйләндереп торыр иде. Сиңа авыр булыр бит?

—Авыр булыр?—диде Садыйк абзый һәм, киенә башлаган җиреннән бик азга гына туктап, Сәләхи картка төбәп карап алды, ә картның кечкенә соргылт күзләрендә сизелер-сизелмәс кенә булып ике чаткы кисәге җемелди иде. Бу аның гадәттәге шаянлыгы идеме, әллә Садыйк дустының, аның карашынча, иртә картаеп китүеннән көлүе идеме? Садыйк абзый моны төшенеп бетә алмады:—Нигә авыр булыр дип уйлыйсың? Әле мин ул кадәр бирешергә уйламыйм. Син бигрәк тагы...

—Бирешергә уйламасаң, яхшы,—диде Сәләхи карт тыныч кына.— Бирешергә ярамый әле безгә.

Садыйк абзый, өстен-башын киенеп, чыгарга дип, ишек төбенә Сәләхи карт янына килеп басты. Сәләхи карт бу озын буйлы, салынып төшкән куе кашлы, бераз итләч борынлы, шундый ук итләч иренле һәм эре сөякле дусты янында кечкенә генә булып калды.

—Әйдә алайса чыктык,—диде хуҗа, ләкин ул ишекне ачарга өлгермәде, почмак ягыннан карчыгының тавышы ишетелде:

—Сиңа әйтәм, кара әле, шарыфың бу якта бит синең. Бәйләмичә чыгасы булма тагы. Салкын-мазар тияр.—Һәм мич алдында, җылыда эленеп торган шарыфны, ике кулы белән тотып, җыерчыкларын яза-яза, картына чыгарып бирде.

Садыйк абзый, шарыфын муенына ураган чагында, күз кырые белән генә Сәләхи картка тагын карап алды. Картның соргылт күзләрендә һаман да әлеге ике чаткы җемелди иде.

«Урануымнан көлә булса кирәк»,—дип уйлап алды Садыйк абзый. Чөнки бу, ишекне кискен һәм каты шакылдатып керә торган карт үзенең аз гына кысыла төшкән соргылт, үткен күзләре белән кайчакларында кешенең күңеленә керергә һәм чәнечкеле теле белән тешләштергәләп алырга да ярата иде. Дөрес, ул үзе киң күңелле, ачык чырайлы һәм кешеләргә һәрвакытта да яхшылык итәргә тели иде. Аның шундый яхшы сыйфатларына һәм иптәшлек итә белүенә карамастан, Садыйк абзый аның күзләренең бораy кебек очлаеп киткән чакларын яратып бетерми иде. Шуның белән бергә аның күңелендә Сәләхи картка ихтирам да юк түгел иде. Ул яшьтән үк бик туры сүзле, гадел һәм эш сөючән булып яшәде. Аннары ул тормышында туры килгән барлык авырлыкларны тавыш-тынсыз гына күтәрә һәм бервакытта да зарланмый

иде. Сугыш алдыннан берничә ел элек, күршесендәге бала-чагаларның шырпы белән уйнаулары аркасында ут чыгып, аның бөтен йорт-җире янып китте. Ул, кирәктән артык тавыш күтәрмичә һәм күрше-тирәләре белән дошманлашмыйча, йорт-җирен шактый авырлык белән торгызды. Яңадан төгәлләнеп җитеп, кеше кебек яши башлаганда гына Ватан сугышы башланып китте, аның бердәнбер улы шул сугышта корбан булды. Сәләхи карт бу чиксез ачы хәсрәтне ирләрчә күтәрә белде. Авыл кешеләре, шул үзәк өзгеч кайгылы хәбәрдән соң, аның очлы сакалының күзгә күренеп агарганын, соргылт күзләренең тагын да кырыслана төшкәнен һәм картның ниндидер тирән уйга бирелгәндәй тынып калганын күрделәр, ләкин аның авызыннан аһ-зарлы бер генә сүз дә ишетмәделәр. Киресенчә, ул шуннан соң башкаларның кайгы-хәсрәтләренә тагын да игътибарлырак булып китте. Ул аларның сөйләгәннәрен, үз алдына карап, тирән уйга бирелеп, сабыр гына тыңлап тора, хәсрәтләрен уртаклаша һәм күңел юаткыч акыллы киңәшләр бирә иде. Үзенең йөрәк әрнүләрен сөйләмичә, башкаларның авыр кайгыларын уртаклаша белгән бу акыллы карт янынннан кешеләр, үзләре дә сизмәстән, башларын ничектер күтәрәрәк төшеп, җинелрәк атлап китеп баралар иде. Аның бу сыйфатын Садыйк абзый шунда ук сизеп алды һәм йөрәгендәге чамасыз кайгысын хезмәт белән басарга теләгәнен дә күрде. Ул һаман электәгечә яратып, ләкин инде ниндидер билгеле бер максатка барып җитәргә теләгәндәй бирелеп, картларча ашыкмый гына бик тырышып эшләде... Авыр еллар узып китте, йөрәктәге хәсрәтнең дә ачысы кими төште, ләкин картның күзләрендәге кырыслык бетмәде...

Алар ишек алдына чыктылар, ашыкмый гына басмадан төштеләр. Көн салкын түгел иде. Кичә кич белән яуган йомшак кар, бик пөхтә генә итеп көрәлеп, койма буйларына өелеп куелган, ишек алды капка төбеннән алып әвеслек асларына кадәр яп-якты итеп себерелгән. Ул төшлектән авышып барган февраль кояшы астында күзне чагылдыргыч исәпсез-хисапсыз вак-вак чаткылар белән җемелдәп ята. Өй, абзар, келәт түбәләрен, әвеслек башларын калын кар каплаган, хәтта ул капка һәм койма баганалары башына катлауланып, бүрек шикелле булып, түгәрәкләнеп утырып калган.

Сәләхи карт, ишек алдының бер башыннан икенче башына кадәр күз йөгертеп чыгып, яшьтәшенең хезмәтенә бәя биргәндәй, әйтеп куйды:

—Себереп кенә торасың икән. Яхшы. Ә моны кем төзәтте?—диде ул, яңа бүрәнәләр белән сипләнгән сыер абзарына таба башы белән ымлап.

—Үзем. Көз көне үк инде.

—Онытмагансың икән әле. Ә мин инде балтаны кулына да алмый торгансыңдыр дип уйлаган идем. Галәмәт шәп сипләгәнсең бит, ә?

Садыйк абзый аның мактавын җавапсыз калдырды. Бу мактау бер яктан аның күңелен рәхәтләндерә, ә икенче яктан аңа ничектер шелтә булып та ишетелә иде. Менә берничә айдан бирле инде Сәләхи карт һәм колхозның балта тота белгән берничә кешесе яңа сыер абзары салалар. Әйтүләренә караганда, ул элек салынган абзарлардан биегрәк тә, яктырак та булырга тиеш икән, хәтта анда сыерлар суны да автомат улактан эчәчәкләр икән. План буенча абзарны мартка салып бетерергә, быел яшь бозауларны шунда тотарга уйлаганнар иде, ләкин эш куллары җитмәгәнлектән, аның кайчан салынып бетәчәген председатель үзе дә ачык итеп әйтә алмый иде. Декабрь азакларында Садыйк абзый төзелешкә барырга, балта осталары белән бергә эшләргә дә уйлаган һәм балтасы белән пычкысын да хәзерләп куйган иде, ләкин өйдәгеләр аны бу ниятеннән кайтардылар. Ул аларның сүзләрен тыңлады, бармады. Ә хәзер менә, Сәләхи картны күргәч, бигрәк тә аның ишек алды түрендә торган, сап-сары яңа бүрәнәләре белән ялтырап яткан сипләнгән сыер абзарын мактавыннан соң, колхоз сыер абзарын салышуда катнашмавына үзен гаепле кебек итеп сизеп куйды. Бу хис яңа түгел иде. Төзелештә кешеләр җитми икән, дип ишеткән саен, ул үзен сиздереп, калкып чыга һәм картның йөрәген чеметеп-чеметеп ала иде. Хәзер исә Садыйк абзый аны ничектер янача тойды: менә бит ул, Садыйк Галләм улы, нинди кеше—үзенең, үз хуҗалыгындагы сыер абзарын, өрьяңа, гәрәбәдәй сап-сары

бүрәнәләр белән сипләп, «галәмәт шәп» итеп төзәтә ала, ә яна салынып ята торган колхоз сыер абзарына барып, анда аркылы саламны буйга да алып куя алмый. Менә нинди кеше ул!

Садыйк абзый, сүзне икенчегә борырга теләп, ләкин нәрсә турында башларга белмичә, кыюсыз адымнар белән келәткә таба китте. Аның чыгырлы кайрагы шунда иде, тик Садыйк абзыйның келәт ишеген ачасы һәм Сәләхи картны анда алып керәсе килми иде, чөнки әле ул моннан бер-ике атна элек кенә келәт идәнен яңадан түшәгән иде. Яшьтәше аны күрәчәк һәм төзелештә шундый кирәкле кешенең гомуми эштән читтә торуы өчен, теленнән әйтмәсә дә, күңеленнән шелтәләячәк.

—Кайракны мин өйгә генә алып керермен,—диде ул, ишек алды уртасында туктап.—Су белән кайрарга кирәк булыр бит? Бар, син керә тор.

—Сусыз да ярар, нигә су?—диде Сәләхи карт, аның хәйләсен төшенмичә, һәм, табан салган итеге белән карны шыгырдата-шыгырдата, атлап, келәт ишегенә таба туп-туры китте.

Садыйк абзыйның инде аның артыннан бармыйча хәле юк иде. Ул келәтнең озынча, бормалы йозагына ачкычын тыкканчы, аяк астында чуалып йөргән тавыкларны бияләе белән куркытып куып җибәрде.

—Көш-ш, көш-ш, мәхлуклар!..

Ләкин мәхлукларның тиз генә китәргә исәпләре юк иде, алар келәт ишеге ачылганын шатланып көтәләр инде: аларга аннан нәрсә булса да сибәчәкләр бит!

—Көш-ш-ш, көш-ш-шегез, каһәр төшкән нәрсәләр!—дип ачуланып алды аларга Садыйк абзый. Аннары ул, тынгысыз тавыкларның китүләреннән тәмам өметен өзеп, келәт ишеген ачып җибәрде. Чыннан да, Сәләхи картның күзенә ташланган беренче нәрсә ап-ак итеп ышкылап түшәлгән идән булды.

—Син үзең бер дә тик тормыйсың икән, моны да рәтләгәнсең икән!—диде ул, идәннең бик пөхтә түшәлүенә карап.—Ярыкның әсәрен дә калдырмагансың.

Садыйк абзый, сүзне игътибарсыз үткәреп җибәрергә теләп, борыны астына мыгырданып алды:

—Маташтым инде шунда акрын-акрын...

—Акрын-акрын булса да, галәмәт шәп булган!

Садыйк абзый кайракны келәт ишеге төбенә тартып, яктыгарак китерде һәм әйләндерергә тотынды. Сәләхи карт балта йөзен ташка куйды һәм аннан, гыжлаган тавыш белән бергә, яктыга, кояшка чыгарга теләгәндәй, вак кына чаткылар караңгыга сибелә башлады.

Алар сөйләшми генә, бары балтага һәм кайракка бәйләнешле сүзләрне генә әйткәләп ала-ала, алмаш-тилмәш әйләндереп, кайрадылар. Бер унбиш минуттан соң балтаның кителгән җире тигезләнде. Картлар икесе дә аның йөзен бармаклары белән капшап карадылар һәм яхшы кайралган диган фикергә килделәр.

—Хәзер инде кул кайрагы белән шомартасы гына калды,—диде Сәләхи карт. —Электәге кебек үткен булачак. Саф корыч.—Ул, балтасын бусага янына сөяп куеп, кесәсеннән үзе белән бергә шактый гомер яшәгән, кайчандыр ачык яшел булган, хәзер инде билгесез төскә кергән тәмәке янчыгын чыгарды.

Алар, аркаларын ларга сөяп, арыш капчыклары өстенә уңайлап утырдылар. Сәләхи карт тәмәке янчыгын чиште, кечкенә китап кебек итеп, катлап, хәзерләп куйган газета кәгазенең бер битен ертып алды. Кәгазенә бер чеметем тәмәке салганнан соң, янчыгын яшьтәшенә сузды.

—Тукта, минем папирос бар бит әле,—диде Садыйк абзый һәм бишмәт кесәсеннән бераз янчелә төшкән папирос тартмасын чыгарды.—Улым алып кайткан иде. Әллә нигә бер тартам. Эч пошканда гына.

—Эч пошканнан яхшы нәрсә ул—тәмәке,—диде Сәләхи карт һәм спортчы рәсеме төшерелгән папирос тартмасын әйләндерә-әйләндерә карады.—Алай да иркәлиләр үзеңне. Тәмәкенең дә ниндиен алып кайтканнар.

Сәләхи карт, төргән тәмәкесен колак артына кыстырганнан соң, озынча яссы бармаклары белән бер папиросны алып, авызына капты. Кабыздылар.

һавага сыек зәңгәр төтен күтәрелде һәм, тирбәлә-тирбәлә, ишеккә таба йөзеп китте.

Сәләхи карт, бер-ике тапкыр суырганнан соң ук, гыжлап йөткерергә тотынды.

—Күкрәккә ярамый, йомшак,—диде ул һәм, колак артындагы тәмәкесен алып үрләткәннән соң, тартылып бетмәгән папиросын сүндереп, янадан тартмага тыгып куйды.—Безнең ише халыкка ярамый бу. Контордагылар гына тарта торган. Менә син минекен тартып кара. Саранск тәмәкесе. Бик зәһәр. Орлыгын шуннан алып кайтканнар иде. Бөтен күкрәкне рәхәтләндереп җибәрә, күзләр ачылып китә.

Бу юлы Садыйк абзый, буыла-буыла, йөткерергә тотынды. Саранск тәмәкесе аның өчен артык каты иде.

—Сирәк тартам мин,—диде ул, акланып,—оныткада бер генә.

Яшьтәше, аның урынсыз йомшаклыгын яратмагандай, көлемсерәп карап алды. Аның чал кергән сирәк кашлары астында инде янадан әлеге ике чаткы җемелди иде.

—Артык иркәлиләр сине. Карчыгың да салкын-мазар тимәсен, дигән була. Хәер, электә дә ул синең шундый иде.

Садыйк абзыйның бу темага сөйләшәсе килми иде, шуңа күрә дә ул сүзне икенчегә борырга теләде:

—Терлек абзарын кайчан салып бетерәсез инде? Бик озакка китте. Әллә бүрәнәләрегез, такталарыгыз җитешеп бетмиме?

—Барысы да җитәрлек. Нәрсә сорасаң, шуны китереп кенә торалар. Тик кешеләрне генә китерә алмыйлар. Чөнки юк. Җыен бала-чага. Аларның һәркайсын өйрәтергә кирәк. Балта да тота белми торганнары бар... Бер килеп чыгарга иде сиңа. Галәмәт яхшы абзар салабыз бит. Андый абзар әле тирә-күрше колхозның берсендә дә юк.—Сәләхи карт, чүгәләп, бармаклары белән идәнгә сызып күрсәтә-күрсәтә, яңа сыер абзарының ничек булачагы турында бик җентекләп һәм бирелеп сөйләргә тотынды. Бу минутта ул аны тузанлы идәнгә бармаклары белән сызып кына күрсәтми, ә сала, үстерә, һәм аның стеналары белән бергә үзе дә үсә шикелле итеп тоя иде. Аңа үзенең көче кергән нәрсәләр турында сөйләве рәхәт иде. Хәзер ул, үзенең яшьтәше янында да, колхоз төзелешендә эшләве белән мактана иде.—Менә монда,—диде ул, бер шакмакка төртеп күрсәтеп,—сыерлар бозаулый торган урын була. Ә яңа туган бозауны коридор аркылы менә монда алып киләчәкләр. Аларның һәркайсына, бишек кебек итеп, ящик ясатабыз, диделәр. Галәмәт була инде. Килеп чык әле бер, күреп китәрсең.

—Болай бик барасы килә үземнең. Бер дә җыена алмыйм шул.

—Җыена алмыйсың?—диде Сәләхи карт, аңа сәер генә карап.—Ә моны түшәргә җыена алгансың бит.—Ул, сүзен расларга теләгәндәй, кул аркасы белән идәнгә шапылдатып сугып алды. Аннары, чүгәләгән җиреннән торып, келәт ишегенә таба атлады.—Сыер абзарынны да менә дигән итеп сипләгәнсең. Кулың һаман да бик ята әле синең. Безнең яңга килеп яшьләрне өйрәтергә иде сиңа. Ә? Галәмәт шәп булыр иде.

—Әллә нигә бик картаеп киттем әле, яшьтәш,—диде Садыйк абзый, уңайсызланып кына.—Йә билем, йә аякларым сызлаштыргалап тора. Аннары беркөнне малай белән бергә доктор кереп чыккан иде. Йөрәк тә начар дигән булды.

—Йөрәгеңдә нәрсә соң?—диде Сәләхи карт, кинәт йомшарып китеп, һәм аның соргылт күзләрендәге әле кабынып киткән чаткылар, сүнеп, яхшылык аңкытып торган җылы, мөлаем нурга әверелделәр. Карт янадан капчык өстенә килеп утырды.—Анысы да сызлыймы әллә? Йөрәк сызласа, начар инде ул. Сакланырга кирәк, яшьтәш. Һе, шулай диген, ә? Йөрәк исән түгел, диген? Менә бит син аны...

Карт, кесәсеннән янчыгын чыгарып, янадан тәмәке төреп җибәрде. Бу юлы инде ул йөткертә торган бу каты тәмәкесен яшьтәшенә тәкъдим итмәде. Берничә минут алар, икесе дә үз уйларына бирелеп, тын гына утырдылар. Сәләхи карт, тәмәкесен тирән-тирән суырып, төтенен ашыкмыйча

өреп чыгара, ә Садыйк абзый, нәрсәдер әйтергә теләп тә, каян сүз башларга белмәгән шикелле, сакалын сыйпаштыргалап, идән тактасына текәлгән иде.

Келәт эченең тынып калганлыгын сизгән тавыклар, кыюланып, бусагага ук килеп менделәр. Әлеге, койрыгына салам каткан ак тавык, муенын бер сузып, бер җыерып, келәт эченә каракларча караштыргалап алды, хәтта идәнгә дә төште. Картлар аларга игътибар итмәделәр.

—Ә мин тагы болай гына, иркәләнеп киттең дип кенә торам,—диде Сәләхи карт үзенең ялгыш фикеренә үкенгән сыман.—Ике малае да сугыштан исән-сау кайтты, берсе колхозда—бригадир булып эшли, икенчесе—районда, җаваплы урында, мәйтәм. Шуңа күрә иркәләнеп ята торгандыр, дим. Менә бит мин, карт юләр, синең турында нәрсә уйлаган идем. Ә синең монда йөрәк икән! Борчыштыргалый дисең? Начар нәрсә инде ул.—Сәләхи карт, тәмәкесен төкереп сүндереп, итек үкчәсе белән изде.—Ә бар иде бит, әле күптән түгел генә нинди эшләп йөри идең. Исән булсаң, әле чыгар идең.

—Чыгар идем, билгеле.

—Сау кешегә хәзер өйдә ята торган заман түгел. Тегесен салырга, бусын үстерергә кирәк. Иркәләнергә вакыт юк... Газеталар укый торгансың бит?

—Укыштыргалыйм.

—Әнә анда Америка капиталистлары—ничек диләр әле аларны, исемнәрен ташка үлчим, уоллстрит диләрме әле? Теленне сындырырсың. Менә шул кабәхәт бәндәләр нишләмәкче булалар бит. Үз кулларындагы Германияне яңадан коралландырырга маташалар... Кореяны җир белән тигезләргә азапланалар... Бөтен дөньяны йотарга телиләр.

—Йота алмаслар,—диде Садыйк абзый, чын күнеленнән ышанып.

—Йота алмасларын мин дә беләм аны. Аларның тамакларына пычак булып кадалырбыз, тончыгып үләрләр. Гитлер да бик йотарга җыенган иде, булдыра алмады. Хәзер инде күмелгән кабере дә юк... Котырган этнең дә күмелгән урыны була, ә Гитлерның юк. Ә шулай да безгә, алар бу турыда уйлый да алмасыннар өчен, тагын да үсәргә кирәк. Бөтен колхоз белән, бөтен шәһәрләр белән,—диде Сәләхи карт һәм, иксез-чиксез Ватаныбызны кочаклап күрсәтергә теләгәндәй, кулларын киң итеп җәеп җибәрде:—Бөтен ил белән! Менә нәрсә, яшьтәш. Шуңа күрә дә хәзер исән кешегә иркәләнергә вакыт юк...

Ул арада өйалды ишеге ачылды һәм аннан Бибисаҗидә карчыкның тавышы ишетелде.

—Сиңа әйтәм, сиңа әйтәм, үзең генәме син анда? Нигә кермисең инде? Салкын-мазар тиюе бар.

Садыйк абзый урыныннан торды һәм, келәт ишегеннән башын чыгарып, кулын селтәп, коры гына әйтте:

—Бар, бар, үзенә салкын тимәсен.

—Чыгып та җиткән,—диде Сәләхи карт, көлемсерәп, һәм аның күзләрендәге әлеге чаткылар яңадан кабынып киттеләр.—Яшь баланы кадерләгән шикелле, кадерләп торалар үзенне. Хәер, анысы да кирәк.—Ул кулына балтасын алды, аның йөзен баш бармагы белән тагын бер тапкыр капшап караганнан соң, биленә кыстырды.—Кайрагың өчен рәхмәт. Шулай да син, яшьтәш, бер килеп кит әле безнең янга. Киңәшәсе эшләр дә юк түгел.

Сәләхи карт, салмак-салмак атлап, бераз бөкерәя төшеп, кечкенә капкадан чыгып китте. Садыйк абзый, нәрсәнендер очына чыгарга теләгәндәй уйчанланып, келәт алдында баскан килеш аның артыннан карап калды. «Аның иркәләнергә вакыты юк,—дип уйлады ул, аның уен дәвам иткәндәй.—Ә минем? Чыннан да, иркәләнәмме әллә мин?» Юк, ул иркәләнми шикелле тоелды аңа. Ничек итеп иркәләнсен ул? Кул-аяклары сызламаган, йөрәге борчымаган чагында эшләмәдемени ул? Ничек кенә эшләде әле! Колхоз председателе аны, авылдагы җыелышта булсын, райондагы җыелышта булсын, мактап бетерә алмый иде. Дөресен әйтик, Садыйк абзый тышыннан сиздермәсә дә, эченнән бу мактауны бик ярата иде. Шундый салпы ягы бар иде аның. Әле хәзер дә ул мактаулар аның күнелен рәхәтләндереп, җылытып торалар

һәм «өйдә, үз хуҗалыгында гына эшләргә хакым бар» дигән уен ныгыталар.

Тавыклар келәт эченә кереп тулганнар икән. Садыйк абзый кергәндә, алар, арыш капчыклары янына барып житеп, куанычларыннан шаулаша-шаулаша, капчыкны тишәргә, чукырга тотынганнар иде инде. Садыйк абзый аларны, ачуланып, бияләен ыргыта-ыргыта, өркетеп куып чыгарды.

Ул, өйгә кергәнче, ишек алды буйлап максатсыз гына әйләнеп чыкты. Яна бүрәнәләр белән сипләнгән сыер абзары янында, үз-үзен онытккандай хәрәкәтсез калып, басып торды. Чыннан да, ул яхшы, пөхтә итеп сипләнгән. Сыер жылысы аның мүк араларыннан гына түгел, хәтта ишегеннән дә чыкмый диярлек. Һава алмашыр өчен махсус төнлек ясалган. Тик шуннан гына пар чыгып тора һәм стена аша сыерның ялкау гына күшәгәне ишетелә.

Нәрсә булды соң безнең Садыйк абзыйга? Нигә ул шулай, бернәрсә уйламыйча онытылып, катып калган шикелле, бер урында басып тора? Инде терлекләргә азык салырга да вакыт житкән, тавыклар да, һаман тынгысызлап, артыннан ияреп йөриләр. Ләкин Садыйк абзыйның бернәрсәгә дә тотынасы килми, хәтта аның әнә анда, жирдә аунап яткан себеркене дә биегрәк урынга алып куясы килми. Кич белән сарыкларны эчәргә чыгарганда, алар аны, чәйнәп бөтенләй эштән чыгарачаклар.

Сәләхи карт килгәнче ул, бернәрсә дә уйламыйча, бөтен эштән күңелне тынычландыргыч бер ләззәт табып, ишек алдында рәхәтләнеп эшләп йөргән иде. Мич янында утырганда да ул өй тирәсендә эшләнгән эшләргә күңеленнән хисап биреп, киләчәктә эшләнергә тиеш эшләр турында план корып утырган иде. Сәләхи карт килде дә аның күңеленә нинди тынычсызлык орлыгы салып китте. Ул, кайчаклардагы шикелле, гадәте буенча, аңа каты итеп, күңелне кырырлык сүзләр дә әйтмәде. Хәтта, аның йөрәге начар икәнен белеп, дусларча игътибарлылык та күрсәтте. Шулай да ул, балтасын биленә кыстырып, табан салган итекләре белән салмак-салмак кына атлап ишек алдыннан чыгып киткәндә, үзе белән бергә аның тынычлыгын да алып китте.

Садыйк абзый, кич буе пошынып, нигә икәнен үзе дә белмичә, борчылып үткәрде. Улы, килене эштән, оныклары сабактан кайтып, табын янына жыелып утыргач та, аның күңеле күтәрелмәде. Ул сөйләшмичә, үзенә мөрәҗәгать ителгән сүзләргә өзек-өзек кенә жавап биреп, кашларын жыерган килеш ашады.

Ятар алдыннан карчыгы, аның кәефсезлеген сизеп алып, сорады:

—Сиңа әйтәм, нәрсә булды сиңа? Әллә авырыйсыңмы?—диде. Һәм шунда ук, аның жавабын көтмичә, кайгыртучан йөз белән сорауларын тезеп китте:—Әллә аягың сызлыймы? Әллә тагын йөрәгең борчырга тотындымы? Әйтәм бит мин сиңа, кер дә кер дип, кеше сүзен тыңламыйсың бит син. Нигә ул кадәр озак торырга иде сиңа? Аягың сызлый икән, жылы тун белән төрик. Кыска туныңны, жылынсын дип, мич башына куйган идем. Хәзер бирәм.

—Бернәрсә дә кирәкми,—диде Садыйк абзый. Ул почмак ягында, ялангач аякларын караваттан салындырып, һаман да шулай кашларын жыерган килеш утыра иде.

—Нигә кирәкмәсен?—диде карчыгы аңа каршы.—Аякларыңны жылы тун белән төреп куйсак, бөтен тәнең рәхәтләнеп китер. Май кебек йомшартып жибәрә ул.—Карчыгы, аның каршы килүенә карамыйча, мич башындагы тунны, жылысын качырмаска теләп, күкрәгенә кысып тоткан килеш алып килде:—Йә әле, ят әле, хәзер төрәм.

—Куйсана, зинһар! Нигә син мине баланы иркәләгән шикелле иркәлисең,—диде Садыйк абзый, яшьтәше әйткән сүзләрне хәтерләп.

Карчыкның йөзе жәелеп китте:

—Нигә иркәләмәскә? Картым бит син. Хәзер синең рәхәтләнеп, иркәләнеп ятыр чагың гына. Биргәнгә шөкер, гаиләбез түп-түгәрәк, барыбыз да исән-сау, балаларыбыз менә дигән урында, ашарыңа дисеңме, кияреңә бернәрсә дисеңме,—берсенә дә мохтаҗлыгыбыз юк...

Карты май кебек эреп китәргә хәзер торган карчыгына сагышлы һәм

сораулы күзләре белән карады:

—Шулай булгач, иркәләнеп ятарга кирәкмени?

—Нигә ятмаска?—диде карчыгы, ана гаҗәпләнеп карап.

—Ә башкалар? Әйтик, менә Сәләхи яшьтәш?..

—Ул да бик иркәләнер иде дә... анын тормышы шулайрак булып куйды шул. Башкалар дип тагын син?..

—Юк,—диде карты, анын сүзен бүлеп.—Ул иркәләнмәс иде. Андый камырдан ясалмаган ул. Ә дөресе, мин түгел, ул иркәләнергә тиеш иде. Анын хакы зуррак.—Ул, карчыгынын нишләтергә белмичә тотып торган кыска тунны кулы белән бер читкә этеп җибәреп, урыныннан торды һәм яланаяклары белән тәрәзәгә таба атлады.

—Нишләвен бу синен?—диде карчыгы, өтәләнеп.—Салкын идәнгә яланаяк басарга ярыймыни? Каталарынны ки тизрәк.—Һәм ул ана караватянында торган киез каталарын китереп бирде.

Карты карышмады, киде, әмма шулай да ул, карчыгын кызганган да һәм шелтәләгән дә шикелле итеп, әйтеп куйды:

—Аяк, аяк, дисен син. Хикмәт аяктамыни? Хикмәт менә монда,—диде ул һәм кулмәк изүе чишелеп, күренеп торган ялангач күкрәгенә төртеп күрсәтте.—Күнелем тынычсыз минем, карчык, менә нәрсә.

Ул, урынына килеп яткач та, тиз генә йокыга китә алмады. Инде электричество сүнгән, якты ай нуры кин көмеш тасма төсле булып, тәрәзә аша мич алдына кадәр сузылган иде. Ул, йокысыз күзләрен шул көмеш тасмага текәп, озак уйланып ятты. Ана аркасын бирөп, кечкенә булып йомарланып яткан карчыгы инде күптән йокыга киткән. Садыйк абзый, анын тыныч кына сузып-сузып сулавына колак салып, тынланып торды һәм анын беркатлылыгын, дөнья эшен анлап бетермәвен гафу иткәндәй, кызганып һәм шул ук вакытта яратып, эченнән әйтеп куйды: «Нәрсә белә сон ул мескен. Гомер буе ирем дип, балалар дип яшәде...»

## II

Садыйк абзыйнын аяклары турында Сәҗидә карчыкнын борчылуы урынсыз түгел иде. Чыннан да, анын аяклары яз һәм көз көннәрендә сызлаштыргалый, кайчакларында һаваларнын үзгәрүләрен дә шактый дөрес сизә иде. Анын әйтүенә караганда, бу коры сызлауны ул беренче бөтендөнья сугышы вакытында Пинский губернасындагы сазлыкларда оборонада яткан чагында алган иде.

Садыйк абзый бу күзгә күренми торган авыруны, крестьян гадәте буенча, зарланмыйча, ынгырашмыйча, ул турыда артык сөйләшмичә, бөтен гомере буенча саклап алып килде дияргә ярый. Ләкин бервакытта да ул, аяктан язып, авырып ятмады. Аннары анын карчыгына да бик зур рәхмәт! Ул аны, авылдагы тәҗрибәле карт-карчыклар өйрәткәнчә, төрлечә дәвалады: яз һәм җәй көннәрендә ямь-яшел кычытканга яланаяк сәгатьләр буенча бастырып торды, кызу ком өстендә йөртте, кырмыска кислотасы дип аталган сыекча белән дә, Кавказ ягыннан кайткан, аракыга салып ачыткан ниндидер тамыр белән дә уды. Анын аякларын корыда тоту, корыда тотудан да бигрәк, шуна өйрәтү һәм кышкы төннәрдә җылы тун белән урап яткыру турында инде сөйләп торасы да юк. Әллә инде шундый тырышып дәвалауларнын файдасы булды, әллә инде карчыгынын чамадан тыш җылы мәхәббәте, сызланмаган чакларда да анын бу авыруы турында өзлексез кайгыртуы, иренен үзенә караганда да артыграк борчылуы шифалы булып чыкты,—нәрсә генә булмасын, Садыйк абзый бу авыруын кайчакларда еллар буенча оныткалап та торгалады.

Күрәсен, авыру да кайчан сызларга, кайчан тынып торырга иканен белә булса кирәк. Бөек Ватан сугышы булды, Садыйк абзый ул еллардагы авырлыкны бөтен ил белән бергә үз җилкәсендә үткәрде, анын аякларынын корыда торуга караганда, юештә торган чагы, җылыда булуга караганда, тунган чагы, бәлки, күбрәк тә булгандыр, шулай да, әйтмәгән булсын, ул

аякларының сызлавыннан зарланмады. Әллә инде аларның сызларга вакытлары булмады, әллә инде Садыйк абзый кызу эш белән, Ватанның язмышы өчен чамадан тыш борчылу белән үткәргән ул елларда аларның сызлаганын сизмәде. Кем белә, бәлки, боларның икесе дә булгандыр, бәлки, аякларның сызлауларына караганда, ил кайгысы чагыштырмаслык дәрәҗәдә зур булганга барысын да басып киткәндер.

Сугыш бетте. Уллары, күкрәкләрен орденнар, медальләр белән тутырып, чыныгып, өлкәнләнеп, тормышка янача карый торган кешеләр булып, исән-сау кайтып керделәр. Кайтып керүләре белән үк алар ата-аналары җилкәсендәге авырлыкның иң зур өлешен үз җилкәләренә күчерделәр. Аяклары гына түгел, җилкәсе дә авыр йөктән бушанган Садыйк абзый, кайчандыр Карпат таулары арасында дошман гаскәрләренә каршы көненә дүрт-биш тапкыр атакага барган, Пинский сазлыкларында оборонада яткан, дөньяның барлык авырлыкларын батырларча күтәрә белгән карт солдат, җиңү һәм улларын күрү шатлыгыннан, балалар кебек, юк, балалар кебек кенә түгел, нечкә күңелле карчыклар кебек, йомшап китте. Без аның карт күзләреннән чыккан берничә бөртек яшь турында әйтмибез. Күз яшьләренең чыгуы мөмкин һәм чыкмавы да мөмкин. Аннары шатлыктан, җиңү сүзенең бөеклеген аңлап, карт солдатларча, горурланудан тамган күз яшьләре бервакытта да оят түгел.

Эш күз яшендәмени! Ул менә уллары кайту белән үзенең физик яктан йомшарганын, көченең көннән-көн кими барганын сизеп алды. Моңа нәрсә сәбәп булгандыр: сакал-мыекны гына түгел, баштагы чәчне дә елдан-ел агарта барган шул каһәр төшкән картлыкмы, әллә инде өлкәнләнеп кайткан, атасының хезмәтләрен тәкъдир итә белгән улларының ихтирамнарымы? Кем белә, монда беренче сәбәпнең дә, шулай ук икенче сәбәпнең дә йогынтысы булмый калмагандыр. Чәч инде ул берәүдән дә сорамыйча агарганнан-агара бара, ә уллары менә, колхоз председателеннән сорап, аның белән киңәшеп, аталарының өйдә утыруын, аның колхозда эшләүгә караганда, өй тирәсендә йөрештергәләвен артыграк күрделәр. Иркәләү идеме бу, әллә ихтирам идеме? Ләкин үзенең табигате буенча хезмәтне сөйгән, бөтен авырлыкларны күтәрә белгән, үзен генә түгел, улларын да чыдамлы итеп тәрбияләргә тырышкан Садыйк абзыйның күңеле иркәләнү дигән сүзне кабул итәсе килмәде. Ул моны ихтирам итеп кабул итте.

Нинди гаҗәп! Аның аяклары яңадан сызлаштыргалый башлады. Ләкин кичә, Сәләхи карт килеп киткәннән соң, ул үзенең тынычсыз аякларына түгел, ә күңеленә урын таба алмады. Хәтта иртәгесен дә ул төшкә кадәр беркем белән сөйләшмичә, һаман шулай кашларын җыерып, ишек алдына чыккалап эшләп йөрде.

Карчыгы, аның бүген дә күңелсез йөргәнен күреп, пошынып, берничә мәртәбә сорады:

—Нәрсә булды соң сиңа? Нигә кашларыңны җыерып йөрисең? Сөйләшмисең дә! Әллә Сәләхи карт белән сүзгә килденме? Берәр каты сүз әйттеме үзенә?

—Берәү белән дә сүзгә килмәдем,—диде Садыйк абзый сүрән генә. Карчыгының яңадан очсыз-кырыйсыз сорауларны тезергә хәзер торганын һәм аның чыннан да бик борчылганын күреп, кыска гына әйтеп куйды:—Кәефем юк. Болай гына.

Карчыгы исә шунда ук яңа сорауларын тезә башлады:

—Ничек инде ул болай гына? Кешенең кәефе болай гына бозыламыни? Бәлки, җил-фәлән тигәндер? Әллә, баллап, мәтрүшкәләп чәй эчеп, төргәләнеп ятып карыйсыңмы? Шулай итсәң, күңелең ачылып китмәсме икән? Әллә инде мунча ягып җибәрикме? Яхшылап парланып, каен себеркесе белән чабынсаң, рәхәтләнеп китмәссеңме?

—Бернәрсә дә кирәкми,—диде карты, кулын селтәп.—Ташла әле, зинһар, шул бетмәс сорауларыңны. Сиңа минем карчык булырга түгел, ә судья булырга кирәк иде. Сораша-сораша гаепле кешеләрнең җаннарын алыр идең. Синең хөкем карарыннан куркуга караганда сорауларыңнан куркарак төшәрләр иде.

Карчыгы, иренең бу мактавыннан, бик кәефләнеп, көлеп җибәрде һәм шунда ук сорау белән җавап кайтарды:

—Әллә булмас идемме? Без яшь чакта шулай совет булып, хәзерге шикелле укытсалар, кемнән ким-хур булыр идем мин? Анда эшләүчеләр кемнәр соң алар? Безнең шикелле кешеләр түгелмени?

—Тагын башланды,—диде карты, түзә алмыйча елмаеп.—Булмаса, миңа тышлы тунны бир әле. Бераз авылдан әйләнеп кайтыйм.

—Кая бармакчы буласың?—диде карчыгы аңа тунын кидертә-кидертә.—Озак тормассың бит?

—Хәзер кайтам,—диде Садыйк абзый һәм, чөмәкле артыш таягын кулына алып, чыгып китте.

Карчыгы аның кая таба киткәнен тәрәзәдән карап калды. Ул, таягын селтәп ала-ала, урам уртасындагы чана юлыннан авылның арбашына таба ашыкмый гына китеп бара иде. Карчыгы, аның белән сөйләшкәндәй, үзенең гадәттәге сораулы җөмләләре белән уйлады: «Кая бара инде бу карт нәрсә? Ат юлыннан бармаса ярамас идеме икәнни? Сукмакка сыймыйсыңмы әллә? Машина-фәлән килеп чыгар дип тә курыкмыйсыңмы?..»

Садыйк абзый караңгы төшәр алдыннан гына кайтты. Салкыннан аның яңаклары, итләч борыны шактый кызарган, сакал-мыегына һәм куе кашларына бераз бәс тә кунган иде. Ул, өйгә кергәч, җылынып киткән бәсләрне, пошкыра-пошкыра, бармаклары белән йолкып алып ыргытты. Карчыгы аның пошкырган, ярым тамак кырган кебек тавышыннан ук кәефенең яхшылыгын, күңеленең күтәрелгәнен сизеп алды.

—Кайттыңмыни?—диде ул аның шулай күтәренке күңел белән кайтып кергәненә шатланып.—Кайларда булдың? Нәрсәләр күрдең? Яңа салына торган терлек абзарлары янында булдым дисеңме? Салып бетерәләрме соң инде аны, юкмы? Күпмесен күтәргәннәр?

Садыйк абзый аңа бу юлы үзенең күргәннәрен һич тә кыстатмыйча сөйләп бирде, хәтта Саҗидә карчыкка сорауларны да ара-тирә генә бирергә туры килде.

Тыштагы эшләрне бетереп кергәннән соң, карт, бөтен гаилә белән табын янына утыргач, һәм тамагын бераз ялгагач, сүзне янәдән терлек абзарларына күчерде.

—Бик тә яхшы булачак икән,—диде ул, башлаган сүзен дәвам иткәндәй,—рәхәтләнеп карап йөрдем.—Мондый абзарны күргәнем юк иде әле. Тирә-күрше колхозларда да юктыр әле аның кебек.

—Электә юк иде. Хәзер бар. Кайберләре салалар,—диде улы.—Проектын Казаннан, министрлыктан алып кайттылар.

Улы өстәлнең икенче ягында, аңа каршы утырган һәм алдындагы ашын ашыкмый гына бик тәмләп ашый иде. Ул да, атасы кебек, зур гәүдәле, киң кашлы, ләкин аның шикелле түгел, ә кылыч борынлы һәм калын иренле иде. Тик ул маңгае һәм күзләре белән бераз гына анасына охшый төшкән иде. Ләкин аның мөлаем күзләрендә яхшылык сирпеп торган чаткылар гына түгел, властьлылык, үз-үзенә ышану да бар иде. Анасының күзләрендә булмаган бу сыйфатларны ул Ватан сугышыннан алып кайтты. Гвардия ротасында старшина булып хезмәт иткән улының бу яңа сыйфатларын тормыш тәҗрибәсе зур булган һәм солдатка бәя бирә белгән атасы бик тиз сизеп алды һәм ошатты. Ул аңа улы итеп кенә түгел, көчле ихтыярга ия булган, властьлы күз карашлы һәм үз-үзенә ышанып, уйлап эш итүчән кеше итеп карый башлады. Аннары аның, колхозда кырчылык бригадиры булып, соңгы елларда иген уңышы буенча ярышта беренче урынны алып килүе дә атасы күңелендәге ул карашны ныгытуга сәбәпче булды. Шуның белән бергә, ул үзе дөрес дип ышанган нәрсәне эшләтергә теләгәндә, аңа каршы килүче булса, кырыс та булып китә иде. Атасы аның бу сыйфаты турында уйлаганда, эченнән елмаймыйча калмый иде: «Минем шикелле»,—дип уйлый иде ул, моннан нindидер җанны рәхәтләндергеч бер ләззәт табып. Улының кайчакларында шундый кырыслыгы булганга күрә, ул әйтергә теләгән сүзен, ерактан урап килеп, киңәш төсле итеп куярга теләде.

—Проекты да яхшы, абзары да яхшы булачак,—диде Садыйк абзый, җәймәдәге икмәк валчыкларын кулы белән бер урынга сыпырып китерә-китерә.—Аның шулай булачагы күренеп тора. Колхозчылар да инде салынып беткәнен бик көтәләр. Колхозга ямь биреп торачак. Кайсы колхозныкы бу? «Ирек» колхозыныкы диячәкләр. Менә бит ул ничек! Котәрлек тә шул. Тик бик әкрен салалар. Болай салсалар, киләсе көзгә дә бетерә алмаслар. Нигә алай әкрен салалар соң аны?—диде ул, улына бераз елмаеп карап һәм җәймәдәге валчыкларны сыпырудан да туктады.—Болай әкрен салмаска кирәк иде бит!

—Кеше житешми, әти. Күрәсең бит, кырыкка ярылабыз.

Атасы, сакалын учлап тотып, аны уыштыргалап, бераз уйланып торды.

—Һе,—диде ул, үз-үзенә эндәшкәндәй,—кеше житешми диген, ә? Шулай ук колхозда кеше житешми башладымыни инде? Менә бит ничек икән ул.

—Шулай шул,—диде улы, ашавында дәвам итеп.

—Әгәр дә мәгәр менә минем кебек картлар чыкса? Ягъни, әйтик, мин чыксам?

Сажидә карчык, моны ишетеп, иренә берничә сорау бирергә хәзер иде, хәтта беренче сорауны бирергә дип, авызын да ачкан иде, әмма улының атасына житди генә итеп күтәрелеп караганын күргәч, бераз көтеп торырга булды.

—Әти,—диде улы тыныч кына,—син моны чынлап әйтәсеңме, әллә болай гынамы? Әгәр чынлап әйтәсең икән, без инде бу турыда берничә тапкыр сөйләшкән идек. Абый да сөйләште бит. Эшләгән эшең житәрлек синең. Кирәк чагында эшләмәдең түгел. Аннары сиңа анда эшләргә дә ярамый. Озакка сузыла торган эш ул. Яңгыры, салкыны, бураны дигәндәй... Аякларыңның ничек икәнен беләсең бит син. Бөтенләй урынга ятуың мөмкин...

Сажидә карчык, улының иң кирәкле сүзләрне әле һаман да әйтмәгәнен күреп, сүзгә кушылырга кирәк тапты:

—Сиңа әйтәм, нигә кымыржыйсың син? Нигә кирәкмәгәнгә кычынасың? Нәрсә житми сиңа? Колхозда эшләүчеләребез юкмыни безнең? Бер таңнан алып икенче таңга кадәр кемнәр эшли—безнекеләр эшли.

Ләкин аның сүзләренә карты да, улы да игътибар итмәде, карчык шулай үзенең бик урынлы кыстырып куйган сүзләреннән канәгать иде.

Улы, атасының үз сүзен итәргә торганын һәм салынып торган куе кашларының дугаланып килгәнен күреп, аның теләгенә каты каршы килмәскә булды:

—Ярар,—диде ул, аның фикере белән килешкәндәй,—председатель белән сөйләшеп карармын. Аннары бу көннәрдә абый да кайтып китәргә тиеш. Ул да нәрсә әйтер. Бер караганда, синең көз һәм кыш көннәрендә өй тирәсендә генә йөрүең яхшы булыр иде. Терлек-туарны карарга да кеше кирәк бит. Без, Җәмилә белән икәү, күрәсең, өйгә дә кайтып кермибез,—диде ул һәм самовар янында сүзсез генә утырган хатынына карап алды.—Менә сыер бозаулар, сарыклар бәрәнли башларлар. Җәмиләне колхоз эшеннән аерасым килми минем. Әни балалар яныннан да бушый алмый. Ә сиңа мөмкин. Синең яшең дә инде... Аннары сине эшкә чакырмыйлар да бит.

—Ә Сәләхи яшьтәшне нигә чакыралар!—диде Садыйк абзый, улының сүзен бүлеп.—Мин нигә мыеклы да, ул нигә кыеклы?

—Ул үзе йөри,—диде улы, бераз уйлап торганнан соң.—Ана йөрмәскә дә туры килми. Аның, безнең шикелле, жимереп эшли торган кешеләре юк.

—Менә шул-шул. Аның жимереп эшли торган кешеләре юк, ә минем бар. Без соң барыбыз да бер колхозны үстерибез түгелме? Нигә ул, камыт киеп, йөкне тартып барырга тиеш тә, мин утырып барырга тиеш?

—Син утырып бармыйсың, әти. Һәркем, үзенең хезмәт көненә карап, үзенә тиешлесен ала.

—Тукта, син минем сүземне бүлмә,—диде Садыйк абзый, урыныннан торып, һәм, улының сүзләреннән таңга калгандай, кулларын җәеп җибәрде:—Бәрәннәр, дисең. Син мине шул дүрт аяклы бәрәннәр янына бәйләп куймакчы буласың. Бәрәннәрем минем син туганчы да бар иде, хәзер дә бар. Менә

анаң белә, безнең бервакытта да бәрәннәребезнең тышта катып үлгәне булмады, ачтан да интегеп йөрмәделәр. Әллә мин аларны хәзер карый алмам дисеңме?

—Синең аякларың, йөрәгең...—дип әйтә башлаган иде улы, атасы аның соңгы сүзен тотып алды.

—Йөрәгем шуны куша, аякларым шунда таба тарта,—диде ул.

—И-и, карап-карап торам да, әллә инде кычкырыша да башладыгыз?—диде Сәҗидә карчык, алар арасына кереп.—Нәрсә бүлешәсез соң сез? Нәрсә җитми сезгә?

Шакирның эш белән чыгып китәсе бар иде. Ул, өстен киенә-киенә, атасына акыллы күзләре белән карап, тыныч кына әйтте:

—Синең сүзең дөрес, әти. Колхозда барыбыз да эшләргә тиеш. Тик мин сине, терлек-туар тирәсендә йөртүдән бигрәк, әти итеп, хөрмәт итеп, олылап, өйдә тотарга телим. Аңлыйсыңмы, олылап. Сугыш елларында син безнең барыбыз өчен дә эшләдең. Хәзер инде без өйдә...

Ана карчык, улының шундый ягымлы сүзләрен ишетеп, бөтенләй эреп китте:

—Ишетәсеңме, сиңа әйтәм, олылап бит ул, олылап,—диде, алар тирәсендә орчык шикелле бөтерелеп.—Безне олылыйлар бит алар, рәхмәт төшкерләре... Ай, авызыңа бал да май...

Карт инде тынып калган иде. Күрәсең, аңа да бу сүз бик нык тәэсир итте булса кирәк. Ул, кинәт йомшарып киткән борынын тартып, тәрәзәгә таба борылды һәм, өйдәгеләргә күрсәтергә теләмичә, күзләрендәге ике бөртек яшьне кул аркасы белән сыпырып төшерде. Улы ишекне ябып чыгып киткәч, ул, тәмам тынып, уйчанланып, мич буендагы скамьягә барып утырды. Мичтән аркага рәхәтләндереп җылы бәреп тора, ул бөтен тәнгә, тамырларга тарала, хәтта йөрәкне дә үзенең җылы һәм бик йомшак, бик йомшак пәрдәсе белән урый шикелле. Идәндә Шакирның ике баласы уйнап йөри. Күптән караңгы төшүгә карамастан, алар әле һаман да йокламаганнар. Иң кечкенәсе, әле ике-өч ай элек кенә тәпи йөри башлаган кыз, абые артыннан калышмаска тырышып, каз бәпкәсе канатларын җилпегән шикелле, кулларын күтәрә төшеп бутый-бутый, идәннең бер башыннан икенче башына йөгерә. Бабасы аларга таба, елмаеп, бик яратып, берникадәр вакыт карап торды. Бу минутта инде аның күңеленнән җанны эреткеч, гаҗәеп җылы хисләр ташый иде. Ул хисләр үзләренең күзгә күренмәс нурлары белән шул идәндә уйнап йөри торган балаларга, колхоз эше белән караңгыда каядыр чыгып киткән улына, эштән арып кайтуына карамастан, почмакта савыт-сабалар юучы килененә, тормыш мәгънәсен һаман да әле беркатлы аңлаучы, дөнья хәлләрен төшенә алмаучы карчыгына, хәтта өйдәге җан иясе булган, мич буенда йоклап яткан мәчегә дә юнәлгән иде.

Садыйк абзый иң кечкенә оныгын, янынннан йөгереп үткәнен сагалап торып, күтәреп алды. Бала шатлыгыннан шыркылдап көлеп җибәрде һәм шунда ук, бабасының алдына менеп утырып, кечкенә генә аякларын селки-селки, абыеңа таба төртеп күрсәтеп, үз телендә тәкелдәргә тотынды.

—Йокларга кирәк, кызым, йокларга,—диде бабасы, үзенең зур кытыршы кулы белән аның тузгыган башыннан сыйпап.—Йә әле, минем казаки эченә кер, кач әле абыеңнан. Тукта, тукта, кызым, борын астыңны тәти итик.—Һәм ул, кызының күлмәк итәген кайтарып, аның борынын сөртеп алды.

Бабасы аны әкрен генә иркәли һәм, йокласын дип көйләп, авыз эченнән үз-үзенә сөйләнә иде:

—Шулай булмыйча соң, кызым, билгеле, олылап... кадерләп ... ата итеп... Башкача ничек булсын тагы... Ата итмәскә соң... Шулай да өйдә ята торган заман түгел хәзер...

Озакламыйча бала аның алдында, җылынып, изрәп йоклап китте...

❀

# КҮҢЕЛ ОФЫКЛАРЫ

## БИКӘ РӘХИМОВАНЫҢ ЯҢА КИТАБЫН УКЫГАЧ

Безнең кулда — шагыйрәнең сайланма әсәрләре «Иделләр казанында». Бу җыентыкның бер үзенчәлеге бар — андагы әсәрләр кайчан, ничек иҗат ителгән, шул килеш һәм шул тәртиптә биреләләр. Монда—җанлы тормыш биографиясе, хис-күңел биографиясе, милләт, халык, Ватан язмышын җан кыйбласы итеп алган олы шәхес язмышы...

Бикә Рәхимованың исеме татар укучысына күптән таныш. Аны лирик әсәрләр остасы буларак та, балалар өчен табигый-самими шигырьләр язучы әдибә буларак та, шулай ук публицист, хикәяче, тәрҗемәче буларак та, күп еллар Татарстан китап нәшриятында эшләгән мөхәррир сыйфатында да яхшы беләләр. Шулай да, ул иң элек—шагыйрә. Үзенчәлекле, үзенә генә хас шигъри аһәң-интонациясе, холкы-характеры, темалары, образ-сурәтләре булган шагыйрә.

Бикә ханым, башка күп кенә хатын-кыз шагыйрәләрдән аермалы буларак, актуаль һем интеллектуаль лирика канатындарак иҗат итә. Аның һәр шигъри юлыннан, фикер сөрешеннән, образ-сурәтеннән зыялылык һәм затлылык бөркелеп тора, ул форма ягыннан да, эчтәлек ягыннан да халыкчан (авылчан) лириканы интеллектуаль-фикри (шәһри) лирикага куша алган. Аның шигырьләрендә моң, ритм, гармония үзгә. Бу моң бик тирәнтен яшерелгән, күпләрнеке кебек, күзгә кереп тормый, өстә йөзеп йөрми, тирәннән бәреп тора. Ә бит мәгълүм нәрсә: тирәннән бәреп чыккан чишмә суы чистарак та, шифалырак та була... Бикә Рәхимованың шигърияттен мин нәкъ шулай кабул итәм.

* * *

Шигърият, шигъри сүз—илаһи төшенчә. Шуңа күрәдерме, шагыйрьләрне, дөресрәге, аларның иҗатларын галәми образлар аша күзалларга күнеккәнбез. Берләрен Кояшка йә Айга тиңлиләр, икенчеләрен йолдызлар белән чагыштыралар, өченчеләре аяз күккә, кауршй болытларга, яшен-күкрәүләргә, аҗаган балкышына тиңләнә.

Бикә Рәхимованың иҗатын мин офыкка тиңләр идем. Әйе, Җир белән Күк тоташкан чик сызыгы үтә бу шагыйрә иҗатыннан. Офык ул—илаһи Күк белән гөнаһлы Җир кавышкан урын, төн белән көн, яктылык белән караңгылык арасындагы алыш мәйданы, ниһаять, күз алдындагы чынбарлыктан чиксез хыяллар дөньясына алып керә торган галәм капкасы... Иң кызыгы, шагыйрә үзе дә шигъриятнең мәгънәсен шушы образ аша күз алдына китерә икән:

Каным, җаным, бәгърем, сулышым да
Һәр сүземә кереп таралсын!
Дөньяның һәр тараф чигенә
Минем күзем белән каралсын...

*("Яралар яңарган".)*

Офык—көрәш символы, дидек. Чынлап та, Б. Рәхимованың һәр шигырендә, һәр фикер төенендә яки хис йомгагында көрәш рухы, фидакарьлек һәм батырлык белән очрашабыз. Лирик яисә фәлсәфи парчамы, мәхәббәт шигыреме, актуаль-сәяси лирикамы, яисә күләмле поэмамы—шул ук киеренкелек, офык чиге, көчеш мизгеле, көрәш... Шагыйрәнең эчке күңел хасиятләрен, холкын, яшәеш асылын да, рухын да шушы офык чиге билгели: бер караганда ул үтә да самими, эчкерсез, саф, хәтта, яклаучысыз-гаҗиз калган хатын-кыз ("Хәува"), икенче караганда—көрәштә чыныгып үскән, кан тамырларында көрәш рухы, яшәү ярсуы тибеп торган көчле шәхес ("Ачулы чагым"). Үзенең эчке "җан диалектикасын" шагыйрә яшерми:

Күзәнәкләр тетри-таумы, ташмы?
Тау-таш тетрәгәндәй куркыныч.
Ләкин үз-үземне тота беләм,
Үтәли күр, кара—мин тыныч!

*("Тынычмын".)*

Менә ул офыкның бер кыры: кайвакыт шагыйрә табигатькә шулкадәр якын килә ки, агачлар, чәчәкләр белән җандаш булып яши башлавын сизми дә кала ("Аңлашу", "Яфрак—гөлгәдер", "Яшел агач акыллырак" һ. б.) Икенче очракта ул табигатьтән шулкадәр еракลаша, хәтта, куркыныч дәрәҗәдә ераклаша башлый, табигый яшәеш кануннарыннан шактый аерылып торган сәяси гыйбрәтләр, социаль катаклизмнар, тарихи хөрлек, гуманизм, кыскасы, халык язмышы хакында язарга керешә. Мондый әсәрләр күпчелек. "Сак бул", "Ни килә?..", "Яңгыравык исемебез", "Тарих языла", "Кулыңда тот" ("Язмышың ялгышып китмәсен, учыңа йомарла котыңны!")—аларның бер өлеше генә.

Бүгенге сәясәт, иҗтимагый хәрәкәт өермәләре дә шагыйрәнең игътибарыннан читтә калмый: "30 август бәйрәме", "1 Май, Ирек мәйданы, Казан, 1991" ("Трибунада—курку катыш ачу..."), "Безгә дигән ирек" ("Кирәк икән, азатлыкны күз буып та алыйк без!"), "Әләм тотып бара" ("Кем уйлаган сиксән яшьтә әләм тотып барасын...") һ. б.

Күңел офыгының тагын бер кыры—үткән белән киләчәк очрашкан мизгел. Бу кыр да шагыйрәнең йөрәге уртасыннан уза ("Туган якларда", "Әйтү кирәкме", "Өмет", "Күңелем актарылганда" һ. б.).

Офык символына салынган тагын бер мәгънә — акыл (фикер) һәм хис (тойгы) гармониясе...

Их, уйлаган сүзне әйтәсе!..
Йөрәк тыя, акыл әйдәсә...

*("Баллар белән телем балладым".)*

Үкенечле, әрнүле уй-хисләр еш кына бу гармонияне таркатып җибәрәләр; шагыйрәнең ихлас күңеле ничек кенә тыныч калырга тырышса да, барыбер, үзе дә сизмәстән, кабынып китә, җан-күңел кысаларыннан ташып чыга, шулай да, кулына кылыч алмый, күңелендә генә яшен яшьнәтә:

Үзем кылычлы булсам да,
Җаным күбәләк кебек...

*("Бәргәлисең мине, Тормыш".)*

Соңге-кылыч алмыйм, хәтта инә,
Куып йөрмим ачу, саклап кинә.
Әмма бүген бик ачулы чагым—
Гүя чаян, йөрәгемне чактым.

*("Ачулы чагым".)*

"Чәчәк белән кылыч" шигырендә дә шул ук хәл. Хәтта, шагыйрә үзе гаҗәпләнеп куя: "И Ходаем, чәчәк белән тагын янәшә кылыч",— ди ул. Бу янәшәлекне бик җиңел аңлатып була. Кылыч—көчле рух, каһарманлык, ир-егетлек, көрәш символы, чәчәк—йомшак, нәзберек күңелле хатын-кыз, ана, мәхәббәт символы. Менә шушы ике арада бәргәләнә шагыйрәнең җаны. Бу каршылык, икеләнү, бәргәләнү шулкадәр тирәнгә киткән ки, шагыйрәнең күңел дөньясы кырт урталай ярылган. Әчке тавышы югалган, җан авазы яңгырашына шомлы аһәң кергән... Кайчакта ул күңел офыгының чиген югалта язып кала, әмма һәрвакыт үз кыйбласына кайта. "Мине төзәтеп торучы тавышны югалттым",—ди ул бер шигырендә. "Өмет бар", "Тиң булсын" әсәрләрендә дә шул ук борчылу, җан газабы.

Әлбәттә, һәркемгә мәгълүм: иң элек яшәеш үзе катлаулы, шуңа күрә шагыйрәнең тоемчан йөрәге дә катлаулы; ул өзгәләнә, бәргәләнә, эзләнә, үзен-үзе кая куярга белми. Менә шундый кызык шәхес белән очрашабыз без бу җыентык битләрендә. Шунысы сөендерә: гуманистик башлангыч, яктылык, хатын-кызлык, сөю хисе ачуны да, чарасызлыкны да җиңеп чыга. Б. Рәхимованың яшь буын, мәктәп, татар китабы, шигърият, җыр язмышына, саф мәхәббәткә багышланган әсәрләрендә бу аеруча ачык сиземләнә. "Иркен сулыш алыйм дисәм, Сулышым иркен түгел",—дип башланган, беренче карашка, икеләнү, чарасызлык шигыре, мәсәлән, якты, кояшлы хисләр белән тәмамланган:

Ә шулай да, мин кайсысын
Сайлыйсын белер идем:
Кояш балаларын җыйган
Мәйданга килер идем...

Ә менә бу юллар җыр, китап, ягъни шигърият, рухи мирас язмышы хакында. Аларны да "өмет юллары" дип билгеләргә кирәктер.

Яраланган шәфкать туташыдай,
Буыннарны безнең җыр бәйли!

*("Буыннарны безнең җыр бәйли".)*

Кояшка күтәрдем шигырьне,
Күрегез—манчылды нурларга!

*("Кояшка күтәрик".)*

Бикә Рәхимованың иҗатында мәхәббәт лирикасы аерым урын тота. Әмма анда күп кенә шагыйрьләребез иҗатында киң таралган традицион образларны сирәк очратабыз. Шундыйларның берсе—"сандугач" образы ("Сандугач булсам әгәр"). Бу теманы ачучы образ-сурәтләр шагыйрә иҗатында күпкә катлаулы. Еш кына аларны аңлап бетерү дә мөмкин түгел. Менә, мәсәлән, Б. Рәхимовада үпкәләү ничек бирелә:

Якты, якты, якты яктан,
Якты шул күләгәң дә...

*("Холык-фигыль".)*

"Бар ич бурычым" шигырендәге каршылыклы символларны да күрми калу мөмкин түгел:

Караңгы бит кара гына түгел,
Кара янып ут-хис уйнасын!

Ә менә монысы чарасызлык образы:

Юлыма ак булып төшә
Синең җаның шәүләсе!

*("Өндәгечә төшкә керден...")*

Шушы ук алым Сак-Сок мотивы кысаларында да уңышлы кабатланган. Шундый ук чишелеш: "Сак белән Сок булсак та без... юлымны аралап күрсәтә синең нурың яктысы",—дип яза ул бер шигырендә.

Ниһаять, яралы йөрәкне юату мотивы:

Әллә яра, әллә күңел
Тынган инде, чигенгән.
...Җан талпына, узыйм, диеп,
Мөмкинлекләр чигеннән...

Шул ук фәлсәфә: офык, чик, күчеш фәлсәфәсе. Сөю хисе дә гел күчештән тора түгелме соң: Мәхәббәт—*сагыш*—югалту, үпкә-зар... Яки киресенчә: Югалту—сагыш—табу, олы сөю хисе. Ничек кенә яклаучысыз яки, киресенчә, дуамал-усал булмасын, шагыйрәнең яралы йөрәген тутырып торган әрнүле сагышны сизми калу мөмкин түгел.

* * *

Бикә Рәхимова тудырган образлар хакында берничә сүз. Искиткеч кызык һәм гыйбрәтле образ-символлар белән эш итә ул. Башта ук искәртеп куярга кирәк: шагыйрә үз әсәрләрендә татар халкының гомуми образ-сурәтен тудырырга омтыла. "Көн кадагына суккан шигырь", "Халыклар, холыклар", "Җиңеләбез..." кебек шигъри әсәрләрдә Халык образының төп чалымнарын шәйләү кыен түгел. Шунда ук бер нәрсә күзгә ташлана: автор үз халкының бүгенге холкы һәм гамәлләре белән бик үк разый түгел. Аның таркау, кыюсыз, гаҗиз булуына ачынып яза, бәхет эзләп туган җирләреннән читкә китүчеләрне битәрли, хәтта, заман шаукымнарына бирелгән яшьләребезгә дә каты шелтә элгә... Әмма укучыны ялгызлык кочагына да ташларга теләми шагыйрә. Хөрлеккә ирешүнең, күңел тынычлыгының ике юлын да күрсәтә: берсе Ходайга сыгыну, рухи сафлану, иманга кайту булса, икенчесе—уйларда һәм гамәлләрдә халыкка якынаю, шәхси омтылыш-хыялларны халык, милләт, ил омтылыш-хыялларына көйләү:

Халык белән уйны берләштереп,
Күтәрелсәк иде хөрлеккә!

Шушы үзәк образ эченнән башка төп образ-символлар чыга. Сандугач, мәсәлән, җан символы. Шагыйрә иҗатында ул ике яклы—якты сөю һем тирән хисләрне бирүче символ.

Шулай ук гөлчәчәк ("Гөлчәчәккә карап исем китә, теле дә юк, үзе иркәли"), яшел агач ("Яшел агач акыллырак"), ак каен (Сталин репрессияләрендә газапланган язмышларны, сындырылган, сытылган каен аша сурәтләү) символлары да матур бирелгән. Тагын бер кызык, татар әдәбиятында шактый ерак традицияләргә ия символ—арба символы. Бу

символның тарихы, диңгез буенда яшәп, көймә-корабларда дөнья гизгән бабаларыбыз мифологиясенә кадәр барып җитә. (Юкка гына төрки-татар арбасын көймәгә охшатмыйлар бит!) Арба—гомер символы, язмыш билгесе дип тә әйтергә мөмкиндер. Тәгәрмәч үзе вакыт символы әле!

Иртә таңда кояш белән
Мин дә торам, җыенам.
Җәмәгать арбасының бер
Чит-чатына сыенам, —

ди шагыйрә. Бу шигырь җыентыкның башында бирелгән, димәк, элгәрерәк язылган. Ә менә соңгырак елларда язылган юллар:

Мин әзергә бәзер бәндәләрнең
Түгел фикердәше-сердәше.
Үз арбамны үзем этүче мин,
Һәрчак хәләл минем тир-яшем!

Сиздегезме — шәхес ничек үзгәрә, ничек үсә!

Б. Рәхимова иҗатында Идел—вакыт символы. Китапның исеменә чыгарылса да, бу символ әлегә зәгыйфь эшләнгән.

Ак кар символы илаһи мәгънә алган. Ул Ходай ихтыяры, Ходай мәрхәмәте буларак кузаллана ("Кар ява"). Аргамак ат символы да шул ук эчтәлектә бирелгән.

Көрәш ике яклы. Чикнең икенче ягында—күңел кайтаргыч образ-символлар. Шулардан иң яхшы эшләнгәне—кара кош символы. "Тукай әйткән кара кош" шигырендә үк үзәккә чыгарылган бу символ. Ул "Җәүһәр Дудаев үлеменә" багышланган әсәрдә зур тарихи мәгънә белән ачылып җитә:

Бәбкәләрне ничә гасыр буе
Кара кош ала...

Сәяси шартлы риторикадан арынып, бу кадәр образлы итеп ачылганы юк иде әле чечен трагедиясенең. "Империя тормышы", "Россияле зары", "Кешене төпченә" дигән шигырьләргә салынган эчтәлек эченә кергән дә беткән.

Каракоштан чукылганнар шулай
Гомере буе ирек юксына...
*("Әйтү кирәкме?..")*

Б. Рәхимова мифологиядән кергән образ-символларны яратып куллана. Дию символы үзенең егәрлеге, бай эчтәлеге белән җәлеп итә.

Олы Диюләр чакырып,
Гел һушны алыр идең...
*("Ачылган саен куркыныч".)*

Яисә:

Кояшны каплаган Дию кебек,
Елмаюым урлый кайчак хырсыз (угры).
*("Ачулы чагым".)*

"Шәҗәрә" поэмасының үзәк герое Газизә үз сөйгәнен әзли; аны урыс баскынчылары алып киткән:

Җилләр белен Дию килеп,
Гүя шулай ул урланды...

Кара кош кебек үк, Дию дә—явызлык, баскынчылык символы, империя символы.

Шул ук мәгънәдәге тагын бер символ:

...Тузгыган йоннан да кайчакта
Сугалар келәмнең матурын—
Албасты туфанын аралап,
Төзиләр дәүләтнең татуын.

*("Җиңеләбез...")*

Кыска гына язмада шагыйрә иҗатындагы тулы образлар системасын күзаллау мөмкин түгел. Манара (Сөембикә), Арыслан, Кылыч, Күбәләк, Җил, Бал, Күпер, Канатлы ат, Хәүва яисә Иблис, Пәри туе, Тәмуг, Кыямәт хисабы, Туфан, елан-чаян һ. б. образларның барысы да тигез эшләнмәгән, әлбәттә. Әмма алар шагыйрәнең күңел һәм хыял офыклары киң вә бай булуына ышандыралар.

* * *

Җыентыкта урын алган "Шәҗәрә" исемле тарихи поэма, күңелне кузгатырлык сюжет-вакыйгага корылган булса да, шулай ук гел символлардан тора.

Исеме үк символик эчтәлектә алынган.

Шәҗәрә—нәсел башы, нәсел дәвамы, милләт миссиясе, халык язмышы дигән сүз. "Беренче башлам"да ук шагыйрә ике көчле символ тәкъдим итә—"Сүнгән кояш" һәм "шәүләләр". Соңрак аларга карт имән (шәҗәрәнең образлы рәвеше), аккош ("Аккош булып кагынсам да..."), бөркет ("Бөркет кебек үткен күзле"), Албасты, Хөзер баба, башка образлар өстәлә. Символлар тезмәсе буйлап барып, без, баскынчылар тоткынлыгыннан качып, авыр, газаплы хәлләргә тарган, әмма өметен, яшәү дәртен югалтмаган үсмер кыз язмышына килеп чыгабыз. Бу безнең халкыбыз язмышы да.

Яшермим, бу поэма мине тетрәтте. Мин үткәндәге фаҗигаләргә, яра-җәрәхәтләргә тагын да якынайган кебек булдым. Шуны искәрдем: поэманы укып чыккан минутта йодрыгым таш кебек каткан, иреннәрем кысылган, ә күзләрем мөлдерәмә тулган иде. Күптән, бик күптән бу хискә кергәнем юк иде. Ачыну, көенү, рәнҗү катыш өмет хисенә...

Бикә Рәхимованың татар шигъриятендә үз урыны бар. Зур исемнәр, югары урыннар дәгъвалап йөрмәсә дә, тыйнак кына, салмак кына иҗат итүче бу шагыйрәнең йөрәгендә ир-атларга биргесез көчегәрлек, хөрлек рухы бар. Бик күпләргә караганда аның шигъри сүзе чынлыкка, ихласлыкка, иманлыкка якынрак тора.

**Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ.**

*Әдәбият тарихына*

# ӘХМӘТ ФӘЙЗИ ИҖАТЫНДА ТУКАЙ

Татар халкының сөекле шагыйре Г. Тукай образы ничә буын әдипләрне иҗатка рухландырып, илһам, көч биреп килде. Ләкин аның иҗатын һәм тормыш юлын чагылдырган аерым әсәрләр, хезмәтләр, истәлекләр булса да, Әхмәт Фәйзигә кадәр Тукай образын сәнгатьчә осталык белән яктырта алучы башка язучы табылыр микән?! Мөгаен, юктыр!

Тукай шигырьләре Әхмәт Фәйзине үсмерчактан ук сокландыра. Үзе дә ул башлангыч шигырьләрен Тукай йогынтысында яза, алга таба да аның иҗат алымнарын, традицияләрен дәвам итә.

Әйе, Габдулла Тукай Әхмәт Фәйзинең гомере буе табынган шагыйре булды.

Утызынчы елларның ахырларында язучылар әдәбиятыбызның унай традицияләрен, халык иҗатын өйрәнүгә ныграк әһәмият бирә башлыйлар. Шул исәптән Тукай иҗатына багышланган фәнни хезмәтләр дә дөнья күрә (Г.Халит, Г. Нигъмәти).

Шул рәвешле, әдәбиятта Тукай образы ныклы урын ала, күп кенә шагыйрьләр аңа багышлап шигырьләр иҗат итәләр. Тукай турында тәнкыйть мәкаләләре күп булса да, аның тормышы һәм иҗаты төпле-тирән итеп аз өйрәнелә әле. Әхмәт Фәйзи дә шушы изге эшкә алына. Ул Г. Тукай, аның гыйбрәтле биографиясе, татар әдәбиятында тоткан урыны, Тукай яшәгән чор, Тукай яшәгән Казан, Тукай аякка баскан Җаек турында җитди уйлана башлый. Әдип күп еллык иҗат тәҗрибәсен, илһамын, осталыгын шушы зур һәм җаваплы максатка юнәлтә.

Ә. Фәйзинең Тукай образын гәүдәләндерүдәге беренче адымы драматургиягә карый. «Тукай» драмасының кайчан языла башлавын рәсми дәлилләүче документлар әдипнең шәхси архивында очрамады. Бары Ә. Фәйзинең «Әдипнең эрудициясе» дигән китабына (1973) төзелгән искәрмәләрдә генә «Тукай» драмасының якынча 1935 елларда языла башлавы искәртелә *(334 бит)*.

Әхмәт Фәйзи төрле архивларда эзләнә, Тукайның замандашларын эзләп таба, ул яшәгән заманны җентекләп өйрәнергә керешә. Тукай эшләгән газеталар, Тукай сөйләшкән кешеләр, Тукай яшәгән урыннар һәм башка бик күп нәрсәләр аның игътибарыннан читтә калмый. Бу эштә аңа күбрәк Тукайның замандашы артист Касыйм ага Шамил ярдәм итә:

«Ә. Фәйзи шул Тукай яшәгән чорны ныклап өйрәнде, әсәренә кирәкмәсә дә, мәдрәсәдә шәкертләр ничек утыралар иде, ничек укыйлар һ. б. дип сорашып йөрде. Тукайның кайда торуын, кайсы типографиядә эшләвен, элеккеге Печән базарларын күрсәтеп, аңлашып, Тукай турында әдип шактый гына истәлекләр алды. Казанда типографиядә эшләгән, Тукайны яхшы белгән бер эшче—Закир абзыйны һәм «Болгар» гостиницасының швейцарын эзләп таптык. Алар Фәйзигә Тукайның киеме, эше, дуслары һ. б. лары турында сөйләделәр. Ә. Фәйзи шул тормышка дәвамлы рәвештә керә барды».

«Гариф Төхфәтуллин һәм Вафа Бәхтияровлар да сөйләгән истәлекләре белән абыйга зур ярдәм күрсәттеләр»,—дигән иде Ә. Фәйзинең бертуган сеңлесе Зәйнәп апа Фәйзиева минем белән булган әңгәмәсендә *(1994 ел, 15 дек.)*.

Ә. Фәйзи тарихи чыганакларны да өйрәнә, шул чордагы матбугатны күздән кичерә, Тукайның мохите, дөньяга карашы һәм әдәби яктан формалашуы турында төрле мәгълүматлар җыя. Шушы кызыклы тарихи материаллар, бик күп сандагы

истәлекләр һәм, ниһаять, авторның үз хыялы җирлегендә, Әхмәт Фәйзи «Тукай Җаекта» пьесасын иҗат итә. Тукай образының сәхнәдә урын алуы да нәкъ әнә шуннан башлана. Пьеса 1939 елны «Совет әдәбияты» журналында *(№3-4)* басыла. Шул ук елны «Тукай Җаекта» әсәре Татарстан дәүләт академия театрында «Тукай» («Талантның һәлакәте») трагедиясенең беренче пәрдәсе итеп куела.

Хәзер язучының шәхси архивына күз салыйк. Материаллар арасында Ә. Фәйзи белән Татарстан дәүләт академия театры арасында 1938 елның 20 ноябрендә төзелгән килешү кәгазе бар. Килешү нигезендә автор (Ә. Фәйзи) 20 ноябрьдән дә соңга калмыйча театрга «Тукай» («Талантның һәлакәте») исемле биш пәрдәле пьесасын төгәлләнгән хәлдә тапшырырга тиеш. Документтан аңлашылганча, «Тукай» драмасы 1938 елда язылып беткән булган. Архивта «Тукай» драмасының соңгы варианты, пьесаның биш күренеше басылган «Кызыл Татарстан» газетасы кисемтәсе, 1939 һәм 1940 елларда гарәп графикасында язылган каралама вариантлар һәм датасы куелмаган каралама вариантлар саклана. Болардан тыш «Тукай Җаекта» драматик поэмасының төзәтмәләр белән машинкада басылган датасыз варианты һәм русчага тәрҗемә ителгән датасыз вариантлары да бар.

Ә. Фәйзи «Тукай» драмасы буенча уйлануларын, сызмаларын, план вариантларын, материалларны ничек туплавын һәм драманы тикшерүләрне блокнотларга теркәп калдырган. «Тукай» драмасының 1-6 күренешләренә редакцион төзәтмәләр гарәп графикасында карандаш белән язылганнар. Хәтта «Тукай» драмасының сәхнәдә уйналуын дәлилләүче бер-ике фото да сакланып калган.

1940 елның 28 маенда Татгосиздат белән Ә. Фәйзи арасында нәшрият договоры төзелә. Килешү буенча Татгосиздат авторның «Тукай» драмасын китап итеп бастырып чыгаруны үз өстенә ала. Бу китап 1941 елны басылып чыга. Аннан соңгы басмалары 1943, 1948, 1954 елларны дөнья күрә.

«Тукай» драмасы сәхнәдә уңыш белән барса да, автор үзе беренче вариант белән канәгать булмый. Ул үзе театрга пьесаны үзгәртеп эшләргә теләвен белдерә. Нәтиҗәдә, 1940 елның 9 сентябрендә театр директоры Хәмит Алханов белән Ә. Фәйзи арасында яңа килешү төзелә. Автор театр коллективы белән берлектә драманы үзгәртеп эшләргә һәм 1940 елның 1 ноябренә тәмамлап тапшырырга тиеш була. Алга таба да бу эш тукталмый. 1942 елның 29 апрелендә театр белән яңа килешү төзелә. Анда Ә. Фәйзинең 3 пәрдә, 6 күренештән торган «Тукай» пьесасын 1942 елның 15 июненә өлгертергә тиешлеге әйтелгән. 1942 елның апрелендә Тукайның 56 еллык юбилее көннәрендә казанлылар «Тукай» спектакленең яңа вариантын карыйлар. Аны сәхнәгә режиссер Ширияздан Сарымсаков куя һәм әсәр киң җәмәгатьчелек тарафыннан уңай бәя ала. Беренче вариантта тормыш күренешләре күбрәк булса, икенче вариант шигъриятькә, фәлсәфәгә баерак булып чыга. Автор образларның җиргә генә сырышып ятуын һәм кимсетелгән рәвештәрәк яшәүләрен теләми. Аның төп максаты—халык улы Тукайның тарихи урынын күрсәтү. Вариантлар арасында Тукай образының үсешен чагыштырып тикшерүдә катнашкан Гадел Кутуй болай дип сөйли: «Новый вариант спектакля «Тукай» резко отличается от первого варианта и отличается в лучшую сторону. Спектакль по сравнению с первым вариантом теперь более собран, более компактен. При слове Тукай перед нами встает нежный образ патриота, поэта, любимого миллионами народного певца, крупнейшего общественного деятеля, публициста». *(1942, 16 апр. Тат. ВТО).*

Давыллы сугыш елларыннан соң театрның репертуары үзгәрә, аның алдына тормыш яңа бурычлар куя. «Тукай» спектакленең икенче варианты сәхнәдә аз яши, әкренләп репертуардан төшеп кала. Шулай да Мәскәүдә театр студиясендә укучы яшьләр тарафыннан 1961 елда Г. Тукайның 75 еллыгы уңае белән бу спектакль яңадан сәхнәдә уйнала. Тик Әхмәт Фәйзи аны күрә алмый инде—ул 1958 елны Казанда вафат була.

Әхмәт Фәйзи «Тукай» пьесасын иҗат иткән елларда, бер үк вакытта, аның киносценариен да язган. Шәхси архивында киносценарийның 1940-52 елларда язылган ике варианты сакланып калган. Бу эшкә бәлки Татарстанның Халык Комиссарлары Советы рәисе урынбасары З. Тинчуринның *(1940 ел, 15 август)* «Тукай» пьесасын СССР кинематография эшләре комитетының сценарийлар бүлегенә җибәрергә тәкъдим ясап язган хаты да сәбәпче булгандыр. Рәсми

бланкта басылган әлеге хаттан соң шул ук көнне икенче хат СССР Халык Комиссарлары Советы каршындагы кинематография эшләре комитетына да җибәрелә, ә копиясе Әхмәт Фәйзигә юллана. Хатта «ТАССР Халык Комиссарлары Советы Әхмәт Фәйзине «Тукай» кинофильмын чыгару мәсьәләләре буенча консультант итеп билгели»,—дип язылган була. Димәк, шушы елларда ук Г. Тукай турында нәфис фильм төшерергә уйлаганнар икән.

Ә. Фәйзи сценарийга нигез итеп үзенен «Тукай» тарихи драмасын алган. Драмадагы конфликтлар, образлар сценарийда да урын тапкан. Күренеш-эпизодларның күп булып, аларның тиз алышынып торулары—композициядәге һәм сюжет корудагы бу үзенчәлек—шиксез, Ә. Фәйзинең кино сәнгате белән мавыгуыннан, кино үзенчәлекләрен өйрәнүеннән, кино тәэсиреннән килә. Язучы бу елларда җитди рәвештә кино сәнгатен, аның теориясен өйрәнә, яна чыккан фильмнарны карап бара.

Ә. Фәйзинең Тукай турында язган фәнни тикшеренүләре һәм публицистик мәкаләләре дә байтак. Мәсәлән, 1939 елны ул «Габдулла Тукай» очеркын «Атаклы кешеләрнең Казандагы тормышлары» исемле җыентык өчен әзерли. Җыентык рус телендә 1940 елда басылып чыга. Архивтагы кульязмада бу очеркның датасы күрсәтелмәгән, татар телендә һәм рус телендә икешәр каралама варианты бар. «Халык шагыйре» исемле икенче бер хезмәте Тукайның русча җыентыгына сүз башы буларак язылган. Шушы ук хезмәтне файдаланып, кыскартып, Ә. Фәйзи 1956 елның 26 апрелендә университетның актлар залында Тукайның тууына 70 ел тулуга багышланган тантаналы кичәдә доклад ясый. Шәхси архивында шул докладның өч каралама варианты һәм аңа булган материаллар саклана. «Тукай һәм аның заманы» исемле хезмәте исә 1951 елны Татарстан китап нәшрияты чыгарган «Г. Тукай. Стихи, поэмы, сказки» җыентыгында сүз башы буларак урнаштырыла. Шул ук исемдәге мәкалә «Дружба народов» журналында да басылып чыга *(1950, № 5)*. Архивта аның машинкада басылган каралама варианты һәм датасыз тагы ике варианты бар. «Халкыбызның горурлыгы» исемле тагын бер мәкалә 1956 елны Детгиз (Мәскәү) чыгарган «Г. Тукай. Избранное» җыентыгына, 1961 елны «Г. Тукай. Вступающим в жизнь» китабына кереш сүз буларак урнаштырыла. «Габдулла Тукай турында» исемле мәкаләсе исә «Совет әдәбияты»нда *(1936, № 5, 65-66 бб.)*, «Халык һәм шагыйрь» мәкаләсе «Совет Татарстаны» газетасында *(1953, 15 апрель)* һәм «Совет әдәбияты»нда *(1953, № 8-9)* дөнья күрәләр. Тукайның үлеменә 40 ел тулу унае белән язылган «Халык һәм шагыйрь» мәкаләсенең қараламасы да архивта саклана.

Әхмәт Фәйзинең Тукай турындагы хезмәтләре болар белән генә чикләнми. Архивта шулай ук «Поэт красоты и свободы» мәкаләсенең «Литературная газета»дан кисемтәсе, Г. Тукайның яңа табылган хатлары турында мәкалә, «Тукай и русская классическая литература» исемле мәкаләнең ике варианты бар. «Тукай и его эпоха» мәкаләсенең датасы күрсәтелмәгән биш каралама варианты, Тукай турында мәкаләләр язу буенча уйланмалар дәфтәре, Тукайның сайланма әсәрләре җыентыгына карата өч варианттагы рецензиясе, Г. Халитнең «Татар халык шагыйре Габдулла Тукай» очеркына рецензия караламасы—болар Ә. Фәйзинең Тукай чорын һәм иҗатын фәнни яктан тирәнтен өйрәнгәнен ачык дәлилләп торалар. Ул мәкаләләр язу белән генә шөгыльләнми, бәлки Тукайны киң халык массаларына җиткерү буенча да зур эш алып бара. Бу уңайдан Тукайның 60 еллыгына карата сөйләнгән докладының шәхси архивындагы ике вариантын, 1954 елга карата үзенең иҗади эш планы буенча чыгышын, Тукай турындагы доклады фрагментларын санап китәргә мөмкин. Ә. Фәйзи Тукайның яшәгән чорына да, дөньяга карашына да, сәяси карашларының үсүенә дә, эстетик карашларының формалашуына да игътибар итә һәм аларны җентекләп күзәтә.

Болар барысы да Әхмәт Фәйзигә киләчәктә шагыйрь турында зур әдәби әсәр язар өчен әзерлек чоры булып хезмәт иткәннәр. Һәм, ниһаять, Тукай турында күләмле, тарихи биографик әсәр—роман языла. Әдипнең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында сакланган шәхси архивын өйрәнгәннән соң, аның нинди юллар белән «Тукай» романы өчен материаллар туплавын ачыкладык. Ул бу эшне күп төрле юнәлешләрдә алып барган:

1. Әлбәттә, иң беренче чыганак—Тукай үзе, аның барлык язганы,

шигырьләре, мәкаләләре, истәлекләре. Мәсәлән, архивка Г. Тукайның «Исемдә калганнар» истәлегенең машинкада басылган күчермәсе саклана. Ә. Фәйзи аны җентекләп өйрәнгән һәм үз кулы белән юл кырыйларына Тукайның замандашлары сөйләгән истәлекләрдән төзәтмәләр язып барган. Тукайның «Таң йолдызы» газетасында *(1906, 2 сентябрь)* басылган «Уральскида хөррият бәйрәме» мәкаләсенең машинкада басылган күчермәсе дә бар.

**2**. Төрле кешеләрдән тупланган истәлекләр җыелмасы.

Тукайның дусты, журналист, «Әльислах» газетасының мөхәррире Вафа Бәхтияров үз кулы белән дәфтәргә язган истәлек «Хөсәен Ямашев һәм аның турында кайбер истәлекләр» дип атала. Ә. Фәйзигә Тукай яшәгән чорны, мохитне дә яхшы белергә кирәк була. Шуның өчен ул бу истәлекне дә игътибар белән өйрәнеп, файдаланырдай урыннарын төсле карандашлар белән сызып куйган. Сугыш елларында (1944) әдәбият галиме М. Гали дә Тукай турында истәлекләр язып алган. Әдип алардан да файдаланган. Фондта шулай ук Аликов Мөхәммәтҗан улының (1947), А. К. Гладышевның (1952), П. Маскаев, Н. Покатилов, Н. Габделхаковларның да истәлекләре бар.

**3**. Халык авыз иҗаты материаллары.

«Балкан сугышы бәете», «Эрбет бәете», «Шәкертләр садәсе», тышына «N I» дип язылган куш блокнотта халык чыгарган такмаклар, аерым кәгазь битләрендә «Бер мәхзүмнең зары» (ике варианттагы мөнәҗәт), «Бер кадим шәкертнең еглаганы», «Үлем мөнәҗәте», «Татарлар бәете», «Татарларга хитап» кебек мөнәҗәтләр бар.

Ә. Фәйзи «Тукай» романында күп төрле социаль төркемнәрне сурәтләгәндә еш кына фольклор материалларына мөрәҗәгать иткән. Мәсәлән, романда «Эрбет бәетен» бик күп бәетләрне яттан белүче Сәхәби шәкерт кунаклар алдында көйләп бирә. «Балкан сугышы бәете»н Ташъяк ярминкәсендә 1878 елгы рус-төрек сугышында имгәнеп кайткан карт солдат халык алдында җырлап йөри. Романдагы аерым персонажларны, татар халкы тормышыннан этнографик күренешләрне, тарихи, дини, фәлсәфи вакыйгаларны яктыртканда да язучы мәкаль-әйтем, табышмак, җыр, бәет-мөнәҗәт кебек халкыбыз гасырлар буе туплаган акыл җәүһәрләреннән оста һәм урынлы файдаланган.

**4.** Этнографик материаллар.

Архивта татар байлары турында һәм туй үткәрү йоласы турында Нурыямал апа Мәсәгутовадан язып алынган «Урал туе» дигән язма бар. Болар шулай ук романда үз урыннарында файдаланылган.

**5**. Архив, газета-журнал, матур әдәбият материаллары.

Ә. Фәйзи бик күп архивларда, китапханәләрдә эзләнә. Тукай яшәгән урыннарга бара, шул чорда чыккан газета-журналларны җентекләп өйрәнә. XIX гасыр һәм XX гасыр башы турындагы һәр төрле чыганакларны (тарихи, икътисади, фәлсәфи, дини, этнографик, әдәби һ. б.) тәфсилләп тикшерә. Мәсәлән, ул төрле газеталардан күп кенә кызыклы материаллар күчереп алган. Шул чорларга караган бик күп матур әдәбият исемлеге, төрле китапханәләрдәге китапларның шифрлары, байлар, муллалар турында мәгълүматлар туплаган. Ленинград архивларында казынып материаллар җыйган. Болардан башка да архивта бик күп кульязмалар, документлар һ. б. бар. Без биредә аларның барысын да санап торуны кирәк тапмадык.

**6.** Хатлар.

Әхмәт Фәйзи романын язу чорында бик күп кешеләр белән хат алышкан. Архивта 880 хат бар! Аларның һәрберсенә аерым-аерым тукталу мөмкин дә түгел. Мисалга Уральскида Тукай белән бергә наборщик булып эшләгән А. К. Гладышев хатлары. *(1952-56 елларда язылган 18 хат).* Бу хатларда «Тукай» романы өчен бик кыйммәтле фактлар бар. Алар Тукайның Җаекта яшәгән чорын күз алдына ачык итеп китереп бастыралар. Анда Уральскиның географик урнашуы да, төрле социаль катлаулар, аларның үзара мөнәсәбәте, милләтара бәйләнешләр, 1904-1905 ел вакыйгалары, шул чорның тарихи шартлары, шәһәрнең күренекле кешеләре, революционерлар, аларның исем-фамилияләре һ. б. да бар. Гладышев 1956 елның 27 ноябрендә язган хатында үзенең 66 яшьтә икәнен, сәламәтлегенең какшаган булуын искәртә дә: «Мондагы татарлар да, руслар да романның II

китабын зур түземсезлек белән көтәләр. Без башка күрешә алмабыз инде, хет китапны күреп, игътибар белән укып чыгып үләргә иде»,—ди. Ул елларда Уральскидан Казанга килеп аспирантурага укырга кергән Нәфиков Рәфыйк Измайлович хатлары да гаять кызыклы (22 хат, язылган еллары 1951-1956). Анын һәрбер хатында диярлек фактик материал, төрле белешмәләр, фотолар бар.

**7.** Татар әдәбияты буенча фәнни-теоретик хезмәтләр.

Ә. Фәйзи Тукай яшәгән чорны сурәтләгәндә үзе тапкан материаллар белән генә чикләнеп калмый, бәлки Казан университеты һәм Фәннәр Академиясенен Казан филиалы галимнәре белән очрашып, алардан файдалы киңәшләр, фәнни консультацияләр ала. Моны әдип архивындагы рәсми кәгазьләр, әйтик, ТАССР Язучылар союзынын 1949 ел 30 апрельдә биргән белешмәсе дә раслый. Анда анын өч ай (февраль, март, апрель дәвамында) Фәннәр Академиясенен Тел, әдәбият һәм тарих институтында, Эчке эшләр министрлыгы архивында, Тукайнын туган җире—Кызыл юл (хәзер Арча р-ны) районына барып, материаллар җыюы әйтелгән. Аны Тел, әдәбият һәм тарих институтынын гыйльми советы утырышына (1952 ел, 19 июнь) «XX йөз башындагы татар әдәбияты тарихы очерклары»н тикшерүгә дә чакырганнар. Язучы, билгеле, татар әдәбияты тарихын, әдәби тәнкыйть материалларын җентекләп укып өйрәнә, аларны үз хезмәтендә теоретик база итеп файдалана. Кайбер шундый хезмәтләр шәхси архивында да сакланып калганнар *(М. Гайнуллин, Г. Халит, Р. Нәфиҗов хезмәтләре).*

Ә. Фәйзинен шәхси архивында «Тукай» романынын илле алты (!) каралама варианты саклана, ләкин шулардан уналтысынын гына язылу датасы күрсәтелгән. Романнын вариантлары кулдан ясалган унбиш дәфтәр, утыз дүрт калын дәфтәр, егерме дүрт укучы дәфтәре һәм машинкада басылган ике төпләмә тәшкил итәләр. Нинди гаять зур көч түгелгән! Әдипнен эшчәнлегенә сокланмый мөмкин түгел.

Романнын беренче китабы «Үги еллар» исеме белән Казанда 1952 елда басылып чыга. Ул ике өлештән тора (Беренче өлеш—«Яна бистә. Икенче өлеш—«Кырлай»).

Төзәтелгән икенче басма 1956 елны дөнья күрә, ул өч өлештән тора («Яна бистә», «Кырлай», «Җаек»). 1964 елда Ә. Фәйзи әсәрләре өч томлыгынын беренче томында икенче китапнын беренче-икенче бүлекләре дә кертеп басыла. 1984 елда Ә. Фәйзи әсәрләренен биш томлыгы фәнни аңлатмалар һәм искәрмәләр белән нәшер ителде. «Тукай» романы биштомлыкнын икенче томын тәшкил итә.

Йомгаклап шуны әйтергә мөмкин: Әхмәт Фәйзи Тукай образын мәнгеләштерү өчен бик күп көч куйган, Тукай образын эзлекле рәвештә төрле жанрларда сурәтли килеп, ниһаять, «Тукай» романын иҗат иткән һәм аны дөньяга таныткан.

**Зәһир ИСЛАМ,**
*Тел, әдәбият һәм сәнгать институтынын фәнни хезмәткәре.*

*

*Мәдәниятебез тарихына*

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙ һӘМ ТАТАР ТЕАТРЫ

Татар халкының күренекле улы Гаяз Исхакыйның тормыш һәм иҗат юлы милли театр сәнгате белән аерылгысыз бәйләнгән. Монын шулай икәнен раслау өчен бер генә фактны күрсәтеп китү дә җитә. Татар халкынын Октябрь инкыйлабына кадәрге мәдәният үзәкләреннән булган Уфа шәһәрендә милли телебездә 1906 елның 21 апрелендә халык алдында уйналган беренче спектакль Гаяз әфәнденен «Өч хатын берлән тормыш» әсәре буенча куелган була. Әле бүгенгә көнгә кадәр татар театрының туган көне итеп 1906 елның 22 декабре исәпләнә килде. Инде хәзер тарихи дөреслекне кире кайтарырга вакыт.

Гаяз Исхакыйның драматург буларак иҗатын ике чорга бүлеп карау мәслихәт булыр.

Беренче чор—1906-1923 еллар. Татар театр сәнгатенен туу көннәреннән алып, Гаяз әфәнде эмиграциягә киткәч, аның әсәре буенча куелган иң соңгы спектакль уйналу еллары бу. Исхакыйның шул вакытта татар сәхнәсенә күтәрелгән иң соңгы әсәре—«Салих хаҗи балалары» («Юлсызлар») 1923 елның 9 ноябрендә уйнала.

Икенче чор—Гаяз Исхакый мирасы халкыбызга кире кайту чоры. Театр сәнгатендә ул Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында 1992 елның 19 декабрендә «Зөләйха» трагедиясен сәхнәләштерү белән башланды.

Арадагы җитмеш елга якын сузылган бушлык Г. Исхакый иҗаты өчен дә, татар театр сәнгате өчен дә кара еллар булып күзаллана. Бу чорда, табигый ки, милли театрлар Гаяз Исхакый әсәрләрен репертуарга кертә алмый. Татар профессиональ сәхнә җирлегеннән аерылган Гаяз әфәнде исә, драматургиягә берничә кат кире кайтып карый. Чит җирләрдә «Дулкын эчендә» (1920), «Ике ут арасында» (1920), «Җан Баевич» (1923), «Олуг Мөхәммәд» (1947-1948) әсәрләре языла. Ләкин инде болар—элекке мул сулы иҗат чишмәсенен соңгы чайпалышы гына...

Г. Исхакыйның театр сәнгате, драматургия белән кызыксына башлавы Казан Татар укытучылар мәктәбендә (Татарская учительская школа) уку елларына туры килә. Биредә ул 1898-1902 елларда татар халкының Х. Ямашев, Г. Коләхмәтов кебек күренекле шәхесләре белән бергә укый. Укытучылар мәктәбе шәкертләре еш кына рус телендә спектакльләр уйныйлар. Акрынлап Г. Исхакый да театр сәнгатенә тартыла. Шуның нәтиҗәсе буларак, ул 1900 елда үзенең «Өч хатын берлән тормыш» исемле беренче драмасын яза һәм шул ук елны бастырып та чыгара.

Бу вакытта инде милли драматургиянең тәүге вәкилләре Г. Ильяси, Ф. Халиди, Г. Камалларның беренче әсәрләре язылган, әмма аларны сәхнәгә күтәрәчәк театр сәнгате дөньяга килергә әзерләнә генә әле. Тиздән, җәмгыятьнен 1905 ел давылы нәтиҗәсендә, ана тормыш бүләк ителер. Озак та үтми, аның исеме ачыкланыр: Татар театры!

Гаяз әфәнде Исхакыйның драматурглардан иң беренче булып милли театр сәхнәсенә аяк басуы әйтелде инде. Яшь театр алдына баскан һәр мәсьәлә, куелган һәр бурыч аның иҗаты аша уза, чишелеш таба килә.

Театр сәнгатенен иң мөһим өлеше—артистлар уены. Шуна күрә татар театрының иң зур мәсьәләләреннән беренчесе, сәхнә серләренең бөтен нечкәлекләрен үзләштергән профессиональ артистлар тәрбияләү була. Хәл ителәсе икенче зур мәсьәлә—милли тамашачы булдыру. Мона кадәр сәхнә сәнгате

белән бөтенләй диярлек таныш булмаган халыкны тамаша залларына тарту җинел эш түгел. Моның өчен татар халкының тормышын, милләт алдында торган бурычларын, уй-кичереш, кайгы-шатлыкларын чагылдырган заманча әсәрләр иҗат итәргә кирәк. Шундый әсәрләрне тамашачы яратырлык спектакльләр итеп сәхнәгә күтәрү—милли театр чишкән иң мөһим проблемаларның өченчесе.

Татар театрының Октябрьгә кадәрге үсеш чоры репертуарын җентекләбрәк карасак, заман темасын яктырткан иң кызыклы пьесаларның күбесе Гаяз Исхакый тарафыннан иҗат ителүе күренә.

Бу чорда әдип тарафыннан язылган тугыз әсәр сәхнәгә күтәрелә. «Татар драматургиясенең атасы» Г. Камал да Октябрь инкыйлабына кадәр шулай ук тугыз пьеса иҗат итә һәм театрда куйдыра. Әмма әсәрләрендәге тормыш материалы, күтәрелгән мәсьәләләрнең масштаблылыгы, кискенлеге һәм актуальлеге, иҗат ителгән характерлар төрлелеге ягыннан Гаяз Исхакый иҗаты шактый алда тора.

1907 елның 21 маенда «Тавыш» газетасында дөнья күргән «Театр китаплары» дигән мәкаләсендә Г. Исхакый әлегә кадәр басылып чыккан әсәрләргә тукталa. Русчадан «түбәтәй кигезеп» тәрҗемә ителгән «Деньщик Гали», «Кыз сорау», «Көтелмәгән кадерле кунак» кебек бер пәрдәле комедияләрне тикшергәннән соң, ул сәхнә әдәбияты белән шөгыльләнүчеләр өчен программа булырлык таләп куя: милли театр өчен язылган пьесалар татар тормышын чагылдырырга тиеш. Г. Исхакыйның драматургия өлкәсендә калдырган бай мирасы әнә шул программа-таләпнең үтәлеше булып тора.

Мәкалә язылган 1907 елда ук әдип ул чор татар тормышы өчен иң җитди мәсьәләләрнең берсе булган хатын-кыз азатлыгы, ирекле никах проблемасын күтәргән, торгынлык белән алгарыш яклылар арасындагы көрәштә сонгыларның җиңүен раслаган «Алдым-бирдем» драмасын иҗат итә һәм китап итеп бастырып чыгара. Китапка күренекле әдип Ф. Әмирхан рецензия яза. Ул иң беренче чиратта әсәрнең тормышчанлыгына, геройларның характеры дөреслегенә басым ясый. «Гаяз әфәнде бу әсәрендә башкаларындагы шикелле үк типларны, хосусан хатыннар типларын... бик дөрест вә халис татар мәгыйшәтеннән алып тасвир итәдер,— дип яза ул һәм пьесаның хатын-кыз каһарманы Галия образына тукталып:—Галия дә, бер киреләнсә, бер нәрсәгә дә карамый теләгәнен итәргә тырыша торган вә бөтенләй бирелеп берәүне сөя ала торган кыз булып, табигате белән хөррият вә киң мәгыйшәткә иткән татар кызының дөрест тибыдыр»,—дип билгели.

Чынлап та, хатын-кызлар тормышы Гаяз Исхакыйның ул чорда язылган шактый күп әсәрләрендә, шул исәптән прозасында да киң чагылыш таба. Аның хатын-кыз каһарманнары күп очракта актив, үз язмышын үзе хәл итәргә омтылучы, алдынгы фикерле, кыю, кайвакыт хәтта ирләргә караганда да тәвәккәл эш йөртүче булдыклы шәхесләр итеп күрсәтеләләр. Фикерне раслар өчен мисал итеп, «Алдым-бирдем»нән тыш, «Мөгаллимә», «Ике гашыйк», «Зөләйха» әсәрләренең героиняларын атау да җитә.

«Алдым-бирдем» драмасы «Сәйяр» труппа артистлары тарафыннан беренче тапкыр Уральск шәһәр театрында 1908 елның 31 гыйнварында С. Гыйззәтуллина-Волжская бенефисында уйнала. Бенефис иясе Галия ролен башкара. Спектакльгә рецензия язган аноним автор сүзләре белән әйткәндә, ул «гайрәт илә бик тырышып уйный». Ана «пәрдә төшерелгән саен кул чабалар». Спектакльдә Ибраһим ролендә В. Мортазин-Иманский, Хәлил бай ролендә Г. Кариев шулай ук уңышлы чыгыш ясый. Шул көннән башлап «Алдым-бирдем» бик актив уйнала торган спектакль булып китә.

Әлеге уңышлы спектакльдән соң Г. Исхакый бер-бер артлы «Мөгаллим» (1908), «Кыямәт» (1910), «Җәмгыять» (1911), «Зөләйха» (1912) пьесаларын яза. Бу әсәрләрендә инде ул театр сәнгатенең халыкка фикер җиткерү мөмкинлекләрен тирәннән аңлаган, сәнгатьчә эшләнеше ягыннан шактый югары дәрәҗәдәге драмалар язарлык оста буларак чыгыш ясый. Халык тормышының кискен проблемалары сурәтләнгән вакыйгалар аркылы тамашачыга тапшырылачак фикер һәр очракта да Гаяз әфәнде тарафыннан иң беренче планга куела, пьесаларда феодал артталык, рухи хәерчелек, байлыкка табыну, наданлык, дин исеме белән алыш-биреш ясау һ. б. тискәре күренешләр тәнкыйть утына алына.

«Алдым-бирдем» әсәрендә төп конфликт бер-берсен яраткан алдынгы

карашлы яшь пар һәм аларның бергә булуына каршы килүче әхлаксыз, алдакчы туган-тумачасы арасында булып, финалда ул мәхәббәт һәм гаделлек тантанасы белән тәмамланса, «Мөгаллим» драмасы андый оптимистик нәтиҗәләргә урын калдырмый. Җәмгыятькә файдалы булу, халыкка хезмәт итү проблемалары үзәккә куела да, шәхес белән җәмгыять арасындагы каршылык аша уздырыла һәм шәхеснең идеалларын югалтып, тормыш ваклыкларында, мещанлык сазлыгында батып калуы белән тәгәлләнә. Күренгәнчә, пьеса кин социаль яңгырашка ия. Шуна күрә дә аның сәхнәгә килү юлы шактый озак һәм каршылыклы булып чыга.

Әйткәнебезчә, драма 1908 елда язылa. «Йолдыз» газетасына язган мәкаләсендә Г. Камал аңа «гүзәл әсәр» дигән бәя бирә һәм аның каһарманының әхлагы һәм кыяфәте, омтылышлары җанлы итеп тасвирлануын күрсәтә. Театр тәнкыйте өлкәсендә шактый актив эшләп килгән К. Бәкер дә әсәрнең тормышчанлыгына игътибар итә. Әмма драманың цензура белән мөнәсәбәте шактый катлаулы булып чыга: цензор В. Смирнов аны кулъязма хәлендә укып чыга һәм бастырырга киңәш итми. Киңәш исәпкә алынмыйча, әсәр басылгач, ул аны сәхнәгә куярга рөхсәт бирми. Шулай да пьеса 1910 елның 7 мартыннан куела башлый. Башта ул Оренбургның Халык йорты сәхнәсендә күрсәтелә, Казан тамашачылары аны Панаев бакчасының ябык театрында 18 июньдә карыйлар. Шул унай белән рецензия язган «Яшенче» (Г. Камал) әсәрнең куелышы, бөтенлеге турында шактый кискен тәнкыйть фикерләре әйтә, әмма артистлар хезмәтенә карата: «Уенчылар гомумән үзләренә гаид вазифаларында кимчелек күрсәтмәделәр»,—дип билгеләп үтә. Кайбер сәнгатькәрләрне канәгатьләндереп җиткермәсә дә, «Мөгаллим» «Сәйяр» труппасы репертуарында даими урын ала һәм, табигый, уеннан-уенга шомара, үсә бара. Аны 1914 елның 27 гыйнварында караган Фатих Әмирхан: «Татар мөгаллиме тормышының Гаязның маһир куллары тарафыннан ясалган картинасы безнең алда авыр, фаҗигале вә өмидсез булып басып торадыр. Моны күреп җан ачына, сызлана, пьеса бер трагедиягә әйләнә,—дип яза.—Пьесаны бу юлда артистлар шундый бер иттифак вә шундый бер мәһарәт белән уйнадылар ки, карауч ыларга җуелмаслык авыр, ләкин дөрест тәэсир калдырдылар». Мәкалә ахырында Ф. Әмирхан артистлар эшенә тукталa һәм Мөгаллим—В. Мортазин-Иманский, Мөгаллимә—Г. Болгарская, Кадимче мужик—Б. Болгарский, Әхәд—К. Тинчуриннарның уеннарын унай бәяли.

Татар театрының Октябрьгә кадәрге репертуарында Г. Исхакыйның бик җыйнак язылган ике сатирик комедиясе дә шактый әһәмиятле урын тота. «Кыямәт» һәм «Җәмгыять» исемле ул пьесалар икесе дә җәмгыять үсешен тоткарлаучы наданлык, комсызлык, мин-минлек кебек тискәре күренешләрне тәнкыйтьләү, алгарыш яклы укымышлы, белемле яшьләрне күтәрүне максат итеп язылганнар. Әсәрләрнең сәхнә тарихы «Мөгаллим» драмасына охшый. Алар, шактый кыенлыклар аша цензордан куярга рөхсәт алынганнан соң да, урындагы хакимият вәкилләре, иске фикерле мулла-имамнар тарафыннан байтак вакыт сәхнәгә чыгарылмый торалар. Чит шәһәрләрдә гастроль вакытларында уйналганда да бу пьесалар шактый зур шау-шу кузгаталар. Мәсәлән, Оренбург шәһәрендә «Кыямәт» спектакле куелгач, «Дин вә мәгыйшәт» журналында (1911 ел, N 5) «Татар театры, яхуд имамнарны тәхкыйрь» исемле мәкалә басылып чыга. Анда аноним автор спектакльдә дин әһелләренең фанатик, артта калган өлешенә юнәлдерелгән укны, бөтен руханиларга каршы юнәлдерелгән хурлау дип кабул итә.

Гомумән, Гаяз Исхакыйның кайсы гына драматургия әсәрен алсак та, аның сәхнәгә юлы, сәхнә тормышы зур каршылыклар, бәхәсләр, шау-шу белән үткәне күренер. Бу хәл аларда кузгатылган мәсьәләләрнең үткенлеге, актуальлеге, халык тормышының «авырткан» нокталарына юнәлдерелгән булуы белән аңлатыла. Шуңа күрә дә Гаяз әфәнде тарафыннан бөтенләй башка төсмерләр, башка алымнар һәм сурәтләү чаралары белән язылган әсәрләр дә кин җәмәгатьчелектә каршылыклы фикерләр тудыра, бәхәс уята.

Мисалга «Сәйяр» труппасы беренче тапкыр 1914 елның 16 августында Түбән Новгородта Мәкәрҗә ярминкәсе вакытында куйган 3 пәрдәлек «Мөгаллимә» драмасын алыйк. Спектакльнең үзәгендә—бәхетле язмышлы мөгаллимә кыз Фатыйма образы. Аның тормышы тигез юлдан, артык сикереш-борчуларсыз аккан. Бу акыллы, чибәр, белемле кыз халыкка хезмәт итү максатын унышлы тормышка

ашыра алган. Әмма ул да яшәешеннән тулысынча канәгать түгел. Чөнки беренче мәхәббәтен оныта алмый. Шунлыктан ул үзенә гыйшкын белдергән мөгаллим Габдулланың хисләрен кире кагып, ялгыз калуны артыграк таба.

Күренгәнчә, драмада конфликт социаль характерда түгел. Ул геройның эчке дөньясына юнәлтелгән. Әмма әсәргә карата зыялылар фикере төрлечә була. Берәүләр ана каршы чыга, берәүләр күккә күтәрә. Зыялылар тарафыннан төрлечә каршы алынса да, «Мөгаллимә» татар сәхнәсе репертуарында лаеклы урын ала һәм Октябрь инкыйлабына кадәрге чорда бик еш куела. Табигый, милли драматургия, театр сәнгатенә татар хатын-кызларының әле монарчы күрелмәгән яна образын сәхнәгә чыгару жинел эш булмаган. Спектакльне тамашачының кабул итү—итмәве дә мөһим. Авыр булса да, «Сәйяр» труппасы мәсьәләне уңышлы хәл итә. Г. Болгарская (Фатыйма), В. Мортазин—Иманский (Габдулла), Г. Кариев (Карт хәзрәт), Б. Болгарский (Остабикә), К. Тинчурин (Артист), С. Байкина (Әсма) уеннарында Исхакый әсәренен рухи байлыгы, фәлсәфәсе, әйтергә теләгән фикере ачык гәүдәләнеш таба.

Үз дәүләтчелеген югалткан татар милләтенен ачы язмышы, колониаль изү шартларында узган авыр тормышы Гаяз Исхакыйны һәрвакыт борчып тора һәм ул драматург, театр эшлеклесе буларак, әлеге проблемаларны һәрвакыт күз уңында тота. Алар тегеяки бу дәрәжәдә Гаяз әфәнденен бөтен әсәрләрендә диярлек чагылыш табалар. Бу жәһәттән, татар халкы тормышын милли фажига дәрәжәсенә күтәргән әсәрләрнен ин уңышлысы—Г. Исхакыйның «Зөләйха» трагедиясе.

Колониаль изүнен кин кулланылган бер алымы—көчләп чукындыру, халыкны диненнән, иманыннан мәхрүм итү, шовинистик рус хакимиятенен башка халыкларны ассимиляцияләү, руслаштыру сәясәтендә ин куркыныч, ин әшәке алымнарның берсе. «Зөләйха» трагедиясен сәхнәгә куючы Г. Кариев халыкның дин өчен көрәшен милли азатлык хәрәкәтенен аерылгысыз зур бер өлеше итеп карый һәм көчләп чукындырылган татарларның түзә алмаслык авыр кичерешләрен, ислам кануннарын саклау өчен канлы көрәшен жан тетрәткеч тормыш күренешләре аша тамашачыга житкерә. Дөресен әйтергә кирәк, әсәр сәхнәләштерүгә бик авыр бирелә. Биш пәрдәле хроникаль драмада төп урынны күп кешеле күренешләр, кискен көрәш моментлары алып тора. Кайбер эпизодларда катнашучылар саны хәтта алтмышка житә. Вакыйгалар урыны да бик оригиналь сайланган: зират, татар һәм рус авылы күренешләре, мәчет, чиркәү һ.б. «Зөләйха» трагедиясен сәхнәләштергәндә татар театры тагын бер өр-яңа сурәтләү чарасы белән баеды—композитор С. Габәши тарафыннан әсәр өчен махсус музыка языла. Туй һәм Зөләйханың үлемен тасвирлаган күренешләрдә янгыраган милли музыка әсәрне тагын да тәэсирлерәк итә.

Тамашага беренчеләрдән булып бәяләмәне театр тәнкыйтьчесе Г. Кәрам язып чыга. Аның фикеренчә, әсәрне сәхнәгә куючы режиссер Г. Кариевның күп фигуралы, үзәккә омтылучан композициясендә төп урынны өч образ—Зөләйха (Г. Болгарская), Сәлимжан (К. Тинчурин), Петр (Камал Беренче) образлары алып тора. Г. Кәрам алар арасында беренчелекне, икеләнмичә, көчле рухлы милли характер тудырган Г. Болгарскаяга бирә. «Болгарская Зөләйха ролен шул дәрәжәдә яхшы вә оста уйнады ки, аның таланты вә мәһарәтенен зурлыгына вә төрлелегенә хәйран булмый мөмкин түгел—дип яза ул.—Икенче вә өченче пәрдәләрдә күнелләрне тетрәтерлек реальность илә уйнап, бөтен тамашачыларны һәйәжан рикъкатькә китерде вә онытылмаслык тирән бер тәэсир калдырды».

Спектакльнен режиссеры Г. Кариев үзе сәхнәдә берьюлы ике роль башкара. Әсәр композициясендә артык зур күләмле булмаган Гыймади карт һәм Габдулла мөрит образлары аның башкаруында тамашадагы милли-дини рухны үстерү, авторның әйтергә теләгән фикерен көчәйтү өчен хезмәт итә. Икесе ике характердагы, бер-берсеннән танылмас дәрәжәдә аерылып торган татар картлары образларын башкаруда Г. Кариевка элеккечә үк тиңнәр табылмый һәм тамашачы, жиде сәгатькә сузылган тамашадан сон да, яраткан артистның озакка сузылган алкышларга күмә.

Тамашачылар спектакльдән тетрәнеп, чистарынып, милләт язмышы турында уйланып чыгалар. Әсәр бигрәк тә зыялылар тарафыннан югары бәяләнә.

Казанда чыга торган бөтен газетлар диярлек ана зур күләмле рецензияләр багышлый. Бу вакытта Г. Исхакый С.-Петербургта була. Спектакльнең уңышы белән канатланган Г. Кариев Гаяз әфәндегә махсус котлау телеграммасы җибәрә. «Ил» газетының 1917 елгы 28 март санында басылган бу телеграмма көчле милли-дини рух белән сугарылган, колониаль изүне фаш иткән «Зөләйха» трагедиясе авторына бөтен татар зыялыларының котлавы буларак кабул ителә.

Олы әдипнең җиде дистә елга якын тоткынлыкта яткан зур иҗади мирасы халкыбызга кире кайтарыла башлагач, татар сәхнәсенә ин беренче булып янәдән «Зөләйха» әсәре күтәрелә. Бу очраклы хәл түгел. Илдә барган үзгәртеп кору, милли азатлык хәрәкәтенең яңа күтәрелеше шартларында халыкның үзаңын уяту, тәрбияләү, үстерү бурычы Г. Исхакыйның бу әсәрен гаять актуаль итә. Яз килүен белдергән беренче карлыгач шикелле, «Зөләйха» да җәмгыять тормышындагы уңай үзгәрешләр хәбәрчесе булды.

Белүемчә, бүген дә Гаяз Исхакый әсәрләрен сәхнәгә күтәрү җиңел эш түгел. Чөнки аларны куюу, уйнау традицияләре күптән югалган-онытылган. Шулай булса да, сәнгать әһелләре Г. Исхакыйның театраль эстетикасын яңабаштан торгызу, үзләштерү өлкәсендә шактый зур тырышлык күрсәтәләр.

Уфадагы «Нур» татар театрында яшь режиссерлар Б. Ибраһимов белән Ф. Бикчәнтәев бөек әдипнең «Зөләйха» трагедиясен һәм «Көз» повестен куйдылар. Соңгы әсәр Гаяз әфәндене прозасын сәхнәләштерү өлкәсендә тәүге адым буларак та әһәмиятле.

Өлкән режиссерларыбыздан Празат Исәнбәтнең хезмәте аеруча игътибарга лаек. Г. Камал исемендәге театр сәхнәсенә ул Гаяз Исхакыйның өч әсәрен күтәрде. П. Исәнбәт куйган «Зөләйха» (1992), «Алдым-бирдем» (1994), «Җан Баевич» (1995) спектакльләре республика мәдәни тормышында күренекле вакыйга буларак кабул ителделәр. Шуларның баштагы икесе игътибарга аеруча лаек иде.

Алдан әйтелгәнчә, Г. Исхакый мөһаҗирлеккә киткәч, татар сәхнәсендә аның әсәре соңгы мәртәбә 1923 елда уйналган. Узган җитмеш ел эчендә инде ничәмә буын актерлар үскән, режиссерлар килеп киткән. Революциягә кадәр иң күп уйналган әлеге авторны бүгенге көндә нинди сурәтләү чаралары ярдәмендә ачарга, нинди алымнар белән уйнарга? Сәхнәләштерелүе нинди булырга тиеш ул спектакльнең? Шартлылык дәрәҗәсе, нинди темп-ритм, музыка, театраль шау-шулар, бутафория, реквизит нинди урынны тотарга тиеш ул әсәрләрдә? Тарих җилләре тарафыннан рәхимсез өзелгән вакыт җепләрен ялгап тоташтырыр алдыннан һәр режиссер әнә шундый йөзләрчә сорауга җавап эзләргә тиеш һәм ул җаваплар тәвәккәллек, кыюлык, үз дигәнеңә ныклы ышану сорый.

Вакыт аяусыз. Узган җитмеш ел эчендә театраль эстетика бик нык үзгәрде. Г. Исхакый драматургиясе бәлки аңарга бик үк туры да килеп бетмидер. Әйтик, бишәр пәрдәлек спектакльләрне элеккеге тамашачы төнге сәгать ике-өчләргә кадәр карап утыра алган. Ә бүгенге спектакльләр күп дигәндә өч-өч сәгать ярымнан артмаска тиеш. Бу очракта нишләргә? Бик тизләтелгән ритмда уйнаргамы? Әллә икегә бүлеп, ике кич куяргамы? Театр сәнгате мондый очракны да белә. Мәсәлән, Ленинградның Кече драма театрында Ф. Абрамов әсәре буенча Л. Додин куйган «Братья и сестры» спектакле ике кич бара һәм тамашачы ике кич буе тын да алмый, суларга да куркып тамаша карый. Әйе, алай да булырга мөмкин. «Зөләйха»ны куйганда, бәлки, шулай эшләү отышлырак булыр иде. Минем карашка, соңгы ике пәрдәне кырт кисеп ташлау, иң беренче чиратта, Г. Исхакый әйтергә теләгән фикергә, пьесаның фәлсәфи тирәнлегенә хилафлык китерде. Автор, бер яктан, дөньялыктагы изгелек, каһарманлык, сабырлык, инануның ахирәттә кыйммәт бәяләнүен белдерсә, тамашачыны үз диненнән, халкыннан, яшәешеннән теләсә нинди шартларда да баш тартмаска чакырса, ныклыкка, кыюлыкка өндәсә, икенче яктан, кеше гомеренең үзкыйммәтен раслый. Адәм баласының гомере—җир йөзендәге иң зур кыйммәт! Яшәү хокукына беркемнең, берничек кул сузарга хакы юк! Җинаять теләсә нинди очракта да, барыбер, җинаять! Аның дин юлында эшләнгәне меңләтә гөнаһлы. Чөнки Ходайга чиста күңел, керсез куллы кешеләр генә хезмәт итәргә хаклы. Күренгәнчә, әсәр нигезендә русның бөек фәлсәфи язучыларыннан Ф. М. Достоевский, А. М. Горькийлар масштабындагы тирән гомумкешелек фикерләре ята. Әлеге фикерләрне үтемләрәк итү өчен Г. Исхакый

соңгы ике пәрдәдә бөтен игътибарны Зөләйханың эчке дөньясына юнәлтә һәм аны авыр газаплар, тирән кичерешләр аша рухи чистарынуга алып килә. Рус әдәбият фәнендә: «Искупление грехов через страдания»,—дигән төшенчә бар. Бу очракта Зөләйха узган юл әнә шул анлатмага туры килә кебек. Г. Камал исемендәге театрда режиссер П. Исәнбәт куйган спектакльдә исә беренче планга җинаять һәм җәза проблемасы чыкты. Әйе, Зөләйха дин юлында җинаять эшли. Әйе, бу эше өчен закон тарафыннан тиешле җәзасын ала. Театр тәкъдим иткән финал—Зөләйханы этап белән каторгага алып киту—бары тик әнә шундый нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә. Тамашачы бит Зөләйханың җинаятьтән соңгы газапларын, аның узган авыр юлын, югалтуларын күрми һәм, ахыр чиктә, кайгы-хәсрәт, аларны каһарманнарча кичерүе, сабырлыгы өчен хак Тәгалә тарафыннан ярлыкалуын, изге җаннар рәтенә кертелүен, оҗмахка юл алуын да белми. Әсәр бөтен фәлсәфи тирәнлеге белән халыкка барып җитсен өчен, һичшиксез, аның соңгы өлеше дә кирәк.

«Зөләйха»ны кабат сәхнәгә күтәргәндә әнә шундый зур югалтулар булса, «Алдым-бирдем» спектакле исә шактый уңышлы чыккан. Режиссер биредә ин элек геройларның вакыйгалар үсешен тоткарлый торган озын-озын монологларын, берсен-берсе кабатлый торган анлашу сәхнәләрен, бик үк әһәмиятле булмаган персонажларны төшереп калдырган. Шулай итеп, тамаша җыйнакланган, композиция бөтенәйгән, спектакльгә үсеш динамикасы өстәлгән. Тик бу очракта да бөтенләй үк югалтусыз булмаган. Әйтик, финал өлешендәге кыскартулар спектакль өчен ин мөһим булган йомгаклау күренешенен сизелерлек бөтәрләнүенә китергән.

Инде килеп, Г. Исхакый драмаларын уйнау манерасы турында да берничә сүз. Мәгълүм булганча, һәр олуг әдипнен үз дөньясы, үз стиле бар. Драматургиядә бу стиль спектакльнен бөтен компонентларын, шул исәптән артистларның башкару үзенчәлекләрен дә билгели. Г. Камал исемендәге театрда Г. Исхакый әсәрләрен бүгенге тамашачылар өчен кызыклы итеп күрсәтү юнәлешендә эзләнүләр бара. Ике спектакль—диңгездән бер тамчы, бөек әдибебез иҗатын үзләштерү юлында әле тәүге адымнар гына. Шуна күрә дә куелган тамашаларның кайбер күренешләре Г. Камал әсәрләрен, ә кайсыберләре К. Тинчурин пьесалары буенча уйналган спектакльләрне хәтерләтәләр. Мисал өчен, «Алдым-бирдем»нен баштагы сәхнәләре «Банкрот»ның экспозициясен (шул ук тормыш-көнкүреш вакыйкаларын эченә алган, акрынайтылган уен манерасы, тормыштагы вакыт берәмлегенә тигез диярлек сәхнә вакыты һ. б.), ә «Зөләйха»дагы туй күренешләре, «Алдым-бирдем»дәге «аксаклар» катнашындагы эпизодлар «Зәңгәр шәл»нен яшьләр сәхнәләрен, Ишан хатыннары картиналарын искә төшерә. Бервакытта да Г. Исхакыйның Г. Камал белән бер үк вакытта диярлек, ә К. Тинчуриннан шактый алда яза башлавын хәтердән чыгарырга ярамый. Әйткәнемчә, аның үз дөньясы, үзенә генә хас стиле бар. Театрда Гаяз Исхакыйның үз стиле табылырга тиеш! Моннысы инде театр сәнгатебез хәл итәргә лазем мәсьәлә. Бу эштә бөтен сәнгать әһелләре, беренче чиратта режиссерларыбыз тәвәккәллек күрсәтергә бурычлы.

Йомгаклап шуны әйтергә кирәк. Татар театрының формалашу, үсешенен тәүге этаплары Г. Исхакый иҗаты белән тыгыз бәйләнгән. Октябрь инкыйлабына кадәр драматург Гаяз Исхакый татар театрын заман проблематикасы, ил язмышы, халык язмышы турындагы уйланулар, көчле характерлар, кызыклы вакыйгалар, драматизмга бай милли репертуар белән тәэмин итеп килә. Ул тәкъдим иткән драма әсәрләре татар режиссура, актерлык осталыгы мәктәпләрен үстерү өчен ышанычлы, ныклы нигез хезмәтен үти. Озак еллардан соң Г. Исхакыйның тамашачыга кире кайтарылган мирасы үзенен рухи-милли кыйммәтен югалтмавын, сон дәрәҗәдә актуальлеген раслады. Әмма бөек әдипнен театраль эстетикасын янабаштан үзләштерү, тарих тарафыннан өзелгән традиция җепләрен ялгау эше әле башланып кына килә. Бу процесс алга таба милли театрларыбызда кинрәк масштаб алыр дип уйларга кирәк. Гаяз Исхакыйның чәчмә әсәрләре дә сәхнәбез өчен бай материал булырлык. Республика театрлары җитәкчеләренә, режиссерларга ул турыда ныклабрак уйларга кирәктер.

**Гали АРСЛАНОВ,**
*сәнгать фәннәре докторы.*

Китап күзәтү

# АЛЛАЛАР, ФИРГАВЕННӘР НИНДИ ТЕЛДӘ СӨЙЛӘШКӘННӘР?

Бу сорауга мин алдан ук җавап бирергә булдым. Алар төрки телләрдә дә сөйләшкәннәр! Нурихан Фәттахның яңарак кына урыс телендә дөнья күргән «Язык Богов и фараонов» дигән китабы *(Казан, 1999)* белән танышкач, мин бу фикернең дөреслегенә кабат ышандым. Һәм Нурихан Фәттах шуны борынгы бабаларыбыздан сакланып калган, моннан алты мең еллар ук ташка уеп язылган беренче язуларны уку юлында алып барылган ачышлар нигезендә раслый. *(Сүз пиктографик һәйкәлләр турында түгел, аларның ясалу тарихлары тагы да тирәнрәк гасырларга кереп китә).*

Иң борынгы язу истәлекләре Мессопатомия, Мисыр, Эгей диңгезе төбәкләрендә, Атлантидада безнең эрага хәтле дүрт мең еллар ук инде гамәлдә булган. Крито-микон һәм крито-миной культурасына караганнары безнең эрага хәтле ике мең еллар элек барлыкка килгән дип фараз кылалар. Җир шарының төрле кыйтгаларында болардан тыш та төрле ысуллы язулар куллану очрый. Бу язмаларның кайберләрен әле дә укый алмыйлар. Пасха атавындагы кохау ронго-ронго язмалары, Америка индейцлары—майя язулары да сер булып кала бирә. Дөрес, майя язмаларын Ю. Кнорозов «укыды», ләкин бу «уку» майя легендаларындагы сүзләрне майя язуларына яраклаштыру юлы белән укуга кайтып калды. Соңгы дәвергә хәтле «Фест дисбесе» дигән язманың серләрен кемнәр генә ачарга тырышып карамады, бернинди нәтиҗәгә, унышка ирешә алмадылар. Һәм менә 1986 елны «Казан утлары» журналында *(5 сан)* әдибебез Нурихан Фәттахның «Фест дисбесенең сере» дигән хезмәте басылды. Моны татар тел галимнәре «күрмичә» генә үттеләр. Унбиш елдан соң бу хезмәт нигезендә Нурихан Фәттахның Урта диңгез буйларында табылган борынгы язуларга караган яңа хезмәте—«Шәҗәрә» дигән тарихи-лингвистик эзләнүләре дөнья күрде. 320 биттән артык зур күләмле бу китапны күрми үтү мөмкин түгел иде. Татар матбугатында китапка югары бәя биргән өч мәкалә басылды. Миргазиян Юнысның «Идел» журналында *(1993, № 11)* басылган «Родословная будущего» дигән рецензиясендә аңа тирәнрәк күзәтү ясарга омтылыш ясалды. Заманында мин бу хезмәтне «Фест дисбесенең сере»н ачып булмаячак» дип язып чыккан бер Лондон галименә җибәрдем. Китапны алуы турында җавап язса да, Нурихан Фәттахның бу ачышы турында ул галим дә бер сүз әйтеп матбугатта чыкмады.

Индоевропизм чире белән агуланган тел белгечләре, телләрне сортларга бүлеп карау нәтиҗәсендә, «иң алдынгы телләр—индоевропа телләре, алар борынгы телләр, ә төрки телләр яшь телләр, безнең эраның өченче гасырында гына барлыкка килгән телләр» дигән карашын алга сөрделәр. Кызганыч ки, әле дә шуны такылдыйлар. «Фест дисбесе»нең телен ачарга тырышып, бу галимнәр бары тик «борынгы» телләрне генә кулланып карадылар. Төрки телләргә мөрәҗәгать итәргә аларның башына да килмәде.

Алардан аермалы буларак, Нурихан Фәттах «Фест дисбесен» уку өчен төрки телләргә таянды.

«Язык богов и фараонов» дигән әлеге монографик китапның беренче

бүлеге кешелек тарихында беренче сүзләрнен ничек барлыкка килүен ачыклауга багышлана. Автор беренче сүзләрнен бер аваздан, аннан ике аваздан башланып, тора-бара катлауланууларын исбатлый. Шуннан чыгып, ул «Фест дисбесе»ндәге язуларнын серләрен ижек методы белән ачуга ирешә.

«Фест дисбесе» тексты безнен эрага хәтле XVII гасырда язылган. Аны археологлар 1908 елда Крит атавында казынулар алып барганда, Фест шәһәре тирәсендәге эзләнүләр вакытында табып алалар. Табылу урнына карап аны «Фест дисбесе» дип атыйлар. Әдип-галим Нурихан Фәттах монографиясенен икенче бүлеге «Фест дисбесе»н ничек укуы, анда язылганнарны шәрехләве белән кызыклы. «Дисбе»дәге билгеләрне төрки телләр нигезендә уку нәтижәсендә Нурихан Фәттах дөньяда беренче буларак дөньякүләм ачыш ясый. Анын бу ачышын мин шумер чөй язулары уку, борынгы Мисыр иероглифларынын серенә төшенгән Шлиман, Шампольон ачышлары белән бер рәткә куям. Китап урыс телендә дөнья күрде. Урыс телендәге хезмәтләргә игътибар итүче Европа галимнәре аны укый алсалар, бу ачышнын дөньякүләм танылачагына минем шигем юк. Әмма еврошовинистик идеология белән агуланган Россия тел белгечләренен бу хезмәтне тиз генә таныячакларына шигем зур. Мина калса, китапнын «Фест дисбесе» өлешен генә булса да инглиз теленә тәржемә итеп дөнья аренасына чыгару бик кирәк. Ул татар тарихы фәне, татарларнын кемнәрдән-кайлардан килеп чыгуы турында сөйли торган хезмәт булыр иде.

«Фест дисбесе» табылган Крит атавы ул үзе—легендаларга кергән Атлантида «кыйтгасы»нын бер өлеше. Шуна күрә Нурихан Фәттахнын Крит һәм Атлантида тарихына караган махсус бүлек бирүе бик яхшы анлашыла. Крит атавы Атлантиданын безнен эрага хәтле унбиш гасыр элек булып үткән гаять көчле жир тетрәве—Санторино зилзиләсеннән сон су астына китеп бетми калган өлеше. Санторино зилзиләсе кырык ел буе дәвам иткән. Шушы вакыт эчендә анда яшәгән атлант халкы Аппенин ярыматавы һәм Эгей дингезендәге атауларга, Грециягә, өлешчә Африкага—Нил буйларына күчеп киткән. Үзәге Эгей дингезе булган төбәктә микон-миной культурасы барлыкка килгән. Нәтижәдә биредә борынгы грек культурасы үсеп чыга. Борынгы грек тарихчылары, галимнәре, әдипләре Гомер, Плутарх, Геродот, Платон, Страбон һәм башкаларнын безгә килеп житкән хезмәтләреннән Нурихан Фәттах «Фест дисбесе»ндә очрый торган һәм башка борынгы прототөрки сүзләр таба. Телебезгә якын булган күп топонимнар, этнонимнарга тап була. Крит атавында хәзерге көндә безнен телебезгә авваздаш Бакалды (Бакалы), Кондурач (Кондырлы), Куртес (Курташ), Магес (Магаш), Исман (Ишман), Кабир (Кәбир), Караны (Каран), Торсий (Тарса), Салмон )Салман), Саба, Самара кебек топонимнар бар икән. Нурихан Фәттах грек әдибе Гомернен «Одиссея»се белән төрки «Алпамыш»нын бер үк тамырдан чыгуы, хәтта «Алпамыш»нын борынгырак булуын да күрсәтеп уза. Шактый гына мәкальләре безнен нигезе дә шул чор культурасына барып тоташа икән.

Китапнын дүртенче бүлеге борынгы Рим һәм римлеләрнен тарихына багышланган. Римлеләрнен бер өлешенен бабалары саба дигән халык, икенче өлешенен бабалары этрусклар булган. Этрускларнын төрки халыкларга каравы турында инде күп хезмәтләр басылып чыкты. Әйтик, Казыйм Миршаннын «Борынгы прототөрек язулары» *(Анкара, 1970)* Адилә Аиданын «Этрусклар төркиләр иде» *(Анкара, 1992)* китаплары һәм башкалар. Нурихан Фәттах этрускларнын төрки халыкларга якынлыгын тел, топонимия, гореф-гадәтләргә бәйләп һәм фольклор образлары белән чагыштырып карый. Шулай да аларны турыдан-туры төрки халык булган дип санарга ашыкмаска чакыра: «...термины этрусского языка по структуре и значению татарские. Несмотря на это нельзя с уверенностью утверждать, что этрусский язык, каким он известен сегодня науке, является в полном смысле родственным татарским»,—дип яза ул.

Римлеләрнен икенче өлеше булган саба халкынын да төркиләргә якынлыгын Нурихан Фәттах Саба районындагы шушы исемнән ясалган топонимнар белән дә чагыштырып карый. Саба, Сабабаш, Чәпке Саба кебек авылларнын тарихы әнә шул римлеләр тарихына барып тоташа дигәнрәк фикерне алга сөрә ул.

Безнен эрага хәтле IV гасырда Римгә галл кабиләләре басып керү нәтиҗәсендә римлеләрнең теле латинлаша, этруск-саба телләре әкренләп йотыла бара.

Эгей дингезе янәшәсендәге Алгы Азия белән Нил-Мисыр мәдәнияты арасында үзара мәдәни бәйләнешләр көчле булган. Кайбер галимнәр крит-миной, Рим, этруск культураларына, аларның теленә Алгы Азиядә яшәгән шумерлар, аккадлар да зур йогынты ясаган дип язалар.

Шумер культурасының тел, мәдәният, мифология, этнонимиясе үрнәкләре аркылы Н. Фәттах огузлар, хазарлар, бәҗәнәкләр, таврлар, киммерийлар, хеттларга да барып чыга. Шумер телендәге төрки сүзләр турында башка галимнәр хезмәтләрендә дә сүзләр аз булмады. Заманында бу хакта Олжас Сөләйманов та үзенең «Аз и Я» исемле китабында шактый тәфсилләп язган иде.

Борынгы Мисыр мәдәниятына багышланган бүлектә дә автор бу халык телендә төрки сүзләр, этнонимнар, мифологик паралельләрне күп таба. Алар арасында берсе безнен өчен аерата кызык. «Мисыр» сүзе ассирия теленнән икән, ул Мисырның үзендә безнең эрага хәтле IX гасырда ук кулланыла башлаган. Н. Фәттах шушы «мисыр» сүзеннән «мишәр» дигән сүз барлыкка килгән дигән фикер уткәрә. Мишәрләр Мисырда хәрбиләр-сугышчылар булып хисапланганнар. «Мишә» сүзе гаскәрне, армияне аңлаткан, ә «мишәр» сүзе «сугышчы» дигән мәгънәдә кулланылган. Шушы сыйфатлары белән алар башка төркиләрдән аерылып торган. Соңга таба алар кыпчаклар исемендә дә йөри башлаган булырга тиеш. Милләтебезнең аерылмас бер өлешен тәшкил иткән мишәрләр-кыпчакларнын гасырлар буе төрле халыкларга ялланып (грузин, әрмән, француз, гарәп, поляк, урыс, монголларга), алар ягыннан сугышларда катнашып килүен искә төшерсәк, «мишәр» сүзенең этноним буларак үзгәрүен аңлау авыр түгел. Олжас Сөләйманов та «Язык письма: Взгляд в доисторию письменности и языка малого человечества» дигән хезмәтендә *(Рим, 1998)* «мишәр» этнонимының борынгы мисыр теле аркылы безнен этимология фондына кереп китүен искә ала.

Нурихан Фәттах бу монографиясендә кешелек цивилизациясенең бишеге Якын Көнчыгышта булуын, шуннан бөтен Җир шарына таралуын да ачыкларга тырыша.

Хезмәттә күтәрелгән мәсьәләләр күп кырлы, без аларның бары безгә якын, төркиләргә якын якларына гына күз салу белән чикләнәбез. Анда да әле күп мәсьәләләргә тукталмыйбыз.

Бу хезмәтне мин татар тарихы фәне тарихында моңа хәтле тиңдәше булмаган хезмәтләрнең берсе дип саныйм. Андый хезмәтләрнең беренчесе академик М. З. Зәкиевнең «Төрки-татар этногенезы» иде *(Казан, 1998)*. Бу хезмәтләрнен икесе дә милләтебезнең ерак-ерак гасырларга барып тоташа торган эзләрен барлау, ачыклау юнәлешендә, төрки-татар этногенезы өлкәсендә моңарчы тиңе булмаган ачышларга бай хезмәтләр.

Нурихан Фәттах үзенең монографиясендә, миңа калса, тарихта беренче буларак телнең, димәк, сөйләшә башлаучы кабиләнең бары тик бер генә урында, бердәнбер булып барлыкка килүен яклап чыга. Тел иң әүвәл бер генә кабиләдә барлыкка килгән, ди ул. Кабиләнең үсү-ишәюе нәтиҗәсендә шул бер телле халык төрле җирләргә таралган. Гасырлар, меннәрчә еллар дәвамында ул аерылган халыкларнын теле төрле географик, социаль, икътисади шартлар нигезендә аерымланып үсеп, хәзерге хәлгә килеп җиткәннәр. Барлык телләрнең нигезе шул бер телдән башлана. Нининдидер беренче сортлы индоевропик, икенче сортлы палеазиатик төрки телләр юк. Бу турыда Н. Фәттах аерым басым ясап әйтми әйтүен, әмма хезмәтнен логик фикер сөреше шуны күрсәтә.

Әдип-галим милләтебезнең чыгышы мәсьәләсенә махсус тукталмаса да, теләсә теләмәсә дә, ана кагылырга мәҗбүр була. Без аны авторның түбәндәге юлларында да күрәбез: «Без вековых корней с цивилизованным миром древности не удалось бы создать нашим предкам то, что они создали за историческое короткое время... Наши предки, несмотря на свое южное происхождение, перебрались, наоборот, в холодные края. Как и когда оказались они на Волге, Урале, Алтае, в Сибири или в Монголии? Не все известно Истории...»

Жир шарында кешеләр тропик Африкада барлыкка киләләр, аларның теле Якын Көнчыгышта ачыла, Шуннан алар башка кыйтгаларга да таралганнар, хәтта Океанияне дә үзләштергәннәр. Жир шарын берничә мең елларга сузылган цивилизацияләү дәверендә шумер, мисыр, грек, этруск телләре культурасында таврлар да, скифлар да, болгар һәм кыпчаклар да формалашкан, алар дөньяның төрле кисәкләрендә эзләрен калдырганнар—кешелек цивилизациясе үсешенә зур өлеш керткәннәр.

Әлеге хезмәте белән Нурихан Фәттах үзенең олуг тарихчы галим, шул ук вакытта тирән белемле тел галиме—лингвист икәнен дә күрсәтте. Тарихыбызның монарчы ябык булган күп тәрәзәләрен ачу белән бергә, тарихчылар алдында хәл итүне сорый торган байтак проблемаларны да кузгатты. Хәзер инде татар халкының гаять тирән гасырларга барып тоташкан тарихын урыс шовинистлары күзлегеннән язылган хезмәтләр белән генә әвәләп ятуга киртә куелды дияргә була. «Язык богов и фараонов» дигән бу китапны мин милли җаны булган һәр милләттәшемә укырга, кабат-кабат укырга тәкъдим итәр идем. Китапта яктыртылган чорларны-тарихларны инләп чыгу өчен укучыдан зур игътибарлылык, тырышлык та сорала. Чөнки халыкта тиешле дәрәҗәдә белем дә, мәгълумат та җитми, чөнки безнең белем урыс, совет «патриотизмы» тәрбияләүгә генә корылган иде. Безгә чын тарихны укытмадылар. Чын тарих Нурихан Фәттах хезмәте кебек хезмәтләрдән башлана.

Нурихан Фәттах хезмәтендә барлык мәсьәләләр дә хәл ителгән дип раслаудан ерак торабыз. Әле сорау тудыра торган урыннары да аз түгел китапның. Болар бигрәк тә төрки телләрнең этимологиясе мисалларына карыйлар. «Этюды русского языка» дигән бүлек исә, минa калса, кирәксезгә тагылган. Иш янына куш булсын дигән кебек кенә. Ул монографиядә күтәрелгән мәсьәләләргә бер яңалык та өстәми дияргә була.

Нурихан Фәттахның бу хезмәте тарих фәннәре буенча докторлык диссертациясенә тиң хезмәт дип саныйм. Шәт, Татарстан Фәннәр Академиясе Нурихан Фәттахка әлеге монографиясе, башка тарихи хезмәтләре һәм романнары өчен шәрәфле академик исемен бирер дигән өметтә калам. Ул монар, һичшиксез, лаек.

Тел - тарихи хәзинәләр тавы. Ана үтеп керү өчен галәти фән докторы булу гына җитми. Моның өчен маңгай күзләре генә аз, күңел күзеңнең тирән күрә, сиземли белүе кирәк. Бу сыйфат Нурихан Фәттахка Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән, армый-талмый эзләнүләре, милләтенә булган тирән хөрмәте белән үстерелгән.

**Әбрар КӘРИМУЛЛИН.**

*Халык иҗаты җәүһәрләре*

**Хуҗи Мәхмүтов,**

филология фәннәре докторы

# ГЫЙБАРӘЛӘР ТАРИХЫНА СӘЯХӘТ

ТУГАН телебездәге мәкаль һәм әйтемнәр хәзинәсе берничә дистә мең исәпләнә. Алар күп гасырлар дәвамында төрле-төрле юллар белән иҗат ителә килгәннәр. Әйтик, бер төркем мәкальләрнең килеп чыгышы конкрет тарихи вакыйгалар, тормыш-көнкүрештә булып тора торган кызыклы һәм гыйбрәтле хәлләр белән бәйләнгән. Әнә шундый вакыйгалардан халык тирән бер хикмәт, фәлсәфи фикер эзли, тапкыр һәм үткен итеп йомгак, нәтиҗә чыгарып куя. Шул йомгак сүзләре еш кына халык телендә мәкаль буларак әйтелеп йөри башлый.

Реаль тормыш хәлләреннән тыш, халыкның кайбер әкиятләре, мәзәкләре, кыйссалары, миф, риваять-легендалары да мәкаль-әйтем туу өчен бәрәкәтле җирлек булып хезмәт итә. Мондый хикәятләрнең гадәттә «кыйссадан хисса»сы, ягъни, җыйнак, тапкыр формага салынган морале, сөземтәсе була, һәм шулар тора-бара, төп тексттан аерылып, мөстәкыйль төстә (мәкаль сыйфатында) яшәүгә күчә.

Мәкаль-әйтем җыентыкларында без килеп чыгышлары буенча язма әдәбиятка караган текстларга да еш юлыгабыз. Фольклорга әдәби чыганаклардан күчкән, димәк ки, авторлары да билгеле булган мондый өзекләрне гадәттә «канатлы сүзләр» (әйтелмәләр) дип атыйлар. Шулай ук күренекле тарихи шәхесләрнең, популяр әдәби геройларның хикмәтле сүзләре, хәтта аерым әсәрләр вә персонажлар исемнәре дә канатлы әйтелмә булып телгә кереп китү очраклары күп.

Мәкальләр һәм әйтемнәрнең мәгънәләренә еш кына текстлардагы сүзләр яки сурәтләр аша җиңел төшенеп була: «Хезмәт түбе—хөрмәт», «Берлек кайда—көч шунда», «Сандугач та: «Чытырым, чытырым!»—дип сайрар, имеш» (ягъни: һәркемгә үз туган җире газиз), «Ай белән Кояш берәр генә була» (ата-ана берәү генә була дигәне); «Төлке тиресе ябыну» (хәйләгә, алдауга салыну) һ. б. Әмма кайбер тәгъбирләрне бу рәвешчә, ягъни тексттан чыгып кына, аңлап булмаска да мөмкин. Мәсәлән, «Сур өрү», «Мәккә кяфере», «Шыксыз үрдәк бәбкәсе», «Кыр чиреү чаклы», «Корабларны яндыру» кебек әйтелмәләр әнә шундыйлар җөмләсенә керәләр. Аларга нинди күчерелмә мәгънә салынганлыгын хәтердән белергә кирәк. Моның өчен исә әйтелмәнең «биографиясе», нинди җирлектә барлыкка килүе белән дә таныш булу сорала.

Бу мәкаләдә әле санап үтелгән әйтелмәләрнең һәркайсы буенча аерым-аерым түбәндәге мәгълүматлар бирелә:

—Әйтелмәнең телебездә беллдерә торган мәгънәсе һәм мәгънә төсмерләре.

—Шул мәгънәне ачучы контекст (татар матур әдәбиятыннан, публицистикадан бу әйтелмә кергән өзек).

—Әйтелмәнең барлыкка килүенә нигез булган тарихи-этнографик яисә әдәби чыганак: вакыйга, йола, ышану, миф, кыйсса, риваять, легенда, әкият, мәзәк һ. б. лар. Болары тел җәһәтеннән генә түгел, ә бәлки халыкның рухи дөньясын тирәнрәк ачу, әдәби-эстетик тәрбия бирү, мавыктыргыч уку материалы булу ягыннан да зур әһәмияткә ияләр.

## Сур өрү (Исрафил суры)

ИСЛАМ дине буенча, Исрафил—Аллаһы Тәгаләнең төп дүрт фәрештәләреннән берсе. Аңа сур (быргы, мөгез) өреп, ахыр заман, кыямәт көне житүен хәбәр итү

вазифасы йөкләнгән. Коръәндәге Бәни Исраил (Ягъкуб балалары) сүрәсенең 52 аятендә бу хакта болай әйтелгән: «Ул көндә Исрафилнең сур өрүен Аллаһуга хәмед* әйтеп кабул итәрбез...».

Дини тәгълимат буенча, Аллаһы Тәгалә жир белән күкләрне яратканнан соң сурны бар итә. Сур—нурдан булган мөгез, аның киңлеге жир вә күк киңлеге кадәр, ди. Исрафил фәрештә ул сурны авызына куйган хәлдә Аллаһының әмерен көтеп тора, ди. Исрафил фәрештә сурны өч мәртәбә өрәчәк икән. Беренчесе—жир өстендәге адәм балаларын куркытыр өчен, икенчесе—сур тавышы белән үтереп бетерер өчен, өченчесе—кыямәт көнендә үлекләрне кабат терелтеп каберләреннән кубару өчен. Сурның тавышы Жир-күкләрне жимерерлек көчле булачак икән.

«Исрафил суры» әйтелмәсе әдәби телебездә әле Г. Кандалый чорында ук кулланылышта була. Дөрес, шагыйрь аны үзенең туры мәгънәсендә, төгәлрәге—дини эчтәлеге белән файдалана. «Риссаләи-л-иршад» поэмасының XX бүлегендә—ахыр заманда дөньяның юкка чыгуын һәм аның авырлыкларын бәян кылганда—автор болай яза *(«Шигырьләр һәм поэмалар», Казан, 1988, 298 б.)*:

Чү! Исрафил чаладыр сур,
Уладыр Йир вә күкләр һур,
Хәлаикъ уладыр һәм бур,
Уладыр көлләсе әфуат.

(Чү! Исрафил быргысын кычкырта, Жир вә күкләр жимерелә, халыклар һәлак була, барысы да вафат булалар).

Соңга табарак, бигрәк тә XX йөзнең беренче чирегендә, Исрафил суры әйтелмәсе безнең әдәбиятта сурәтле тәгъбир буларак киң кулланылыш тапты. Алдарак әйткәнебезчә, сурны өч өрүнең һәркайсына аерым бер вазифа йөкләтелә. Күрәсең, шул жирлектәдер, әдипләребез дә аны төрле-төрле мәгънә төсмерләрендә файдаланалар.

1. Ифрат көчле, тәэсирле, дәһшәтле оран салу, сигнал бирү, чакыру ташлау һ. б. ш. (беренче сур).

«Тавышына Исрафил сурының көчен кушып, ул (Тукай) шул нәләтне бөтен дөньяга кычкыра» *(Г. Исхакый. Милли фаҗига.—Ил, 1914, 2 апрель)*.

Менә бүгенге көн әдипләреннән мисаллар:

Сурың өрдеме Исрафил?—
Ишетелә нинди аваз?

*(Ш. Маннапов. Өндәге тешләр.—Казан, 1997, 139 б.)*.

«Томан кораб йөртү эшендә бик тә зур киеренкелекләр тудыра. Минут саен диярлек томан гудоклары ишетелеп китә. Өч дистә ел чамасы диңгезләрдә йөреп мин күп нәрсәгә күнектем, бары тик томан гудогына, шушы сур өрүгә охшашлы шомлы матәм тавышына гына күнегә алмадым». *(М. Юныс. Соңгы сулыш.—Казан утлары, 1997, № 9, 22 б.)*.

2. Кайбер әсәрләрдә, мәсәлән, М. Гафуриның 1921 елгы ачлык турындагы «Кеше ашаучылар» поэмасында, сур өрү—гомум фаҗига, һәлакәт символы (икенче сур):

Әллә канат жилпеп ил өстенә
Үлем «фәрештәсе» киләме,
Әллә бар жаннарны суырырга
Исрафил сурын өрәме?

*(Әсәрләр. Дүрт томда. 2.—Казан, 1980, 87 б.)*.

3. Табигатьтәге яки жәмгыять тормышындагы кискен үзгәрешне, уянуны, жанлануны, янарышны тасвирлау өчен әлеге әйтелмә аеруча еш файдаланыла (өченче сур). Мәсәлән, Г. Тукайның «Әлгасрел жәдит»кә матди һәм мәгънәви катнашкан кешеләрнең хәл телләре (күнеле) нәрсә әйтә?» шигырендә мондый юллар бар *(Әсәрләр. Дүрт томда. 1.—Казан, 1975, 327 б. Текст хәзерге телгә күчерелде)*:

Карангылыкта нур тараттык без, Бу үлгән милләтне тергездек без. һәм,

* Хәмед—мактау, шөкер итү.

Исрафил кебек, сур өрдек без, Бу шаять җинүче бер сур булыр.

Шәехзадә Бабич, Нәҗип Думавилар да «сур өрелү»не милләтнең терелүе, янадан хәяткә кайтуы сурәтләмәсе итеп алалар:

Башкорт халык терелде,
Терелү суры өрелде.—

*(Ш. Бабич, Зәңгәр җырлар.—Казан, 1990, 231 б.).*

Качан булса, хәят сурын өреп,
Килеп чыгар әле Исрафил.—

*(Н. Думави. Тормыш сәхифәләре.—Казан, 1985, 124 б.).*

Әле китерелгән мисалларның барысында да «сур өрү» тәгъбиренә иҗтимагый яңгыраш салынган. Аның саф табигать тасвирында кулланылышына бер үрнәк:

«Нил суы елына бер мәртәбә ташый, ярларыннан чыга һәм сусызлыктан корып кипкән, тузанга әйләнгән яисә таштай каткан җирләргә җан кертә, сур өрә» *(Н. Фәттах. Шәҗәрә.—Казан, 1990, 261 б.).*

«Исрафил суры», «сур өрү» вариантлары белән бергә, әйтелмәнең татарчага тәрҗемә ителеп, «мөгез өрү» рәвешендә килү очраклары да күзәтелә. Мәсәлән, Г. Тукайның «Яз» шигырендә *(Әсәрләр. Дүрт томда. 1.—Казан, 1975, 81 б.):*

Кисәктән җанланып, бозлар агалар,
Чабалар, берсенә берсе кагалар,
Белерсең син боларның мәхшәре[1] дип,
Бу бозларны—үлекләр гаскәре дип.
Өрелмеш дип белерсең санки[2] мөгез...

## Мәккә кяфере

ГАРӘП телендәге «кяфир» сүзенең башлангыч мәгънәләре «танымаучы, белмәүче», «күргән яхшылыкны онытучы, аш кадерен белмәүче» дигәнгә туры килә. Гарәбстанда ислам тарала башлагач, аны, инде дини эчтәлек салып, «Алланы бер дип танымаучы», «Алла биргән яхшылыкның кадерен белмәүче» мәҗүси гарәпләргә карата куллана башлаганнар. Тора-бара бу сүзнең мәгънәсе тагын да киңәйгән: ул барлык башка диндәге кешеләрне, дингә бөтенләй ышанмаучыларны (атеистларны), шулай ук, мөселман булып та, ислам кагыйдәләрен бозучыларны (яки боза дип саналучыларны) атый торган исем булып әверелгән.

Шушы төрле «сорт» динсезләрне белдерүче «кяфер» сүзенең мөселманнарның иң изге шәһәре Мәккә исеме белән берегеп тотрыклы әйтелмә хасил итүе беренче карашка сәер булып күренергә мөмкин. Мәккә—Мөхәммәт пәйгамбәрнең туган каласы. Башта Мәккәдә төрле таш сыннарга, потларга табынучы мәҗүсиләр яшәсә, тиздән анда ике төркем: Мәккә мөселманнары һәм Мәккә кяферләре барлыкка килгән. Әйтергә кирәк ки, башларында Әбу-Җәһил дигән кеше торган Мәккә кяферләре Мөхәммәткә бик каты каршылык күрсәткәннәр. Алар мөселманнарны төрлечә эзәрлекләгәннәр, җәберләгәннәр, хәтта пәйгамбәрне үтерергә берничә тапкыр омтылыш ясаганнар. Бу хакта дини әдәбиятта күп язылган. Менә бер өзек:

«... Кяферләр, җыелышып, киңәш-табыш кылдылар һәм Әбу-Җәһил:

—Барыбыз да кылычларыбыз белән Мөхәммәтне турап ташлыйк,—диде. Мәккә кяферләре сүзнең ахырында аның тәкъдимен кабул иттеләр һәм пәйгамбәрне үтерергә карар биреп таралыштылар... Имансыз Мәккә кяферләре, кан таләп итеп, җинаять юлына бастылар, кылычларын айкап, кулларына үлем богавы тоттылар» *(Фәрит Яхин. Олуг пәйгамбәр.—Казан, 1994, 192 б.).*

Бу хәл 622 елда була. Мөхәммәт ашыгыч рәвештә Мәдинә шәһәренә күчеп китә (Һиҗрәт кыла). Туган каласына ул 8 елдан соң гына, инде җиңүче булып, әйләнеп кайта. Һәм Мәккә ислам дөньясының үзәге булып әверелә.

«Мәккә кяферләре» дигән әйтелмә баштагы чорда туры мәгънәсендә

1 Мәхшәр—ислам диненчә, яңадан терелгән кешеләрнең теге дөньяга җыелу көне.
2 Санки—гүя.

кулланылып йөри, ул нәкъ менә Мәккәдә яшәүче кяферләрне генә күздә тота. Соңга таба исә әйтелмәнең көчерелмә мәгънәсе барлыкка килә: ул «иң явыз, иң әшәке, иң гөнаһлы кяфер» дигәнне белдерә башлый. Татар телендә дә шушы мәгънәдә кулланылып, үз эченә тиргәү, хурлау төсмерләрен дә ала.

—Син алай дисең дә бит, кода,—диде ул (Вәли абзый),—безнең хәзрәт сезнең ишанның сүзен бидгатькә чыгара *.

—Сезнең Галләм муллагыз да, Сабитовларыгыз да—һәммәсе Мәккә кяферләре...—диде Җәгъфәр *(Ә. Фәйзи. Әсәрләр. Биш томда. 2.—Казан, 1984, 67 б.)*.

«Аблай (ныграк ыжгырып). Кычкырмыйча! Син гомер буе ил өстендә өйдән-өйгә чират йөреп, тыгынып аша да, әле тагын башыбызга менеп атланыр иденме, имансыз, Коръән таптаган Мәккә кяфере!

Гайнетдин. Ничек син указный мулланы кяфер дип әйтәсең?

Аблай. Мин сиңе әйтәммe? Көтүче Гыймрайны әйтәм! Чурапан Хәйретдин малаен! Йә? Атасын кара инде; гомер буе муенында—тәре, куенында түбәтәй йөртте. Урыс янында тәресен чыгарып күрсәтте, татар янында түбәтәен чыгарып киде *(Н. Исәнбәт. Сайланма әсәрләр. Өч томда, 2 т.—Казан, 1963, 288 б.)*.

## Шыксыз үрдәк бәбкәсе

АТАКЛЫ балалар язучысы данияле Ганс Христиан Андерсенның (1805-1870) бер әкияте исеменнән туган әйтелмә. Андерсен әкиятләре татар теленә XX йөзнең 30 нчы елларында ук тәрҗемә ителәләр. Мәсәлән, 1939 елда аның «Әкиятләр» җыентыгы Казанда 10 мең данә тираж белән басылып чыга.

Әлеге әйтелмәнең мәгънәсен ачыграк аңлау өчен башта «Шыксыз үрдәк бәбкәсе» әкиятенең кыскача эчтәлеген бәян итеп узыйк:

«Җәйге матур көн. Шәһәр читендәге куе әрекмәннәр арасында кара урмандагы шикелле тынлык, аулак. Шунда бер ана үрдәк йомыркалар өстендә бәбкә чыгарырга утыра. Менә йомыркаларның кабыклары чатный башлый. Алар эченнән: «Пип! Пип!»—дигән тавыш ишетелә: йомырка сарылары җанлана, бәбкәләре борынлап чыгалар.

—Бак! Бак!—ди әнкәләре.—Йә, нәрсә, барыгыз да бирелдәме инде?. Ах, юк, барыгыз да түгел икән әле! Иң зур йомырка бөтен килеш калган!

Шулай ди дә, ул янадан йомырка басарга утыра. Хәл белергә килгән карт үрдәккә үзенең зарын сөйләп бирә.

—Бу күркә йомыркасы!—ди карт үрдәк.—Мине дә бер тапкыр шулай алдадылар...

Ниһаять, зур йомырка да ярыла. Бәбкә:—«Пип! Пип!»—дип йомыркадан килеп тә чыга. Ләкин ул бик тә зур һәм килбәтсез була. Башка үрдәкләр аны күргәч, кычкырып бакылдашырга тотыналар:

—Күрче, нинди килбәтсез!

Башкалардан соңга калып чыккан бичара үрдәк бәбкәсен бар да кыерсыта, үрдәкләр генә түгел, хәтта тавыклар да аны чукыйлар, читкә кагалар, үчеклиләр. Үзен патша дип хис иткән ата күркә ана карап коточкыч итеп гангылдый башлый... Ниһаять, үрдәк бәбкәсенең түземлеге калмый, ул качып китәргә мәҗбүр була. Ләкин кая гына бармасын, кемне генә очратмасын, шул ук мыскыллау-җәберләүләрдән башканы күрми. Шыксыз үрдәк бәбкәсе, күп җәфалар чигеп, кышны кичерә.

Менә янадан яз килә. Бер көнне үрдәк бәбкәсе канатларын кага да очып китә. Хәзер инде аның канатлары элеккегә караганда ныграк булалар. Бераз очкач, ул бер зур бакчага килеп төшә. Алмагачлар ап-ак чәчәктә, хуш исле сиреньнең озын яшел ботаклары бормалы-бормалы канау өстенә салынган. Канау буенча ап-ак, гаҗәеп зур өч аккош йөзеп килә.

—Шул мәһабәт кошлар янына йөзим әле!—ди үрдәк бәбкәсе.—Шундый мәхәббәтсез көе алар янына килергә батырчылык иткәнем өчен, мөгаен, үтергәнче чукырлар үземне. Чукысыннар әйдә!

Шуннан ул суга төшә дә, гүзәл аккошларның каршысына йөзеп китә. Ә аккошлар, аны күрүгә, канатларын каккалап үзләре дә аңа таба йөзә башлыйлар. Мескен үрдәк бәбкәсе, башын түбән иеп:

* Бидгатькә чыгару - шәригать законнарын бозучы дип санау.

—Үтерегез мине!—ди.

Шул вакыт ул көзге кебек чиста су өстендә үзенең шәүләсен күрә: ләкин хәзер инде ул элеккеге карасу-соры үрдәк бәбкәсе түгел, ә ап-ак аккош икән ләбаса! Ул арада яр буена балалар йөгерешеп киләләр һәм шатланып кычкырыша башлыйлар:

—Яңасы килгән! Яңасы килгән!

—Яңа аккош тегеләреннән дә матуррак!

Ә олы аккошлар яше алдында башларын ияләр».

Бу гаҗәеп кешелекле, гыйбрәтле әкиятнең исеме, алдарак әйтелгәнчә, канатлы тәгъбир булып дөньяның күп телләренә кергән. Башта озак кына үзенең лаеклы бәясен алмаган, хәтта урынсызга кимсетелеп, түбәнсетелеп килгән, аннан әйләнә-тирәдәгеләр каршында кинәт кенә асыл, күркәм сыйфатлары белән ачылып киткән кешене «шыксыз үрдәк бәбкәсе», диләр. Әйтелмәне еш кына сабый һәм үсмер чакта бик үк сөйкемле күренмәгән, әмма үсеп житкәч һич көтмәгәндә чын гүзәлгә әйләнгән кыз балага карата да кулланалар.

«Ярда калган «шыксыз үрдәк» сизә
аккошлыгы әле алдалыгын».—

*(Р. Фәйзуллин. Яктылык.—Казан, 1985, 14 б.).*

«Шыксыз гына үрдәк бәбкәсе, дип,
Карауччылар азмы аккошка?»

«Шыксыз үрдәк бәбкәсе, дип,
Уйлады аны күпләр.
Үскәч белделәр: ул затлы
Аккош нәселеннән икән».—

*(Ш. Маннапов. Өндәге төшләр.—Казан, 1997, 201, 235 б.б.).*

## Кыр (Кырым) чирүе чаклы

Л. Җәләй, Н. Борһанова, Л. Мәхмүтовалар төзегән «Татар теленең фразеологиясе, мәкаль һәм әйтемнәре җыентыгында» *(Казан, 1957, 95 б.)* бу әйтелмәнең «бик күп» дигән мәгънәдә йөрүе күрсәтелә. Моның мисаллары матур әдәбиятта да очрый:

«Янәсе, ул (авылдашларын Пугач ягына ияртеп чыккан гренадер Зариф): «Петр Федрич кыр чирүе чаклы халык белән Казанны алмага килә!»—дип хәбәр таратып, шул замандагы губернатор фон Брантны куркуга төшергән» *(К. Нәҗми. Әсәрләр. Дүрт томда. III Язгы җилләр.—Казан, 1983, 8 б.).*

Бу әйтелмәдәге «чирү» сүзе телебездә элек «гаскәр» мәгънәсендә кулланылган. Кырда (ачык урында) барган сугышларда, гадәттә, бик күп гаскәр катнашканга, «кыр чирүе» дип әйтү, бәлки, шуннан килгәндер. Яки «кыр чирүе» икенче бер әйтелмәдән—«Кырым чирүе»ннән үзгәргән булырга мөмкин. Н. Исәнбәт аңлатуынча, Казан тәхетенә Кырым ханы Сәхипгәрәйне утыртканда, аны туганы Мөхәммәтгәрәй хан күпсанлы кырым чирүе белән Казанга китереп куйган була. Бу хәтле чирүне кунак итү, Казанда нык кына сизелерлек һәм телләрдә мисал булып калырлык зур вакыйга булгандыр. Шул заманнардан соң, гаскәр һәм күп халык җыйнавын яки бик ишле зур гаиләне күргәндә, күплеккә мисалдан «Кырым чирүе кебек» дигән гыйбарә кулланылышка кергән *(Татар теленең фразеологик сүзлеге. Ике томда. 1.—Казан, 1989, 433 б.).*

Күп вакытлар үткәч, әйтелмәдәге Кырымның конкрет тарихи эчтәлеге онытылгач, ихтимал, аны «кыр» дип үзгәрткәннәрдер.

## Корабларны (күперләрне) яндыру

АГАМЕМНОН патша житәкчелегендәге ахейлар (беренче греклар) Трояны* тугыз ел буе камап торалар, ләкин унышка ирешә алмыйлар. Ахыр чиктә, алар хәйләгә керешәләр. Троялыларның ат яратуларын истә тотып, греклар бик зур агач ат ясыйлар һәм, аны диңгез буенда калдырып, үзләре корабларга төялеп китеп

баралар. Ләкин алар, троялылар уйлаганча, үз илләренә кайтып китмиләр, ә якындагы бер утрауда яшеренәләр. Троя кешеләре агач атны шәһәргә алып керәләр, чөнки аның эченә кораллы грек сугышчылары яшеренгән икәнлеген белмиләр. Төнлә, кешеләр йоклап киткәч, әлеге сугышчылар, ат эченнән чыгып, аз санлы сакчыларны үтереп бетерәләр һәм шәһәр капкаларын ачалар. Дошман гаскәрләре Трояга бәреп керә. Бу көтелмәгән хәлдән каушап, югалып калган троялылар кача башлыйлар. Шул чакта Троя хатын-кызлары, ирләренен хурлыклы качуын туктату өчен, гаваньдә тора торган корабларга ут төртәләр. Кораблар янып юкка чыга, шулай итеп Троя сугышчыларына чигенү юлы да киселә...

Шушы борынгы риваять жирлегендә телдә «корабларны яндыру» дигән канатлы әйтелмә туа. Аның күчерелмә мәгънәсе—артка чигенергә мөмкинлек калдырмау, үткәннәр белән араны өзүдә кискен, хәлиткеч адым ясау.

Дөнья телләрендә шушы ук әйтелмәнең «күперләрне яндыру» дигән икенче бер синонимы да еш кулланыла. Конкрет вакыйгага бәйләп каралмаса да, аның ничек килеп чыгуын чамалау кыен түгел. Сугыш вакытында, арттан эзәрлекләп килүче дошманны бераз булса да тоткарлау өчен, чигенүче якның үзе үткән күперләрне жимереп баруы гадәти күренеш булып тора. Кайбер борынгы полководецлар исә еш кына чигенү түгел, ә һөҗүмгә бару юлындагы күперләрне яндырып-ваттырып калдыру тактикасын тотканнар. Артта качып котылу юлы калмавын белгән гаскәр дошман белән актык чиккә кадәр аяусыз сугышырга тиеш булган...

«Корабларны яндыру» әйтелмәсе әлегә татар әдәби теленә үтеп кермәде шикелле. Ә «күперләрне яндыру»ны, киресенчә, безнең әдипләр шактый күптәннән һәм еш файдаланалар:

«Без үсәбез!—
Үткән күперләрне ягып,
Якты киләчәккә күчәбез».—

*(Һ. Такташ. Әсәрләр. Өч томда. 1.—Казан, 1980, 200 б.).*

«Азмы күпер янып барган арттан—
Кире кайтыр юллар киселгән».—

*(Рифкать Закиров. Автобиография.—Мәдәни җомга, 1998, 24 июль).*

«Бетереп вәгъдәләштегезмени соң? Чигенер жай юкмы? Барлык күперләр янганмы артта?» *(Б. Камалов. Язмыш сәхифәләре.—Казан, 1990, 124 б.).*

## Аягыңа сыер басмаган

**ЯҢАРАК** кына өйләнгән бер егет абзарга сыер ябып йөри икән. Урамнан узып баручы бер буйдак дусты, моның хәленә кызыгып, болай дигән:

—Син кеше булып життең бит, ә! Хатының бар, йортың шәп, сыерың шәп!..

Шул вакыт сыер ничектер хуҗасының аягына басмасынмы! Өйләнгән егет, каты авыртуга түзә алмыйча, кычкырып жибәргән:

—Шәп тә шәп! Син нәрсә беләсең соң? Аягыңа сыер басмаган әле синең!..

«Аягыңа сыер басмаган» тәгъбире тормыш тәжрибәсе булмаган, авырлыклар күрмәгән кешегә карата әйтелә.

«Син әле күктә, болытлар өстендә. Бабайлар әйткәндәй, аягыңа сыер баскач, һаман очмассың, канатларың сәлперәер әле» *(Б. Камалов. Язмыш сәхифәләре.—Казан, 1990, 53 б.)*

* * *

Шул рәвешчә, без әдәби телебездә актив кулланыла торган кайбер канатлы сүзләрнең туу һәм таралу тарихлары белән танышып үттек. Мондый гыйбарәләр безнең көннәрдә дә барлыкка килә торалар.

---

* Троя шәһәре Кече Азиянең төньяк-көнбатыш өлешендә, диңгезгә якын бер жирдә, хәзерге Төркиядәге Гиссарлык калкулыгында урнашкан була. Б.э.к. 1260 еллар тирәсендә жимерелгән дип санала. Троялылар төркиләр булган дигән фараз да бар.

*Шамил Рәкыйповка 70 яшь*

# КЕШЕЛЕКЛЕЛЕКНЕҢ ДӘВАМЫ—БАТЫРЛЫК!

Калага тартылу... Йоп-йомшак яшел чирәмле гүзәл табигать кочагында бәләкәйдән үк кошлар жырын көнелено сендерә-сендерә һәм ул чагында мәңге аерылмас дус сыман тоелган шаян кәжә бәтиләре белән жылы өй иданендә уйныйуйный үскән нарасый адәм баласының жанында «шәһәргә тартылу» дигән әнә шул яна тойгы, ят омтылыш кайчан һәм ничек туа, ни рәвешле барлыкка килә икән?

Калалардан бик-бик еракта, ләкин табигатьнен бик күркәм кочагында урнашкан авылда үткән балачагымны, үсмер елларымны күз алдына китерәм дә, хатирәләрне янарта-янарта әлеге сорауга бер ышанычлы җавап табарга телим.

Бу чагында авылга электр да кермәгән әле. Шуна күрә кичләрен өйләрне бик тиз арада эңгер билэп ала.

Әнә шундый моңсу кичләрдә үсмер авыл малае үз өйләренен кояш баешына караган бәләкәй тәрәзәсе янына килеп утыра да, радио тәлинкәсеннән талгын гына агылган симфоник музыка тынлый. Татар жегетенен күнелено Вивальди аһәннәре, гажәеп лирик Свиридовнын хис дулкыннары килеп-килеп кагыла...

Калага тартылу тойгысы әнә шунда тәү мәртәбә борын төрттеме икән?

Әллә күрше авылыбызда туып үскән Тажи Гыйззәтнен, үзебезнен укытучыбыз Юныс Әминовнын серле эшләренә кызыга, ымсына башлаганмы күнел дигәнен?

Әллә инде 1968 елны Казаннан килгән шагыйрьләр Равил Фәйзуллин белән Айдар Хәлимне бер матур кышкы көнне ат жигеп үз авылыбыздан күрше авылга хәтле озатып куюу, уникe чакрым араны үткәндәге сүзләр, әңгәмә, аралашу яшь күнелне жилкендереп калдырганмы?

Әйе, болар барысы да булгандыр... Язмыш юлын сайлаган чагында һәркайсы үз сүзен әйткәндер.

Шулай да, Казанга әләгүемә «иң гаепле» кеше Шамил абый Рәкыйпов булды.

Алтмышынчы елларнын башы иде ул. Баржы урта мәктәбенен алтынчымы, жиденчеме сыйныфында укыган чагында мин бик мавыгып, кызыксынып киттем дә, Казандагы «Татарстан яшьләре» редакциясенә «ничек журналист булырга икән?» дигән—беренче карауга беркатлы, әмма ул вакытта минем өчен үтә мөһим булган ихлас сорау белән хат яздым. Хатым китте Казан тарафына, ә минем көннәр мәктәп ыгы-зыгысы һәм романтикасы белән, китаплар укый-укый һәм кичләрен барыр урын булмаганга күрә радио тәлинкәсенә кереп китәрдәй булып әдәби спектакльләр, музыка тынлый-тынлый ага бирә... Тан тудымы, хат ташучы апаны көтә башлыйсын—ул сина ин-ин мөһим хатны, ин кадерле сүзләрне алып килер шикелле... Ә бераздан күнелне шик тә кимерә башлый: «Минем кебекләр бик күптер бит инде ул,—барысына да ничек жавап язып бетерсеннәр алар...»—дисен...

Әмма жавап хаты килеп төште бит! Әле анын да нинди диген!

Ерак бер татар авылында яшәп ятучы гап-гади бер малайга атап, үз кулы белән һәм матур итеп, һич тә иренмичә биш бит итеп язылган ул хатнын авторы Шамил абый Рәкыйпов иде!

Ижат доньясынын серләре белән таныштырган да, кызыктырган да, үтә мөһим киңәшләрен дә биргән, беренче адымнарны ничек-ничек атлап китәргә дә өйрәткән бик тә тәфсилле, бик тә жентекләп язылган хат иде ул!

Менә хәзер—мона инде бик күп еллар үткәч—уйлап утырам: редакция тормышынын тынгысыз «кухня»сында кайнаган Шамил абый ул чагында ничек вакыт тапты икән? Бер белмәгән кешегә ничек итеп шундый ихлас, шундый кешелекле хат яза алды икән?

Тумыштан ук, нәселдән ук килгән һәм кан буенча күчә торган кешелеклелек, ярдәмчеллек сыйфаты этәргәнме аны бу эшкә?

Әллә мона кадәр үзенен тормышта бик күп «кыен ашавы», Урал һәм Себер якларында авыр физик эшләр башкарып, дөнья күргән бик күп агайлар белән аралашып, акыл, гыйбрәт һәм үрнәк туплау нәтиҗәсе булганмы бу эчкерсез адым?

Яисә иҗат дөньясына бик тә бирелгәнлек, ана табыну һәм әнә шул юлга азмы-күпме ярдәм итәрдәй һәр адымны башкарырга теләве булганмы ул анын?

Әллә инде «кеше үтенеченә һәм инде, яшь кеше язмышына бигрәк тә, игътибарлы булу» дигән сыйфатмы икән ул?

Шамил абыйнын үзен күргәнче үк күнелдә ана карата ихтирам уяткан тагын бер очракны әйтеп узасы килә. 1963 елда анын «Барып аласы хат» исемле беренче повесте китап булып басылып чыкты. «... Менә мин тагын Әгерҗе кунакханәсендә...» дигән сүзләр белән ачылып китә ул әсәр. *Ләкин* биредә хикмәт бу повестьнын безнен як кешесенә—ике аяксыз килеш комбайнга утырып эшләгән һәм шунын белән Алексей Мересьев батырлыгын кабатлаган иргә багышланган булуда гына түгел. Ныклап уйласан, гади кешенен зур рухи көче, ныклыгы турында сүз бара иде биредә. Анын ил ышанырдай, ил таянырдай чын ир булуы хакында иде сүз! Проза өлкәсендәге үзенчә бер «гадиләргә гимн» иде бу повесть! Шуна күрә әсәрне ул елларнын әдәби җәмәгатьчелеге дә бик җылы каршылады.

Ә шәхсән минем өчен бу эш—хат язып күнелгә гомергә кереп калган изге абыйнын безнен як кешесе турында шундый шәп әсәр иҗат итүе—мина тагын да бер мәртәбә канат кую, тагын бер кат олы юлга дәртләндерү кебек иде. Ул чагында мин бу повестьны әнә шулай кабул иттем.

Менә әле без ике генә фактка тукталып үттек. Шамил Рәкыйповнын бер белмәгән яшүсмер малайга үтә җитди, үтә кешелекле хат язуына һәм шулай ук гапгади бер комбайнчы батырлыгына багышлап повесть иҗат итүенә. *Ләкин* менә шуларда да бу шәхеснен тормышта һәм иҗатта тоткан юнәлеше, кредосы бик ачык чагыла түгелме?

Ә инде 1967 елда татар халкынын кыю улы—немец фашизмы белән көрәштә Александр Матросов һәм Газинур Гафиятуллин батырлыгына тин каһарманлык кылган Барый Шәвәлиев турында «Чәчәкләр сөйли белә» исемле повестен бастырып Шамил абый Рәкыйпов үзенен иҗади юнәлешен тагын да ныгытты, ачыграк итеп раслады. *Дөрес*, бу әсәр документаль нигездә язылган. *Ләкин* укыган чагында аны чын әдәбият җимеше буларак кабул итәсен. Чөнки образлар тулы канлы, тел һәм сурәтләү чаралары да укучыны кызыктырып, мавыктырып барырлык. Ә эчтәлегенен мөһимлеген, тирәнлеген инде әйткән дә юк!

Моннан сонгы елларда Ш. Рәкыйпов безнен Казан шәһәрендә яшәп сугышка алынган белорус егете Иван Кабушкин турында «Кайдан син, Җан?» дигән, татарлардан беренче мәртәбә Советлар Союзы Герое исемен алган Гыйльфан Батыршин һәм анын сугышчан дусты турындагы «Таннар һаман матурмы?» исемле һәм данлыклы хатын-кыз очучыларыбыз Мәгубә Сыртланова, Ольга Санфирова һәм аларнын полкташлары хакында «Кызлар-йолдызлар» дигән, шулай ук «Кипарислар җыры» исемле повестьлар да язды. Үз иҗатындагы шушы бәрәкәтле юнәлешне ул сонрак басылган «Геройлар эзеннән», «Геройлар үлмиләр», «Аяз күктә карлыгачлар» кебек җыентыкларда да уңышлы дәвам итте.

Әйе, һичбер шик булырга мөмкин түгел: бу әсәрләр басылып чыккан елларда да укучылар тарафыннан бик җылы кабул ителделәр, яратып укылдылар. Һәм ышанып әйтергә була—алар хәзер дә еш укыла, хәтердә кала, эзләнеп алына торган әсәрләр рәтендә.

Билгеле, сонгы елларда бездә үткән сугышка һәм анын каһарманнарына карата бүтәнчә фикер йөртүчеләр дә табыла башлады. *Ләкин*, әйдәгез, менә шушы урында ныклап, ашыкмыйча, җитди итеп уйланып алыйк—ә шулай да дөреслек кайсы якта сон?

Милләтнен көчле уллары, асыл уллары илгә авырлык килгән чакта сынала. Илне һәм ил мәнфәгатен саклаганда сынала! Әнә шундый чакларда инде ихлас күнелле, икейөзләнүне белми торган һәм үз иманнарына тугры кешеләр «туган җирем өчен, гаилэм өчен, үз иманым өчен» дип көрәшкә ташлана. Ә инде бүтән төрле яшәүчеләр—ин беренче чиратта шәхси иминлек, тамак туклыгы хакында төрле-төрле

хәйләгә, сату һәм сатылуга баручылар—алар инде мондый чакларда әллә нинди жайлар таба, әллә нинди хәйләләр куллана һәм кыенлыктан читтәрәк, арттарак калырга тырыша.

Безнен татар халкы тарих буйлап бик озын юл үтеп килә. Кыенлыклар һәм сынаулар тулы авыр юл ул. Әнә шул авыр юлны узу дәверендә—үткәндә, бүгенгедә һәм киләчәктә—әлеге ике төр кешеләрдән кайсылары кадерлерәк сон милләт өчен?

Әлбәттә, көчле, кыю рухлылар! Ил өчен, иман өчен, гаделлек өчен кыю рәвештә алга бара алучылар! Болар—мондыйлар—алар бит кеше жанынын, кеше рухынын да никадәр көчле һәм бөек була алуын раслый!

Безнен бәйсезлегебез өчен көрәш барган елларда да ин алгы сызыкта әнә шундый ихлас жанлы, шагыйрь йөрәкле, матур күнелле затлар булды бит! Халкыбыз, милләтебез ул вакытта да, хәзер дә аларга сокланып карый!

Әйе, тегесе дә дөрес: яшәү дәвам иткәндә хәйләкәрләр дә бетмәс. Милләтнен каһарман улларына карата алар чәчә торган төрле гайбәтләр дә тукталмас... Ләкин, һәр иртәнге балкып Кояш чыккан һәм дөньяга якты нурын сипкән шикелле, милләтнен батыр, каһарман улларынын садә, керсез, фидакарь адымнарына карата да халык мәхәббәте сүрелмәс! Ә куркак хәйләкәрләр сүзе исә, ярканат сыман, гел күләгәгә, гел карангыга таба качар... Халык, милләт күзеннән читкәрәк качар.

Менә шушы хакыйкатьне яшьтән үк яхшы анлаган Шамил Рәкыйпов татар халкынын батыр улларын барлауга бөтен ижатын, гомерен багышлады. Татарстан китап нәшриятында эшләгән чагында анын үз хисабына ял алып, ил буенча архивларда йөрүен, анда айлар, атналар буе утыруын бик күп язучылар белә. Шулай ук Язучылар берлегендә оешкан хәрби-патриотик комиссияне житәкләп тә Шамил абый бик күп яшь ижатчыларга ярдәм итте, әдәбиятыбызда шушы тармак көчәйсен өчен тырышты.

Ә инде сиксәненче елларда Шамил абый Рәкыйпов үткән сугышнын аеруча бер мәгънәгә ия булган эпизодын—Берлиндагы рейхстагка байрак кадау күренешен ачыклау өчен күп көч куйды. Һәм үзенен тынгысызлыгы, тырышлыгы, хәтта үжәтлеге аркасында, гаделлекнен «Правда» газетасы битләрендә урын алуына иреште! Анда милләттәшебез Гази Заһитовнын рейхстагка беренче булып байрак кадавы расланды, шул хакта язып чыгылды! Бу—безнен язучыбызнын да зур жинүе иде.

Шул ук вакытта моны хәрби-патриотик темага каршы сүз сөйләп йөрүчеләрнен борынына чиртү дип тә анларга кирәк. Чөнки татар халкынын асыл улларынын зур батырлыгы тагын бер мәртәбә бөтен дөнья каршысында расланды бит!

Әйе, безнен даһи Тукаебыз бер дә юкка гына:

Без тынычта аттан артык эшлибез,
Без сугышта юлбарыстан көчлебез!—

димәгән шул! Милләтнен көче, анын яшәү сәләте һәм ниндилеге чыннан да әнә шундый вакытларда күренә бит ул!

Татарстан китап нәшриятында эшләгән чагында Шамил абый озак еллар буе яшьләрнен «Идел» альманахынын редколлегия әгъзасы булып торды. Кайберәүләр ин беренче таләп итеп югарыдагы түрәләргә ошау принцибын куйган вакытта, Шамил абый әсәрләрнен әдәби сыйфатына, ижатчынын талант дәрәжәсенә игътибарын юнәлтә иде. Әнә шул чагында мин күп еллар элек үземә дәртләндергеч хат язган бу кешенен чыннан да кешелекле, зур шәхес булуына тагын бер мәртәбә ышандым.

Ижат йортларында да еш кына күрергә туры килде Шамил абыйны. Мәскәү янындагы ижат йортында якташыбыз татар генералы Гордов турындагы әсәрен язды ул. Кайбер өлешләрен мина да укып күрсәтте. Анын бу әсәрендә дә кешенен ничек итеп көчле һәм рухи нык була алуы раслана иде. Тормыш вакыйгаларын жинә алу сәләте ачыла иде.

Әйе, батырлык темасы—тормышта да, әдәбиятта да беркайчан да искерәчәк түгел. Хатын-кызларыбызнын матурлыгына һәм ирләребезнен батырлыгына халкыбыз һәрчак дан жырлаячак!

Менә шушы юлдан ышанычлы атлаучы Шамил абыйга сәламәтлек һәм яна уңышлар телибез!

**Мансур ВӘЛИ.**

## *Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан*

### БЕРДӘМ БЛОК ТӨЗЕЛДЕ

Россиядә яна сәяси көч барлыкка килде. Август башында Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев житәкчелегендәге «Бөтен Россия» һәм Мәскәү мэры Ю. Лушков оештырган «Ватан» хәрәкәтләре үзара берләште. Төзелгән яна блок, тиздән булачак сайлауларда жинеп чыгып, булачак парламентның түбәнге палатасында чагыштырмача зуррак урынны яулап алырга, ә аннан соң, Думадагы күпчелек нигезендә, Россия хөкүмәтен төзәргә ниятли. «Без 226 урынга исәп тотабыз, максатыбыз—Россияне демократик үсештә яна баскычка алып чыгу»,—дип белдерде М. Шәймиев 4 августта үткән матбугат конференциясендә.

### Ф. МӨХӘММӘТШИН—ЖУРНАЛИСТЛАР ЯНЫНДА

13 августта Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин халыкара «Идел» лагеренда республикабызда чыгучы газета-журналларның баш мөхәррирләре белән очрашты. ТР Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы оештырган әлеге семинарда сүз Россиядә һәм Татарстанда килеп туган ижтимагый-сәяси хәл һәм социаль-икътисадый реформаларның киләчәктәге язмышы, журналистларның сайлау алды компаниясендәге роле турында барды.

### Г. ИСХАКЫЙ МУЗЕЕ АЧЫЛДЫ

30 июль көнне Чистай районының Яушырмә авылында олуг әдип һәм күренекле жәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакыйга багышланган тарихи-мемориаль һәм этнографик музей комплексы ачылды. Комплекс бөек милләттәшебезнең гыйбрәтле тормыш юлы һәм киң кырлы ижаты, шул чактагы көнкүреш әйберләре белән таныштыра, Яушырмә авылында яшәүчеләрнең үзенчәлекле гореф-гадәтләре турында сөйли.

Комплексны ачу тантанасында Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев, ТР Премьер-министры урынбасары И. Хәйруллин, Төркиянең Казандагы генераль консулы Ә. Реза Демирер, Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитеты рәисе И. Таһиров, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин, Мәдәният һәм Мәгариф министрлары М. Таишев, Ф. Харисов, Чистай шәһәре һәм районы хакимияте башлыгы А. Хәйруллин, депутат язучылар Р. Вәлиев, Р. Миннуллин, күренекле галимнәребез Ә. Кәримуллин, Х. Миннегулов, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры М. Хәкимжанов һ. б. мөхтәрәм зыялыларыбыз, киң жәмәгатьчелек вәкилләре катнашты.

### КАЗАНДА—ДӨНЬЯ ЧЕМПИОНАТЫ

29 июль—7 август көннәрендә Казанның Зур концерт залында хатын-кызлар арасында шахмат буенча дөнья чемпионаты исемен алу өчен киеренке көрәш барды. Якташыбыз Алисә Галлямова белән Кытай кызы Се Цзюнь арасында барган уен, 8 партиядән соң, 4:4 исәбе белән тәгәлләнде. Калган 8 партияне көндәшләр Кытайда, Се Цзюньның туган жирендә—Шэньян шәһәрендә уйнадылар. Ул 8,5:6,5 исәбе белән Се Цзюнь файдасына тәгәлләнде.

### ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНДӘ

XIII корылтайдан соң, 2 августта, яңа сайланган Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең беренче утырышы булды. Иң элек, ижат берлеге рәисе Фоат Галимуллин тәкъдиме белән, язучылар оешмасының киләчәктәге эшчәнлеген заман таләпләре югарылыгында тагын да яхшырту буенча идарә әгъзалары үзара фикер алыштылар. Утырышта ижат берлегенең Өлкән әдипләр шурасы, Кабул итү коллегиясе әгъзалары сайланды.

Аннары идарә әгъзалары «Казан утлары» журналының баш мөхәррире итеп Равил Фәйзуллинны, «Идел» журналының баш мөхәррире итеп Рашат Низамиевны, «Салават күпере» журналының баш мөхәррире итеп Зиннур Хөсниярны бертавыштан янадан расладылар.

Идарә утырышында Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары итеп монарчы «Казан утлары» журналында бүлек мөхәррире булып эшләгән Шаһинур Мостафин бертавыштан сайланды.

* * *

Утырышта шулай ук М. Җәлил һәм аның көрәштәшләрен искә алу көнен уздыру, мөхтәрәм әдипләребездән Нәкый Исәнбәтнен—100 еллык, Яков Емельяновның 150 еллык юбилейларын зурлап билгеләп үтү турында да эшлекле сөйләшү булды.

### «КАЗАН УТЛАРЫ»НДА ОЧРАШУ

3 августта Татарстан язучылары оешмасы җитәкчесе Ф. Галимуллин «Казан утлары» журналы редакциясендә булып, анда эшләүчеләр белән очрашты. Ул редакциянең эш планнары белән җентекләп танышты һәм «Казан утлары» журналы белән киләчәктә дә үзара ярдәмләшеп, нык бәйләнештә торачагын әйтте.

### ХӘРӘКӘТТӘ—БӘРӘКӘТ

Татар халкының Милли Мәҗлесе рәисе—язучы Айдар Хәлим Ульян шәһәрендә булып, өлкәдәге татарларның яшәеше, татар милли тәрәккыятенең торышы белән танышты, үзәк мәйданда Сембер шәһәренең нигезләнүенә багышланган күмәк намазда катнашты. Кичен «Дуслык Сарае»нда татар җәмәгатьчелеге белән очрашты, күп сорауларга җаваплар бирде, шигырьләрен укыды.

А. Хәлим шулай ук Мәскәүдә үткән «Рәсәйне рухи яңартуда мөселманнарның роле» дип аталган халыкара ислам конференциясендә катнашты, күптән түгел генә ачылган беренче татар мәктәбендә булды, китаплар бүләк итте.

### УНИВЕРСИТЕТТА КУНАКТА

Казан дәүләт университетының Көнчыгыш телләр факультетында «Казан утлары» журналының шигърият бүлеге мөхәррире Р. Гаташ белән очрашу булды. Кичәдә катнашучы язучы-академиклардан Тәлгат Галиуллин белән Хатип Миңнегулов тыңлаучыларны кунак шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗатының төп үзенчәлекләре белән таныштырдылар. Аннары сүз шагыйрьнең үзенә бирелде. Ул талибләргә һәм мөгаллимнәргә соңгы вакытта дөнья күргән яңа китапларыннан шигырьләр укыды, аларның язылу тарихларын сөйләде.

### БЕРЬЮЛЫ ИКЕ БҮЛӘК

Чиләбе шәһәрендә яшәүче күренекле музыкант—тальянчы, күп кенә иҗади конкурслар лауреаты Вазыйх Шәрәфетдинов (тумышы белән—Буа районының Яңа Чәчкап авылыннан), июнь-август айларында Татарстанда булып, Казанда, Буа, Апас, Кукмара һәм Мамадыш районнарында халык белән очрашты, чыгышлар ясады. Күпьеллык нәтиҗәле эшчәнлеге өчен, Вазыйх абый мәшһүр композитор Фасил Әхмәтов исемендәге медаль һәм Идел буе—Урал республикалары композиторлары берләшмәсенең Мактау Дипломы белән бүләкләнде. Ошбу зур бүләкләрне аңа әлеге берләшмәнең рәисе—Казан дәүләт консерваториясенең татар музыка сәнгате факультеты деканы, танылган композитор Мирсәет Яруллин һәм Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеев тапшырды. Шул уңайдан «Курай» радиосы В. Шәрәфетдинов иҗатына багышланган махсус 2 тапшыру да оештырды.

### ГАЛИМНӘР ТАБЫШЫ

Татарстан милли китапханәсе һәм Казан дәүләт университеты галимнәренең Оренбург өлкәсенә оештырган фәнниархеологик экспедициясе уңышлы тәмамланды. Әлеге өлкәнең Сакмар, Саракташ, Куандык, Гай, Беляев, Шарлык, Александр районнарындагы 27 татар авылыннан фәнни әһәмияткә ия булган кулъязма истәлекләр, иске басма китаплар һәм журналлар табылды. Табышлар арасында Ә. Каргалый, Һ. Салихов, Г. Кандалый, Акмулла, М. Җәлил кебек татар әдәбиятында тирән эз калдырган күренекле каләм әһелләренең безгә билгеле һәм билгеле булмаган әсәрләренең күчермәләре, аларның тормышларына кагылышлы башка фактик язма чыганаклар, җирле фольклор әсәрләре һ. б. бар.

### *Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** «Йосыф вә Зөләйха» китабыннан бер сурәт. 1813 ел. Һиндстан. Бизәүче - каллиграф Муллаим Кәшмири.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** күренекле язучы Шамил Рәкыйпов.

# ЯҢА КИТАПЛАР

**И туган тел...** Төзүчесе—Ф. С. Сафиуллина. Казан: «Хәтер» нәшрияты.— 1999, 96 б. Тиражы—2000 данә.




Бу җыентыкка шагыйрьләребезнең туган телебезгә багышлап язылган йөздән артык шигырьләре тупланган. Авторлар арасында Мөхәммәдъяр, Тукай, Дәрдемәнд, М. Гафури, Һ. Такташ, Х. Туфан, С. Хәким кебек үткән заман классиклары да, бүгенге шигъриятнең күренекле вәкилләре Н. Нәҗми, Г. Афзал, И. Юзиев, Ш. Галиев, Ф. Яруллин, Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Роберт Әхмәтҗанов, Рәшит Әхмәтҗанов, М. Әгъләмов, Зөлфәт, Р. Мингалимов, Г. Рәхим һәм башкалар да бар.

Бу китапның кереш сүзендә проф. Флера Сафиуллина болай дип яза: «40 елга якын татар теле дәрьясында булуым даими рәвештә төрле китаплар, газета-журналлар белән танышып баруны таләп итте. Мәктәптә студентлар белән практика үтү, элеккеге елларда студентларның актив иҗтимагый-мәдәни тормыш эчендә кайнавы, күп санлы тематик кичәләр, КВНнар, олимпиадалар, диалектологик экспедицияләргә, колхозга бәрәңге алырга барганда куелган концертлар, тулай торактагы матур-матур әдәби очрашулар үткәрү, мәктәпләр, югары уку йортлары өчен күп санлы дәреслекләр язу, күнегүләр һәм дидактик материаллар җыентыклары төзү, татар теле курслары буенча лекцияләргә әзерләнү дәвамында телебез турында күп санлы шигырьләр тупланды».

Китап, татар теле укытучыларына гына түгел, киң катлау укучылар өчен дә кызыклы булачак. Китапка кергән шигырьләрне дәресләрдә, әдәби кичәләрдә, олимпиадаларда файдаланырга мөмкин.

Индекс 73210



Шамил Рәкыйпов

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARЬ
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)